# казан утлары

6

ИЮНЬ-1976


# КОТЛЫЙБЫЗ!



ДИАС ВӘЛИЕВ



МАРС ШАБАЕВ



РАВИЛ ТУМАШЕВ

*КПСС өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы, республиканың Габдулла Тукай исемендәге премияләр комитеты тәкъдимнәрен караганнан соң, 1976 ел өчен республиканың Габдулла Тукай исемендәге премияләрен түбәндәге иптәшләргә бирү турында карар чыгардылар:*

*Драматург Диас Нәзих улы Вәлиевкә — «Дәвам» («Сиңа тормыш бүләк итәм») пьесасы өчен; шагыйрь Марс Садри улы Шабаевк*а — «Җикән камыш», «Онытма», «Сине эзлим» дигән шигырь китаплары өчен; режиссер Равил Рәхим улы Тумашевка — Татар дәүләт күчмә театрындагы «Сандугачлар килде безгә», «Үзебез сайлаган язмыш», «Сары чәчәк ата көнбагыш» спектакльләре өчен.*

* * *

*ВЦСПС Президиумы һәм СССР Язучылар союзы идарәсе секретариаты художестволы проза әсәрләрендә бүгенге совет эшчеләр сыйныфын чагылдыру буенча 1974—1976 еллардагы иң яхшы әсәрләр өчен Бөтенсоюз конкурсына йомгак ясадылар. Шушы конкурста «Каты токым» романы өчен Шамил Мотыйгулла улы Бикчуринга икенче*



ШАМИЛ БИКЧУРИН

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ һӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**6**

ИЮНЬ
1976

## Бу санда

Р. МИНГАЛИМОВ. Юл өстендә тургай. Поэма . 3
А. ВЕРГАЗОВ. Дулкыннар ни сөйли! Повесть . . 11
Н. АРСЛАНОВ. Сәфәр чыксам. Шигырьләр . . 54
Д. ВӘЛИЕВ. Сиңа тормыш бүләк итәм. Пьеса . . 62
Б. СӨЛӘЙМАНОВ. Юлда. Шигырьләр . . . . . 109
Ф. ЧАНЫШЕВА. Очрашулар-аерылулар. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . 111
Р. БИКБАЕВ. Уфа — Казан. Шигырьләр . . . . . 115

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

АКЪЕГЕТ. Кил син, яме... Шигырьләр . . . . . 118

ОЧЕРКЛАР

Беренче маршрут: Чаллы — Мәскәү! . . . . . . 121
КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . . . 126
Җ. КӘЛИМУЛЛИН. Яшьлеккә тартыла күңел . . 129

ТАТАР ТЕАТРЫНЫҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

Х. ГОБӘЙДУЛЛИН, И. ИНГВАР. Мәгънәви театрыбыз остазы . . . . . . . . . . . . . . 139

СӘНГАТЬ

И. АЛЕКСЕЕВ. Казанда кино ничек башланган. . 144

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Ә. ХАЛИД. Әбү Хәмид әл-Гарнатыйның Болгарга сәяхәте . . . . . . . . . . . . . . 148

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Көн тәртибендә — дәреслекләр . . . . . . . . 158
М. МӘҺДИЕВ. Мәктәпләрдә әдәбият укытуның кайбер мәсьәләләре . . . . . . . . . . . 158

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА һӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

**Ф. ГАНИЕВА.** Әдәбият — тәрбия чарасы да . . . 163
**Ш. САДРЕТДИНОВ.** Дус һәм сердәш итеп . . . 167
**Х. МИҢНЕГУЛОВ.** Дәреслек һәм программа . . 170
**Ш. АСЫЛГӘРӘЕВ.** Дәреслек һәм тормыш . . . 174
**Р. МОСТАФИН.** Дәреслек нинди булырга тиеш! 177
**Г. ӘДҺӘМОВА.** Әдәбият дәресләре һәм интернациональ тәрбия . . . . . . . . . . . . 180

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**Т. МИҢНУЛЛИН.** Ничә яшь! Этюд . . . . . . . 185

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәукәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 1/III-1976 ел. Басарга кул куелды 10/V-1976 ел. ПФ 09025. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 91944 экз. Заказ К-92. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1976 ел.

## Рөстәм Мингалимов

# Юл өстендә тургай

ПОЭМА

I

Нидер кала дөнья тизлегеннән
Яфрак кебек, кырга ягылып,
Канатсыз кош булып утырып кала,
Ятып кала башсыз яу булып...
Кала соңгы тапкыр үрә баскан,
Ак күбеккә баткан ат булып.

Дусың булып кала кулын болгап,
Кала — арттан аткан ят булып.

... Ниләр кала шулай, кемнәр кала?
Көйләр кала микән, илләрме?
Мөмкин түгел җиңел генә бару
Дөнья тизлегенә ияреп.

Бүген алган тизлек бүген ярый,
Яңа тизлек кирәк иртәгә.
Гел үзгәреп очкан дөнья белән,
Әй, китәргә ерак китәргә!

Бүләгем бар ерак ул көннәргә,
Илтә барам Тукай якларын,
Хәтфә түшле яшел тауларымның
Язмышлары бездә чакларын.

Борынгыдан килгән кырлар монда,
Шәһәрләре — исән килмәгән. —
Күпне белгән безнең борынгылар
Нәрсәнедер, димәк, белмәгән...
Читекләре килгән Идел белән,
Кешеләре — тузып килгәннәр.
Җайдагы юк атлар йөзеп килгән,
Агып килгән атсыз иярләр.
Күпне белгән безнең борынгылар
Нәрсәнедер, димәк, белмәгән.
Борынгыдан килгән кырларында
Шәплекләре исән килмәгән.

...Җир астында килгән җиз комганнар,
Алкаларның — алтын, затлысы.
Хәрабәләр арасына посып —
Поэмасы килгән, эпосы.
Күпне белгән безнең борынгылар,
Нәрсәнедер, барыбер, белмәгән.
Борынгыдан килгән кырларында
Шөһрәтләре исән килмәгән.
Алар янган борынгы йорт белән,
Тукай эзе — бетеп янмаган...
Борынгыдан килгән кырларында
Без яшәргә булдык яңадан!
Юкса, безгә Рәсәй патшалары
Урын булгән музей түреннән.
Унҗиденче елда китеп бардык
Музеенең ишеге төбеннән!

Юк, музейга безгә иртә булыр!
Без яшәргә булдык яңадан...

Гел үзгәреп алга оча дөнья,
Без калмаска булдык аңардан.

Гел үзгәреп алга оча дөнья,
Илтә барам Тукай якларын:
Аэропортлар, юллар,
Байракларның
Язмышлары бездә чакларын.
Иксез-чиксез әрәмәләр илтәм,
Эче тулы шомырт, бал исе:
Шомырт чәчәкләре ап-ак дәрья,
Ак дәрьяда хыял көймәсе.
Йөзә һаман, йөзә сары көймә,
Малай-шалай карый кызыгып.
Аннан йөгерә алар — егетлеккә,
Акбай чаба арттан сузылып.

Кызлар җитә монда, җыйнаклана
Күз алдында бераз суырылып.
Монда җылы сөю җиле исә,
Көннәр исә рәхәт җил булып.
Үсә монда каен һәм бозаулар,
Үсә фикер, үлән һәм тайлар...
Башын чайкап бөгелеп, биеп кенә
Үсә кырда безнең бодайлар.
Тимер ауның кара авызына
Без бирмәскә тиеш аларны.
Усаллык та алдым үзем белән
Җиңәр өчен усал җаннарны.
Күңеле гаҗәп яхшы кешеләр дә
Көтмәгәндә каза күргәннәр.
Серләрем бар әле, киңәшем бар
Кабынасы яңа көннәргә...

Ни икәнен беләм юлларның да,
Озын юлда буш кул кем йөрсен?!

... Уенчыклар алдым оныкларга,
Уенчыклар алдым — төрлесен:
Сыбызгылар... битлек... курчак алдым...
Бәлки күп тә китә алмамын.
Янәшәмдә яхшы дусларым бар,
Юлда калмас ләкин алганым.

II

Юл өстендә, кыр өстендә
Сайрый тургай биектә.
Ничек болай сайрый тургай,
Борчак кына кебек лә?!

Сайрый тургай, өзә тургай,
Каян алган шундый көй?
Эче тулы — шатлык кына,
Шатлык кына микәнни?!

Җирдә тургай бәхет кенә,
Бәхет кенә күргәнме?
Бәхетле кыяфәтенә
Әллә юри кергәнме?!

Әллә болай кирәкмиме?
Әллә шулай кирәкме?
Чакыра бит, яшәтә бит,
Яшәртә бит йөрәкне!!!

Күе белән коендыра,
Керендерә, юа бит...
Яңарта бит өметләрне!
Борчуларны җуя бит!

Кыр өстендә, чор өстендә —
Кыл өстендә бугай ла?!
Җыр ягына көн тартыла,
Гөл тартыла — тургайга.

Көй артыннан тал сузыла,
Үлән күккә үрелә.
Таш, үрелеп көйгә таба,
Йортларга әверелә...

Кынысында кылычы бар
Ир тартыла тургайга.

Уйламагыз тартылмый дип,
Җир тартыла тургайга.

Әллә тургай оча торгач,
Сихри куәт булганмы?
Чор өстендә, кыл өстендә
Хикмәте бар тургайның.

Әллә тургай түгелме ул?
Ул очар шигырь микән?
Ник булмасын тургай-шигырь,
Канаты булган икән?!

Кыл өстендә, чор өстендә
Үз урыны тургайның,
Бу чорны канатсыз кичеп
Булмыйдыр ул, мөгаен.

Чор юлында —
Татарстан,
Чор юлында —
Чал Идел...
Канат булса безнең хезмәт,
Безнең сәнгать, безнең тел,
Канатлыдыр Татарстан
Һәм канатлыдыр Идел.

III

Бу дөньяда үз ягымның
Чын кыйммәтен беләм мин.
Шагыйрәнә сөйләп аны
Арттырырга теләмим.
Шаярмыйм мин чынлык белән,
Ялган белән уйнамыйм.
Татарстан, Идел диеп,
Мактанырга уйламыйм.
Идел икән, Идел инде! —
Җанга якын, туган бит.
Бабайларның канлы йөзен
Юган чагы булган бит.
Идел икән, Идел инде! —
Яратыйк та, кадерлик.
Әмма моннан зур суларның
Җирдә барын кем белми?!
Тормышка Татарстанмы
Иң кирәкле, иң матур?
Кай шәһәрдән Казан артык,
Кешеләре кемнән зур?
Зур булсалар, андый зурлар —
Бездә генәме алар?
Әйе, бездә Сәйдәшләр бар!
Бездә Мулланурлар бар!
Аксакаллар булган икән,
Алмаш булырга тиеш!
Без ничек язмыйк ди икән,
Кол Гали булган килеш.

«Безнең халыкның үткәне,
Зур юлы булган», имеш.

Халкы булгач, аның инде
Юлы булырга тиеш!

... Истәлек океан булыр,
Истәлек булыр инеш...

Истәлекләр булыр алар,
Күргән дә бар аларны.
Хөрмәтлик истәлекләрне,
Хөрмәтлик бабайларны.
Һәм узганга салават та
Шуны да уйлау кирәк:
Чыгышы бөркет икәннең
Очышы ничегерәк?
Ачышларда-очышларда
Бүген хәбәр өр-яңа!
Суны кысып металл итә
Сәхнәсендә замана.
Тезләнеп сәҗдә кылсаң да
Изге Болгар ягына,
Ир дигәннең — бүгене ир,
Узганы — малай гына.

IV

Без очышта, без очышта,
Мин моны тоеп барам.
Без очышта, гел очышта.
Гел шуңа сөенеп барам.
Җәлилгә булган алкышның
Җилләрен сизеп барам...

«Китмибез»не «Төшмибез» дип
Әйтәсеңмени аны?!

Шаяртып, әнә «Шүрәле» —
Кытыклады дөньяны...

Сабалардан, Арчалардан
Чәчрәп чыккан егетләр —
Кирәк җиргә барып явар
Җылы яңгыр кебекләр.
Кара күзле кызларыбыз
Ак шәһәрләр өстендә! —
«Кама»ларны, «КамАЗ»ларны
Тартып-тартып үстерә.
Әлмәтләрдә, Төмәннәрдә,
Томаннарда торбалар —
Татарстан куәтенең
Киңәйгәнен тоялар.

Без очышта, без очышта,
Әй, Җәлил егетләре!
Тизлекне үзгәртәбезме?
Көч-куәт бармы әле?
Ярсудыр сезнең күңел дә,
Минем дә ярсу күңел.

Елмаеп сорау бирсәм дә,
Шаярып сорау түгел.
Шаярыр заман түгел бу,
Очмасаң, туктау кирәк —
Инде күккә күтәрелмәс
Самолетлар төслерәк.
Озак уйлар заман түгел,
Очсаң — очарга кирәк —
Шәүләсе дә җирдән купкан
Ракеталар төслерәк.
Күзендә күкнең очарга,
Дөньядан гыйбарәт алып.
Очарга янып-янып,
Очарга — исән калып!
Хәерле юл тели Ватан,
Алда нинди зәңгәрлек!
Халкыңны, оча алмаса,
«Ник туган» дип жәлләрлек.

Тизлекне үзгәртәбезме,
Татарстан, бер генәм?
Улың булып, хуҗаң булып
Киңәшәм синең белән...
Аңлар мине синең киңлек,
Анда бар да минеке:
Төлкеләр дә, куяннар да,
Боланнар да минеке.
Суда балык чиртүе дә,
Камышы да минеке.
Торналарың, бүреләрең
Тавышы да минеке.
Яккан учак, пешкән шулпа,
Аксыл пары — минеке.
... Малайлары, әнкәләре
Һәм кызлары минеке.
Шаулы Казан минеке ул,
Юкәләр дә минеке.
Синеке түгел дисәләр?
Дисәләр дә минеке!
Урам саен мәрмәр такта,
Алары да минеке.
Кичләре дә, төннәре дә,
Таңнары да минеке.
Зур тәрәзләр, киң мәйданнар
Һәм гөлләр дә минеке...
Гөл куяр кешесе беткән
Каберләр дә минеке!
Мин аларга шигыръ куям!
Куярлык шигырь микән?
Безнең шәплек, яшәү тавышы
Шуннан ишетелер микән?
Мин аларга шигырь куям,
Җыр куегыз, җырчылар!
Кайсыгызның сан бирерлек,
Сан алырлык тавышы бар?
Кайсыгызның дөнья тавышы
Саналырлык тавышы бар?

V

Син башласаң, без дә кушыласы —
Әйдә килешеп алыйк булмаса?!
Чыдарбызмы, әгәр синең җырың
Ил өстенә җәелеп еласа?!
Чыдарбызмы? Никтер безнең халык
Әллә нинди җырлар чыгарган:
Зур җир шары төшеп тирбәлерлек,
Кайгы диңгезедәй җырлар бар.
Чыдарбызмы? Болай чыдам да без,
Ә барыбер күпме моң ага?!
Син җырлама инде авыр көйләр,
Мин теләмим хәзер еларга.
Син җырлама инде авыр көйләр,
Күңелләрне алар йомшата.
Алда әле йомшак күңел белән
Узып булмый торган юл ята.
Күңеле йомшап киткәннәр дә бардыр,
Алга бара ләкин барысы да.
Күренәләр генә тыныч сыман,
Бөтен кеше җирдә ярсыган.
Алышалар күпләр, бүлешәләр,
Көчләрәге тарта күбрәген —
Бармакларын гына карасаң да,
Тишкәләнә — йомшак йөрәгең.

Юлда әле бәхет эзләүчеләр,
Бәхетеннән шашкан кешеләр бар.
... Чишеләсе бәхәсләр бар юлда,
Үтерешкә җиткән эшләр бар...

Без барабыз тыныч тормыш даулап,
Дошман бара җыелып-серләшеп.
Йөкле ана уза киләчәккә,
Һәм танклар уза гөрләшеп...

Юк, җырлама моңлы озын көйләр,
Күңелләрне артык йомшата.
Алда әле йомшак күңел белән
Узып булмый торган юл ята.
Син үрләрне җырла, күперләрне:
Юллар кинәт аска киткәнне.
Борылышларны җырла, бәрелешләрне,
Тормыш һаман җиңеп үткәнне.
Үзебезне җырла, гыйшкыбызны,
Чоры өчен — без дә Таһирлар.
Эш күбрәктер бугай, вакыты шулай.
Ләкин азмы бездә ярсу бар?!
Мәңге яңа дигән шәп җырлар да
Искерәдер бераз, мөгаен —
Җырладык ла инде андыйларны
Юл читендә оеп, моңаеп...

Әмма бүген безгә инде күбрәк
Лазер җыры кирәк, ут җыры!
Кыенлыклар моны сорый бездән,
Тизлек моны сорый, юл сорый.
Исән илтик юлда Кеше йортын,
Шатлык белән тулы йорт ясап.
Тукай ягын илтик, шәһәрләрен
Һәм шөһрәтен илтик исән-сау.
Ерак китик әле дөнья белән,
Чын бәйрәмнәр булыр шуннан соң.
Ул чакларда гөнаһ булмас йомшау,
Һәм җырларсың безгә... җырларсың...

## VI

Нидер кала дөнья тизлегеннән
Кабат килер сыман яз булып.
Төркем-төркем кошлар сыман кала,
Канатлары кала язылып.
Кала тыныч кына, кайчан да бер
Адресатка җитәр хат сыман.
Калмас өчен кузгалырга кала,
Кешнәп үрә баскан ат сыман.

Гел үзгәреп дөнья алга оча,
Ярып керә кызыл таңнарга...
Оча дөнья алга гел үзгәреп,
Без калмаска булдык аңардан.

1975

Азат Вергазов

# ДУЛКЫННАР НИ СӨЙЛИ?

ПОВЕСТЬ



Фәрдәнә Илүзәнең күкрәгенә башын куйды да, аның кояшта янып алсу төскә кергән тәнен чем-кара чәч толымыннан шыбырдап тамган су тамчылары белән чылата-чылата, сулыгып елап җибәрде:

— Идел суында коенгач җиңел булмасмы дигән идем. Шуңа сезне бирегә дәштем ич мин... Көчләп диярлек китердем сезне... Юкка икән... Күкрәгемдә актарылган утны су салкыны гына баса аламыни, кызлар!..

— Я, тынычлан инде, үзеңне кулга ал... Бар да узар...

— Их, сез, узар, дисез... Сез аңламадыгыз мине... Мин үзем дә дөмсукыр булганмын.. Менә күзем ачылды хәзер... ачылды. — Тунуданмы, нерв киеренкелегеннәнме, үзе дер-дер калтырый, эчке үксүдән калку күкрәге талпынып-талпынып куя иде.— Мин сез түгел икән,— дип дәвам итте ул, Идел дулкыннарына бераз карап торгач, — ә сез мине үзегез белән бер аршинга салмакчы идегез... Мин карыштым, тартыштым... Ләкин үземне эзләмәдем... Агым иркенә бирелдем мин... Ә хәзер... Хәзер мин сездән китәм...

Фәрдәнә, һаман шулай Иделгә караган килеш, Илүзәдән аерылып авыр гына кузгалды. Юеш тәненә ябышкан эре ком бөртекләрен кулы белән ара-тирә сыпыргалап, үргә таба атлады.

— Фәрдәнә?

— Кирәкми...

Әйе, Фәрдәнә китә иде. Кем булды соң ул Илүзә өчен: дусмы? Дус дисәң — ничаклы кичерешләр, бәлалар китерде бит ул Илүзәгә... Хәер, Илүзәгә генәме? Әллә дошманымы ул аның? Алай булгач, Фәрдәнәнең үзләреннән китүенә «котылдык» дип ник куанмый Илүзә? Ул гына да түгел, борчыла, йөрәге сыкрый...

— Кайтыйк ла...

Бу — Зәкия. Һәрнәрсәгә артык исе китмичә карый торган Зәкия. Бу дөньяның тискәре якларына исе китмәскә өйрәнгән ул.

Ә Илүзә алай түгел.

— Сез кайта торыгыз... Мин бераз утырам әле... Утырам әле мин...

Илүзә зәңгәр күзләрен әле ярга шапылдатып килеп бәрелгән, әле сары ком өстендә яшькелт юшкын калдырып кире чигентән дулкыннарга төбәде.

Дулкыннар үз эшләре белән мәшгуль: чайкалалар да чайкалалар. Аларның һичнидә гаме юк кебек. Ләкин шулай микән соң?..

Әнә кайдадыр Идел уртасында вак дулкыннар бергә кушылып, зур дулкын хасил булды да ярдагы комлыкка килеп бәрелде. Илүзәнең аяк очына тикле җитеп, авыр көрсенә-көрсенә, нидер пышылдады.

Аңлый Илүзә, аңлый. Күптән түгел булып үткән хәлләрне искә төшерә дулкыннар. Тәртибе белән. Дулкын артыннан дулкын булып...

## БЕРЕНЧЕ ДУЛКЫН

— Я, комсорг итеп кемне тәкъдим итәсез?

Кечерәк буйлы, көләч йөзле группа мастеры Наилә Хәбировна җавап көтеп кызларга төбәлде.

Бүлмәдә беравык киеренке тынлык урнашты. Кызлар, башларын ия төшеп, бер-берсенә караштылар. Нәрсәдер пышылдашып алдылар. Менә иң артта тәрәзә буенда утыручы кыз мастерның мөлаем йөзенә карап торды да дулкын-дулкын кабарган чәчләрен бер кулы белән янга сыпырып торып басты:

— Мин Фәрдәнәне тәкъдим итәм...

Фәрдәнә дигәне шул кыңгырау чәчәге сыман зәңгәр күзле Илүзәнең итәгеннән тартты бугай, анысы иелеп ниндидер хәрәкәт ясады (шул итәген ычкындырды, күрәсең) һәм берни булмагандай өстәп куйды:

— Фәрдәнә Гыйләҗеваны...

Урта рәттә утыручы Зәкия малайларныкыдай калын тавышы белән:

— Торып бассын! — диде.

Фәрдәнә торып басты. Сыгылмалы тал чыбыктай зифа буйлы, чем-кара күзле бу кызның кара чәчләре ике як чигәсе янында алка-алка булып бөдрәләнеп тора. «Торып бассын!» диюләре кызларның бер чаялыгы гына. Алар Фәрдәнә белән яхшы ук таныш иделәр инде. Шул кызый нәрсәсе беләндер бар группа кызын үзенә каратып өлгергән иде. Урамда булсын, тәнәфес вакытында коридорда булсын — кызлар гел аның тирәсендә.

Әле училищега укырга килгәннең беренче көнендә үк иң күзгә чалынган шул Фәрдәнә булды. Аңа игътибар итми мөмкин түгел: шомырттай күзләре ут чәчә, теле-тәлгә йокмый.

Тиздән кызлар Фәрдәнәнең Казандагы абыйсы артист булуын, үзенең дә җырга оста икәнен белеп алдылар.

Ә бер атнадан Фәрдәнәләр группасын шәһәрдән ерак түгел сөзәк тау итәгендә җәйрәп яткан Мичурин исемендәге совхозга бәрәңге алырга җибәргәннәр иде. Группа икегә бүленеп, аның берсе мастер Наилә Хәбировна җитәкчелегендә Күлбәш бригадасында калды, Фәрдәнәләр төркеме Ташлыяр авылында урнашты.

Авыл шактый зур. Авылдан өскә күтәрелеп киткән сөзәк тау итәген ерактан йөз яшәр картларның кул тамырлары сыман булып күренгән ерымнар телгәләгән. Шул ерым төпләрендә, әкияттәге дию сыннары сыман, зур-зур ташлар тырпаеп тора. Эреле-ваклы ташлар белән тулы ерганаклары өчен булса кирәк, бу авылны Ташлыяр дип атаганнар.

Үзләрен йортларга урнаштырып чыкканны көтеп, кызлар идарә каршында кагаеп шактый тордылар. Урамнан үтүче егетләр яңа килгән кызларга я мутланып, я болай гына кызыксынып күз атты. Йөк машинасында баскан көе чайкалып килә-килә, кызлар ярыйсы ук арганнар

иде, күрәсең, үзләрен күзәтүчеләрдән тартынып-нитеп тормадылар, кайсы өеп куйган бүрәнә өстенә елышты, кайсы коры бәрәңге сабагына ауды.

Фәрдәнәнең тенә арыганы сизелми. Ул әле мәзәкләр сөйли, әле бөтен урамны яңгыратып көлә, әле җырлап җибәрә иде:

Ташлыярның егетләре
Нигә туганнар икән?
Елмая да белмиләр ич,
Бабай булганнар икән.

Чая кыз Фәрдәнә. Шул үткенлеге өчен дә Ташлыярда эшләргә калган кызларга җитәкче итеп билгеләде аны Наилә Хәбировна.

Нигә яшереп торырга, Фәрдәнә Илүзәгә беренче күрүдә үк ошаган иде. Үзе йомык табигатьле булмаса да, Фәрдәнә кебек чаялыгы, үткенлеге юк иде аның. Һәр вакыт шулай бит ул: кешедәге сыйфатларның синең үзеңдә югы җәлеп итә. Хәтта шул кешегә охшарга тырыша башлыйсың. Илүзәнең дә Фәрдәнә төсле кыю, үткен телле буласы, чатнапчәчрәп йөрисе килде. Илүзә кешегә тиз иякләшүчән, Фәрдәнә белән дә ул тиз дуслашып китте. Алар авылдагы бер әби яшәгән йортка да икәү бергә урнаштылар.

Әби бик кунакчыл, ягымлы булып чыкты. Урнашкан көнне үк кызларны әле генә баздан алып чыккан салкын сөзмә белән сыйлады.

— Ашагыз, бәбкәчләрем, ашагыз! — дип, үзе бертуктаусыз сөйләнде ул, — бер дә тартынып тормагыз, аллага шөкер, үз сыебыз.

Илүзәләрнең тегүчелеккә укыячагын белгәч:

— И, әйбәт һөнәргә өйрәнәсез икән,— дип мактады.

Ә аннары әби, бөтенләй юмартланып, чормага менеп китте һәм аннан сап-сары чикләвекләр алып төште.

— И әби, кирәкмәс ие,— дигән булды Фәрдәнә. Ә үзе Илүзәгә күз кысып куйды: син аптырама, мин болай гына, күңел өчен генә әйтәм, янәсе.

— Улым белән киленем кайтуына дип иң әйбәтләрен генә җыеп куйган идем, бәхетегез бар икән, бәбкәчләрем, — дип сөйләнде сөйкемле әби.

Бала чагы авылда үткәнгә, Илүзә мондый күркәм әбиләрнең холкын белә. Аның үз әбисе дә шушы Фәхирә әби төсле лә.

Бу киң күңелле карчыклар кеше килгәнгә дә, узгынчылар кереп йөргәнгә дә тарсына белмиләр. Йөзләре һәр вакыт ягымлы. Сөзмә-катыгы, ипи-тозы гел әзер аларның. Бу әбиләрнең күбесе җитмеш бишсиксәннәр тирәсендә. Әйтерсең табигать аларга шул киң күңеллелекләре өчен озын гомер биргән.

... Бәрәңге җыю башта уен кебек тоелган иде. Кызлар чыр-чу килеп, бер-берсен урташа-урташа эшләделәр. Ләкин шәһәрдә туып үскән кызларның бертуктаусыз җиргә иелеп эшләүдән билләре авырта башлады.

Фәрдәнәгә дә җиңел түгел иде. Ләкин ул сынатмаска тырыша, уенкөлке сөйләшүен дәвам итә. Ул гына да түгел, күзләренә таралып төшкән чәчен, бармаклары кара балчыкка буялганга, кул аркасы белән генә өскә күтәреп куя да үзенең нәфис тавышы белән җырлап җибәрә:

Ай-урагың салып иңбашыңа
Кояш нурларыннан нур алдың...

— Сиңа артист гына буласы калган, — диләр аңа кызлар. Ә Фәрдәнә төн карасыдай күзләрен уйнаткалап ала да:

— И кызлар, кая инде ул миңа андый бәхет, — дип уфтанып куя.

Кырда эшләүче апайлар да Фәрдәнәнең җырлавына игътибар итми калмады:

— Сеңелем, безгә көне буе билетсыз концерт тыңлаттың инде, әллә клубта да җырлап карыйсыңмы? Бүтәннәр дә тавышыңны ишетеп бер ләззәт алсын иде.

Фәрдәнә уйлап та бирми:

— Була ул, апайлар, бүген үк концерт куябыз! — ди, бөтен кырны яңгыратып.

Илүзә Фәрдәнәгә шелтәле караш ташлый:

— Син апайларны ышандырма, берүзең генә әллә ни кыра алмассың бит.

— Ник берүзем генә ди... Ә сез?

— Мин, мәсәлән, җырлый да, бии дә белмим. Аннары өйрәнмәгән килеш...

— Әтәч булып кычкырырсың!

Кызлар гөр килеп көлешәләр...

Фәрдәнә хатыннарга биргән вәгъдәсен, билгеле, шул минутта ук оныткан иде. Ә ташлыярлылар оныта торганнардан түгел икән.

Илүзә белән Фәрдәнә эштән кайтып, хуҗа әбинең көлдә тәгәрәтеп пешергән бәрәңгесен бик әйбәтләп сөт белән ашап утырганда, кемдер тәрәзә чиртте. Клуб мөдире икән.

— Халык җыелып бетте инде, ник килмисез? — ди бу.

Фәрдәнә аптырап Илүзәгә карады:

— И дустым, нишлибез? Алар минем теге сүзне чынга алган икән бит!

— Әйттем бит мин сиңа.

Клуб мөдире үзенекен белә:

— Ашыгыгыз, кызлар!

Фәрдәнә:

— Без уйнап кына әйттек ич! — дип тә караган иде. Клуб мөдире ишетергә дә теләмәде.

— Шул тикле халыкны кире кайтарып җибәрсәгез — җир йотар! — дип, чат ябышты.

— Тик тормаган телдә бәла бар шул! — дип сукрана-сукрана, беренче булып Фәрдәнә урыныннан кузгалды.

— Әйткән сүз — аткан ук, диләр. Вәгъдә биргәнбез икән, үтәргә кирәк, — дип, Илүзә дә киенә башлады...

Илүзә белән Фәрдәнә көне буе эшләп изрәгән, инде йокыга да китәргә өлгергән кызларны, өй саен кереп, уятып йөрделәр. Кызлар — җитез халык — ярты сәгать эчендә җыелып та бетте.

— Мин җырлармын анысы, сез нишләрсез? — дип сорады Фәрдәнә.

— Мин Такташ шигырен сөйлим.

— Ә син, Оля?

— Белмим шул,— диде Оля, яшькелт күзләрен челт-челт йомгалап.

— Биисең!

— Абау, бии белмим ич мин.

— Сәхнәгә менгәч биерсең әле!

Шулай итеп, тиз арада концерт программасын да төзеп, сәхнәгә чыктылар...

Концертны халык яратты. Бер агай соңыннан сәхнәгә менеп хәтта: «Яхшы хәзерләнгәнсез», — дип мактап та куйды әле.

Концерттан соң яшьләр күңел ачарга калды.

Җомга көн иде бу. Бу көнне гадәттә авылга шәһәрдән бик күп яшьләр кайта. Бүген дә стена буйлап тезелгән озын эскәмияләрдә буш урын калмаган иде. Фәрдәнә чаткы чәчеп торган күзләрен рәтләр буйлап уйнатып алды да Илүзәнең колагына иелде:

— Сул як кырыйга кара әле! Нинди чибәр егет, ә?

Илүзә Фәрдәнә әйткән якка күз салды һәм шул секундта аның йөрәге икеләтә ешрак тибәргә тотынды: «Әйе, әйе, бу — ул». Коңгырт күз-

ле, куе кашлы егет... истә... барысы да истә. Ул чакта Илүзә сигезенчедә укый иде. Алар классында үткәрелгән әдәбият кичәсенә Казан музыка училищесыннан ялга кайткан өч егет килгән иде... Ул егетләрнең берсе — менә шул куе кашлысы — аеруча нык истә калган. Карашы гынамы соң. Аның тапкыр сүзле, үзе әйтмешли, эрудит булуы һәм җорлыгы. Юк, үткен сүзләре белән генә түгел, тигез агышлы җырдай тавышы, һәр фикерен кул хәрәкәте ярдәмендә бик килешле генә «озатып» баруы, хәтта сөйләгәндә зәңгәрсу күзләрен кыса төшүе белән дә әңгәмәдәшен шул минутта ук әсир итә торган егет иде ул.

— Син гашыйк булдың да, ахры, — диде Фәрданә.

Илүзә ни әйтергә белмичә:

— Ә... ә... юк, юк, — дип куйды.

— Танышыйкмы үзе белән?

— Безме?.. Нигә?

— Тиле...

— Мин аны беләм. Бу — Илсур.

— Кит аннан? Каян беләсең?

Илүзә җавап бирмәде. Аның башына: «Әгәр мине күреп калса?» — дигән уй килде. Шул уеннан коты очып, урыныннан сикереп торды да ишеккә ташланды.

— Илүзә, кая киттең? Илүзә!

Фәрданәнең аңа кычкыруына да игътибар итмичә, Илүзә, клубтан чыгып, чирәмле тыкрык буйлап үзләре яшәгән очка йөгерде. Аның Илсурдан болай качуы беренче генә түгел инде. Теге кичәдә күргәннән соң Илүзә аны Түбән Камада автобуста очраткан иде. Илсур Илүзәне күрү белән ап-ак тешләрен балкытып елмайды да, кешеләр арасыннан кысыла-кысыла, аңа таба килә башлады. Илүзә каушап-кызарып китте һәм, нигә алай эшләвен үзе дә белештермичә, автобусның ябылып җитмәгән ишегеннән кысылып төшеп калды. Ә автобуста калган Илсурның зәңгәрсу күзләре шактый гомер йөрәгеннән җилкетеп күз алдында торды. Ни хәл итәсең, йөзләгән еллар буе шулай булган ич. Яшь кыз белән яшь егет бер-берсенә тартылса да, ниндидер көч аларны якын җибәрми этәреп торган. Шуңа да гүзәллекнең илаһи сафлыгы булып яшьлеге дөньясына килеп кергән иң якын кешесеннән шулай атылып-бәрелеп качкан кыз бала. Ә бит шул мизгелдә кубарылып качып китмичә, бер-ике секундка — сөйгән кешесе янына килеп җиткәнче генә баскан урынында торасы, югыйсә! Юк шул, кыз бала моңа җөрьәт итәр өчен вакыт кирәк булган. Һәм бу серле мизгел барыбер килгән: кыз бала, дымсу күз керфекләрен тибрәтеп, ярым ачык иреннәрен дерелдәвеннән гаҗиз калып, могҗиза булып тоелган язмышын каршылаган.

Ә язмышы гап-гади егет икән аның.

Җиргә көн дә сыенып килгән җәйге кичләрнең берсе шундый сөйләшүгә шаһит булган:

— Кич нинди гүзәл, йолдызлы...

— Кешедән яхшы түгел...

— Тополь ябалдашлары безне яшереп тора.

— Шулай да... уңайсыз.

— Йолдызлар күрер дисеңме?

— Алар сансыз...

— Кайсындадыр безнең төсле егет белән кыз ерактагы җирне күзәткәндер.

— Әйе, моннан мең ел элек. Ә хәзерге йолдыз кызының карашы безнең яшәү дәверенә килеп җитмәс.

— Ә безнеке аларга барып җитәр дисеңме?

— Бәлки алар меңәр ел яшиләрдер.

— Мең ел да аз... Синең белән шулай мең ел янәшә басып торсаң иде...

— Туяр идең...
— Юк...
Беренче дуслык... Беренче мәхәббәт... Шулай килде ул Илүзәгә дә. Гади дә, серле дә булып. Ә Фәрдәнә дусты өчен сөенгән кебек иде. Ләкин шулай микән? Ни генә булмасын, Фәрдәнә группага сөенеч, матур җыр, күңел күтәренкелеге булып килеп керде. Группа кызлары шуңа күрә Фәрдәнәне үзләренең әйдәп йөртүчесе итәп кабул иттеләр дә. Яшьлекнең тынгысыз дулкыны Фәрдәнәне өскә әнә шулай тиз чыгарып куйды. Ә аннан соң...
... Дулкыннар комлы ярга ябырылалар да ябырылалар. Илүзә кочаклап утырган тезләренә ияген куйган да үзенә таба ишелеп килүче шул яшькелт дулкыннардан күзен алмый.

## ИКЕНЧЕ ДУЛКЫН

Училищеда дәресләр башланыр алдыннан Илүзә фатирга Фәрдәнә белән бергә урнашты. Хуҗа апай кызларны баштанаяк күзеннән кичерде дә:
— Сез миңа ошадыгыз. Тыйнак күренәсез. Югыйсә, кыска күлмәкле, су анасыныкыдай чәчле кызларны җенем сөйми, — диде.
Класста да Илүзә Фәрдәнә белән бер өстәл артына утырды. Беренче дәрес — җәмгыять белеме дәресе иде. Утыз биш яшь тирәсендәге бик җиңел гәүдәле Кыям абый кызып-кызып бу фәннең әһәмияте турында сөйли. Кызлар тын да алмый йотылып тыңлыйлар. Әнә Фәрдәнә дә күзләрен укытучыга төбәгән. Карашы — акыллы. Болай караганда шаян холыклы дип кем уйлар. Шаяру-җырлавы ял вакытында гына икән. Дәрес ахырында Фәрдәнә үтелгән материалны чатнатып сөйләп тә бирде. Шулай итеп, беренче бишле аңа насыйп булды.
Материаловедениедән дәрес бирүче озын буйлы, ач яңаклы Мария Семеновна, класска кергәндә, тавыш чыгарырга курыккандай, аяк очына басып кына атлый. Сабыр, салмак кына сөйли. Әнә хәзер дә гап-гади ситсы кисәген учына иләп кенә салган да шуның сыйфатлары хакында сөйли. Вакыт-вакыт учындагы шул ситсы кисәген тере җан иясен назлагандай, йомшак кына итеп сыпыргалап ала. Кызларның да чүпрәк кисәген сыйпап карыйсы килә.
— Мария Семеновна, тотып карыйм әле шуны! — ди иң алгы рәттә утыручы тиктормас Оля.
Мария Семеновна, билгеле, рөхсәт итә. Кызлар моңарчы кибетләрдә әллә ничә кат күргәннәрдер мондый материя кисәген. Ә шулай да беренче мәртәбә күргәндәй: «Уң ягы нинди нәфис», «Тискәре ягын аеру җиңел түгел икән», — дип пышылдашалар.
Бу вакытта Мария Семеновнаның зур соры күзләрендә якты нурлар балкый. Иреннәре елмая. Ләкин бу хәл күпкә бармый. Менә аның күзләрендәге көләчлек яңадан җитдилек белән алышына. Әле генә пыш-пыш килеп селкенгәләп алган кызларны Мария Семеновна күренмәс җепләр белән зыңгылдатып тартып куямыни: бөтен группа тып-тын кала. Күзләр тагын укытучыга төбәлә.
Илүзәгә иң ошаганы — тегүгә өйрәнү дәресе. Бик ягымлы, елмаерга гына торучы Наилә Хәбировна укыта бу дәресне. Кечкенә гәүдәсен бик җиңел йөртеп, мастерның класска килеп керүе башка дәресләрдәге шикелле тантаналы булмый, ничектер бик гади генә. Шулай да кызлар Наилә Хәбировна ишектән күренүгә бик тиз урыннарыннан торалар. Наилә Хәбировна озак бастырып тотмый: «Утырыгыз, кызлар, утырыгыз», — дияргә ашыга. Үзен шулай басып каршы алуларына уңайсызлана кебек. Ул акыл өйрәтергә яратмый. Киңәш биргәндәгедәй: «Менә шулайрак итеп кара әле, әйбәтрәк булмасмы?» — ди. Кызлар Наилә

Хәбировнаның бу сүзләрен һичшиксез шулай эшләнергә тиеш дип кабул итәләр һәм нәкъ ул кушканча эшләргә тырышалар.

Беренче дәресләрдә Наилә Хәбировна энә-җеп һәм уймак белән ничек эш итәргә кирәклеген өйрәтте. Ә бүген кызлар материя кисәген туры һәм тигез итеп кул белән тегеп чыгарга өйрәнделәр. Авылда һәм әбиле өйдә үскән Илүзәгә әллә ни авыр булмады. Ә менә Фәрдәнәнең җөе бормалы-бормалы булып, читкә чыгып киткән. Наилә Хәбировна аңа икенче материал бирде. Бу юлы Фәрдәнә ничек тә сынатмаска уйлады, ахры, чүпрәк кисәгеннән җеп суырып алды да шул суырылган җеп юлы буйлап тегеп барды. Ләкин Наилә Хәбировнаны алдамассың:

— Болай җөйләр тигез чыга чыгуын, кием тегкәндә дә материяннең җепләрен суыргаларсыңмы, Фәрдәнә? — ди ул елмаеп.

Фәрдәнә кулындагы көрән төстәге тукыманы бөтергәли. Аңа уңайсыз. Ичмасам, Наилә Хәбировна шулай елмаймаса иде...

## ӨЧЕНЧЕ ДУЛКЫН

— Барысы да табигый булырга тиеш. Табигать — безнең укытучыбыз.

Бу — Илсурның иң яраткан сүзе. Дәресләр бетүгә ул Илүзә белән Фәрдәнәне «табигать мажарасын тамаша кылырга» чакыра. Вакыт тигәндә кызлар я Аккош күлендә, я паркта йөриләр. Ә кай көнне тегесенә дә, монысына да өлгерәләр. Чөнки Илсур аларны алмага такси белән килә. Егет акчага шактый иркен яши. Аның әтисе Түбән Кама химкомбинатында цех башлыгы булып эшли. Әнисе культура йортында музыка түгәрәге белән җитәкчелек итә. Һәрхәлдә, бердәнбер улларын яхшы тәэмин итеп торырлык мөмкинлеге бар ата-ананың...

Бүген алар өчәүләп музыка училищесына бардылар. Монда аларны «музыка дөньясы» каршы алды. Аскы катта фортепьяноның әле тигез ритм белән салмак кына агылган, әле ярсып дулаган авазы, өске катта сузып-сузып кычкырткан быргы тавышы яңгырый. Бер бүлмәдә кемдер тырыша-тырыша, күнегү өчен, музыкасыз гына җырлый.

— Тавышы табигый түгел, — ди Илсур. — «Карурман»ны җырлаганда урман шавы һәм кошлар сайравы яңгырап торырга тиеш.

Һәм шунда ук ул, һичкемнән тартынмыйча, бу борынгы көйнең беренче өлешен җырлап җибәрә:

Кара урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк лә утәргә-э-ә.

Илсурның тавышы стеналарга бәрелә-бәрелә залның аргы башында беравык яңгырап тора.

Илсур һәр вакыт диярлек җырлап йөри. Аның тавышы матур, тигез агышлы. Бигрәк тә урманда җырлаганда табигый яңгырый. Кеше юк урында еш кына Фәрдәнә дә аңа кушылып җырлый. Үзенә күрә матур гына вокаль дуэт барлыкка килә. Илүзә, җырлый белсә дә, аларга кушылмый. Күрәсең, оста барында кулың тый, мулла барында телең тый дигән кагыйдәдән чыгып эш итә.

Менә аргы баштагы бүлмәдән скрипка моңы сибелә башлады. Илсур аны игътибар белән тыңлап торды да:

— Ишетәсезме, яз башлану күренеше ничек табигый яңгырый. Бернинди ясалма бозу юк. Кабалевскийның «Яз» поэмасы бу! Безгә көйләребездә табигать бүләк иткән авазларны: кошлар сайравын, чишмә чылтыравын, агач яфракларының бер-берсенә орынып үзләренчә серләшүен, хәтта кечкенә тынлыкны да музыка аша бирә белергә кирәк. Барысы да шулай саф, табигатьтәгечә булырга тиеш...

Болай Илсур гына сөйли белә.

— Әнә, — дип дәвам итте ул, — бер Америка профессоры табигатькә якын булырга өндәп язып чыккан анда. Безгә җиребез бергәнне түкми-чәчми файдаланырга кирәк. Югыйсә, без җанлы табигатьтән шактый аерылып киттек. Меңләгән ясалма әйберләр уйлап таптык: джаз, абстракция, картон декорацияләр, неон утлары, синтетика... Чәчәк исе урынына җиребез һавасын төтен, корым белән каплап барабыз... Үзебез өчен меңләгән чикләүләр уйлап чыгардык. Кыскасы, үз-үзебезне бик теләп тоткын иттек. Һәм шуңа чиксез куанып: цивилизация вәкиле без, дип күкрәкләребезгә шап-шоп сугабыз...

Илсурның мондый сөйләнүләре Илүзәгә ошый да, ошамый да. Бер яктан, әллә ни яңалык булмаса да, аның үз фикеренә чын күңелдән инанып сөйләвенә соклана Илүзә. Икенче яктан, Илсурның бу фәлсәфәсендә ниндидер ят булган, үзе әйтмешли, чит ноталарның яңгырап китүе аны сискәндереп тә ала. Бигрәк тә кызларга ялгыш орынып киткәндә: «Гафу, бернишләтеп булмый — табигать», диюе Илүзәдә күңел кайтаргыч тойгы тудырып куйгалый.

Илсур белән ялгыз калган минутларда Илүзә үзен шактый коры тота. Ул моны махсус эшләми. Кызның бу халәте үзеннән-үзе шулай килеп чыга. Юк, Илсур аңа ошамый түгел, ошый. Илүзә аны һәр вакыт сагынып көтеп ала. Берничә көн күрми торса, юксына башлый. Йөрәген сагыш баса. Ә егет белән очрашты исә Илүзәнең сөйләр сүзе тагын онытыла.

Кызга болай кыен. Ул да уйлары белән уртаклашыр иде. Эч серен бушатасы килгән минутлары булмыймыни Илүзәнең. Ләкин нидер аны тотып тора, нидер сөйләтми, тартындырып тора...

## ДҮРТЕНЧЕ ДУЛКЫН

Бер айлык укуга йомгак ясадылар бүген. Илүзә ударниклар рәтендә. Ә Фәрдәнәнең теория дәресләреннән барысы да бишле. Бары практикадан гына өчле. Ах, шул практика. Ул булмаса, отличник булыр иде Фәрдәнә!.. Ләкин барыбер күңеле күтәренке кызларның. Өйгә кайтканда җырлый-җырлый кайтты алар. Торган бүлмәләренә дә шау-гөр итеп, көлешә-көлешә килеп керделәр. Ләкин Илүзәгә тыныч яшәргә язмаган икән. Өстәл өстендә аңа атап килгән телеграмма ята. Түбән Кама шәһәрендә яшәүче әнисеннән. Кош теледәй кәгазь кисәгендә бары өч сүз: «Кайт, әбиең авырый». Илүзә куркуга төште. «Авырса гына телеграмма сукмаслар иде. Әллә әбием үлгәнме?»

Шикләнерлек урын бар иде шул. Чөнки менә ике ел инде Илүзәнең әбисе урын өстендә ята. Паралич зәхмәте кагылганнан бирле ул утырып кына тора ала. Аяклары йөрми. Зәңгәр-шәмәхә тамырлар белән чуарланган кытыршы кулы да хәлсезләнеп калган иде әбисенең.

Икенче көнне Илүзә «Ракета»га утырып Түбән Камага кайтып китте. «Ракета» суда аксыл күбекле буразна калдырып алга ыргыла. Зәңгәр су өсте тип-тигез. Илүзә, «Ракета» тәрәзәсенә кайнар маңгае белән орынып, тирбәлә-тирбәлә артка таба шуышкан яшькелт-сары төстәге тыныч ярларга зәңгәр күзләрен төбәгән дә уйга талган. Ул әбисен бүтән беркайчан да күрмәс микәнни?.. Аның ягымлы тавышын ишетмәс микәнни инде?..

Илүзә Мәрфуга әбисе янында үсте. Җәй житүгә әнисе — Галия апа — Илүзәне авылга, әбисе янына илтә торган иде. Илүзә әбисен бик ярата иде шул. Мәрфуга түти дә хәтфәдәй йомшак куллары белән Илүзәнең башыннан сөяр иде дә: «Я, кызым, бүгән нәрсә белән куандырырсың әбиеңне?»— дип сорар иде. Шуннан Илүзә көн озын йөреп күргән-белгәнен әнәсеннән җебенә чаклы сөйләп китәр иде. Җөплап торыр-

га дигәндә шул әбисенә куш инде. «И, булдыргансың, кызым, һай, рәхмәт, кызым!» — дип, үзе дә куанып, Илүзәне дә куандырып утырыр иде.

Әбисеннән бер нәрсәне дә яшерми иде Илүзә. Ник яшерсен, һичкайчан ачуланмый иде аның әбисе. «Ай-һай» — дип башын селкеп торса тора, әмма әнисе шикелле кашларын җыермый. «Син тәртипсез кыз»! дип орышмый иде ул.

Мәрфуга әби тегү тегәргә, әллә ниткән сурәтләр төшереп чигү чигәргә оста иде. «Миңа да энә-җеп бир, мин дә чигү чигәм», — дип йөдәткәч, әбисе Илүзәгә энә-җеп, чүпрәк кисәкләре тоттырыр иде. Әбисе янына утырып, нәни бармагына аның кебек итеп уймак киеп, курчак күлмәкләре тегеп утырудан да рәхәт эш бар идеме икән!

Аның әллә ничә балитәкле курчак күлмәкләрен күргәч, иптәш кызлары көнләшүдән нишләргә белми тора иделәр. Аннары, авызларын бүлтәйтеп:

— Синең әбиең бар шул,— дип куя иде алар. Иптәш кызларым бөтенләй үпкәләп китмәсен тагы дип, аларның курчагына да балитәкле күлмәк тегеп бирә иде Илүзә.

Кыш керүгә Мәрфуга әби, Илүзәне алып, кызы Галия янына шәһәргә килә. Әбисе шәһәргә килгәч булган бер вакыйга Илүзәнең хәтеренә нык сеңеп калган.

Шулай бервакыт Илүзәнең әнисе бик нәфис ромашка чәчәкләре төшерелгән ситсы алып кайтты да:

— Кызым, бу ситсыдан сиңа күлмәк тегәрбез, — диде Илүзәгә.

Ә Илүзә, әнисе эшкә киткәч, әбисенең күршегә йомыш белән кереп киткәнен сагалап торды да, күлмәкне үзе тегеп карарга булды. Нигә кемдер теккәнен көтеп торырга! Курчак өчен менә дигән күлмәкләр тегә ич ул. Әллә үзенә текмәсме. Башын кыңгыр салып үзе генә белгән җырлар көйли-көйли әлеге ситсыны буена үлчәп карады. Урындыкка басты да шкафтан үрелеп кайчы алды. Аннары шул ситсыны үзе белгәнчә кискәләде. Ләкин тегеп бетерергә өлгермәде, әнисе кайтып керде. Галия апа пыр туздырды Илүзәне. Әбисе кереп араламаса, уклау да эләгәсе иде әле. Әбисе бик яхшы иде шул:

— Нәрсә юкка ачуланасың баланы, бер дә бозмый-нитми, һөнәргә өйрәнеп буламыни, — дип, Илүзәне яклады.

Ә әнисе һәр вакыттагыча:

— Узындырып бетерәсең инде шуны, — дип сукранды.

Әнисенең кояштай ачылып-чәчелеп йөргән чаклары сирәк була. Дөнья мәшәкате баскан иде шул аны: көне буе эштә, кичен дә еш кына җәмагать эшләре белән мәшгуль иде ул. Илүзә әнисен бары кич булгач кына күрә. Кичке ашны ашап, җыйнаулашып телевизор каршына килеп утыргач, Илүзә дә песи шикелле йомарланып әнисе куенына сыенып иде. Шунда әнисе аның йомшак сары чәченнән сыйпый, битләреннән үбә... Шундый чакта әнисенең коңгырт күзләре никтер сагышланып китә, күзләре дымлана торган иде.

Илүзә буй җитте дигәндә генә Мурфуга әби урынга егылды. Әбисенә бер игелек эшләргә дә өлгерми калды шул Илүзә. «Әби үлсә, әнигә үзенә генә бик күңелсез калыр инде», — дигән уй юлның юл буе Илүзәнең йөрәген әрнетте. Шул борчуыннан озак арынып торырга теләп, Илүзә тирә-юньне тамаша кылып бара башлады. Көз булса да, яр буйлары искиткеч матур иде. Агач яфраклары нинди төскә генә кермәгән: алтын сыман, комачтай, көрән... Аз гына җил исте исә, күз явыңны алырлык булып уйнаклаган бу алтын көз хәбәрчеләре, һавада талгын тибрәнә-тибрәнә, су өстенә ваемсыз гына төшеп кунаклыйлар. Күз манзарасына төренгән Кама буйлары әйтерсең демонстрациягә чыккан. Ике яклап юкә, имән, карагайлар колоннасы үтә. Артка таба үтә...

Ә «Ракета», берни булмагандай, суны икегә ярып алга ашкынуын белә. Әле аның алдына, әле артына чыгып, акчарлаклар уйнаклый.

Ачыргаланып нидер кычкыра алар. Ник шулай кычкыра икән акчарлаклар?

«Әби чынлап та авырый гына торгандыр әле. Бераз салкын тидергәндер дә... Элеккечә ястыгын югары күтәрә төшеп яткан көе нәрсәдер чигә булыр. Бер минут та эшсез тора белми бит ул... Ә ник алай булгач.. Әбекәем, ни булды соң сиңа?»

... Башта Илүзә өй ишеген ачарга куркып торды. Кerә керешкә әбисе ята торган кече якка ашыкты. Һәм әбисен күрде. Ул элеккечә урын өстендә утыра.

— Ни булды, әбекәем? Авырып киттеңмени?

Мәрфуга түтинең башы калтырап куйды. Ул нидер әйтергә теләде. Ләкин гаепле кеше сыман:

— Авырды дип... карчык кешенең шул инде, — дип, авыз эченнән генә сөйләнеп алды.

Әбисенең моңсуланып калган күз карашы бу өйдә гадәттән тыш бер хәл булуы турында сөйли иде.

— Әни кайда?

Шул чак олы яктан әнисе килеп чыкты.

— Әни, әбекәйгә ни булды?

— Илүзә кызым, ачуланма инде...

Әни кеше кызына карамаска тырыша иде.

Ни булган соң? Ни өчен әнисе дә гаепле кеше төсле өтәләнә? Әле чәчләрен рәтли, әле яулыгын кысып бәйләп куя. Аннары, ярдәм сорагандай, әбигә ялварып карый. Ә Мәрфуга әби «аллага тапшыр» дигәндәй башын селкеп куйды.

Ниһаять, Галия апа танымаслык булып үзгәргән ят тавыш белән:

— Әтиең килде! — диде.

— Нәрсә?!

Илүзәнең тавышы көчсез чыкты. Ә иреннәре, бу нинди сүз икән дигән шикелле, әле генә әнисе әйткән җөмләне тәкърарлады: «Нинди әти? Кайдан килгән әти?..»

Илүзә үзенең әтисе исән икәнен белми иде. Әнисе аңа: «Казагыстан шахталарында эшләгәндә җир убылып, әтиең шунда басылып калды», — дип сөйләгән иде. Әнисенең әйтүенә караганда, ире үлгәч бер яшьлек Илүзәне күтәреп Галия апа үз якларына кайткан. Көчкенә Илүзәне әбисе янында калдырып торган. Ә үзе яңа төзелә башлаган Түбән Кама химкомбинатына эшкә кергән. Илүзә шушы яшенә чаклы әнә шул хакыйкатькә ышанып үсте. Кайдадыр аның үз әтисе яшәве турындагы уй башына да килмәде аның. Шуңа күрә «әтиең килде» дигән сүз бөтенләй ят булып, кеше ышанмаслык булып ишетелде Илүзәгә.

— Әтием исәнмени? — диде ул шаккатып.

Аның төсе киткәнен күреп әбисе дә, әнисе дә куркып калды. Әнисе Илүзәне кочып ук алды һәм карлыгып киткән тавышы белән ашыгаашыга сөйли башлады:

— Исән иде шул... Син миңа, зинһар, ачуланма, кызым. Кем уйлаган... Әнә килеп чыккан ич... Ничә еллар үткәч... Дөнья шулай шул... Син мине ачуланма инде...

Галия апа тотлыкты, буталды. Сүзләре бәйләнешсез һәм өзек-өзек булып чыга иде аның.

Ә урын өстендә утырган Мәрфуга әби иренен мимылдатты, күз яшьләрен тыеп калырга теләп, күз кабагын көчләп йомды. Ләкин яшьләре барыбер йомык күз кабагыннан саркылып, карчыкның җыерчыклы бите буйлап ага башлады.

— Ник килгән соң ул? — диде Илүзә.

— Үзеннән сорарсың. Әйдә, кызым, әтиең белән таныш.

— Ой, кирәкми, — диде кыз, әнисеннән читкә тартылып, — кирәкми!..

Илүзәгә болар барысы да бик сәер һәм җанны өшетер дәрәҗәдә уңайсыз тоела иде. Чыннан да, үз әтиең белән танышу була димени. Ник соң әле аның әнисе үзен һәм кызын ташлап киткән кешегә шулай якын итеп карый, ник өйдән куып чыгармый аны?

Әнисе кызының уйларын сизеп алгандай:

— Барысын да аңларсың, кызым, әйдә-әйдә, — дип сөйләнеп, Илүзәне, көчләп диярлек, түр бүлмәгә этәрде.

Илүзә бала чакта әтисенең фоторәсемен сорап караса да, әнисе «югалды» дип җавап биргән иде. Менә хәзер бүлмә уртасында басып торган кырык яшьләрендәге кешегә текәлеп бермәл өнсез торды кыз. Әтисе икән шул! Инде олыгая башлаган йөзгә әйтерсең Илүзәнең үз күзләрен утыртып куйганнар. Борыны, авызы... «Менә кемгә охшаганмын икән мин», — дип аһ итте Илүзә.

— Исәнме, кызым!

Үзенә таба сузылган дәү кулны күрсә дә, Илүзәнең кулы күтәрелмәде. Әти булган кеше үзе Илүзәнең кулын тотып алды:

— Исәнме, кызым Илүзә?..

Бу юлы әтисенең тавышы йомшак, кызганыч чыкты. Илүзә шуңа гаҗәпләнеп аның йөзенә күтәрелеп бакканда, әтисе, күзләрен кулы белән каплап, читкә борылган иде.

Сүз тиз генә ялганып китә алмады. Әтисе Илүзәнең укуы турында сорашкан булды. Гәрчә аннан беркем сорашмаса да, үз эше турында сөйләп алды. Аннары пеләшләнә башлаган башын аска иеп:

— Менә кайттым, — дип куйды.

Ниһаять, Илүзә телгә килде:

— Ник кайттыгыз соң?

— Ник дип... сезне сагындым, кызым...

— Безне сагындыгыз?.. Ә мин сезне белмим дә!.

Әтисе әнисенә карап куйды. Әнисе дәшмәде.

— Мин әтине үлгән дип йөрдем.

— Әниең шулай диеме?

— Әнинең әйтүе ни... миңа уналты яшь хәзер. Шул яшемә чаклы сез кайда идегез?

Әти кеше авыр сулап куйды.

— Әй, кызым, тормыш син уйлаганча бик гади нәрсә түгел икән ул.

Илүзә ачынып:

— Сез безне ташлап киткәнсез ич! — диде.

Әти кеше урыныннан кырт сикереп торды:

— Дөрес түгел!

Илүзә зәңгәр күзен мөлдерәтеп бермәлгә аптырап торды. Аннары тавышын бик нык акрынайтып, әле әнисенә, әле әтисенә дәште:

— Алай булгач, нигә, нигә киттегез соң?

— Син яшь әле, Илүзә, — диде әнисе, — бик яшь. Аңлап бетермисең...

Нәрсә соң бу? Кара, Илүзәнең әнисе бу кеше белән бер сүздә икән бит! Илүзә әнисенә үпкәле караш ташлады да ишеккә таба атлады:

— Алай булгач, нәрсәгә мине монда чакырдыгыз соң?

Әтисе Илүзәне кулыннан тотып алды.

— Туктале, кызым... ашыкма... Шуны әйт: өйрәнәчәк һөнәрең сиңа ошыймы?

Илүзә, ни дияргә дә белмичә, җавапсыз калды.

— Я, әйт, ошыймы?

— Ник ошамасын. Ошамаса анда укырга да кермәс идем.

— Бик яхшы. Әгәр укып бетереп эшли башлагач, сиңа бу эшеңне ташла, я бүтән эшкә кер дисәләр, тыңлар идеңме?

— Кем әйтсен миңа алай дип?

— Әйтик яраткан кешең... Егетең...

Илүзә дәшми торды. Бары байтактан соң гына:

— Мин андый егет белән бүтән... — диде дә, нәрсәдер төшенгәндәй, кинәт туктап калды. Бала чагындагы кебек итеп, имән бармаган тешләде.

— Я, я?

— Нәрсә, әни сезгә шулай дип әйттеме?

— Әниеңнән үзеннән сора.

— Нәрсәсен сорыйсың...

Илүзә, ике күзен тутырып, әнисенә текәлде. Аның зәңгәр күзләре сабыйларча беркатлылык белән тулы иде. Галия апа кызының күз карашында үпкә катыш рәнҗү сиземләгәндәй булды. Бу күзләр гүя: «Менә ничек. Сез, зурлар, җиңел кулдан теләсә нәрсә хәл итә аласыз. Безнең ятим калуыбыз сезне борчымый шул», — дия иде. Шул чагында Галия апа үксеп елап җибәрде:

— Ничек туган җирәмнән читтә яши алыйм мин?.. Булдыра алмадым... Ә әтиең аннан китмим дип аяк терәде...

Әти кеше сүзгә кушылды:

— Мин — шахтер. Монда күмер шахталары юк лабаса...

Илүзә читләтеп-нитеп тормады, турыдан ярды:

— Әнине, мине ташлауны артыграк күрдең алай булгач...

— Әниең үзе китте. Мин хат язсам да җавап бирмәде.

Галия апа тәрәзә аша өй турындагы карама агачының салынкы ботакларына карап тора иде. Читтән караганда әйтерсең инде бу әңгәмә аңа кагылмый да... Ләкин аның сагышлы күзләре яшь белән мөлдерәмә тулы. Менә-менә агып төшәргә тора. Үзен тыеп торудан иреннәре дерелди иде. Илүзәгә әтисе дә кызганыч. Һәрхәлдә, ул әтисенең хәлен аңлый кебек... Ләкин нишләргә соң? Ничек аны якын итәргә... Моңарчы белмәгән кешегә ничек әти дип әйтергә?.. Кинәт ул, әтисенә борылды да, ачыйгланып.

— Ни өчен килдең?! Мин сине белми идем бит! Хәзер... хәзер миңа авыр! Безгә авыр, ишетәсеңме! — диде һәм үз-үзен белештерми, әбисе янына атылып чыкты. Әнисе аның артыннан ташланды:

— Илүзә, тилермә!

— Мине әбиең авырый дип алдагансыз. Нигә чакырдыгыз мине? Килгән китәр иде. Мин белми дә калыр идем!

Галия апа бары бер сүзне кабатлады:

— Кызым, кызым...

Ә Мәрфуга әби караватында утырган көе нәрсәдер чигүен белә. Тик аның җан тетрәткеч киеренкелек белән шулай чигүе, әллә ничек тоныкланып калган соры күзләре Илүзәне куркытып җибәрде. Ул әбисенең кулларына барып тотынды:

— Борчылма, әбекәем, борчылма!

Мәрфуга әби чигү эшен боз кебек кулларында чытырдатып кыскан килеш, илереп пышылдады:

— Кит, балам, кит! — һәм калтырана-калтырана чигүендә булды.

Галия апа да Мәрфуга әби янына килде. Аны тынычландырырга тырышты:

— Әни, тынычлан, тынычлан, зинһар! Бар да үтәр... үтәр...

Галия апа белән Илүзә төн буе Мәрфуга әби яныннан китмәделәр. Мәрфуга әби инде урында ята. Күзләре йомык. Сөякчел куллары гына чигүлеген тоткан килеш хәлсез кыймылдый иде.

Ул таң алдыннан бөтенләйгә тынды.

Галия апа, иренен авырткančы тешләп, саклык белән әбинең кулларыннан чигү өлгесен ычкындырды. Өлгедә хатын белән ир силуэты чигелгән иде. Бу ике җан иясе ике якка омтыла. Ә аларның уртасындагы бөдрә чәчле кызчык, әти-әнисенең кулларыннан тоткан да аларны ике якка аерылып китәргә ирек бирми кебек иде.

## БИШЕНЧЕ ДУЛКЫН

Яшьлек яшьлек инде ул. Кайгы-хәсрәте, борчулары белән Илүзәнең күңеле тугланды-тугланды да берзаман тынып калды. Ничә көннәр буе бөтен җанын чуарлап торган шаукым арасыннан, яктырып һәм изге булып, әбисенең мөлаем сурәте калыкты. Бу сурәт шул кадәр җылы һәм ягымлы иде ки, Илүзә берәр күңелсезлеккә юлыккан чакларда, нурдай яктырып, күз алдында пәйда була иде. Шундый мизгелләрдә Илүзәгә канат үскәндәй булып китә. Ник дисәң, ул әбисе гомер буе сөеп башкарган эшне дәвам итәргә алынды лабаса. Юк, гади дәвам итү генә түгел, ул аны тагын да камилрәк, гүзәлрәк итәргә тиеш.

Мәрфуга әбинең гомер бакый кулында энә дә җеп булган. Менә шуның ише тиз йөрешле тегү һәм чигү машиналарын күрү насыйп булганмыни аңа.

Тегү мастерскоенда рәт-рәт булып ачык яшел төстәге тегү машиналары тезелеп тора. Ә бер читтә шундый ук төстә — чигү, төймә тагу, җалау ясау машиналары. Бик матурлар алар. Эстетика дәресендә Рузия Хаковна әйтте инде: «Күңелләрне куандырып торсын өчен шулай аксыл яшел төскә буялган алар. Май аенда каен яфраклары әнә шундый төстә була!» — диде.

Әле мәктәптә укыганда ук өй эшләре дәресендә Илүзәнең кул машинасы белән эш иткәне бар иде. Әмма моның ише йөгерек машинаны күргәне юк әле аның. Шуңа күрә баштарак, ай-һай, куркыныч булды. Илүзәнең йөрәге дөп-дөп типте. Тегәргә тиешле тукыма кисәген машинасының тегү табаны астына куеп, педальгә басуы булды, энә шарт итеп сынып та китте. Механик апалары Галимә Шагиевна яңа энә куеп биргәч, Илүзә, икенче энәне сындырудан куркып, шактый вакыт текми утырды. Әйе, берьюлы ничә төрле хәрәкәт ясарга кирәк бит: машинаны электр көчәнешенә тоташтырырга, педальгә басарга, тукыманы тигез итеп шудырырга, кирәк чакта нәкъ үз вакытында туктатып өлгерергә...

— Педальгә акрын гына бас, акыллым.— Күтәрелеп караса, Наилә Хәбировна елмаеп тора.— Кинәт басканга шүрең сикереп чыккан да, энәгә бәрелеп аны сындырган. Ә син акрын гына, тигез генә...

Илүзә тынычлангандай булды һәм машина җай гына гөлдерәп эшли башлады.

Кушылган эшне, ниһаять, эшләп бетергәндә Илүзәнең маңгаена бөрчек-бөрчек тир бәреп чыккан иде. Эш белән мавыгып, бар дөньясын оныткан иде ул. Күтәрелеп караса, Фәрдәнә дусты һаман тегә алмый газап чигә икән әле. Үзе кызарынган. Елап та җибәргән, ахры, күзләре яшьле.

Илүзә, Наилә Хәбировнадан рөхсәт сорап, Фәрдәнә янына килде.

— Эшләрең ничек, дустым?

Фәрдәнә тегә торган әйберен йомарлап бер читкә ыргытты да тагы еларга тотынды:

— Булмый миннән... Алты энә сындырдым инде.

— Яле, икәүләп тегеп карыйк.

— Нәрсәсен тегәсең. Мин тукыманы бозып бетердем ич.

Шул ара Наилә Хәбировна да килеп җитте:

— Мә, Фәрдәнә, мин сиңа икенче тукыма бирәм. Менә Илүзә белән икәүләп тырышып карагыз әле... Була, була, борчылма, акыллым.

«Акыллым» дип торганда ничек акыллы булмыйсың инде. Фәрдәнә күз яшьләрен сөртте дә яңадан эшкә керешә.

— Менә, була ич! — дип, дустының күңелен күтәрергә тырышты Илүзә.

Чынлап та бу юлы энә дә сынмады, җөй дә ярыйсы гына тигез чыга башлады. Фәрдәнә үзе дә шатлыгыннан яшь аралаш көлеп җибәрде. Елый-елый көлүче Фәрдәнә бу вакытта кызганычрак та һәм гаҗәп сөйкемле дә иде.

Ләкин Фәрдәнәнең эше ахырга чаклы барып чыкмады. Наилә Хәбировна аңа булышырга Зәкияне кушкан иде дә, тик ул:

— Минем өчен өйрәнми, үзе азаплансын, — дип кенә җавап бирде.

Зәкия һәр вакыт шулай тупас сөйләшә. Наилә Хәбировна да аның бу холкына күнегеп килә инде. Шуңа:

— Ай-һай, Зәкия — дип кенә әйтте дә, Фәрдәнә янына үзе килде. Ә Зәкия, берни булмагандай, тәрәзәгә борылып утырды. Аның күзләре шундый усал карый, әйтерсең кемдер аңа начарлык эшләгән. Хәер, аны аңларга да була. Бу кызыйга тормыш гел тискәре ягы белән ачылган. Әтисе дә, әнисе дә көн-төн эчәләр икән. Бигрәк тә әнисе... Сыра сатучы булып эшләгән булган ул. Аннары зур гына сума өстенә чыгып, төрмәгә эләккән. Ул төрмәдә чагында Зәкиянең әтисе дә кешелектән чыккан: эчкән, азып-тузып йөргән. Әнисе төрмәдән чыккач та эчүен ташламаган. Еш кына Зәкия:

— Бүген тагы Мәшүрәне сөйрәп кайттым әле. Бөтенләй дуңгызга әйләнгәнче лыкынган, — ди.

Ул әнисен шулай Мәшүрә дип атый.

Иптәшләреннән ике яшькә генә өлкән булса да, Зәкия олы кыяфәтле күренә. Аз елмая, кешеләрне яратмый. Бигрәк тә егетләрне дошман күрә.

— Кирәкләре бер тиен, — дип кенә җибәрә.

Иптәш кызларының сөйләвенә караганда, Зәкия ике ел элек бер егетне яратып йөргән. «Зәкия ул чакта бөтенләй үзгәргән иде. Ягымлы иде», — диләр кызлар.

Ләкин соңыннан Зәкия егетнең башка кызлар белән дә йөргәнен белеп алган һәм аулакта аны тотып кыйнаган, ди. Моңа ышанырга да була. Чөнки Зәкия таза гәүдәле. Үзе тагын бик эшчән дә. Училищеда уку белән бергә, кайдадыр җыештыручы булып та эшли икән. Чөнки әти-әнисе үз акчаларын эчеп бетерәләр. Шуңа күрә кечкенә энесен туйдыру, киендерү — Зәкия өстендә. Күлмәк, халат, кебек нәрсәләрне үзе тегә икән. Ул практик дәресләрдә иң яхшы тегүче булып санала. Ә теория дәресләрен һич тә яратмый. «Тагын сөйләү дәресе икән», ди ул чын күңеленнән ачынып.

...Инде дәрес бетеп килә. Кызларның күбесе үз эшләрен тәмамлап Наилә Хәбировнага тапшырдылар. Озак кына интеккәннән соң Оля да теккән тукымасын мастер өстәле янына күтәреп килде. Аңа да практика авыр бирелә. Ләкин кызый иренен тешләп канатып бетерсә бетерә, әмма максатына ирешми туктамый. Бары Фәрдәнә генә, мастер күрсәтеп бирүгә карамастан, кушылган эшен тәки башкарып чыга алмады. Икенче тукыманы бозгач, бөтәнен алудан баш тартып, сөмсерен коеп, калган вакытны тик утырды. Ул бу вакытта ак мәрмәрдән оста скульптор ясаган нәфис сынга охшаган иде.

Борчылулар һәм күз яшьләре булуга карамастан, Илүзә училищедан күтәренке күңел белән кайтты.

«Ярый әле, безнең училище бар,— дип сөенде ул,— югыйсә, соңгы көннәрдә булып үткән җан газабын бу башкаем ничек күтәреп бетерә алыр иде?»

Илүзә юатуга да карамастан, бу көнне Фәрдәнәнең генә күңеле тәки күтәрелмәде. Ул уйчан һәм боек иде.

## АЛТЫНЧЫ ДУЛКЫН

Фатирга кайтуына Илүзәгә өйләреннән посылкага язу килгән иде. Фәрдәнә белән икесе почта бүлегенә барып шуны алып кайттылар. Кечкенә фанера ящик эчендә әллә ни хикмәтле нәрсәләр юк, әлбәттә: рызык затыннан алма, конфет, банкалы бал. Кием-салымнан,— кыш кияр өчен йон кофта, мамык шарф. Боларын Илүзә үзе бәйләгән иде. Ящик эченнән шактый озын хат та чыкты. Хатны әтисе язган. Әти кеше шактый тәфсилләп элеккеге тормышы хакында сөйләгән. Үзләренең шахталарын шундый мактаган — әйтерсең анда җир асты түгел, ә хуш исле гөлләр бакчасы. Шул юлларны укыгач, ихтыярсыз үзеннең дә күкрәк тутырып шул шахта һавасын иснисең килә башлый. Аннары күмер комбайнының ничек эшләве турында сүзләр китә. Әтисе сүзе белән әйткәндә, ул шул «отличный машинада» эшләгән икән. Начальниклары бик яраткан үзен. Рәсеме һәр вакыт Мактау тактасында эленеп торган. Гәзитләргә дә гел мактап язалар иде, дигән. Үз сүзен раслар өчен булса кирәк, шул гәзитләрдән кисеп алган мәкаләләрне дә салган хат эченә.

Аннары әтисе ул якта ашау-эчүнең бик әйбәт икәнен дә, үзенең акчаны күп алуын да, ике бүлмәле әйбәт квартиры, җиләк-җимеш бакчасы булуын да язган. Хатта ул турыда әйтелмәсә дә, Галия апа белән Илүзәгә шул якка күчеп бару кирәклеген бик яхшы сиздергән әти кеше. Бу хат Илүзәнең күңелен иләсләндереп җибәрде. Аның үзенең дә әтисе яшәгән шул якларны барып күрәсе килеп китте. Чынлап та, ни өчен аның әнисе анда калырга риза булмады икән? Төне буе диярлек Илүзә шул хакта уйлап ятты. Әни урынында булсам, мин нишләгән булыр идем икән дип уйлады. Үзен әнисе урынына куеп карагач, башында ике төрле фикер көрәшә башлады. Шуның берсе — Казагыстан ягына тартканы — ничектер кыю, җил-давылдан курыкмый торган романтиграк теләк иде. Икенчесе — туган якларга бәйләнгәне — нечкәрәк, сизгеррәк. Шушы икенчесе Кама буйларындагы урман һәм болыннарны, шул мәгърур елганың озын көйдәй сабыр һәм җәелеп агышын күз алдына китерде. Әйе, туган якның сине бәйләп торган җепләре бик нык шул. Әнисе юкка үз якларын сагынып кайтмагандыр. Элек Илүзә аның вакыт-вакыт күз карашы нигә шулай моңсуланып китүен аңламый иде. Хәзер төшенде инде менә. Әтисен онытмаган икән шул аның әнисе. Ләкин үзе барыбер аның янында калырга риза булмаган. Туган ягыңны сагыну яраткан кешеңне сагынудан көчлерәк микәнни?.. Ә әтисе? Ул туган туфрагын бер дә сагынмаган микәнни? Сагынгандыр, мөгаен. Ләкин ник ул анда калды икән соң? Эшемне яраттым, ди. Әнисе аны аңламады микәнни?.. Ә Илүзә барыбер ул якларны бер урап кайтыр иде. Бәлки бер-ике ел эшләп тә алыр иде шунда. Ләкин шуннан артык түгел. Туган як кадерле бит ул. Бәлки әти дә башта шулай берике елга дип кенә калган булгандыр. Ә хәзер ул яклар әтинең икенче туган ягына әйләнгәндер инде...

Әти... Кызык... Хәзер, әтием бар, дип әйтә аламы соң ул? Белми әле Илүзә, белми...

## ҖИДЕНЧЕ ДУЛКЫН

Практика көннәрен Илүзә һәр вакыт көтеп ала. Бар кызлардан алда килә дә үзенә беркетелгән машинасын тагы бер кат җентекләп күздән кичерә. Аннары әйләнмәле (күтәреп-төшерү өчен) түгәрәк утыргычына утыра да озак кына итеп машинаның яшькелт корпусына карап тора. «Нәкъ тере зат бу машина, — дип уйлый Илүзә эченнән, — үзе ничек сизгер: син тыныч, сабыр чагында — ул да тыңлаучан. Ачуың

чыктымы, капризлана башлый — әле энә сынып китә, әле җеп өзелә. Ә назлаганны, кадерләгәнне ничек ярата ул. Андый чакта гөрелдәп кенә эшләп тора.

Менә, гадәттәгечә елмаеп, Наилә Хәбировна килеп керде. Аның белән бергә өстәл янына чандыр гына бер малай да үтте.

— Таныш булыгыз, — диде Наилә Хәбировна, — бу егет безнең группада укыячак. Исеме — Вагыйз. Бераз соңгарган соңгаруын. Ләкин тырышса куып җитәр. Шулай бит, Вагыйз?

Чандыр малайны Зәкия белән бергә утырттылар. Зәкия аңа беравык дошманына карагандай карап торды. Кызлар көлеп җибәрделәр. Ә малай аптырап як-ягына каранды. Үзен аккошлар арасына килеп кергән ялгыз үрдәк бәбкәсе төсле тойды, күрәсең. Менә бүлмәдә тагы Наилә Хәбировнаның ягымлы тавышы. Ул күлмәк якасын ничек дөрес утырту турында сөйли. Ул сөйли һәм шул ук вакытта ничек эшләргә икәнен дә күрсәтеп бирә. Син аның кулларына карап торасың. Тигез, төгәл хәрәкәтләр. Шуңа карап күңелеңнән үзең дә тырыша башлыйсың. Бик җиңел булыр төсле бар да. Наилә Хәбировнаныкы төсле шома, нәфис...

Илүзәнең машинасы көннән-көн тыңлаучанрак була бара. Уң аягы белән педальгә басуы була, тукыма өстендә йөзеп китә машина табаны. Һәм тип-тигез җөйләр сызылып үтә...

Ә менә Фәрдәнәнең эшләре һаман әле мактанырлык түгел. Аңа бер үк операцияне кат-кат башкарырга туры килә. Әйе, Фәрдәнәнең Илүзәнеке кебек әбисе булмаган шул. Мәктәптә дә өй эшләре белән әллә ни мавыкмаган. Барысын яңабаштан башларга туры килә аңа. Хәтта үймак киеп караганы да булмады бит Фәрдәнәнең. Машинаны әйткән дә юк инде. Фәрдәнә тегү училищесына килермен дип һич уйламаган иде. Әнисе аңа: «Кулинария мәктәбенә кер», — диде. Фәрдәнәнең әнисе Маһира апа — аш-су остасы. Мәҗлес-мазар үткәрәсе булса, таныш-белешләре Маһира апаны чакырмый калмыйлар инде. Чәкчәген дисеңме, гөбәдиясенме — барын да искиткеч шәп итеп пешерә ул. Табынны көлеп тора торган итә. Фәрдәнә әнисеннән күрә аш-су пешерергә үзе дә өйрәнгән иде. Ләкин аның кулинария мәктәбенә керәсе килмәде. «Артистка булсаң иде», дип хыяллана иде ул. Әгәр быел тегү фабрикасында эшли башлаган Соня дигән дусты котыртмаган булса... Әле дә үпкәли аңа Фәрдәнә:

— Менә, синең аркаңда гына җәфа чигәм мин...

Ә Соня Фәрдәнәне төрлечә үгетли:

— Син иренмә генә, Фәрдәнә! Башта шулай була инде ул. Мин дә күз яшен аз түкмәдем. Аның каравы, хәзер шатланып бетә алмыйм.

— Белмим шул, өйрәнә алсам бик ярый инде,— дип, Фәрдәнә авыр сулап куя.

Бирелгән эшен җиренә җиткереп башкарган көнне баштарак шатланып туя алмый иде Фәрдәнә. Ә инде мастер да мактап җибәрсә, түбәсе күккә тия иде аның. Урам буйлап фатирга кайтышлый, әллә нинткән мәзәкләр сөйләп, Илүзәнең эчен катырып бетерә торган иде. Андый чакта кайтып керү белән әниенә хат язарга утыра. Әйтерсең эченә сыймаган шатлыгын, түгелеп әрәм булмасын өчен, кәгазь битенә төшереп калырга ашыга...

Ә бүген кызлар күлмәгенә яка утырту операциясе тәки харап итте Фәрдәнәне. Җитмәсә, Наилә Хәбировна да алданрак килеп карамады бит. Ул дәрес буенча әлеге Вагыйз яныннан китмәде. Ә яка ясау уен эш кенә булып тоелган иде бит Фәрдәнәгә. Баксаң, нәкъ тиешле урынга тигез итеп яка утырту, ай-һай, читен эш икән... Болай бер карaганда барысы да ярыйсы кебек иде. Ләкин Наилә Хәбировнаның тәҗрибәле күзе хатаны тиз сизеп алды.

— Якаң дөрес утырмаган, кыек чыккан бит, акыллым.

Инде нишләргә? Шул хатаны төзәтергә азапланып утыра-утыра тирләп-пешеп чыкты Фәрдәнә. Сүтте. Тагы текте. Ләкин барыбер берни чыгара алмады. Бу чын мәгънәсендә брак иде. Группада иң беренче җитди брак. Кем диген әле — группа комсоргы брак ясады!

Бу хәлгә тәмам гаҗиз булган Фәрдәнә, йокыга киткән кеше сыман, башын аска иеп утырды-утырды да, су эчәргә дип мастердан сорап чыгып китте. Һәм шуннан мастерскойга кире кермәде.

Илүзә кайтып кергәндә Фәрдәнә өйдә дә юк иде. Бөтен урын-җир актарылган. Фәрдәнәнең чемоданы идән уртасында тора. Ул аңа бөтен кием-салымын тутырып куйган.

Бераздан Фәрдәнә кайтып керде. Туздырып ташланган койкасына ауды да елап җибәрде:

— Нинди кешеләр бу, ә?!

Илүзә аны юатырга тырышты:

— Тынычлан, зинһар, син бигрәк инде...

Фәрдәнә Илүзәнең кулын җилкәсеннән алып ташлады:

— Ник алар минем документларымны бирмиләр? Миннән барыбер бернинди тегүче чыкмаячак!

— Фәрдәнә, дим, Фәрдәнә! Барысы да әйбәт иде бит әле...

— Барыбер китәм! Документларны соңыннан җибәрерләр әле.

— Их, син! Бигрәк йомшак син, Фәрдәнә... Мин сине нык характерлы кыз дип уйлаган идем тагы. Ә син...

Фәрдәнәнең ачуы чыкты:

— Кит, дим, калдыр мине!

— Фәрдәнә, дим... Ну, ярый, мин чыгып китәм. Ә син тынычлан. Менә күрерсең, барысы да әйбәт булыр.

Илүзә Фәрдәнәне дустанә кочаклап, яшькә чыланган тыгыз битеннән үпте дә ишеккә таба атлады. Ләкин тышкы якка чыгарга өлгермәде, Фәрдәнә аңа:

— Тукта, мин дә чыгам! — дип кычкырды.

Алар бер сүз сөйләшмичә урам буйлап бардылар да бардылар. Бер дә уйламаганда каршыларына Илсур килеп чыкты.

— У, — диде ул шаккаткан атлы булып,— күктән көткәнне җирдән биргән диләр... Ләкин нишләп күләгә төшкән туташкайларның нәфис йөзенә?

— Ә син, егет булсаң, тарат күләгәне! — диде Фәрдәнә күңелсез тавыш белән.

— Күләгәне таратыргамы? Кояш балкытыргa? Була ул!

Илсур кызларны «Елочка» кафесына алып килде.

Илүзә:

— Китегез булмаганны,— дип тартышкан иде, ләкин Фәрдәнә:

— Я, нәрсәсе бар аның. Янган йөрәкне мороженое ашап, я коктейль суырып басып чыгарбыз, ичмаса! — дип, аны күндерде.

Илсур мороженое белән коктейль генә алмады. Өстәлгә ниндидер эчемлек тә килеп кунаклады.

Башта беркем дә эчемлеккә кагылмады. Сөйләшә-сөйләшә коктейль суырдылар.

Фәрдәнә туйганчы җанын бушатты.

Илүзә Илсур Фәрдәнәне юатыр, авырлыкларны җиңәргә өндәр дип уйлаган иде.

Ләкин һич көтмәгәндә ул:

— Мин ул училищеда укып та йөрмәс идем,— дип әйтеп салмасынмы! Илүзәнең әйтерсең йөрәген кыскыч белән кысып алдылар. Ул үзен-үзе белештермичә кычкырып диярлек:

— Нәрсә дидең? — дип сорады.

— Я, гади тегүче булырсыз,— диде Илсур, һич тә пошмыйча

гына,— нәрсәсе бар инде аның, Илүзә? Тегү тәккәндә нинди иҗади рухлану булырга мөмкин. Менә безнең училище, ичмаса...

Илсур үзенең училищесы турында горурланып сөйләргә ярата. Музыка турында сүз чыкса, ул бөтенләй ачылып китә: дугаланып торган кашлары турая, коңгырт күзләре җанланып китә, үзе дә, менә-менә очарга җыенгандай, кулларын бутый-бутый сөйләргә тотына. Мондый чакта Илсурны тыңлавы күңелле. Тормышта үз юлын тапкан кеше генә шундый була ич. Үз һөнәре турында сөйләгәндә Илүзә дә шулай. Ләкин Илүзә соңгы вакытта шуны сизә башлаган иде: кешенең тышкы күренешен бизәүче нәфис киемнәр турында сөйләгәндә, Илсур, ни өчендер, аны илтифатсыз тыңлый, хәтта чырае да караңгылана бугай. Илүзәгә бик күңелсез булып китә.

Ә тора-бара Илсур:

— Шул һөнәрнең ни матурлыгын таптың, Илүзә? — дигән сүзләр ычкындыра башлаган иде.

Ләкин, Илүзәнең кәефе китүен сизеп, ул сүзне икенчегә бора иде әле. Ә бүген... Илүзә бөтен җаны-тәне белән үз училищесын якларга әзер бит. Ул тегүче-модельерларның һәм конструкторларның яңадан-яңа иң әйбәт кием модельләре иҗат итүе, мондый иҗат эшенең чикләнмәгән мөмкинлекләре булуы турында сөйләр иде. Мең төрле формадагы күлмәк, костюм, тышкы киемнәрнең әллә никадәр төсләр коллекциясе белән бизәлүен, иң оста рәссамнар гына бу төсләр белән эш итә алуын исбатлар иде Илүзә. Ниһаять, урамнан агылучы менә бу кешеләрнең тирә-юньне бизәвендә тегүче осталарның зур өлеше булуын әйтмәс идемени ул! «Бу иҗат түгелмени?!»— дип кычкырырга да хакы бар иде Илүзәнең. Ләкин Илүзә сөйләмәде дә, исбатламады да... Ул гарьләнде... Якын дустым дип ышанып йөргән кешесенең үзе иң мөһим санаган, чын күңеленнән гашыйк булган эшне мәсхәрәләве аны телсез калдырды. Ә менә Фәрдәнә Илсурның сүзләренә теләп кушылды.

— Бик дөрес әйтәсең, Илсур. Минем күптән күңелем кайтты училищедан. Бернинди кызык юк. Эч пошудан саргаеп үләрсең...

Алар тагы нәрсә сөйләгәннәрдер, Илүзә тыңламады. Беравык үзен кая куярга белми таш сын кебек утырды. Бары үзенә таба сузылган эчемлекле рюмканы күргәч кенә йокыдан уянгандай сискәнеп китте һәм:

— Рәхмәт,— дип урыныннан торды.

Илсур моны көтмәгән иде. Ул Илүзәнең иңнәреннән кочып алып:

— Син, нәрсә, Илүзә? Әгәр дөрес әйтмәсәм, гафу ит! — диде.

Ләкин Илүзә Илсурның кулларын иңеннән алып ташлады да кафедан чыгып ук китте.

## СИГЕЗЕНЧЕ ДУЛКЫН

Наилә Хәбировна бик ягымлы һәм ярдәмчел булса да, кайбер кызлар аңа еш мөрәҗәгать итмәскә тырыша. Моның үзенә күрә сере дә бар: әгәр ярдәм сорасалар, мастер: «Аңламый икән бу!» — дип уйлаудан шикләнә алар. Кемнең йомшак укучылар рәтенә басасы килсен. Иң яхшы тегүче булып саналган Зәкиягә дә ярдәм сорап бармыйлар. Ул барыбер булышмаячак. Күзен акайтыр да, үзенең калын тавышы белән:

— Күңелемне болгатма, слушай, болай да эчем пошып тора,— дияр. Янсә:

— Мин мастер ярдәмчесе булып ялланмаган. Эш хакы да алмыйм,— дип кырт кисәр.

Ә менә Илүзәдән аңламаганыңны сорасаң да була. Һичкайчан баш тартмас. Шуңа күрә, практика дәресе тәмамланута, бер төркем кызлар аның янына җыела. Шулар чолганышында калган Илүзә аны тегеп күрсәтә, моны аңлата. Кызлар әйдәгез кайтыйк инде, димәсә, Илүзә үзе беркайчан да «җитәр» димәс. Юк, бу Илүзәнең башка кызлар алдында яхшы ат казанырга теләве түгел. Мондый эш аның үзенә ләззәт бирә. Җанында рәхәт җинеллек тоя Илүзә кызларга булышканнан соң. Ә кичә Наилә Хәбировна теге яңа килгән Вагыйзны да Илүзәгә беркетте. Көн саен дәрестән соң шул егет белән калырга туры килә аңа. Уен эш түгел: иң беренче операциядән башлап бөтенесен аңлатасы, төшендерәсе бар.

Вагыйз башсыз егет түгел икән. Аннары бик тырыш та. Көннән-көн аның эше уңышлырак була бара. Ләкин менә Фәрдәнәнең алга китеше күренми.

Шулай да ул һичкайчан Илүзә янына ярдәм сорап килми. Янәсе, баш иргә яратмый. Кем белә, бәлки теләмидер дә.

Әллә нәрсә булды Фәрдәнәгә. Соңгы вакытта аның Илүзә белән арасы салкынайды. Алыштырып куйганнар диярсең. Илүзә янына җыелышкан кызлар турысыннан үткәндә дә Фәрдәнә тәкәббер генә елмая да:

— Иптәш мастер ярдәмчесе, миңа кайтырга рөхсәт итәсезме? — ди. Елмаюын елмая, әмма кара күзләре балкышында барыбер гарьләнү күләгәсе чагылып куя.

Ә Илүзә борын чөеп, чәнечкеле мыскыллау сүзләре ыргытып киткән Фәрдәнәгә күтәрелеп тә карамый. Бары, аскы иренен авыртканчы тешләп, күкрәгендә күтәрелеп килгән ачу дулкынын гына басарга тырыша.

Тик Оля түзми, китеп баручы Фәрдәнәгә:

— Иптәш комсорг, бәлки сез аңлатырсыз, ни өчен минем машинаның җебе өзелә икән? — ди.

Фәрдәнә тукталып кала, елмаясы килмәсә дә елмаерга тырышып:

— Аңлатам, Олечка, һичшиксез, аңлатам,— ди.

Кызлар гөр килеп шаулашып ала:

— Башта син үзең өйрән, аннары...

— Үзең комсорг бит әле!..

Менә шул «үзе комсорг» дигән сүзне әйтмәсәләр иде. Бу сүздән соң Фәрдәнә һәр вакыт уенчак,ваемсыз кыз роленнән чыга. Күзләрендә зәһәр очкыннар кабына.

— Булса соң...

— Булса, шул, син кайчанга чаклы шулай йөрерсең?

— Ничек шулай?

— Менә шулай театр уйнап.

— Ә үзең нәрсә булдырасың соң?

Бу — Оляга әйтелә. Барлык кызлар да Оляны яклап тавыш күтәрә:

— Син Оляга сүз әйтмә! Оля булдырырга тырыша ул. Ә син кулыңнан килердәйне дә эшләмисең. Принцесса кебек биленә таянып йөрүдән эш чыкмый шул!

— Әй, вакыт әрәм итеп сезне тыңлап торганчы!.. — ди Фәрдәнә. Һәм, кызу-кызу атлап, класстан чыгып китә.

Илүзә күреп тора: Фәрдәнә көннән-көн группа кызларыннан читләшә бара. Ләкин ничек болай ук булып чыкты соң әле? Башта үзенең җыр-биюе, уен-көлкесе белән генә түгел, теория дәресләрен әйбәт үзләштерүе белән дә бар кызны үзенә караткан Фәрдәнәме бу? Инде

шул дәресләрне дә өнәми башлады, җыр-биюләр бөтенләй онытылды. (Хәер, бүтән кызлардан артта калган башың белән, җырлап-биеп йөрү килешмәс тә иде инде.) Бары йөрәгендә каты төен булып оешкан канәгатьсезлеген сиздермәскә тырышып, кемнәндер көлгән, барысын да уенга борган була. Тышка чыгармый, янәсе.

Фатирына кайтып барышлый Илүзә әнә шуларны уйлады.

Соңгы вакытта Илүзәнең Оля белән серләре килешә башлады. Менә бүген дә икәү кайта алар. Озак кына тып-тын бардылар. Оля да Илүзәчә уйлый икән. Бераздан ул:

— Ник болай кылана бу Фәрдәнә? — дигән сорау бирде.

— Горур бит...

Илүзә эчендәгесен әйтеп бетерми. Теге «Елочка»да Илсур белән Фәрдәнә икәүдән-икәү калган көннән башлап күңелендә элекке дустына карата ышанычсызлык хисе туды. Көнләшүдер бәлки? «Горур» диюендә дә әнә шул мәгънә ята. Ә Оля моны сизми. Чөнки ул әле көнләшү дигән нәрсәне белми шул.

— Горур? Нинди горур булсын ул. Горур булса, тырышыр иде бераз. Горур булса...

Оля туктап калды. Илүзә Оляның кичке ут яктысында яшькелт чаткылар чәчкән күзләренә карады.

— Нәрсә горур булса?

— Мин автобуста ничә мәртәбә күрдем. Нинди дер шалапай егетләр белән әвәрә килә. Тегеләре иләмсез кыланалар. Ә ул шуңа риза. Хәтта ачуы да чыкмый. Шул горурлык буламы?

— Ул бит егетләр. Ә бу эш...

— Нинди аермасы бар. Кеше һәр җирдә дә горур булырга тиеш, минемчә.

Оля аннары, «шулаймы?»* дигәндәй, Илүзәнең күзләренә карады. Ләкин Илүзә «шулай» димәде.

— Я, ник дәшмисең, Илүзә, дөрес әйтәмме?

— Дөрестер...

— Син сәер бүген.

— Әйдә, бу хакта бүтән сөйләшмик бүген, ярыймы?

— Ярый... Әйдә, йөгерәбез!..

Һәм алар җитәкләшкән көе төнге утлар җемелдәгән урам буйлап йөгереп киттеләр.

## ТУГЫЗЫНЧЫ ДУЛКЫН

Фәрдәнә көн саен диярлек яңадан-яңа «һөнәр» уйлап таба башлады.

Менә бүген дә... Ул хирург, имеш. Зифа гәүдәсенә ак халат киеп алган. Кайдандыр бераз спирт юнәткән дә, тегү әнәсен шуңа манчып, кызларның колак яфрагын тишә. Ярдәмчесе, ягъни ассистенты кем диген: әлеге дә баягы Зәкия. «Операция» ясалган биш кыз юан кәтүк җебе тагып куйган колак яфракларын, мөкиббән китеп, түгәрәк көзгедән карап утыралар. «Хирург»ның дизенфекциясе чамалы булган, күрәсең, Динә атлы кызның колак яфрагы эре бавырсак хәтле булып шешеп чыккан. Авырта да, ахры, кызарынып утыра кызый. Берни кылып булмый, тизрәк алка киясең килсә, түзәргә туры килә.

Хәрби дәрес укытучысы Кәрим Фәхриевич килеп кергәндә дә «операция» дәвам итә иде әле. Зәкия тизрәк Фәрдәнә янына — арткы

партага елышты. Соңгы көннәрдә Зәкия ни өчендер Фәрдәнәгә якынайды. Аларны үзара якынайткан нәрсә Зәкиянең теория дәресләрен яратмавы, ә Фәрдәнәнең барысына да төкереп карый башлавыннан иде бугай. Башка кызлар Фәрдәнә әйткәнгә исләре китмәс иде һәм колакларын аннан тиштерергә ризалык та бирмәс иде. Ә менә Зәкиягә карата алай түгел. Аның әйткәнен кызлар тыңлый. Дөресрәге, күбесе Зәкиянең ирләрчә каты кулыннан шүрли иде. Хәер, шүрләү генә Зәкия авторитеты өчен җитмәс иде, билгеле. Аның яхшы тегүче булуы кызлар алдында аны бәрмә-бер өстен итә. Фәрдәнә үзенең шул яңа «һөнәр»ләрен Зәкия аркылы эшли башлады да. Бүгенге колак «операциясе» ясауны оештыру эшен дә Зәкия үтәде. Ә Фәрдәнә дәрес буена «операция» кичергән кызларга консультация биреп утырды:

— Кулың белән тотма! Мамыкны марганцовкага манчып яраңа тидереп ал!

Кечкенә шешәле марганцовка кулдан-кулга күчә. Укытучы инде ничә мәртәбә Фәрдәнәгә кисәтү ясады. Ә Фәрдәнә исә ыжлап та бирми.

— Марганцовканы бетермәгез! Сез генә түгел монда...

Кәрим Фәхриевич тагы түзмәде:

— Фәрдәнә!

— Әү, абый.

— Я, әйт әле, зарарланган участоктан авыруны ничек алып чыгарсың?

Фәрдәнә тураеп бетә алмый. Бераз кыегайган килеш кала. Әйтерсең аның уң ягына капчыклы ком асып куйганнар.

— Нигә алып чыгарга ди аны, абый. Ятсын шунда, ял итсен...

Арттагы бер-ике кыз, учлары белән авызларын каплап, пырхылдап көлеп куялар. Ә укытучы Фәрдәнәнең юри кыланганын күреп торса да, сабырлыгын җуймый:

— Ничек ятсын?.. Зарарланучы ныграк агулансын өченме? Радиация зонасыннан тизрәк алып чыгарга кирәк аны.

— Бик дөрес, абый!

— Менә син аңа беренче ярдәмне ничек күрсәтерсең?

— Беренче ярдәм?

— Әйе!

Фәрдәнә белә, аның язмышы хәл ителгән инде. Бары икеле кую вакытын гына сузмакчы ул. Ләкин бу да аны туйдыра һәм ул «эшне» тизрәк тотар өчен:

— Әнә Илүзә беренче ярдәмне күрсәтәм, ди. Сорагыз, абый. Ул оста! — ди.

— Һе, ул сөйләр. Өйрәнмәдең, димәк. «Начар» билгесе куярга туры килә.

— Абый, куйма инде!

— Бу юлы нокта куеп торам. Икенче юлы кара аны!

Утырып күп тә үтми, Фәрдәнә тарагын өстәл кырына чатыр-чытыр ышкый башлый.

— Кайсыгыз ул?

— Шкаф артында тычкан йөри. Икенче килгәндә мәче алып килимме, абый?

Фәрдәнәнең бу «тапкырлы»гы өчен журналдагы нокта «икеле»гә әйләнә.

...Илүзә еш кына группадагы хәлләр хакында уйланып йөри. Наилә Хәбировнаның үз дәресендә берсе дә кыймылдарга базмый базуын. Аннан шүрлиләр шул. Стипендиядән коры калдырса... Ә калган дәресләрдә кыланып карарга була. Нишли ала ул укытучылар. Ачу-

ланганнан гына кай жирең кими. Их, бу Фәрдәнә... Яхшылыкның кадерен белмәү шулдыр инде. Зәкия... Кызлар аңа каршы сүз әйтмиләр. Шулай ук куркалар микәнни? Әгәр кызлар каршына чыгып: «Кайчанга чаклы алар аркасында безгә кызарып йөрергә соң!» дисәң... Юк, юк, куштан, ялагай диярләр... Тукта... әгәр шимбә көнне кызлар белән чаңгы шуарга чыксак... Шунда сөйләшсәк...

— Оля, Оля!

— Нәрсә инде?.. дип мыгырдана бик бирелеп нидер язып утырган Оля.

— Оля, әйдә иртәгә чаңгы шуарга Аккош күленә барабыз.

— Чаңгы шуарга?

— Әйе. Барабыз яме!

— Ярар.

Ә икенче көнне дәрестә «ЧП» булды. Җәмгыять белеме дәресе бара иде. Гадәттә малайлар үлеп ярата торган «политика» дәресенә кызларның артык исе китми. Группадагы бердәнбер малай булган әлеге бөдрә чәчле Вагыйзның да иң яраткан дәресе бу. Дәресне өйрәнми килгән көнне кызлар шул Вагыйзга ялына инде.

— Вагыйз, кул күтәреп сөйлә инде бүген, ә?

Вагыйз ялындыра:

— Элекке дәрестә генә сөйләдем бит әле.

Фәрдәнә барысыннан да уздыра:

— Үзеңне бер үбәрмен.

Вагыйз комачтай була. Үзе янына җыйналган кызлардан котылу өчен генә:

— Ярар, ярар, сөйләрмен — дип, авыз эченнән ботка пешереп ала.

— Менә, рәхмәт!

Фәрдәнә, ике бармагын чиядәй иренәнә тидереп үпкәндәй итә дә, шул үбүен Вагыйз янына «очырып» җибәрә:

— М-мм-ма!..

Дәрес буена Вагыйз гына сөйли. Менә ул бүген дә плюс «5» ле алды.

— Ә кызлар? — дип сорый укытучы, журналдан башын күтәреп.

Кызларның үз эше. Һәркайсының кулында — кайчы. Сары төстәге калын кәгазьдән кызлар өчен яңа чыгачак күлмәк модасының өлгесен кисәләр. Конструкцияләү укытучысы Ольга Васильевна өйдә эшләргә кушкан иде аны. Күбесе оныткан. Килгәч кенә исләренә төшкән. Китапханәдән «Модалар» журналы эләктереп чыкканнар да эшкә тотынганнар менә.

— Кызлар танцыга йөрер өчен күлмәк әзерлиләр! — дип шаяра Фәрдәнә.

Кызлар ялт кына өлгеләрен өстәл астына яшерәләр.

— Дежурный!

— Мин.

— Яле, барысының да шул кәгазь кисәкләрен җыеп миңа бир!

— Абый? — дип ялына кызлар.

Ләкин абыйлары — мәрхәмәтсез. Өлгеләр укытучы өстәле өстенә өелә.

Менә шуннан соң Ольга Васильевнадан эләгә инде кызларга. Дәрес буе берәм-берәм бастырып тиргәү генә җитми, дәрестән соң калдырып шул күлмәк өлгесен ясаттыра ул алардан.

Аккош күлендәге чаңгы юллары кызларны сагынып көткәндерме-юкмы, әмма бу көнне кызлар кар бураны туздырып таулардан шуу турында онытты лар. Алар мышный-мышный яңа мода өлгесе кисә иделәр.

## УНЫНЧЫ ДУЛКЫН

Ә ял көнне «Аккош күле»нә кызлар килмәде. Илүзә белән Оля мамык мендәрдәй өер-өер карларны көчкә күтәреп торган чыршы кәүсәләре янында бик озак таптандылар. Яңа салынган чаңгы эзләре буйлап әрле-бирле йөренеп тә карадылар. Бары шактый озак көткәч кенә салпы канатларын төрле якка җәеп утырган чыршылар арасыннан җилдереп Вагыйз килеп чыкты...

— Кызлар килмәдемени әле?

— Ә син үзең ник соңга калдың?

— М-мин... ни... күптән килдем инде...

— Ничек күптән?..

— Мин ни... шунда гына шуып йөрдем.

Вагыйз тотлыкты, каушады. Илүзәнең күзләренә күтәрелеп карарга кыймыйча, чаңгы таягы белән карда нинди дә рәсемнәр сызгалады.

Вагыйзның кар өстенә ясаган рәсеменә игътибар белән текәлеп торучы Оля, бөтен урманны яңгыратып:

— Кара әле, нинди кош ясаган! — дип кычкырып җибәрде.

Бу рәсемне күргә Илүзәнең дә исе китте:

— Вагыйз, син рәссам икән ич!

— Юк ла... Мин болай гына, — диде Вагыйз, чаңгы таягы белән үзе ясаган сурәтне тиз-тиз бозгалап.

— И, ник боздың инде, нинди матур кош иде.

Кинәт Вагыйз дәртләнеп китте:

— Телисезме, тагы ясыйм!..

Кызларның җавабын да көтмичә, Вагыйз кар өстенә тукран рәсеме ясады.

— Нинди матур! — дип сөенделәр кызлар.

Шуның артыннан ук Вагыйз көлтә койрыклы төлке сурәте ясап куйды. Аннан куян, аю...

Бераздан Вагыйз, башын күтәреп, нур балкыган күзләре белән кызларга карап торды. Аның күз карашы әйтерсең: «Сезгә кечкенә генә булса да сөенеч китерүем белән бәхетле мин», — дия иде.

— Зур рәхмәт сиңа! — диде Илүзә.

— Үзеңә рәхмәт!

— Ни өчен? — дип гаҗәпләнде Илүзә.

— Ни өченме? — Вагыйзның борын очына тикле кып-кызыл булды,— ни... минем рәсемемне ошатканың өчен... Аннан... Аннан.

Егет Илүзәнең тегәргә өйрәтүдәге ярдәме һәм тагы үзеннән көлмәве өчен дә рәхмәт әйтергә теләгәндер бәлки. Чөнки һәр эшне төгәл үтәп баручы бу оялчан һәм юаш егеткә күп кенә кызлар ничектер шаяртып карый иде.

Класста берәрсе кара тактага килделе-киттеле сүзләр язганнан соң, укытучы кереп:

— Кем эше? — дип сораса, шаян кызлар:

— Әнә Вагыйз язды,— диләр.

Вагыйз соры күзләрен шардай ачып ни әйтергә белми торган арада, укытучы аны шелтәләргә дә өлгерә:

— Яхшы түгел, үзең әйбәт кенә егет күренәсең, ә җыен тузга язмаган сүзләр белән кара тактаны пычраткансың, — ди. Вагыйз ни эшләсен, кызарына-бүртенә, әмма «алар ялганлый» дип әйтә алмый.

Ә чая кызлар: «Син мине яратасыңмы? Үбә беләсеңме?» — дип, бичара егетнең теңкәсенә тияләр. Мондый усал шаяруга Илүзә үзе кушылмый гына түгел, кызларны да әрли:

— Җитәрегез инде! Кызлар булыгыз азрак...

Кызларның да җавабы әзер:

— Ул да егет була белсен!..

Ә бүген чынлап та егетлеген күрсәтә белде Вагыйз: әле баш әйләнерлек текә таулардан бөркеттәй түбәнгә ыргылды, әле шул тау битләрендә киртләч-киртләч чаңгы эзләре калдырып, өскә үрләде...

Ә шулай да яшьләрнең күңелләре тыныч түгел, яшьләргә нидер җитми иде... Ни әйтсәң дә, алар монда өчәү генә шул. Ә бүтән кызлар кайда соң?..

Икенче көнне үк группада зур сөйләшү булды. Беренче булып Илүзә сүз алды:

— Я, урманга барабыз дип, үзегез вәгъдә бирмәдегезме? Нигә алдарга иде, ә?..

Аның ике бит алмасы дулкынланудан уттай яна, тавышы вакыт-вакыт өзелеп кала иде.

— Я, ник җавап бирмисез?

«Минем дәресем хәзерләнеп бетмәгән иде», — дип акланды берсе, ә икенчесе «әни җибәрмәде» дип котылып калмакчы булды. Һәркайсы сәбәп тапты. Бары Зәкия белән Фәрдәнә генә акланып маташмады. Зәкиясе: «Чаңгы шуып йөрергә мин бала-чага түгел, слушай», — дисә, Фәрдәнә турыдан-туры: «Барасым килмәде», — дип җавап бирде.

Илүзә:

— Их, сез, училищеда укыган елыбызны ни белән искә алырбыз соң?! — диде дә, кызу-кызу атлап, урынына барып утырды.

Оля Фәрдәнәне гаепләп сөйләде:

— Бу эшләрнең барысын да комсорг оештырып йөрергә тиеш иде. Ә ул нишли: «Барасы килмәде», имеш. Катнашмавың гына җитмәгән, читтән генә бездән көлеп йөрисең бит син!

Фәрдәнә гаҗәпләнгән булып:

— Кем? Минме? — дип мыгырданды.

— Син түгел — Фәрдәнә!

— Әйтерең юк.

— Зәкия шуңа иярә бит тагы...

Бу сүзләрдән соң Закия чәчрәп чыгып:

— Әй, син, слушай, минем белән авыз чайкама, яме! Нишләргә кирәген синнән сорамам, — дип әйтеп куйды.

— Кемнән сорарсың? Наилә Хәбировна да рәхмәт әйтмәс.

— Әйтмәсә тагы.

Кызлар шаулаштылар-шаулаштылар да шундый карарга килделәр:

1. Группада үрнәк дуслык һәм татулык булдырырга.
2. Диспутлар, кичәләр оештырырга, театрга культпоход ясарга.
3. Фәрдәнәнең комсорглык вазифасын ничек үтәвен тикшерүне комсомол комитетыннан сорарга.

## УНБЕРЕНЧЕ ДУЛКЫН

Соңгы вакытта Илүзәнең әнисеннән бер-бер артлы өч хат килде. Ул хатлардан аңлашылганча, әтисе башта төзелешкә гади ташчы булып урнашкан булган. Ә соңга таба Галия апаны Казагыстан ягына барырга өнди башлаган. Галия апа күнмәгән. Шуннан соң араларына яңадан кара песи үткән, ахры, ачуланышканнар. Һәм әти кеше элек эшләгән җиренә китеп барган.

«Әни берүзе калган икән, — дип борчылып йөрде Илүзә. — Ичмасам, хәзер әби дә юк».

Уку мәшәкатьләре белән Илүзә әбисен бераз онытып торгандай иде. Менә хәзер, каникулга кайту вакыты якынлашканда, әбисенең мөлаем, сабыр йөзе яңадан Илүзәнең күз алдына килеп басты. Сагынырсың да. Балалык гомеренең күп өлешен әбисе белән шул Кирәм

авылында үткәрде бит Илүзә. Утыз гына йортлы авыл ул. Ә үзе нинди гүзәл табигать почмагында урнашкан. Урман. Тирәсендә җиләкле тугайлыклар...

Сарыклары кайтмаган көннәрне Мәрфуга әби, инде җиргә эңгер кунаклагач, Илүзәне ияртеп сарык эзләргә чыга торган иде. Томан сарган Кичүле елгасы буйлап, дымсу һаваны күкрәгең тутырып сулый-сулый, салкынча үлән өстеннән тәпили бирәсең.

— Минем күзем аермый, нинди карамчык анда, кызым, безнең кара сарык түгелме? — дип, атлаган саен Илүзәдән сораштырып бара иде Мәрфуга әби.

Әнә шул хатирәләр ничектер күңелле дә, моңсу да. Никтер елыйсыны китерә.

Менә Илүзәнең күз алдына әбисенең соңгы сәгатьләре килеп басты. Калтырана-калтырана чигү чиккән бармаклары, чигүлектәге сурәтләр... «Ни дип кайтты бу эти? Әби үлмәс иде бәлки»... Нигә болай уйландыра соң әле? Илүзә башындагы күңелсез уйларны көчләп куарга тырышты. Ләкин болары урынына бүтәннәре ябырылып килде.

Илсур... Ничә көннәр күрмәде инде аны Илүзә. «Елочка»да булган теге хәлдән соң Илүзә аннан качып йөри... Ихтимал, Илсур бүтән килмәс тә... Илүзә чемоданын актара башлады. Шунда салып куйган курткасын кире алды. «Нигә монда салдым соң аны?» Шушы курткаными болонья плащыннан үзе теккән иде ул. Илүзәгә ияреп, группадагы алты-җиде кыз да шулай эшләде. Илүзә, чемоданын япты да, тәрәзәгә килде. Тагын Илсур исенә төште. «Килмәсә тагы, бик кирәге бар! Берәр атнадан өйдә булырмын... Бары да онытылыр». Ләкин ник эче поша соң аның? «Бүтән берни уйламыйм, бетте-китте», — диде ул үз-үзенә. Дәрестән соң калып, үзе теккән күлмәген иңенә үлчәп карады. Биле нечкә, озын итәкле. «Мондый күлмәкне әби дә ярата иде». Бүген менә, шул күлмәкне киеп, «Су анасы» балетын карарга бармакчы Илүзә.

Төргәк күтәреп Оля килеп керде.

— Кайда Фәрдәнә?

— Икенче көн кайтканы юк инде... Ой, Олечка, синең күлмәк матуррак!

— Кит әле, кая инде ул синекенә җиту!

Алар шулай бер-берсенең күлмәген макташтылар. Ләкин һәр иксе дә эченнән генә: «Минеке әйбәтрәк, билгеле», — дип уйлый иде.

...Училище. Кызлар барысы да чәчәктәй киенгән бүген. Кабарынкы итәкле ак күлмәк кигән Илүзә залда йөргәндә күлдә йөзгән аккошка охшый. Оля авызын япмыйча мәзәкләр сөйли. Хәтта Фәрдәнәгә дә җан кергән: елмайгандай итә. Кыскасы, кызлар чәчәк ата бүген.

Ләкин дәрес бетүгә, Наилә Хәбировна керде дә кызларның бу сөенечен чәлпәрәмә китерде:

— Кызларым, цехтан сишәмбегә күлмәкләрне өлгертеп тапшырырга куштылар. Без дүшәмбе көнне генә тегеп өлгерә алмыйбыз бит. Бүгенгә балет карарга туры килмәс...

Наилә Хәбировна чыгып китүгә кызлар шаулаша башлады:

— Нәрсә инде бу, ә?

— Һаман эш тә эш буламы? Бер дә күңел ачарга димәгән икән безгә...

Бигрәк тә Фәрдәнә очынды:

— Кызлар, беребез дә эшләмибез, сүз бер булсын!

Группа старостасы аңа каршы төшмәкче иде, Фәрдәнә:

— Ә син куштанланма! — дип, аның авызын тиз томалады.

Илүзә дә, «куштан» сүзен ишетмәс өчен, авыз ачмый калды.

Шулай килеп чыкты, кызлар Фәрдәнәгә иярде.

Наилә Хәбировна кергәндә мастерскойда гомердә булмаган тынлык иде. Кызларның башы аска иелгән. Бары берничәсе, шул исәптән Фәрдәнә дә, мастерга туп-туры карап утыра.

Наилә Хәбировна гаҗәпләнеп сорады:

— Ни булды, кызлар?

Кызлар дәшмәде.

— Гаҗәп, — дип сузып куйды Наилә Хәбировна, — ләкин мин сезне аңлыйм. Шунсыз булмый бит, кызлар. Үзегез эшләячәк фабриканың интересы белән исәпләшми һич ярамый... — һәм мастер ягымлы итеп елмайды:

— Ә балетны икенче атнага һичшиксез караячакбыз. Тыныч күңел белән... Ә хәзер эшкә тотындык.

Беркем дә кузгалмады. Башлар ничек иелгән булса, шул килеш калды. Наилә Хәбировна бөтенләй аптырады. Аның мондый хәлгә беркайчан да юлыкканы юк иде әле.

— Менә сиңа мә, — диде ул, ни әйтергә белмичә, — кызларым минем сүземә колак салмый.

Бүген Зәкия укуга килмәгән иде. Ул булса Фәрдәнәгә: «Төкерәм мин синең сүзеңә!» — дияр иде. Практика дәресләрендә ул Фәрдәнә белән исәпләшеп тормый. Каршы әйтеп маташса, шактый саллы йодрыгын тәти кызның борын төбенә китереп терәргә дә күп сорамый.

Ә Илүзә машина табаны астында ятучы кызгылт чәчәкле зәңгәрсу күлмәккә текәлгән. Бары итәк очын гына тегеп бетерәсе дә сырлагыч машинада борылмалы җөйләр ясыйсы... Шуларны эшләп чыкса, фабрика заказы буенча тегелгән кызлар күлмәге әзер булачак! Гомерендә беренче мәртәбә кешеләр өчен!..

Наилә Хәбировна нишләргә белми. Әле бер кызга дәшә, әле икенчесенә. Илүзәгә Наилә Хәбировна кызганыч булып тоелды. Инде ярты ел буе үзләрен һөнәргә өйрәткән иң якын кешеңә хыянәт итү кебек була ич бу. Наилә Хәбировна ярдәмчел, ягымлы булганы өчен рәхмәт белдерәбезме шулай?!. Ә эшли башласа, кызлар ни әйтер? Куштан диярләр. Юк, юк, бу хурлыклы сүзне ишеткәнче...

— Илүзә!..

Илүзә сискәнеп китте. Наилә Хәбировна аңа эндәшкән иде. Илүзә кузгалып куйды. Ә башында буталчык уйлар берсен-берсе кысрыклый: «Куштан... куштан... Наилә Хәбировна нинди ягымлы... Ачуланмый, тузынмый... Фабрика өчен иң беренче күлмәк бит, иң беренче!»

Кинәт Илүзә машинасы гөлдерәп эшләп җибәрде. Илүзә күз кырые белән Фәрдәнә күзләрендәге усал очкыннарны күреп калды.

Кызлар әйтерсең башлап җибәрүне генә көткәннәр: тагы бер минуттан барлык машиналар да тигез гүли иде инде.

Инде шактый тыңлаучан булып бара торган машинасы да, бөтен тырышлыгын, йөрәк җылысын биреп тегеп бетереп килә торган күлмәге дә Илүзәгә бик үз, бик кадерле тоелды бу мизгелдә. Ул аларның барысыннан, Наилә Хәбировнадан гафу үтенер иде. Елый-елый гафу үтенер иде.

Ләкин Наилә Хәбировна кызлар күзеннән тәгәрәп төшкән саф энҗе бөртекләренең иреннәрдән чыккан гафу сүзеннән кыйммәтрәк икәнен аңлады һәм аларны кичерде.

...Илүзә училищеда кичке дежурда булганга, соң гына кайтырга чыкты. Әле генә яңгырлы кар явып киткән. Һава дымлы һәм салкынча. Уйсурак урыннарда хәтта су да җыелган. Электр уты яктысында бихисап күп энҗе бөртекләредәй җемелдәгән бозлавык тротуарга карап, уйланып барганда, кинәт аның каршысына Илсур белән Фәрдәнә килеп чыкты. Илүзә үз күзләренә үзе ышанмый торды: Илсур Фәрдә-

нәнең биленнән кочаклаган иде. Илүзә күрмәмешкә салышып узып та китмәкче булган иде, ләкин Фәрдәнә аның каршына төште.

— Дустым, ашыкма алай, — ул мыскыллы елмаеп куйды. — Ә... Наилә Хәбировнага бүләк алырга йөгергәнсеңдер әле. Иртәгә аның туган көне диләр бит. Тырыш, дустым, тырыш, отличница булырсың!

Илүзәнең тыны кысылды.

— Кит юлдан!

Ләкин Фәрдәнә мәсхәрәле тонда дәвам итте:

— Бүгенге тырышлыгыңны да искә алмый калмас... Молодец!

Фәрдәнәнең шалкандай ак яңагына сугып җибәрүен Илүзә үзе дә белештерми калды. Юк, элекке дустының аны хурлап әйткән сүзләре генә сәбәп булмады моңа. Юри мыскыллагандай, Илсур белән култыклашып басып торуы һәм, ниһаять, шушы мизгелдәге мәсхәрә — менә шулар барысы бергә җыйналып, Фәрдәнәнең яңагына эз салды.

Бу минутта Фәрдәнәнең илереп елап җибәрүе дә Илүзәнең аңа селтәнүеннән генә түгел иде. Ул селтәнү моңарчы җыелып килгән җан ризасызлыгының тышка ургылып чыгуына ярдәм генә итте.

Кара-каршы бәрелешкән бу ике кызның шушы халәтен Илсур үзенчә аңлады, ахры, ул Илүзә янына килеп:

— Я, нигә инде периферияның бер кыргые төсле кыланасың? Ни... мин... ул... ул просто шаяргандыр...

Шул сүзләр белән Илсур Илүзәнең иңенә кагылмакчы иде. Ләкин Илүзә аны җан ачысы белән этеп җибәрде:

— Кит! Күрәсем килми!..

Илсур, барыбер әрсезләнеп, Илүзәнең биленнән эләктереп алды:

— Илүзә, Илүзә, я инде... юләрләнмә.

Илүзәнең күкрәгендә нидер актарылды, үксеп-үксеп елыйсы килде. Ул шашынган бер көч белән Илсурдан ычкынырга омтылды:

— Кит, дим!!

Шуннан соң нәрсә булганын берәү дә аңламый калды. Минутның кайсыдыр өлешендә Илсур пычрак сулы күлдәвеккә егылып китте.

Илүзә күтәрелеп караганда, аның каршында башын иеп Вагыйз басып тора иде.

— Гафу ит, — дип пышылдады егет, — гафу ит...

— Вагыйз?

— Мин ни...

Шул ара судан күтәрелгән Илсур ярсып-ярсып сүгенергә тотынды:

— Ах, син, хулиган! Моның өчен беләсеңме мин сине!..

Илүзә:

— Туктагыз әле! — дип кычкырды. — Вагыйз, бу ни эшең, ә?

— Мин түзмәдем. Ник ул сине рәнҗетә...

Илсур ачудан, гарьләнүдән буылды:

— Әһә, димәк, бу синең...

Илүзәнең җанында әллә ничә төр тойгы бутала иде. Бер яктан, Илсурга үпкәсе әле басылмаган, басылырмы-юкмы — анысы да билгесез, икенче яктан, йөрәк төбеннән аңа карата ниндидер аңлаешсыз кызгану хисе кузгалып килә:

— Илсур, син нәрсә?.. Ой, минем башым каткан шул.

— Шулаймы? Ну, Илүзә, үкенерсең, ләкин соң булыр!.. Ә синең белән, малай актыгы, сөйләшербез әле!.. Хушыгыз!

Илсур кинәт борылды да китеп барды. Фәрдәнә дә аңа иярде.

Илүзә, ни үле, ни тере килеш, торган җирендә басып калды. Ә Вагыйз, хәленнән килгәнчә, Илүзәне юатырга тырышты:

— Зинһар ачуланма инде, Илүзә... Мин бит...

— Син шул, син. Сез барыгыз да...

— Ул сине рәнҗетте бит. Шуңа мин түзмәдем...

— Рәнҗетте?

— Хәер, белмим. Бәлки миңа кирәкмәс иде... Гафу ит... Мин... Мин — юньсез... Мин бит һәр вакыт сине озатып йөрдем...

Илүзә башын күтәрде:

— Ничек озатып йөрдең?

— Ә син ачуланма... Мин ни... Ленин китапханәсендә синең артта гына утырдым. Син китап алып килгәндә дә карап тордым. Әйтимме, нинди китап алдың?

— Әйт.

— Эстетика китабы.

— Әйе. Ә мин сине күрмәдем.

— Мин сине озатып та кайттым әле. Юк, юк, син күрмәдең. Мин бик артта идем. Менә бүген дә... Син мине ачуланма зинһар... Түзә алмадым.

Илүзә егеткә күтәрелеп карады:

— Бар кайт, Вагыйз, кайт...

— Кайтыйммы? Бәлки...

— Кайт син...

— Кайтам, алайса... Ләкин бу синдә калсын...

Вагыйз, эчке кесәсеннән калын кәгазьгә ясалган яшь кыз портреты алып Илүзәгә бирде һәм, артына бүтән әйләнеп карамыйча, йөгереп диярлек китеп барды.

Рәсемдә шактый охшатып Илүзәнең үз портреты ясалган иде. Илүзә, бакча рәшәткәсенә сөялгән килеш, шул рәсемгә озак кына карап торды.

## УНИКЕНЧЕ ДУЛКЫН

Соңгы көннәрдә бозлавыкка әйләнгән аяк астын бүген мамык кар каплаган. Ак кар җәймәсенә беренче эзләрен төшереп ике кыз атлый. Кызларның аяк атлавында һәр вакыт төгәллек, гармония була. Тигез ритмлы җырдай була ул. Шагыйрь юкка гына:

Уйнап очкан акчарлактай
Син барасың уйнаклап ла,
Җилфердәп, вак-вак атлап,

— дип җырламагандыр.

Бу ике кыз — Илүзә белән Оля. Теге хәлләрдән соң Фәрдәнә Илүзә янына кайтмады. Бу фатирга Оля күчеп килгән иде. Алар хәзер училищега һәр вакыт бергә йөриләр. Ә бүген ак кар җемелдәвеннән кысыла төшкән күзләрендә көтелгән шатлыкның көләч чаткылары бии. Чөнки алар бүген иң беренче эшләрен контроль-мастерга тапшырачаклар.

Менә кызлар училище мастерскоена да җиттеләр. Утырыштылар. Наилә Хәбировна да дукынлана, күрәсең — сүзен башларга кыймыйчарак тора. Яшәреп киткәндәй күренә ул бүген. Ә кызлары тып-тын утырсалар да, алсуланган бит алмалары, күзләренең яктылык сирпүе аларның киеренке эчке халәте хакында сөйли. Монда борчылу да, шатлык та җитәрлек. Борчылу шуннан — контроль-мастер нәрсә әйтер бит, синең күз карасыдай күргән продукцияне нинди сорт белән кабул итәр. Ә шатлыкның ни өчен икәне билгеле инде: ни әйтсәң дә, беренче әйбер һәр вакыт иң кадерле була.

Ләкин әле соңгы эшләр бар: төймә тагу, бирка беркетү. Хәер, монысы соңыннан...

Менә кызлар эшкә тотынды. Кайчы чикылдаган тавыш, машиналар гөрелдәве... Чү, нәрсә бу? Илүзәнең машинасы чатыр-чотыр итте дә туктап калды. Анысын борды Илүзә, монысын борды — юк, машина эшләми. Ул борчылып як-ягына каранды. Анда тагы бер-ике кыз ашыгып-каушап машиналарын эшләтеп җибәрергә азаплана иде.

Наилә Хәбировна йөгереп килеп җитте. Ни булды икән соң? Башкалардан калышмаска, планны вакытында үтәргә кирәк бит! Фәрдәнәнең дә машинасы эшләми икән. Ләкин ул, һәр вакыттагыча, әллә ни кабаланмый.

Механик Галимә Шагиевнаны чакырдылар. Ул машинаны боргалап бакты да сүтеп карамый булмый диде.

Кызларның бәхетләләре башын да күтәрми эшли. Әнә, Зәкия теге беттергән күлмәген мастер янына алып та килә инде. Ә Илүзә сүтелеп ташланган машина янында кайнаша.

— Энә!

Әйе, машина эченнән кәкрәеп беткән энә килеп чыкты.

— Машина эченә энә салганнар!

Шик тә юк, бу усал ният белән эшләнгән эш иде. Ялгышлык белән генә булса, бары бер машина белән шундый хәл килеп чыгарга мөмкин, ә монда — биш машина шулай бозылган.

Дәресләр беткәч, Наилә Хәбировна кызларны класс бүлмәсенә җыйды.

— Кем эше бу?..

Һәр вакыт мөлаем йөзле Наилә Хәбировна кызды:

— Мондый хәлнең училище тарихында булганы юк. Хурлык! Шул бер намуссыз җан аркасында без продукцияне срогына тапшыра алмадык. — Ул, тагы да ярсый төшеп, өстәлгә дә сугып алды. — Галимә Шагиевнада ни ачуыгыз булды? Ни өчен ул сезнең аркада көне буе җәфа чигәргә тиеш? Мин сездән сорыйм!

Беркем бер сүз дәшмәде. Наилә Хәбировна Фәрдәнәгә мөрәҗәгать итте:

— Яле, комсорг, чык бире, ачыклагыз, кем эше бу?

Фәрдәнәнең бөтенләй төсе калмаган. Ул иренеп кенә алга чыкты. Башын тәрәзәгә борып басып торуында булды. Бер-ике минут шулай тын үтте. Наилә Хәбировна түзмәде:

— Шулай кичкә чаклы утырабызмы? Я?

Фәрдәнә яңа йокыдан уянган кеше төсле:

— Ә?.. — дип куйды.

Кызлар Фәрдәнәгә өметсезләнеп карадылар. Аларның карашы: «Аннан ни көтәсең инде», — дигәнне аңлата иде.

Наилә Хәбировна яңадан алга чыкты.

— Ярар, — диде ул, йомгак ясагандай итеп, — болай итәбез, бүген дежур Зәкияме?

Зәкия торып басты.

— Мин.

— Менә син карамагансың. Син җавабын да бирерсең. А то комсорг берни белми, ә дежурный берни карамый. Бу ни дигән эш!

Зәкия капылт кына торды да бер сүз әйтми алга үтте.

— Ник мин җавап бирим ди? Кемдер машинаны ваткан, мин җавап биримме?

— Ә кем җавап бирсен, синеңчә, кем?

Алгы рәттән Оля тавышы яңгырады:

— Кем эшләргә яратмый, кем һәр вакыт тик утыра — шул бирсен җавапны!

Бар да Фәрдәнә ягына карады.

— Нәрсә миңа карыйсыз? Әллә мин...

Берничә кыз дәррәү сөрән салды:

— Кем булсын?!

Ниһаять, Фәрдәнә түзмәде, чәрелдәп кычкырырга тотынды:

— Мин, мин!.. Чөнки эшлисем килми минем! Яратмыйм!!.

Шушы җыелышта кызлар Фәрдәнәне комсорглыктан төшерергә карар чыгардылар. Комсорг итеп Илүзә сайланды.

## УНӨЧЕНЧЕ ДУЛКЫН

Яңа ел кичәсенә Фәрдәнә танымаслык булып буянып һәм бизәнеп-ясанып килде. Үзе белән чуар пальтосын иләмсез зур прәшкәле каеш белән буган бер егет тә ияртеп килгән иде.

Ләкин башка кызлар үз дөньясы белән мәшгуль бүген. Бу — сөенеч дөньясы. Шатлыклы дулкынланудан битләр алсуланган, күзләр — көләч.

Яңа ел алдының тантаналы минутлары гына микән кызлардагы бу нәфис үзгәрешкә сәбәп? Әллә мең төрле ялтыравыклы бизәкләр белән бизәлгән яшел чыршы кызларны шулай сихерләгән микән? Әллә хикмәт бу кичәгә танк училищесыннан килгән егетләрдә идеме? Хәер, ничек кенә булмасын, болар барысы да Яңа ел кичәсен тагын да матурлый, аның тантаналы серлелеген тагын да арттыра гына иде.

Училище директоры Хәлимә Сабировнаның да йөзе шат, сөйләве дә гадәттәгечә таләпчән һәм кырыс түгел, йомшак һәм ягымлы. Менә ул кичәгә килгән кызларны, егетләрне Яңа ел белән тәбрикләде. Аларга уңышлар, бәхет теләде. Аны хуплап, озаклап кул чаптылар... Әнә Кыш бабай. Бүләкләр алып килгән ул. Кызларга бүләк өләшә.

Җыр-биюләр, төрле уеннар башлана.

Кичәгә Илсур да килгән. Ул ап-ак күлмәк, кара галстуктан. Илүзәгә бертуктаусыз төрле мәзәкләр сөйли. Әйтерсең алар арасында берни дә булмаган. Ә Илүзәгә Илсурның сөйләгәне ясалма төсле... Әйе, нәрсәдер үзгәрде... Ләкин нәрсә? Монысын Илүзә үзе дә бик үк ачык итеп аңлата алмый әле...

Илсурның кулы кагылуга Илүзә сискәнеп китте.

— Бәлки без дә?..

Илүзә Илсурга күтәрелеп карады. Зур коңгырт күзләр ялварып карый... Илүзә күз керфекләрен шунда ук төшерде. Янәшәндә генә янган шул коңгырт күзләр кайнарлыгын күтәреп кара син... һәм шушындый кичәдә, бөтен кызлар вальс биегәндә берүзең түзеп торып кара...

Илүзә бөтерелеп әйләнеп китүен сизми дә калды. Соң бүген караңгы чырайлы булырга ярыймы инде! Моны башка китерергә дә мөмкин түгел...

Хәер, мөмкин икән. Илүзәләр янына Фәрдәнә очып килде дә кулларын чапылдатты һәм Илсурны Илүзәдән аерып алып, аның белән әйләнеп тә китте. Әнә үзе Илсурга нидер сөйли, үзе көлә. Илсур да Фәрдәнәгә кушылып көлә. Икенче биюдә Илүзә Илсур үз янына килер дип көткән иде... Ләкин ул килмәде. Фәрдәнә белән биеде. Илүзәнең йөрәге сыкранды. Бу сыкрану бөтен күкрәген тутырды, һава җитмәгәндәй тоелды аңа. Һәм ул йөгереп вестибюльгә чыкты. Каршысына очраган кешеләр барысы да аның хәлен белә һәм барысы да аннан көләләр шикелле тоелды аңа. Кием элгеченнән ничек пальтосын алып, ничек киенгәнен үзе дә хәтерләми Илүзә. Бары карлы урам буйлап йөгереп барганда гына кинәт исенә килеп, шып туктап калды ул: «Тукта, ник йөгерәм соң әле мин, ник кичәдән киттем?»

Хәер, бу сорауга ул ничек өзеп кенә җавап бирсен... Бик күп «ник»ләре җавапсыз калыр чаклары ла Илүзәнең...

*

* *

Ә иртәгесен Илүзә Түбән Камага самолет белән очар өчен аэропортка килде. Аны Оля озата барды. Вакыт иртә иде әле. Алар ыжгырып биеклеккә күтәрелүче һава лайнерларын шактый озак күзәттеләр. Кинәт Илүзәгә үз исемен дәшкәндәй тоелды. Ул ялт кына артына әйләнеп карады һәм Илсурны күрде.

Дөресен генә әйткәндә, кичә бик хәтере калган булса да, Илүзә Илсурны күңеле белән көтә иде. Ләкин менә хәзер, егетне күргәч, ул Оляны култыклап алды да:

— Әйдә, моннан китик,— дип, аэропортның икенче ягына юнәлде. Саклау камералары янына барып туктагач та, Илүзә үзенең артында Илсурның карашын тоеп торды. Ләкин, бөтен ихтыяр көчен җыеп, бер мәртәбә дә артка борылып карамады. Бары самолет җирдән аерылганда гына аның аэропорт рәшәткәсенә ябышып торганын күреп калды ул.



## УНДҮРТЕНЧЕ ДУЛКЫН

Илүзәләрнең өй эчен бүтәннәрнекеннән аерып торган нәрсә — чигүле пәрдә һәм кашагаларның күп булуы. Төрле-төрле чәчәк чигелгән өлгеләр стенага да кыеклап беркетелгән. Заманча ук булып бетмәсә дә, Галия апа аларны Мәрфуга әби төсе итеп саклый. Илүзә киткәннән бирле өйдә нәрсә үзгәргән соң? Үзгәреш бар. Әбисенең киемнәре күренми. Алар Мәрфуга әби сандыгына салынып, нафталинлап куелган. Иң күзгә ташланганы шул: әтисенең тирәүле рамга куелган фотосы өстәл өстендә тора. Илүзәнең күзе әледән-әле шул сурәткә төшүен Галия апа сизде, ахры, кичке якта бу хакта үзе сүз кузгатты:

— Әтиең начар кеше булмады, кызым. Шуңа рәсемен куйдым өстәлгә... Их, язмыш, ул сиңа өлешеңә тигән көмешеңне бирә икән дә, шөкер итмәсәң, сине бу дөньяда бер ялгызыңны гына яшәтеп калдыра икән... Әнә атаң да башкага өйләнгән булган да бит, тормышы барып чыкмаган... Син, кызым, мине битәрләмә инде. Алдап килгән дип ачуланма...

Галия апаның күңеле йомшады, күзеннән яшь бөртекләре тәгәрәде. Ә Илүзә бер сүз дәшми утыра бирде.

— Менә шулай, кызым,— диде Галия апа бераздан,— шулай, бар синең әтиең, бар. Менә бу хатларны укы, аңларсың...

Галия апа Илүзәгә бер төргәк саргаеп беткән хатлар сузды. Алар төрле елларда язылганнар иде. Илүзә хатларны берәм-берәм ачып укый башлады:

«... Эшемдә әйбәт кенә эшлим. Ике норма бирә башладым. Бары сезне генә сагынам. Илүзәм ничек яши? Рөхсәт итсәң, отпускама чыккач, күреп килер идем кызымны...»

« ... Илүзәмә кышкы киемнәр җибәрәм. Туңмасын. Икенче айда кием итекләр җибәрермен...»

«Ник бер хат та язмыйсың? Ни өчен шул чаклы каты бәгырьле син? Кызымны, үзенә күренми генә, читтән булса да күреп китәр идем».

«... Илүзә синең турыда белмәсен дип язгансың. Бик аяныч булса да, синең белән килешәм. Шулай кирәктер. Тик бер үтенечем бар: зинһар, кызымның бер фоторәсемен генә җибәр!»

Илүзә дөньясын онытып укыды да укыды. Аның тормышының моңарчы билгесезлек пәрдәсе белән томаланган өлеше акрын-акрын ачыла бара иде.

Менә ничек бит ул. Әтисе әнисен дә, кызын да яраткан икән. Әни үзе аңа Илүзәне күрергә рөхсәт итмәгән. Әтисе бар икәнен белеп, йөрәген бозып яшәмәсен дигәндер инде. Әти яшәгән җирдә торырлык булмагач, ник әни аңа кияүгә чыкты икән соң?

— Сиңа сәер тоеладыр кызым. Әтиең белән бергә торырга тәвәккәлләгәндә алда ни буласы уйланылмаган.— Күр әле, кайдан әнисе

Илүзәнең бар уен сизеп тора соң? Хәер, ана йөрәге бик сизгер була диләр шул. — Беренче елымда торган җиремнән канәгать идем, китәрмен дигән вәсвәсә башка кереп тә бакмады... Ә аннары әллә ни булды. Эчем поша башлады. Әтиеңнең һәр сүзенә тупас җавап кайтара торган булып киттем. «Их, Галия, яратмыйсың син мине, — дия иде әниең.— Яратсаң, бераз булса да йомшак сүзеңне ишетер идем».— Йомшарырга да тырышып карамадым түгел, тырыштым. Әллә нигә булдыра алмадым. «Һай, хатын, үкенерсең үкенүен, әмма соң булмагае. Гөлләр дә сусыз корый лабаса!» — дип аһ орган чаклары булды аның. Үкенерсең дию шуннан икән, чөнки беравыктан ул үзе дә минем белән дорфа сөйләшә башлады. Шул чакта туган якларым, әбиең өзелеп искә төшеп, күпме күз яшьләре түкмәдем. Әтиеңне калдырып китүе җиңел булды дип беләсеңме? Авыр булды, ай-һай, авыр булды. Ләкин анда да кала алмадым. Әтиең үзе дә ялынып маташмады: «Нишлисең, шулай язгандыр. Җылытмаган кояш кояшмыни ул», — диде. Бу аерылу вакытлыча булыр, әтиең түзмәс, минем арттан кайтыр... дип уйлаган идем. Хатларына җавап язмасам да, үзем көн дә аны көттем... Бары сиздермәдем генә... Горур булам, янәсе... Ә әтиең башкага өйләнде дә куйды. Менә бит язмыш нинди. Ләкин үзең гаепле булгач, ничек аны битәрлисең... Әлфия атлы бу хатын бик ягымлы булган. «Хатын-кыз назының ни икәнен шунда белдем», — дип уйлаган әтиең, сөеп-сөешеп туймабыз дип өметләнгән. Ләкин үтә кызыл тиз уңа диләр бит. Наз дигән нәрсә белән дә чамасыз нык шаярырга ярамый икән шул. Гомергә җитәрлек назны ике-өч ай эчендә тотып бетерсәң, буп-буш булып каласың икән. Ә калган гомерне ничек яшәмәк кирәк... «Соңыннан исемә төште, — ди әтиең. — Хатын-кызның сагындырып-сагындырып китергән иркә назы кадерлерәк икән. Тик шулай булганда гына ялыктырмый бөтен гомергә җитәрлек була икән ул...»

Илүзә әнисенең бу тормыш фәлсәфәсен тыңлап утырганда, тупырдашып иптәш кызлары килеп керде. Керә-керешкә Илүзәне кочаклап алып, шау-гөр иттеләр:

— Тазаргансың, дускай, танырлык та түгел үзеңне.

— Абау, күлмәгеңне үзең тектеңме? Бигрәк матур!

— Кара, ничек тегәргә дә өйрәнгән!

Сорамаган сорау, сөйләшмәгән сүз калмады. Дусларының кайсы техникумга кергән, кайсы училищеда укый икән. Тугызынчы класста укуларын дәвам итүчеләр дә байтак.

Соңыннан Илүзәне көчләп диярлек урамга алып чыгып киттеләр. Инде караңгы төшеп килә иде. Йорт тәрәзәләрендә берәм-берәм утлар кабынды. Ә урамда аларның гына тавышы, аларның гына көлүе булды. Әйтерсең бу шәһәрдә башка кеше яшәми дә. Дуслар бер-берсен бик сагынганнар иде шул.

Аннан барысы да җыелып укыган мәктәпләренә киттеләр. Менә алар классы. Хәзер бушап калган. Илүзә партасында кем утыра икән? Шул ук парта бит. Аның һәр тамгасы таныш. Илүзә йорт эшләре кабинетына керми түзәме соң! Бүлмәдәге машиналар кечкенә дә, үз дә. Марзия апасы да шунда икән әле. Нәрсәдер тегеп маташа. Илүзәне күргәч, җыерчыклана башлаган йөзе яшәреп киткәндәй булды. Гомереңнең үткән өлеше белән очрашу төсле дер инде ул.

— Илүзә, каникулга кайттыңмы, үскәнем? Я, укулар ничек бара? Канәгатьме? Үкенмисеңме?

— Бик канәгать мин, Марзия апа, рәхмәт сезгә!

— Ә беләсеңме, Илүзә, укытучы хезмәте өчен шуннан да олы бүләк юк! Үзеңә дә рәхмәт.

Илүзә хәзер тагы бер кат училище стеналарында ала торган һөнәрнең башы үткәнгә барып тоташуын бөтен җаны белән сизде.

Ул юл әбисе янына утырып курчакка күлмәк тегүдән башланып, менә шушы йорт эшләре кабинеты аша үткән иде.

... Кышкы каникул сизелми үтте дә китте. Илүзәнең ни өчендер яңадан Казанга китәсе дә килмәгән иде. Ләкин китмичә ярамый, чөнки аңа башта училищены тәмамларга кирәк иде әле...

## УНБИШЕНЧЕ ДУЛКЫН

Буш вакыт Илүзәләргә бик әләкми. Күпме дәрес хәзерлисе бар. Урта мәктәп өчен имтиханнар тапшырасы. Өстәвенә, Илүзә модельләү түгәрәгендә дә шөгыльләнә. Ә бүгенге ял көнен саф һавада үткәрергә булды алар. Сәгать унга Оляның танышы Саша киләсе. Электриклар хәзерләүче училищеда укучы сары чәчле, чандыр гәүдәле бу егет белән Оля әле күптән түгел генә танышкан иде.

Кичтән үк алар өчәүләп чаңгы белән Казанка буена төшәргә сөйләшеп куйдылар.

Кызлар иртүк торды.

— Ашарга нәрсә пешерик? — дип сорады Илүзә.

— Мондый чакта иң кулае — йомырка тәбәсе! — диде Оля.

Саша килеп җитәргә күп калмаган иде, шуңа күрә тәбәгә артык исе китмәсә дә, Илүзә ризалашырга мәҗбүр булды.

Тиз-тиз генә ашап алгач, кызлар юлга әзерләнергә тотынды. Иң мәшәкатьле һәм күп вакыт алганы — чәч. Ни генә кыландырып бетерми кызлар шул чәчне: үреп тә карыйлар, төрле формадагы прическалар ясап та интегәләр.

Шушы иртәнге сәгатьтә кызлар бизәнүенең үз мәгънәсе бар. Ни өчен дисәң, нәфис чәчәкләр дә купшы таҗларын иртән менә шушылай ачалар бит. «Менә мине күр инде, күр!..» дигәндәй, дерелдәп-дерелдәп куя ул чәчәк таҗлары. Ә кыз балалар кешелекнең чәчәкләре түгелмени? Һәм ул «чәчәкләр»нең егетләр каршында тагын да матуррак буласылары килмимени? Шуңа шулай тырышып бизәнә алар. Ләкин кызлар — горур. Шуңа күрә алар, бизәнеп, егет күтүләрен сиздермәскә телиләр һәм нинди дә булса берәр шуклык уйлап табалар.

Илүзә белән Оля да егетне кызык итәргә булдылар.

Бер бит кәгазьгә:

«Без сине көтеп тормаска булдык. Киногә киттек», дип язып, аны өстәлгә куйдылар да, чырык-чырык көлешеп, чоланга кереп качтылар.

Ә егет әлеге язуны укып аһ итте. Сөмсерен коеп, нәүмизләнеп, өйдән чыкты да автобус тукталышына ашыкты. Кызлар, егетебез бөтенләй китеп бармагае дип куркып, аның артыннан йөгерделәр һәм, гел шулай чыркылдашып көлешә-көлешә, аның белән Казанкага төшеп киттеләр.

Көн искиткеч матур иде. Март кояшының ягымлы нурлары кар өстендә бии. Чаңгы белән шактый кызу барганга, ахры, кояш хәтта кыздырган шикелле.

Кар шактый тыгызланган. Шуңа күрә, яңа эз салып барасы юк. Сөйләшә-көлешә бара-бара, Горький паркы янына килеп җиткәннәрен сизми дә калдылар.

Таудан шуып төшү бигрәк тә күңелле! Өстә торганда тау шактый текә күренеп, бераз шүрләтә шүрләтүен. Аның караве, җилләтеп таудан шуып төшүләре ни тора.

Менә бу тау бигрәк текә икән. Аска карагач, йөрәгең убылып киткәндәй була. Җитмәсә, аста көрт өелгән. Илүзә кире китмәкче булып борылган гына иде, кинәт Илсурның килгәнен күрде. Нишләргә?

Аның алдында куркак булып күренергәме?.. Юк, иң яхшысы... Һәм ул шашкан тәвәккәллек белән упкынга ыргылды.

— Илүзә, нишлисең син? Тукта!

Кая анда туктау! Секундның ниндидер бер өлешендә очып барган көйгә Илүзә йөрәгенең кытыкланып куюын сизде. Аннары шундук чаңгы очлары көрткә кадалды һәм инерция көче Илүзәне өч-дүрт метрга алга ыргытты. Шул ук мизгелдә уң аягының тубык буе кинәт авыртудан аның башы әйләнеп китте, аңы томалангандай булды.

— Илүзә, Илүзә, ни булды?

«Чү, бу Илсур тавышы түгелме?» Илүзә күзен ачты һәм үзенә иелгән Илсурны күрде.

— Кирәкми... Мин үзем...

Илүзә күтәрелмәкче булды, ләкин каты авыртудан ыңгырашып карга утырды. Маңгаена салкын тир тамчылары бәреп чыкты.

Оля белән Саша да килеп җитте. Алар өчәүләп Илүзәне өскә алып меңделәр. Аннары Саша машинага йөгерде. Илсур Илүзә янынан китмәде.

— Син бер дә кайгырма. Тиз терелерсең. Мин иртәгә үк синең янына килермен, — дип сөйләнде.

...Палатада алар икәү иде. Илүзәнең күршесе — аксыл чырайлы, егерме биш тирәләрендәге Халисә атлы хатынның кулы сынган булган. Ул унбиш көнләп монда яткан инде. Хәзер терелеп килә. Бик ярдәмчел икән. «Сеңелем, ни кирәк?» — дип кенә тора... Беренче көннәрдә Илүзәнең аягы бик каты сызлады. Беркемгә дә күтәрелеп карыйсы килмәде аның. Хәлен белергә тәрәзә төбенә группа кызлары килгәч тә озак торалар кебек тоелды аңа. Илсур белән дә сөйләшә алмады. Хәер, Илсур үзе дә әллә ни төпченеп тормады. Борчыйсы килмәгәндер инде.

Ә менә биш-алты көн үткәч, гипсланган аягының сызлавы басыла төшкәч, Илүзә төрле уйларга бирелә башлады.

Иң борчыганы — якынлашып килүче имтиханнар. Янында китап-дәфтәрләре бар барын. Ләкин училищеда әзерләнүгә ни җитә инде. Шундый чаклар була, хет утырып ела: бөтен җаныңны тынгысыз уйлар төркеме биләп ала. Ә соңгы көннәрдә аның күңелендә — Илсур. Төптән уйлап карасаң, кайгыртучан, әйбәт егет бит ул. Аягы сынгач, Илүзәне берүзе ничаклы җир күтәреп барды. Чөнки Сашаның «ашыгыч ярдәм» машинасына чапкан чагы иде. Нинди ягымлы сүзләр пышылдады Илсур: «Мин сине больницага тикле күтәреп бара алам, Илүзәм». «Ә мин аннан юкка көнләшкән булам. Аның турында әллә ниләр уйлап йөрим. Их, мин дә инде... Кешенең бер дә житешмәгән ягы булмыймы?.. Мине ярата ич ул... Әйе, ярата!.. Ә Фәрдәнә... Фәрдәнә аның дусты, гади бер дусты. Минем белән Вагыйз шикелле... Әле кичә Фәрдәнә дә килгән иде. Минем янга дип килсә дә, күбрәк вакытын күрше палатада ятучы кыз белән сөйләшеп уздырды. Хәер, шуның өчен дә рәхмәт әле аңа...»

Илүзәнең уйларын тәрәзә аша урамны күзәтеп торучы Халисә бүлде:

— Кара әле, Илүзә, нинди егет икән ул? Бер сәгать булыр, безнең тәрәзә буен таптый.

— Кая?

Илүзә, яткан җиреннән күтәрелә төшеп, тәрәзәгә күз салды.

— Вагыйз? Нишләп йөри икән соң? Әйт син аңа, якынрак килсен.

Халисә тәрәзәне ачты да Вагыйзга кычкырды:

— Әй, егет кеше, бирерәк кил, сөйләшәсебез бар.

Тышкы яктан гаҗәпләнгән тавыш ишетелде:

— Минме?

— Син Вагыйздыр бит?

— Әйе!
— Шулай булгач син инде.
Уңайсызланып кына атлап, Вагыйзның тәрәзә кырына якынлашуын Илүзә дә күрде. Кулында зур гына папка бар иде егетнең.
— Нәрсә ул, Вагыйз?
— Бу — эскизлар. Теге чакны үзең әйткән идең бит.
Әйе шул. Илүзә Вагыйзга рәсем эскизларын күрсәтерсең дигән иде. Аның рәсем ясарга өйрәнәсе килә. Шуңа сораган иде ул эскизларны. Ә үзе оныткан да.
— Рәхмәт, Вагыйз. Болай булгач, миңа тагы эш чыга әле.
— Ие, эш чыга.
Вагыйз тыйнак кына көлеп куйды...
Шул көннән башлап Вагыйз Илүзә янына көн дә диярлек килеп йөри. Баштарак шул эскизларын дежур сестра аша биреп кертә иде. Ә апрель азакларында көннәр җылынып китте. Илүзә таякка таянып үзе чыгып йөри башлады.
Хәзер инде Вагыйз килү белән Илүзә больница бакчасына чыга һәм алар карт өянкеләр белән уратып алынган өстәл кырына утыралар. Егет, ихлас күңеленнән тырыша-тырыша, Илүзәне рәсем техникасына өйрәтә. Бу сәер «дәрес» сәгатьләр буе дәвам итә. Бервакыт Вагыйз берничә көн килми торды. Ни өчендер бу көннәр Илүзәгә ямансу тоелды. Җанында әллә ни җитмәгән кебек. Ә тәрәзәдән Вагыйзны күрү белән Илүзә, чиксез шатланып, кәгазь-карандашларын тиз генә эләктерде дә бакчага ашыкты.
— Кайда югалдың, Вагыйз? Мин сине көн дә көттем. Ә син юк та юк.
— Чынмы?.. Мин ни... шәһәрдә үткәрелгән яшь рәссамнар күргәзмәсендә катнаштым.
— Миңа әйтмәдең дә... Их, син...
— Уңайсызландым... Әллә ничек мактанган кебек...
— Я, ничегрәк булды соң?
— Ярыйсы.
— Ә шулай да?..
— Өченче урын...
— И Вагыйз, нинди молодец син!
Кызның мактавыннан Вагыйзның түбәсе күккә тиде һәм дәртләнеп сөйләргә тотынды:
— Беләсеңме, минем бөтен хыялым рәссам булу иде. Художество училищесына керергә теләгән идем. Барып чыкмады. Әти тегүче иде. Мине дә мена монда керергә өндәде. Ә мин карыша алмадым.
— Вагыйз, син үкенәсеңме? Бергәләп өйрәнеп йөрүебез бушкамы?..
— Юк, Илүзә, үкенмим... Рәхмәт сиңа... Син булмасаң, мин бәлки киткән дә булыр идем... Ләкин... ни...
Вагыйз тотлыгып туктап калды. Кызарынды. Кулларын кая куярга белмичә, өстәлдәге кәгазь кисәген бөтәрләде. Ә үзе карт өянкенең тузгыган ябалдашларын караган булды.
Илүзәгә бу минутта Вагыйз кызганыч булып тоелды. Егеттә үзенә карата нинди дер яшерен тойгы уянуын күптән сизә иде Илүзә. Ләкин бит аның Илсуры бар. Көн дә кояштай балкып килүче үз егете бар...
Илүзәнең зәңгәр күзләре кинәт кенә моңсуланып китүеннән Вагыйз аның уйларын сиземләгәндәй ашыгып:
— Гафу ит...— дип куйды.
— Нигә, Вагыйз... Мин бары...
— Әйе, әйе, мин китәрмен, барыбер китәрмен. Ләкин мин хәзер кем буласымны беләм инде.
— Билгеле, син рәссам булачаксың, Вагыйз.

— Юк, мин модельер булам. Шул модельерлар әзерләүче училищега керәм. Ә монда бер елга якын укуыма үкенмим... Монда кермәсәм, андый профессия барын белмәс тә идем...

— Модельер булу шәп! Шул ук рәссам ич ул. Без тегәчәк киемнәрнең төрле бизәктәге модельләрен иҗат итәчәксең бит! Әле аңа ерактыр. Күп тырышасы булыр... Ә мин экспериментал цехта эшләячәкмен. Наилә Хәбировна шулай диде. Әзер модель буенча иң беренче киемнәрне тегеп, производствога без тәкъдим итәчәкбез.

— Ничек яхшы була, Илүзә!

— Әйе, син модельер, ә мин син уйлап тапканны тормышка ашырам! Менә бу, ичмаса...

Шунда Илүзәнең күзе бакчаның аръягына төште һәм сөенеченнән аягы авыртуын да онытып, урыныннан сикереп үк торды:

— Әнә, Илсур килә!

Вагыйз китәргә җыенды.

— Ярый, хуш әлегә...

— Нигә, Вагыйз, өчәүләп сөйләшеп утырыйк бераз. Теге вакыттагы өчен ул сине гафу иткән инде.

— Мине гафу иткән?.. Ә мин гафу итмәдем... Сине мәсхәрә иткән өчен гафу итә алмадым...

Һәм Вагыйз аллея буйлап китеп барды.

Ә Илүзәнең иреннәре:

— Мәхәббәт кенә барысын да кичерә икән шул,— дип пышылдады.

## УНАЛТЫНЧЫ ДУЛКЫН

«Кеше авырлыкта сынала. Әнә Илсур ярдәмгә иң мохтаҗ көннәремдә һаман минем белән бергә булды»,— дип фикер йөртте Илүзә.

Соңгы көннәрдә Илсур аңа бигрәк тә якын тоела башлады. Больницадан чыккач та һәр кич Илүзәсе янына ашыкты егет. Илүзә үзе дә сагынып көтеп ала иде аны.

Бу кич тә алар Илүзә торган өй каршысындагы кечкенә бакчада утырдылар.

Шушы кичне инде Илсур:

— Беләсеңме, Илүзә, мин сине ни өчен яратам? — дип сорады.

Илүзә, башын аска иеп, ишетелер-ишетелмәс кенә:

— Белмим шул,— диде.

— Чөнки син башкалар кебек түгел... Син әллә нинди... кыргыерак дип әйтимме... Безнең бит хәтта...

— Кирәкми, Илсур...

— Шулай шул. Безнең хисләребез киләчәккә күбрәк калсын, иеме?

— Ие... Минем әти дә шулай дигән. Кешенең бер-берен ератуы бөтен гомеренә җитсен өчен бу хисне әрәм-шәрәм итмәскә, бик сак итеп тотарга кирәк, дигән. Ул күбрәк яшәгән кеше, белә торгандыр.

— Без дә шулай ич...

Илүзә озын күз керфекләрен күтәреп Илсурга серле итеп карап куйды.

— Ник алай карыйсың?

— Болай гына...

— Син үпкәли торгансыңдыр, иеме?

— Ни өчен?

— Мин сине аңлап бетермәгәнмен... Хәтереңне калдырган чаклларым булды.

— Мин онытгым инде...

— Рәхмәт, Илүзәм...

Илсур гомерендә беренче тапкыр Илүзәне кочаклап алды...

— Ой, кирәкми, Илсур, үзең ни диден...
— Мин әллә нишләдем бүген, Илүзә, гафу ит...
Илүзә көлеп куйды.
— Бер юлга гына.

Илсур яңа гына яфрак ярган каеннарның күк йөзен челтәрләгән очына күз салды.

— Карале, каен яфраклары ай өстендә тирбәлеп ничек уйнаклый... Үзенә бер моң агылгандай!

— Синең моңың, Илсур...
— Икебезнеке дә, Илүзәм...
Шул мизгел егетнең кайнар ирене Илүзәнең дерелдәгән иреннәренә сарылды.

Илүзәгә карышырга, нидер әйтергә кирәк иде, ләкин ул Илсурның кайнар күкрәгенә маңгаен гына терәде.
Шушыдыр инде мәхәббәтнең иң кайнар дулкыны... иң беренчесе шушыдыр...



## УНҖИДЕНЧЕ ДУЛКЫН

Әни кеше һәр мәлдә үз баласыннан:
— Бала, ничек яшисең? Җиргә тудыруымны акладыңмы син? — дип сорарга хаклы. Бүген Түбән Камадан Илүзәнең әнисе килде... Кызының ничек укуын белешергә килгән иде Галия апа. Төшкә чаклы Илүзә әнисе белән Казанның истәлекле урыннарын карап йөрде. Музейда, Муса Җәлил һәйкәле янында булдылар. Галия апа цирк бинасының матурлыгына сокланды. Ә кичкә таба ул Каравай ягында яшәүче туганнарына кайтып китте. Илүзәгә «Иң яхшы тегүче» дигән исем алу өчен иртәгә булачак смотр-конкурста катнашуга хәзерләнергә кирәк иде. Группа кызлары бу конкурска ике кызны — Зәкия белән Илүзәне сайладылар. Группаның гына түгел, бөтен училищеның дәрәҗәсен яклау бурычы тапшырылган иде аларга. Илүзә бу ышанычны аклый алырмы — иртәгә шуңа җавап әйтелер...

Менә ул көн. Фабрика каршындагы уку-өйрәнү мастерскоенда смотрны күзәтер өчен Казанның төрле тегү училищеларыннан йөзләгән кызлар-егетләр җыелган. Бар да түземсезлек белән бу җаваплы ярышның башлануын көтә.

Әнә комиссия әһелләре урыннарына утырышты. Алар арасында үз эшенең осталары — мастерлар, алтын куллы тегүчеләр, училище, фабрика җитәкчеләре, комсомол комитеты секретарьлары...

Конкурста катнашучыларга ике бирем тәкъдим ителде. Берсе — костюмга яки күлмәккә җиң утырту. Икенчесе — үзең иҗат иткән прекле эш. Бу соңгысы конкурста катнашучының иҗади фантазиягә бай булуын сорый иде.

Илүзәгә күлмәк җиңен утырту эләкте. Бу эш катлаулы булса да, Илүзә аны яхшы ук үзләштергән иде. Бары ашыкмаска, бары каушамаска гына кирәк... һәр җөй тигез, төгәл булсын. Технология нормалары тайпылышсыз үтәлсен. Җиде кат үлчә, бер кат кис дигән кагыйдә монда төп принцип булырга тиеш.

Илүзәнең әнисе Галия апа да монда. Ул тыныч кебек. Ләкин бу тыштан гына шулай. Шундый чакта кайсы ана тыныч була алсын соң?..

Зәкия Илүзәдән шактый еракта утыра. Ул һәрвакыттагыча гәүдәсен бик төз тотып тегә. Йөзендә дулкынлану, каушау галәмәте күрмәссең. Киресенчә, үзенә бер төрле ныклык сизелә аның бөтен хәрәка-

тендә. Әгәр кушсалар, тоташ күлмәкне дә эһ тә итмичә тегеп чыгарга хәленнән килер төсле.

Кызлар беренче биремне тәмамлады. Конкурска бәя бирүчеләр киңәшергә чыгып китте. Илүзә әнисе янына килде. Ул аның биленнән кочып алды.

— Уй, әни!..

— Ярый, ярый, кызым, борчылма, бар да әйбәт булыр.

— Борчылмыйм, әнием...

Илүзә залда утыручыларны күздән кичереп чыкты. Илсур күренми. Эше булды микәнни? Ә Вагыйз килгән. Нихәл, дигәнне аңлатып башын иеп, елмаеп та куйды. Бар да әйбәт булыр, дия иде аның бу елмаюы.

Тәнәфестән соң кызлар иҗади эш биремен үтәргә керешге.

Галия апа ерактан булса да күреп тора — Илүзә бик бирелеп нәрсәдер чигә. Димәк, ул чигүне сайлап алган икән. Кызының нәрсә һәм ничек чигү мәсьәләсен инде күптән уйлап йөрүен кайдан белсен ул. Йөзе бераз агарып китсә дә, бөтен килеш-килбәтендә гаҗәп сәер рухлану сизелә Илүзәнең: шушы минутта кулларын тылсымлы канат итеп, менә-менә очып китәр төсле. Һәм биектән очып барганда:

— Хуш, әнием, мин тиздән әйләнеп кайтырмын, син борчылма гына,— дип аваз бирер кебек.

Озак, бик озак тоелды Галия апага соңгы сәгатьләр. Ахыры булмастыр кебек иде бу зарыгып көтүнең. Башта үзен шактый тыныч тоткан Галия апа соңга таба борчыла башлады. Ул, түземсезләнеп, кулындагы косынкасын бөтәрләде, урыныннан кузгалып-кузгалып куйды.

Ниһаять, бар да тәмам. Нәрсә булыр икән? Галия апаның йөрәге ашкынып гөрселдәде. Илүзә дә бик дулкынлана иде. Ул, әнисе янында гына тора алмыйча, әле Зәкия янына бара, әле кулындагы сәгатен капшап карый. Вагыйз да дулкынлана икән: борчылуы йөзенә чыккан.

Менә комиссия председателе өстәл артына чыгып басты. Юри шулай эшләгәндәй, нәтиҗәне әйтмичә озак торды. Ниһаять, башлады:

— Бүгенге конкурс-смотр нәтиҗәләрен бик җентекләп тикшергәннән соң... беренче бирем буенча беренче урынны...

Юк, бу юлы кызының исемен атамадылар. Шулай да Галия апаның йөрәге нидер сизенә, нәрсәдер булыр кук иде.

— Ә икенче бирем буенча беренче урын... Вәлитова Илүзәгә...

Калган сүзләре ишетелмәде дә. Зал алкышка күмелде. Илүзәне иптәш кызлары урап алды. Аларга чәчәкләр, матур рәсемле шоколадлар бирделәр. Вагыйз Илүзәдән битәр шатланган. Авызы колагына җиткән.

Галия апа белән Наилә Хәбировна шактый вакыт, кызлар божрасын өзеп, Илүзә янына үтә алмадылар. Ә соңыннан алар өчәүләп Илүзә чиккән рәсемне карадылар. Бу рәсемдә өлкән яшьтәге мастер машина янында тегү тегеп утырган кызга ниндидер киңәш биреп тора. Ә композициянең түр өлешендә илаһи образ итеп Мәрфуга әбинең рәсеме чигелгән иде...

Аннары алар өчәүләп фабрика цехлары буйлап уздылар. Илүзә әнисенә машиналарны күрсәтә-күрсәтә сөйләп барды:

— Менә боларында костюмның ян кисемнәрен ялгап тегәләр, тегеләрендә җиң ясыйлар, анда кесә клапаны утырталар, ә аргы башта...

— Нинди якты монда, — дип соклана Галия апа.

— Тәрәзәләрне шулай зур итеп махсус эшләгәннәр,— дип аңлатырга ашыга Илүзә, — күңелләр күтәренке булсын өчен... Эстетика укытучысы сөйләде...

Наилә Хәбировнаның цех начальнигы янына керәсе бар икән. Ул, Галия ападан гафу үтенеп, шунда китте. Ә Илүзә әнисен фабрика ашханәсенә чакырды.

Ашап утырганда Галия апа Илүзәгә әтисеннән килгән хатлар турында сөйләде. Ул һаман Галия апаны һәм Илүзәне үзе эшләгән жиргә килергә чакыра икән.

Илүзә дәшми генә тыңлап торды-торды да:

— Әни, укып бетергәч, мин әти янына барып кайтам. Ошаса, бәлки бер-ике елга шунда эшләргә дә калырмын, — диде.

Галия апа куркып китте:

— Син нәрсә, кызым? Әнә әтиең дә бер-ике ел гына эшлим дигән иде. Аннары бер дә кайтмады. Кайдан башыңа килде бу уй?

— Минем башымнан киткәне дә юк аның, әни. Мин һаман әби соңгы сәгатьләрендә чигеп калдырган теге рәсем турында уйлыйм. Анда бит...

— Кирәкми, кызым!..

— Кирәк, әни... Мин нәни түгел, аңлыйм ич. Минем аркада ялгыз яшәгәнсең бит син.

— Юкны сөйләмә!

— Юк түгел, әни, калган гомереңдә сине күрәләтә бәхетсез итәсем килми минем.

— Илүзә...

— Мин дә үсеп буйга җиттем. Ә бервакыт син үзең генә калсаң...

— Әллә?..

— Курыкма, әнием, әлегә бернәрсә дә юк. Миңа иртә әле... Ләкин вакыт уза бит... Шуңа күрә бәлки без өчәү бергә яшәп карарбыз... Озакламый әти пенсиягә чыгачак бит... Илле яшьтән чыга ич шахтерлар...

— Кызым, син ничек төптән уйлый башлаган хәзер... рәхмәт...

## УНСИГЕЗЕНЧЕ ДУЛКЫН

Наилә Хәбировнаның алты яшьлек кызы — Лена кинәт авырып китте. Аңа операция ясадылар. Ләкин операциягә чаклы ук нәни кызның сукыр эчәге тишелгән булган, авыру көчәеп, перитонит барлыкка килгән. Врачлар Ленаның тормышын саклап калу өчен кулларыннан килгәннең барын да эшләгәннәр. Ләкин ялкынсыну кызның башка органнарына күчеп, хәл куркыныч төс алган.

Кызлар Наилә Хәбировнаның соңгы көннәрдә ябыгып, агарынып калуын сизгәннәр иде. Ләкин мастерларының җанын нинди авыр кайгы талавын белми калганнар икән. Наилә Хәбировна үзе дә бу турыда кызларга сиздермәде шул. Уку елы тәмамланыр алдындагы җаваплы көннәрдә кызларны борчыйсы килмәгәндер, күрәсең.

Беренче булып бу хакта Фәрдәнә белгән. Башка вакытта кызларның берәрсе мастерга яхшылык эшләсә, Фәрдәнә: «Син куштан, син ялагай»,— дия торган иде. Ә бу юлы нәни кызны кызгану хисе барыннан да өстенрәк булып чыккан. Ул Лена ята торган больницага барып, врачлардан аның хәлен сорашкан. Бүтән берәүне больница эченә кертмәгән дә булырлар иде. Ләкин Фәрдәнә, теге вакытта иптәш кызы янына йөреп, андагы сестралар, хәтта врачлар белән танышып беткән. Өстәвенә, әлеге рус кызының апасы да шул больницада эшли икән. Лена янына баруга ул аны шунда ук танып алган да шатланып:

— У, Фәрдәнә килгән! — дигән. Фәрдәнәнең Лена янына килүен белгәч, аңа ак халат белән ак башлык биргән. Фәрдәнә, шуларны киеп,

Лена ята торган палатага кергән. Кыз үзе генә булган. Ул бик сызланып, елап ята икән. Фәрдәнә кергәч, нәни кызый:

— Ишекне ачып куегыз, миңа эссе, — дигән.

Фәрдәнә кызның әйткәнен тыңлаган — ишекне ачып куйган. Ярым ачык ишек аша зал яктан җыр ишетелә икән. Кыз шул җырны тыңлагандай иткән һәм елавыннан тыелып торган. Сызлануы бераз онытылгандай булган, күрәсең. Аннары җыр туктаган һәм Лена тагын елый башлаган. Фәрдәнә аны юаткан:

— Елама, Леночка, телисеңме, мин сиңа үзем җырлыйм? — дигән. Нәни кыз җырла дип баш каккандай иткән. Шунда Фәрдәнә акрын гына җырлап җибәргән:

Куе-куе урманнарда
Үрелеп үскән миләүшә.
Нәни кошчыклар йөргән, ди,
Аның белән янәшә.
Нәни кошчыклар күргәннәр
Миләүшәнең чәчәген.
Сокланып сайрашканнар...

Шул чак таныш түгел сестра килеп кергән.

— Нишлисең син, кем рөхсәт итте монда керергә! — дип, Фәрдәнәне ачуланган. Чыгарга кушкан. Ә Лена:

— Китмәсен! — дип еларга тотынган.

Шулай итеп, Фәрдәнә сәгать буе нәни кызга җырлар җырлаган, әкиятләр сөйләгән.

Фәрдәнә врачлардан Ленаның хәле бик авыр икәнен, канына плазма җибәреп кенә тормышын саклап калырга була икәнен белгән. Ә плазманы сау кеше каныннан ясыйлар икән. Фәрдәнә шунда ук:

— Минем канымны алыгыз! — дип үтенгән.

— Синеке яраса, алырбыз,— дигән врачлар.

Фәрдәнә: «Каным яраса ярар иде», — дип теләгән. «Каның ярый»,— дигәч, чамасыз куанган.

Нәни Ленаның гомерен саклап калу өчен бөтен училище күтәрелде. Аның хәлен кызлар көн саен күзәтеп торды. Ленаның үлемне, ниһаять, җиңүе турындагы хәбәр училищеда бәйрәм булды.

Шушы вакыйга Фәрдәнәне группа кызларына якынайта төште. Кызларның моңарчы Фәрдәнә белән сөйләшергә теләмәгәннәре дә аның белән аралаша башлады. Фәрдәнә үзе дә тыйнакланды, дәресләрен калдырмаска тырышты. Ләкин ул тегү дәресләренә элеккечә үк теләр-теләмәс йөрде. Наилә Хәбировна, Фәрдәнәнең холкын белгәнгә, бу хакта олы итеп сүз кузгатмаска тырышты. Ул бераз гына булса да үзгәрә башлаган Фәрдәнәне читкә тибәрүдән шикләнә иде.

## УНТУГЫЗЫНЧЫ ДУЛКЫН

Эстетика дәресе — кызлар өчен зур бәйрәм. Шуңа күләгә төшәр дип, Илүзәнең башына да килмәгән иде.

Май башлары иде бу. Агачлар яңа гына яфрак ярган чак. Уку башында ук үткән «Табигатьтә һәм сәнгатьтә матурлык» темасын кабатлау йөзеннән урманга экскурсия оештырды Рузия Хаковна. Яшеллек дөньясы кызларны үз итеп, хуш исләре белән каршылады. Менә Илүзәнең колак төбендә генә кемдер пышылдый: «Гап-гади агачлар. Искитәрлек берни юк». Зәкия икән. Аның каравы, Оляның күзләре нинди көләч! Сандугач баласы тотканмыни.

Менә Рузия Хаковна сөйли башлый. Сөйли генәме соң... Ул үзе гүзәллек дөньясында яши, бәйрәм итә!..

Мәгъруր кәүсәләре белән җир өстенә Алып батырдай ныгытып баскан мәһабәт имәнне күр син! Талгын җилдә яфракларын салмак кына шыбырдатып, гасырларның иң данлы вакыйгаларын сөйли шикелле ул. Ә каеннар... Унҗиде яшьлек кыздай сылу һәм иркә. Акрын җил дә тибрәтер аны. Ә баш чайкавы нинди килешле... Йөз яшәр наратлар күккә кадалган гигант сөңгеләр кебек... Яңа шытып килгән яшь-яшел үлән келәменә чалкан ят та рәхәтләнеп хыялга чум икән...

«Тук-тук-тук...»

Айны син, кызый, бу серле төштән. Айны да фараз ит: бу илаһи камиллек нидән? Төп-төз наратлар кояшны күрер өчен генә шулай югары үрелгәнме? Каеннарның сөттәй ак киеме бу назлының сафлыгы гына микән? Фараз ит, кызый!..

«Тук-тук-тук...»

Дистәләгән төс белән бизәнгән тукран, бер агачтан икенчесенә күчә-күчә, шул хакта хәбәр итә. Корычтай нык томшыгы музыкаль ритмга салынган аваз бирә.

«Нинди камиллек! Бу турыда шагыйрь ничек дастан язмасын! Рәсcамның полотносына ничек иң якты буяу буяп төшмәсен ул!..»

Шул чак Илүзә тирәсендә генә утырган Зәкия киерелеп иснәп куйды.

— А-аһ, ничек йокы килә...

Һәм ул көздән калган яфраклар өстенә сузылып ятты.

Ә Рузия Хаковна моны сизмәде. Чөнки ул бүтән кызларга әлеге матурлык һәм камиллек дөньясы турында сөйләп тора иде.

«Кешегә яшәү бик рәхәт булсын өчен табигать ничек шул чаклы гүзәл була алды икән?! — дип фикер йөртте Илүзә. — Нинди оста рәссам да шушындый манзараны иҗат итә алмас иде. Бер композиторның да кошларның бу сихри моңын бөтен табигыйлеген саклаган хәлдә яңгыратырга хәленнән килмәс... Табигатьтәгечә... Кара, кем әйткән иде әле моны? Илсур... Әйе, әйе, ул... Их, Илсурга сөйлисе сүзләре күпме Илүзәнең... Аңа җиткерәсе сөенечләре ничаклы!

Кинәт якында гына җыр ишетелде. Бу җыр урман шавыннан үсеп чыкты бугай.

Нигә, нигә син җырладың миңа,
Истә калды авыр моң гына...

Рузия Хаковна сөйләвеннән шып туктады. Бар да җыр ишетелгән якка борылып карады. Җырның иясе Фәрдәнә аптырап һәм куркынып авызын ачып калган иде. Ялгыш кына җырлап җибәрдем, кичерегез зинһар, дигән шикелле иде аның кара күзләре.

Ә Рузия Хаковна бөтенләй ул көтмәгәнчә:

— Җырла, җырла, Фәрдәнә!.. — диде.

Фәрдәнә, укытучы бу сүзләрне юри генә әйтмәдеме икән дип, Рузия Хаковнага сынап карап торды. Аннары, укытучысының чын күңелдән аның җырлавын көтүен күреп, моңлы, ләкин дулкынланудан бераз калтыравыклы тавыш белән дәвам итте:

...Яр буенда ялгыз каен тора,
Яңгырамый инде җыр гына.

Аннары Фәрдәнә кинәт йөзен куллары белән каплады да кинчкә таба көчәя төшкән җилдә нык кына чайкала башлаган каеннар арасына йөгерде.

Рузия Хаковна борчуга калды.

— Бар әле, Илүзә, нәрсә булды икән? — диде.

Илүзә Фәрдәнә артыннан барырга теләмәсә дә, укытучы әйткәч, каршы алмады.

Фәрдәнә яшь кенә каен төбенә чүгәләп утырган да үксеп-үксеп елый иде. Илүзәне күрүгә ул, яшьле күзләре белән аңа таба борылып, бер-берсенә бәйләнешсез сүзләр тезеп китте:

— Я, ачулан, тетмәмне тет минем! Сезнеңчә, мин бит бөтенләй юлдан язган! Нишләдем генә соң мин! Җанымда коточкыч бушлык булганга мин гаеплемени?! Училище нәрсә соң миңа?.. Тегү эше нәрсә? Болар барысы эчпошыргыч, күңел кайтаргыч... Күңелемне нәрсә беләндер басарга кирәк иде ич... Ичмасам, кемгәдер гашыйк булырга... Нәрсә миңа шулай акаеп карыйсың? Әйе, Илсурны яраттым мин! Бик! Җанымның бөтен кайнарлыгын аңа бирдем... Ә ул... ул... Әйе, ул күңелемне юатты... Ничек кенә юатты әле! Җырлар җырлады... Күңелем күтәрелсен дип шәраб тәкъдим итте... Минем беркайчан андыйны эчкәнем юк иде ич... Шулай да баш тартмадым... Онытылырга кирәк иде миңа. Беренче йотым... Әйе, шуннан соң эчмәскә дә була иде. Нәрсә мәҗбүр итте соң? Әйе, ул. «Дус итмисең... кеше ирекле булырга тиеш...» Ничаклы төче, күңел болгаткыч сүзләр!.. Ул вакытта бу сүзләрдән күңел болганмады бит. Алар әллә ничек җылы, дустанә булып тоелды. Шуннан тагы бер йотым, ике, өч... Тәннең кайнарланып китүе... Сәер рәхәтлек... Кеше үзен алдый алса да ала икән... Эчкән нәрсәм бик тиз изрәтте мине. Башым әйләнде. Аяк буыннарым хәлсезләнде. Илсурның бертуктаусыз нәрсәдер сөйләве, кайнар пышылдавы бары төштәге кебек. Каядыр төпсезлеккә очам шикелле. Нәрсәгәдер ябышып калырга тырыштым. Тотрыгын җуйган кулларым белән аңа сарылдым. Ләкин барыбер аның белән бергә авып барам, каядыр очам шикелле.

Ә ул: «Җаным, син, син барыбер минеке... сүз әйтмә...» — дип пышылдады.

Ә миңа инде барыбер иде. Кулларым юеш чирәмне тойгач: «Ярый, җир икән, бушлык түгел», — дип, хәтта тынычландырдым да үземне...

Фәрдәнә такмаклый-такмаклый елады.

Ләкин аның шуннан соңгы сүзләрен Илүзә ишетмәде. Муенын нәрсәдер буган шикелле булды. Сулыш алуы авырайды. Һәм ул хәлсезләнеп агач төбенә утырды.

Бераздан борчылып Рузия Хаковна килеп җитте:

— Ни булды, кызлар?

Аннары үксеп елаудан шешенеп беткән Фәрдәнәне һәм кәгазь битедәй агарынып калган Илүзәне күреп хәйран калды:

— Илүзә, Фәрдәнә...

Кызлар аларны уратып алдылар.

Зәкия түзмәде:

— Слушай, нишләдегез, сөйләгез инде! — дип, хәтта кычкырып ук җибәрде.

Илүзә көчкә-көчкә:

— Берни эшләмәдек... Барысы да узар, — дип кенә әйтә алды.

— Фәрдәнә, син?..

— Ул сөйләде инде...

...Илүзә, Фәрдәнә сөйләгәннәргә тәмам өнсезләнеп, берүзе җәяүләп фатирына кайтып барганда, урам чатында аны Илсур көтеп тора иде. Ул шатланып:

— Илүзә, ә мин сине бөтен шәһәр буенча эзләп йөрим, — дип, Илүзәгә таба ашыккан иде, Илүзә читкә тайпылды:

— Юкка.

— Илүзә, авырыйсың мәллә? Төсең качкан...

— Юк..

— Илүзә...

— Үз юлыңда бул. Бар да бетте...

— Илүзә, син нәрсә? Нишләдең син?

— Менә синең нишләгәнеңне белми йөргәнмен...

— Ах, бу ул...

Кинәт Илсур Илүзәне кочып алды да ашыгып сөйләргә тотынды...

— Соң, Илүзә... Бу бит вакыт уздыру өчен генә... Эч пошканда җан бушату... Син бит — башка... Мин сине яратам... Мәңгегә... Шуңа сине саклаячакмын, Илүзә.

Илүзә ярсып Илсурны этеп җибәрде:

— Кабахәт!

Һәм җаны өшүдән гаҗиз булып, артына борылып та карамыйча, тар аллея буйлап йөгерде.

*
* *

Ниндидер очраклы бер минутлык зилзилә куптарган соңгы дулкын ярны ялап төште. Ул Фәрдәнәнең ком өстендә ярылып калган аяк эзләрен дә юды.

Ә менә Фәрдәнә, Илсурлар калдырган йөрәктәге әрнеткеч эзләрне ничек юарга?.. Авыр Илүзәгә... Ә Фәрдәнәгә җиңелме соң?.. Ичмасам, Илүзәнең киләчәк сукмагы төсмерле... Менә Фәрдәнә нишләр? Кая барыр ул?.. Хәер, аның училищедан китүе үзе зур тәвәккәллек иң. Димәк, күңелендә карар туган. Соңгы вакытта больница, шәфкать туташларының эше турында юкка бертуктаусыз сөйләнеп йөрмәгәндер... Табар үз юлын Фәрдәнә, табар... Төрле яктан өстенә ишелгән бәлане сылу иңнәре күтәрә алыр... Бөтенләй югалып кала торган кыз түгел лә Фәрдәнә.

Илүзәгә җиңелрәк булып китте. Ул башын күтәреп тирә-юненә күз ташлады. Кара, ярда ул үзе генә түгел икән. Әнә анда — таллыклар буенда — Вагыйз моңаеп басып тора. Китми дә, кызга да якын килми. Ничә сәгать шулай басып тора инде... Илүзәнең сүз әйткәнен көтә. Ә үзе башлап дәшмәс.

## Нури Арсланов

# СӘФӘР ЧЫКСАМ

### Ватандармын

Яшәсәм дә заманында заманнарның,
Күп кичердем баштан яхшы-яманнарын:

Шашып яндым мәхәббәттә Мәҗнүн төсле,
Ә туема Ләйләм белән бараламадым.

Пилад кебек идем дуслык-тугрылыкта,
Ни кызганыч! Орестымны табалмадым [1].

Яшәү бәхете белән көләч мин дивана,
Күпме булды кайгыларга камалганым...

Кисәүгә әйләнә янган барча әйбер,
Ә мин яндым да яктырдым — каралмадым.

Җик итсә дә, күп борчулар кичерсәм дә,
Туган илдән газиз җирне табалмадым.

Олтан булсам булдым изге туфрагымда,
Чит җирләрдә солтан булып калалмадым.

Ташлы юлда абынмастай ат та булмый, —
Абынганны күзгә карап таналмадым.

Нинди атлар атланмадым бәйгеләрдә: —
Гомер үтте, ә туйганчы чабалмадым.

Мин романтик бер хыялый дәрвиш идем,
Фанилеген бу дөньяның чак аңладым.

Шаһит булдым хурлыгына телдән бизгән,
Тарихыннан йөз чөергән яманнарның.

Үзен мескен саный андый гарип җаннар,
Белмәгәнгә батырлыгын бабайларның.

[1] Пилад һәм Орест — борынгы юнан дастанындагы аерылмас дуслар.

Нигез ташы — шул бабайлар сөякләре
Иске җирдә үскән яңа Казаннарның!

Ир ирлеге — ил кайгысын кайгыртуда!
Илем-йортым өчен бөтен җан-арманым [1].

Сынатмадым Ватан сугышы кырларында,
Тапламадым яхшы атын бабамнарның.

Иминлектә уе — яуда юлбарыстай,
Тынычлыкта аттай тырыш татарларның.

Зарыктырмый уңыш хәзер тырышларны, —
Җәһәт кылдым, бәхет көтеп яталмадым.

Бөтен дөнья тынычлыгы өчен янган
Көрәшчеләр белән мин дә катардамын [2].

Тугрылыклы улы булсам Идел-йортның,
Бөек Совет илендә бер ватандармын!

1973

## Нигә, нигә?..

Латвиядә, Рига янындагы Саласпилс концлагеренда фашистлар йөз мең кешене һәлак иткән.

Саласпилста каннан җир каралган...
Тыңла, монда йөз мең йөрәк тибә:
«Нигә тудык икән без анадан,
Үтерделәр безне нигә, нигә?..»

Таш һәйкәлләр җанны сискәндергән
Шомлы әрвах булып алга килә.
Сорый алар бездән — исәннәрдән:
«Үтерделәр безне нигә, нигә?..»

Түшен япкан ялангач кыз бала,
Оятыннан батар иде җиргә!..
Иреннәре аның калтырана:
«Хур иттеләр безне нигә, нигә?..»

Өзгәләнеп елый бер мескенкәй,
Башкалары кушыла шул бәбигә:
«Җылы кочагыңнан, әнкәй, әнкәй,
Аердылар безне нигә, нигә?..»

Ана баскан горур калкан булып,
Балалары поскан итәгенә...
Юк, бәладән кала алмас йолып...
Рәхимсез син, язмыш, нигә, нигә?..

[1] Арман — теләк.
[2] Катарда — янәшә (сафта).

Онытмагыз моны! ди манзара,
Туфрак җанлы — баскан саен иңә.
Тик бер сорау монда кабатлана:
«Үтерделәр безне нигә, нигә?»

1973

## Сәфәр чыксам

Янги-Сайлар [1], Орхон язмалары
Сәлам-хатлар кебек бүгенгә:
Борынгының серле тамгалары
Горур хисләр сала күңелгә.

Идел-Уралларга борган йөзен
Озак юллар кичкән бабайлар, —
Табан эзен күмгән, ә дан эзен
Күмалмаган хәтта заманнар!

Безнең тарих хәзер гасырларның
Катламнарын каерып табыла, —
Бөек дәүләт төзгән батырларның
Истәлеге — кайда казыма.

Зур калалар, патшалыклар янган,
Елъязмалар янган — калмаган...
Янгыннарны кичеп халкым калган,
Яу аны көл итә алмаган.

Сәфәр чыксам, һаман колагымда
Тарих пышылдавын ишетәм, —
Кайда барсам да үз туфрагымда
Атлап йөргән кебек хис итәм!

Мин тынгысыз археолог сыман
Тарихымны казыйм, актарам:
Бүгенгегә карап шөкер кылам,
Узганнарым белән мактанам.

Кичермәгән халкымниләр генә!
Тагын күпме баштан кичәчәк?!.
Ни кичсә дә, үткән көннәренә
Лаек булыр безнең киләчәк.

1973

[1] Янги-Сай — Енисей.

## Болытларга карап

Ак болытлар йөзә биеклектә,
Охшап гаҗәп кучмә тауларга,
Я үркәчен пута белән чиккән
Дөяләргә — гамьсез кәрванга.

Исләре дә китми дөнья эшен
Югарыда күздән үткәреп,
Әйтерсең лә фәкать алар өчен
Күк гөмбәзен куйган түнтәреп.

Ишетмиләр сугыш быргыларын,
Тыңламыйлар халык аһ-зарын,
Уйламыйлар — ниләр көтә тагын
Кешелекнең чукмәс кәрванын.

Болытлардай булсаң иде азат, —
Һаман юлда, һаман биектә!
Ә күпмеләр йөри чигеп азап
Чыгалмыйча һаман иреккә...

Болытларны тартып төшереп булмый, —
Язмышның да җитми буйлары.
Кеше белән генә ул бик уйный,
Үзәкләргә үтә уйнавы!

1974—1976

## Илемә

Син өндәгән саен күтәрелдем,
Син күтәргән саен борчылдым:
Җаваплылык өстәләсен белдем,
Үсәчәген белдем бурычымның.

Гел гаепле төсле синең алда,
Бетералмадым мин шул шигемне;
Бушамас йөк йөри һаман аңда,
Түләнмәгән бурыч шикелле.

...Китәрмен бер, илем, җирләгәндә
Уйлар борчыр микән гүрдә дә?
Тик бер генә гарзым: тиргәсәң дә
Үги улың итеп тиргәмә.

1975

## Кирәк кайчак...

Татып калыйк диеп дөнья кызыгын
Тырмашабыз — гүя кырмыска.
Михнәт чигүчегә — гомер озын,
Рәхәт чигүчегә ул — кыска.

Бу дөньяда күпме михнәт чиктең,
Күпме рәхәт чиктең — кем саный?
Гадиләрчә хәйран гомер иттем,
Ул озын я кыска булса ни?!

Михнәтләрем һаман бергә булды,
Рәхәтләрем йөрде килгәләп;
Кояшыма бик еш болыт кунды,
Аем булды ләкин түгәрәк!

Түгәрәк ай төсле якты булды —
Тормышымнан нигә зарлану?!
Күпне белеп кай фәйләсуф уңды?
Кирәк кайчак татлы алдану.

1975

## Торналар

Җылы яклар моннан ерактыр алар.
Еракларга юнәләләр торналар,
«Торыйк, торыйк!» — дисәләр дә үзләре.

Кешеләрнең нигә дымлы күзләре?..
Ник сагышлы икән кошлар китүе?
Теләкләргә бик кыен шул җитүе.

Бар әле, бар канатларның таласы,
Ерак — өмет белән бәхет арасы, —
Җылы яклар моннан ерак шул алар...

Еракларга очып китә торналар, —
Алар эше — язын, көзен сәяхәт.
Йөрәкләрдә сагышлардан җәрәхәт...

1973

## Реплика

Сәнгатьләр бал куяр бу мичкәдә
Хәтсез кыршау!
Анда рәссамга да, шагыйрьгә дә
Күп комачау.

Тарсынасың икән кыршауларны, —
Сайла тышау:
Ир-егеткә хасмы тышаулаган
Атка охшау?!.

Шигырь, рәсем — бер чикләвек төше,
Ике игзәк,
Тоткарламый алар берсен-берсе,
Яши бизәп.

Тик аерылма Җирнең ширбәт тулы
Мичкәсеннән,
Кансын талант, Абелхәят суы
Эчкән сыман!

1974

## Һаман яңгырар

«...Үләрмен дә — онытырлар диеп
Юкка гына, йөрәк, янасың...»

Һади Такташ

Туфраклары сөрмә, суы ширбәт,
Ризыклары бал да май икән:
Минем туган җирем кебек әйбәт,
Сәйран яклар тагын бар микән?!

Суы тәмле, иле ямьле булды —
Газиз башым кая бармасын.
Әмма күңел һаман тартып торды —
Үз ягыма килде кайтасым.

Борчуларын, сагышларын чыдам,
Уфтанусыз алып иңенә,
Туган илен шагыйрь сөйгән сыман
Сөйсә иде аны иле дә.

Онытылырлар минем хакта монда
Хатирәләр, сагыш-кайгылар...
Мин оныталмам ләкин — җырларымда
Туган ягым һаман яңгырар!

1973

## Күңел бер уйнар

Яфрагын ярган, чәчәген койган,
Җимешен биргән безнең агачлар, —
Яшен яшәгән, ашын ашаган,
Гомерен кичергән инде бу башлар...

Мин шулай дим дә...гомернең көзе
Алтын да була, салкын да була.
Күңел-күбәләк салкыннан безне
Җылыга куа, ялкынга куна.

Яндырсаң яндыр, җылынсын җаным!
Көлгә әйләнсә күңелсез уйлар, —
Бәхеткә тулып, мөлдерәп тагын
Күңел бер елар, күңел бер уйнар!

1975

## Сүрелмәсә

Йолдызлар саны кимеми
Йолдыз атылган белән.
Мәңгелек бу дөньяга ни? —
Йолдыздай хәят кәсасе
Төшеп ватылган белән?!

Аһ, шул ватыкларың белән
Йолдызың күмелмәсә! —
Ул синнән соң да күгеннән
Яктыртса иде җаныңны, —
Сүнмәсә-сүрелмәсә!

1975

## Канкай углы Бәхтияр бәете

Тарих мең дә җиде йөз дә
Җитмеш өчтә — данлы елда
Чыктың, батыр Канкай углы,
Пугач белән канлы юлга.
Канкай углы, һай, Бәхтияр!
Асау икән менгән атың, —
Атландырдың ак патшага
Каршы бөтен Идел халкын.
Бәхтияр, Бәхтияр!
Азатлыкка идең яр.
Искә алыр илең бар,
Горурланыр затың бар,
Канкай батыр дигән атың бар!

Тәхетләрне тетрәткән ир
Пугачка ил ияргәндә,
Салаватлар белән бергә
Мәкан таптың син ирдә.
Пугач явын җиңде дошман,
Син дә билдән канга баттың...
Кай җирләрдә сөякләрең, —
Туфрагыңны кайда таптың?..
Бәхтияр, Бәхтияр!
Азатлыкка идең яр,
Искә алыр илең бар,
Горурланыр затың бар,
Канкай батыр диган атың бар!

Исемең булса да Бәхтияр,
Бәхеткә яр булалмадың, —
Таудай иде кайгыларың,
Бик аз булды куанганың...
Борынгыдан тузан баскан
Эзләреңне тапмасак та,
Һаман килә тояк тавышың, —
Син мәңгелек аргамакта!
Бәхтияр, Бәхтияр!
Азатлыкка идең яр,
Искә алыр илең бар,
Горурланыр затың бар,
Канкай батыр диган атың бар!

1973

**Диас Вәлиев**

# СИҢА ТОРМЫШ БҮЛӘК ИТӘМ

(ДӘВАМ)

ИКЕ БҮЛЕКТӘН ТОРГАН ПАТЕТИК ТРАГЕДИЯ

КАТНАШАЛАР:

Саттаров
Байков
Дания Әхмәдуллина
Алсу
Вадим Байков
Сатынский — проект институты хезмәткәре
Гоголев — министрлык хезмәткәре
Майя Качаева — баш проект институты хезмәткәре
Виктор Дурылин
Таисия
Мөнир Зарипов — Байковның ярдәмчесе
Дунаев — баш механик
Саликова — техника куркынычсызлыгы бүлеге начальнигы
Рушания
Вера
Гәүһәр
Нюра
Корней Петрович
Пыпин
Захарыч
Юрий
Инженер
Ашот
Кыз

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

Сәхнә алдыннан Саттаров үтә. Далага карап, бераз басып тора, аннары китә. Музыка. Җыр.
Тәҗрибә полигоны. Арырак казылып беткән уннарча чакрымга җәелгән дала.

Виктор. Егетләр, бетон китердем! Кабул итегез, мәми авызлар!

Гәүһәр. Нишләп озакладың? Яңгыр ява бит. Эшләмәсәң, бетең дигән сүз! Сезнең өчен, синең тәгәрмәчле ишәгең өчен салабыз бит ул юлны!

Виктор. Ишәк түгел, МАЗ бу! Мыскыл итмә минем машинаны!

**Гәүһәр.** Каян килеп чыккан князь соң әле син!

**Мөнир Зарипов** *(үтеп барышлый — инженерга).* Бездә шулай ул! Син кемгәдер тондырасың, киләләр дә синең үзеңнең җилкә тамырыңа кундыралар — дөнья бу, тормыш!

**Инженер** *(шәһәрара сөйләшү пунктында, телефонга).* Алло, алло!.. Мин шул. Килдем. Шайтан белсенме аны! Ерып йөргесез пычрак, исәпсез-сансыз халык. Ашханәсенә баш тыгарлык түгел... Карарга кирәк әле... Карарга! Әлегә берни дә аңларлык түгел, дим! Аңларлык түгел!.. Аң-лар-лык түгел!..

Тагын яңа көн. Тагын сынау полигоны мәйданчыгы.

**Алсу.**

Күз җитмәс кыр. Иркенлек.
Җәелеп ята чиста дала.
Шул далада яшь бер колын чаба.
Кайгыны да, борчуны да белми шул ул —
Ул бит әле яңа туган нәни бала.
Күзләр явын алырлык матур колын,
Кайнап тора гәүдәсендә яшьлек дәрте.
Аяклары — дөнья күрке.
. . . . . . . . . . . . . . .
Их, буласы иде миңа да
Шундый колын...

**Сатынский, Майя Качаева** һәм **Гоголев** керә. Алсу сүзсез кала һәм аларның сөйләшүләрен тыңлый.

**Гоголев.** Сынау нәтиҗәләре, тыштан караганда, эффектлы, әлбәттә. Беренче карашка. Ләкин, Николай Николаевич, бу фундаментларның вакыт сынавын ничек узачагын без бит әле белмибез. Без алар өстенә заводларның барлык гигант комплексын бастырырга телибез, ә алар соң ышанычлымы?

**Сатынский.** Сент-Экзюпериның «Кечкенә принц»ын укыдыгызмы сез?

**Гоголев.** Укыдым бугай. Бик күптән, бала чагымда ук. Шуннан?

**Сатынский.** Кечкенә принц алла янына килеп чыга.

**Качаева.** Алла янына түгел, король янына.

**Сатынский.** Әйе, әйе, гафу итегез, король янына килә һәм сорый: «Кояшны баетырга боерык бирә аласыңмы син?» ди. Король әйтә: «Боера алам, ләкин нигә кирәк ул? Барысы буталып бетәчәк бит. Ә мин баер сәгате җиткәч инде...»

**Гоголев.** Аңламыйм.

**Сатынский.** Бөтен әкәмәте шунда да шул, Алексей Борисович, сез барыгыз да, шул король сыман, ситуациянең өлгерүен, аның хәттә, гафу итегез, иң соңгы бәйләнчеккә дә табигый булып күренүен көтәсез.

**Гоголев.** Күптәннән белмәсәм икән мин сезне, Николай Николаевич... Ләкин, аллага шөкер, сезнең кул астында эшли башладым бит.

**Сатынский.** Ни сөйлисез сез, ни сөйлисез! Эшли башламадыгыз, карьерагызны башладыгыз сез миндә!

**Качаева.** Николай Николавич, кадерлем, әлбәттә, бу әле минем шәхси фикер генә, ләкин мин сезнең сотрудниклар тагын берничә тәҗрибә үткәрүләрен теләр идем. Ныклы ачыклык кирәк.

**Сатынский.** Һаман ачык түгелмени әле сезгә?

**Качаева.** Берничә көннән дәүләт оештырган комиссиянең башка членнары килеп җитәчәк. Сезнең үз мәнфәгатегез өчен уйлану кирәк...

**Сатынский.** Рәхмәт, рәхмәт. Сез бик кешелекле, минем турыда кайгыртасыз... *(Бүләнеп.)* Француз хушбуемы? Миңа дигән бүкет!

К а ч а е в а *(көлеп)*. Керпе кебек чәнечкеле сез... Ашыйсым килә. Кичә сигарет тартып һәм куе чәй эчеп кенә көн уздырган идем. Безнең белән бармыйсызмы?

С а т ы н с к и й. Рәхмәт. Миңа сигарет белән куе чәй дә җиткән.

*Кесәсеннән бер пачка чәй чыгара, яңадан кесәсенә сала. Кул кысышалар. Кузгалып киткән машина тавышы. Сатынский ялгызы кала, авыз эченнән генә нәрсәдер сөйләнә, йодрык селки.*

А л с у *(Сатынскийга якынлашып)*. Һаман да үз-үзегез белән сөйләшәсезме, Коля абый?

С а т ы н с к и й. Сөйләшмим мин, соңгы сүземне генә әйтеп бетерәм... Гомерем буена бер генә дә, гафу итегез... сүгенү сүзе әйткәнем булмады. Бары тик авыз эченнән генә...

А л с у. Ә хәзер сүгенәсезме? Ә ничек була ул? Сүгенеп күрсәтегез әле, ә?

С а т ы н с к и й *(кесәсеннән яңа кулъяулык алып һәм аңа карап)*. Катлаулы маневр. Һава сугышындагы кебек... *(Алсуга карый.)* Ә синең аны күргәнең юк. Син әле ул вакытта булмаган да.

А л с у. Булмаганмын. Мин, Коля абый, сугыштан соңгы бишьеллыкта туганмын.

С а т ы н с к и й. Һава сугышын ичмаса бер күргән кеше... Төрлетөрле маневрлар... Һәм бары шулар. Маневрларның бетмәс-төкәнмәс элмәкләре... Тик җирдән генә шулай күренә ул.

А л с у. Ерактанмы?

С а т ы н с к и й. Су салып тор әле миңа. Югыйсә... ниндидер кулларны кыстым. *(Алсу бик азга гына вагонга кереп югала, аннан кружка тотып чыга... Сатынский кулларын сөртә... кулъяулыгын җиргә ташлый.)*

А л с у. Тагын комиссия булдымы, Коля абый, ә?

С а т ы н с к и й. Дәүләт комиссиясе шушы көннәрдә киләчәк, ә монысы болай гына... Маневрлар гына. Иснәнергә, сер алырга килгәннәр. Я, чәй кайнат әле миңа. Каты итеп кайнат. *(Чәй бирә.)*

А л с у *(кире әйләнеп килә, дулкынланган)*. Хәтерегездәме, моннан бер атна элек министр килде?.. Мин элек, кабинетта гына эшләп утырганга, министрлар юан буладыр, дип уйлый идем. Ә монысы ярыйсы, түзәрлек. Нәкъ шул вакытта мин субайлар өчен каркаслар ябыштыра идем. Ул минем янга да килде. Ябыштырасыңмы, ди. Ябыштырам, дим. Шуннан ул китеп барды. Чәчләре ап-ак, сөйкемле шундый. Менә сезнеке кебек! Ул да арыган кыяфәттә иде. Ә аны озатып йөрүчеләрдән бер яшьрәге миңа күз акайта, маймыллана башлады, ә мин аңа ваемсыз гына карадым. Шуннан ул юлдашларын куа китте.

С а т ы н с к и й *(утыра һәм көлә башлый)*. Күзләрең төпсез кое кебек синең. Сиңа карап, егетләр, мөгаен, һуштан язадыр?

А л с у. Хәзер үзем һуштан язам мин...

С а т ы н с к и й. Әйе... Кырык ел элек... Фросяның да... күзләре шундый ук иде.

А л с у. Нинди Фрося ул?

С а т ы н с к и й *(паузадан соң)*. Без ул вакытта Кузнецкида домна һәм мартен мичләре кора идек... Өйләнештек. Ә бер елдан, җыелышта чыгыш ясап, бөтен залга: ул — сыйнфый дошман, мин аның белән сәяси җирлектә мәңгегә аерылыштым, дип кычкырды. Үзенең бер кыйблага инанганлыгы белән гүзәл иде ул һәм саф та иде. Мөгаен, син дә шулайдыр. Үзеңчәдер.

А л с у. Ни сөйлисез сез, Николай Николаевич? Ни сөйлисез?

С а т ы н с к и й. Ни сөйлимме?.. Шул ук субай фундаментлары. Кустарь юл белән аннан-моннан гына эшләнделәр. Шул нигезгә мин

төзегән кечкенә бер объект... Үз идеямне генә харап иттем! Ә узган елны тагын очраштык. Очраклы гына... Бер карт, сырхау карчык һәм шул ук фундаментлар. Шул ук алтын балык. Бөтенесе шул субай тирәсенә әйләнеп кайта. Ә күзләре аның — синдә калган.

Алсу. Калган? Сез аны үлеп яраттыгызмы, Коля абый? Ул... Үлдеме?

Сатынский. Хаклы икәнлегемне исбат итәргә кирәк иде миңа, исбат итәргә. Бөтенесенә дә исбат итәргә! Минем фундаментлар ул вакытта илгә кирәк иде. Хәзер дә кирәк ул минем фундаментларым!

Алсу. Сез бәхетле. Сез күпне күргән. Сез яраткансыз. Ә хәзерге егетләр бер дә практик түгелләр! Капшарга гына остарганнар бары. Чирканыч.

Сатынский. Капшарга, дисеңме?.. Ямьсез сүз.

Алсу. Кичә йокларга яттык. Кемдер теш шыгырдата, ишектә тырмаша. Исерек. Бездәге бер кыз янына килгән. Ашханәдә окрошка таптырган кебек таптырмакчы.

Сатынский. Окрошка дисеңме?

Алсу. Анысын мисал өчен генә әйтүем.

Сатынский. Алай икән, алай икән.

Алсу. Шундый ачуым чыкты! Әйдәгез, мәйтәм, шуны адәм мәсхәрәсе итәбез. Сөйрәп алып кердек тә тегене, анадан тума чишендереп төртеп чыгардык. Ярый әле, төн иде. Шул да булдымы мәхәббәт? Түбәнлек бит бу, мәхәббәт түгел. Мәхәббәтне нәфис итеп күзаллыйм мин. Күз карашы белән дә бозылмаслык тынлык булсын ул!.. Мине тыңламыйсыз, ахры?

Сатынский. Шәп әйттең: күз карашы белән дә бозылмасын.. Шәп.

Алсу. Һаман үземнекен көтәм мин, Коля абый. Килергә тиеш бит инде ул. Минем өчен яратылган кешене әйтәм, ә?

Сатынский *(үзенекен уйлап).* Белмим. Белмим. Берни дә белмим мин.

Алсу. Бәлки ул бардыр да инде? Бәлки мин генә улмы, әллә ул түгелме икәнен белмимдер? *(Читкә карый.)* Машина килә!

Сатынский *(урыныннан күтәрелеп).* Димәк, гостиницага кайтып китәм. Минем өчен авыр көннәр булачак, Алсу, авыр!

Алсу. Ә мин сезнең тамакны туйдырмакчы идем. Егетләр-кызлар ашханәгә китте, мин биредә бәрәңге пешерәм.

Сатынский. Рәхмәт. Башка вакытта. Син пешергән кабыклы бәрәңгене башка вакыт татып карарбыз.

Алсу. Без барысын да эшләячәкбез, Коля абый. Борчылмагыз сез. Төннәрен эшләрбез. Коля абый, яратмаган кешеләрегез бар бит сезнең, әйеме?

Сатынский. Яратмаган?

Алсу. Телисезме, сихерлим мин аларны? Мин бит барысын да булдырам. Күзем каты минем.

Сатынский. Күзегез каты булгач, кирәкми. Кирәкми.

Алсу. Куркасызмы, әллә ышанмыйсызмы?

Сатынский. Ышанам, ышанам.

Алсу. Телисезме, күрәзәлек итәм? Кулыгызга карап та булдыра алам, карта белән дә, йөзегезгә карап та. Теләсәгез, ничә ел яшәячәгегезне әйтәм? *(Янына тиз генә килеп, куллары белән Сатынскийның башын кысып тота һәм, керфек тә какмый туры карап, бармаклары белән кашлар өстендәге маңгай тиресен тарттырып карый.)* Курыкмагыз, нәрсәдән куркасыз?

Сатынский *(кинәт булган бу хәлдән аптырап калып).* Нишлисең син, нишлисең?

Алсу *(читкәрәк китеп, аңа текәлеп карап торуын дәвам иттерә).*

Хәзер сезгә алтмыш ике яшьме? Тагын егерме дүрт елдан, сиксән алты яшьтә үләчәксез. Аракы эчсәгез дә, тәмәке тартсагыз да, машина астына керсәгез дә, сезгә берни булмаячак!

Машина тавышы ишетелә. Сатынскийга һәм Алсуга күренмичә, Саттаров белән Әхмәдуллина керә. Мондагы күренешне күпмедер вакыт елмаеп карап торалар. Аннары Әхмәдуллина китә.

Саттаров *(Сатынский белән Алсуга таба атлап)*. Ә миңа багасыңмы? Минем дә эчәсем, машина астына керәсем килә — тик берни булмасын гына! Сәлам, Николай Николаевич. *(Сатынскийның кулын кыса.)*

Алсу. Ә син кем буласың? *(Танып.)* Ә-ә... Юк, сезгә бакмыйм.

Саттаров. Ә ни өчен?

Алсу. Сезгә ярамыйдыр. Сез шәһәр комитеты секретаре...

Саттаров. Нәрсә яраганын, нәрсә ярамаганын син дә беләсеңмени? Барысы да белә, тик мин генә белмим... Бәлки багарсың, ә? Ышануын ышанмам, ә шулай да уйланырмын. Багасыңмы?

Алсу. Әгәр теләсәгез... *(Саттаров янына килә, аның күзләренә карый да кинәт артка чигенә.)*

Саттаров *(маңгаен сөртеп)*. Көч тә соң үзеңдә! Бармаклар түгел, ә шайтан белсен нәрсә... Ник дәшмисең?

Алсу *(коелып төшеп)*. Утыз җиде яшьтә син...

Саттаров *(ачулы мыркылдый)*. Нәрсә, утыз җиде? Миңа хәзер үк утыз җиде инде.

Алсу. Белмим. Берни дә белмим мин.

Саттаров *(аның тавышы ничектер үзгәрә)*. Сөйлә!

Алсу. Болай гына... уен гына бу. Бер ахмаклык. *(Китә.)*

Саттаров. Минә сиңа күрәзә! Сиңа барын да сөйләде, ә миңа сөйләми... *(Озак паузадан соң.)* Нинди кыз ул?

Сатынский. Сварщица. Алсу. Ничектер сәер генә танышып киткән идек. Кайчакта сөйләшкәлибез шулай.

Саттаров *(инде эшлекле тон белән, моңа кадәр булганнарның барын да онытып)*. Я?.. Булдылармы?

Сатынский. Булдылар... Әле генә... Испәнергә килгәннәр. Конкурент проект институтыннан бер ханым — Качаева белән субподряд министрлыгыннан Гоголев...

Саттаров. Амстрдамнан килгән түти... Я, шуннан?

Сатынский. «Яклыйбыз», диләр. Барысы да: «Яклыйбыз!» — ди. Әмма сынауларны дәвам иттерергә кирәк, имеш. Куркам мин, Гайнан... Сәлимович. Дәүләт комиссиясе булмас, бары тик тар ведомство комиссиясе булыр, дип куркам. Составы белән генә түгел, мәсьәләгә карашы белән дә...

Саттаров. Булсын! Сынау нәтиҗәләре белән ышандырырбыз без аларны! Ачыктан-ачык көрәшкә чыгарга телиләр икән, рәхим итсеннәр, дәрәҗәләрен, исемнәрен картага куеп сөйләшсеннәр.

Сатынский. Бары да алай җиңел генә һәм гади генә түгел шул.

Саттаров. Өметем синең фундаментларда минем. Тулы бер ел отачакбыз... Отачакбыз, Николай Николаевич, икенче бер эштә оттырган елны отачакбыз! Матур!

Сатынский. Нәрсә матур?

Саттаров. Нигез базы казырга да, йөзләгән миллион кубометр балчыкны бер урыннан икенче урынга ташырга да кирәкми... Эшкә фикер салынса...

Сатынский. Мин сезгә эш турында сөйлим, Гайнан Сәлимович.

Саттаров. Ә мин нәрсә турында сөйлим соң?

Сатынский. Бары да алай җиңел генә түгел шул... Сезнең буынга барысы да җиңел генә килде! Сезгә бөтенесе гади тоела!

Саттаров *(кырыс)*. Минем әти Магнитка төзелешендә һәлак булды. Әнием сугыш елларында үлде. Аннары балалар йорты, завод, армия... Мин слесарь булып эшләдем һәм юридик факультетны тәмамладым.

Сатынский. Шулай да сезгә бөтен нәрсә җиңел кебек тоела. Фирмалар белән контрактлар, поставщиклар белән договорлар... Бу эшкә бөтенесе тартыла, бөтенесе җигелә! Һәркемгә барын да яңабаштан карарга кирәк булачак. Эш Гоголев белән Качаевада гынамы соң?! Алар — өскә калыккан күбек кенә. Заказ бирүчеләр үзләре дә каршы бит! Ә күпме тәвәккәллек! Практик яктан алганда, бер генә завод та субайда утырмый, бер генә завод та!

Саттаров. Утырмаса, утырыр! Я? Мә, тот! *(Саубуллашып, кулын суза.)*

Сатынский. Миңа инде ялгызак бер кустарьчыга, бар кешегә комачаулаучы сару кайнаткыч картка караган кебек карый башладылар. Ә — мин проект эшләүче бит! Әйтерсең болар минем төп вазифам түгел, ә нindидер бер кирелегем, саташуым гына.

Кинәт сәхнә артында шау-шу.

Тавышлар. — Гәрәев... прораб.
— Гәрәев кайда?
— Юк ул!
— Байковны чакырыгыз! Тизрәк!
— Шалтыратырга кирәк!
— Шалтырату нигә? Исән чакта алып китәргә кирәк!..

Виктор Дурылин күренә. Кулында көрәк. Җиргә карап әкрен генә атлый.

Виктор *(Сатынскийга)*. Алсуны күрмәдегезме?

Саттаров. Зур күзле кара кызнымы?

Виктор *(ачуыннан ярсып)*. Зурмы, түгелме, анда синең ни эшең бар? Синнән сорамыйлар бит.

Саттаров. Ә нигә? Картракмы әллә? *(Кырыс.)* Ни булды?

Виктор *(Сатынскийга карап)*. Берәр начальник кисәгедер әле бу?

Саттаров. Әйтик, алай ук түгел дә ди. Ә эш нидә?

Виктор *(Саттаровка таба атлап)*. Кызларга күз атып йөргәнче, эш вакытында эш белән шөгыльләнергә кирәк, менә шул.

Саттаров. Шуннан?

Виктор. Шуннан шул менә! Төрле диспетчерлар күбәйде. Начальниклар үрчи! Ике экскаваторны бер-берсенә терәтеп куялар да, аннары кешеләр үлә.

Саттаров. Шуннан?

Виктор. Нәрсә шуннан? Нәрсә?! Өченче көн вак таш ташыдым. Ярты көн буе миңгерәүләнергә туры килде. Юлларда бернинди күрсәткеч юк! Кичә бетон төядем. Ә кемгә илтергә? Ярый әле, юл төзүче хатын-кызлар очрады. Аңладыңмы инде?

Саттаров. Аңладым.

Виктор. Бүген тагын бетон. Алучысын таптым, ә алар аны өем итеп катырдылар! Бетонга заявка бирүен биргәннәр, китергәч — инде кирәкми. Түктерделәр! Аңладыңмы?

Саттаров. Аңладым.

Виктор. Мин барып килгән арада, дус егетемне балчык баскан. Аңладыңмы? *(Җавабын бүлдереп.)* Аңласаң, күзеңне әнә шуларга чекерәйт. Бардак бит бу! Ник тел талдырып сөйләп торам соң әле. *(Көрәген бер читкә ыргытып, китә.)*

Вадим Байков күренә.

Саттаров *(аны тотып)*. Ни булды?

Вадим. Гафу итегез, Гайнан Сәлимович! Больницага шалтыратырга кирәк! Носилка белән каршы алсыннар! *(Йөгереп китә.)*

Саттаров *(Сатынскийга)*. Киттек.

Китәләр. Виктор белән Алсу керә.

Алсу. Кемне?

Виктор. Петька Леснякны... балчык белән комде. Саратов ГЭСында ук бергә тир түккән идек, ә монда... Хатыны бүген бала тудыру йортыннан чыга. Механизмнарны шундый ахмакларча куйганнар.

Алсу. Ә ул ни хәлдә?

Виктор. Петькамы? Леснякмы? Аны алып киттеләр. *(Паузадан соң.)* Аның турында сорамадың син. Зур начальник малае турында сорадың бугай? Курыкма, әтисе яклап калыр әле!

Алсу. Ник килдең? Үч алыргамы?

Виктор. Ә син? Нишләттегез кичә мине? Чишендердегез! Оятка калдырдыгыз!

Алсу. Исерек килеш башка күземә күренәсе булма! Сөйрәлеп килдең бит. Горурлык хисе юк синдә.

Виктор. Синең алда бернинди дә горурлыгым юк минем! Синең алда кирәге дә юк аның: юри эчтем мин кичә. Яратам мин сине! Токтогул ГЭСыннан синең өчен килдем мин монда! Минеке бит син!

Алсу. Синеке булырга, ничек сатып алдың соң әле син мине? Кирәгең юк миңа.

Виктор. Ә кем кирәк сиңа? Ул кирәкме? Синең аңа, аның сиңа ничек карашканыгызны хәтерлим мин! Аның кешеләре үлә... Хәтерендәме, теге күзлеклене һушыннан язганчы тукмаган өчен бер ел утырып чыктым. Тагын утырачакмын! Ә монысы өстеннән КрАЗ белән үтәрмен. Дустымны үтерде ул минем, сине миннән тартып алды.

Алсу *(аны төрткәләп)*. Бар, бар, кит!

Виктор. Бик кирәгең бар ди синең аңа! Төзелеш начальнигы малае... Сиңа өйләнер дип уйлыйсыңмы? Синең кебекләрнең бәясе базар көнне дә...

Алсу *(ярсып)*. Минем кебекләр... Дөньяда берәү генә мин. Җир йөзендә миллионлаган ат бар, аларның һәрберсе бердәнбер. Һәрберсе. Без генә ул, атлар, дибез. Бездән тизрәк чапканнарын, оча алмауларын беләбез. Ә бәлки берәрсе оча да торгандыр әле?

Виктор. Атларның ни катнашы бар монда? Нинди атлар?

Алсу. Атлар булмаса, наратлар! Күптән түгел генә бер шигырь укыдым. Нарат турында. Ишегалдында асфальтка җыелган су эчендә үсеп утыра. Кер киптерү өчен кадак кагалар, бау тарттыралар аңа. Ә ул китә дә бара. Керләре белән бергә урманга китә.

Виктор. Мин бүген тагын эчеп исерәм. Тагын киләм.

Алсу. Бәлки син мине яратасыңдыр, ә миңа... кирәкми, аңлыйсыңмы? Ни гаебем бар минем?

Виктор. Ни гаебеңме? Матур син!.. Барысы да тыныч, тын булсын өчен... үтерергә кирәк сине! Әллә синең өчен мин генә җан атаммы? Барыбер калмыйм мин синнән.

Алсу. Беркайчан да синеке булмам. Мин үземнекен көтәм. Минем өчен түгел син!

Виктор. Ә яратам бит мин!

Вадим күренә.

Алсу. Яратасың икән, ярат. Минем ни эшем бар, ярат!.. Күпләр бер-берсен яраталар һәм бер-берсен харап итәләр. *(Вадимны күрә.)*

**Виктор** *(ул да Вадимны күрә)*. Син дә килдеңмени?.. Очраштык та менә...

**Вадим.** Сез миңа әйтәсезме?

**Виктор.** Сиңа... Әйдә, киттек, тормышлар турында сөйләшеп алыйк.

**Вадим.** Ни турында?...

**Алсу** *(Викторга)*. Зинһар кит, Виктор. Үтенеп сорыйм!

**Виктор.** Очрашырбыз әле без синең белән. Очрашырбыз!..

Виктор китә.

Русча жыр ишетелә: «Ванька Морозовка ник тияргә, аның бит бернинди дә гаебе юк? Егет башын кыз үзе әйләндерде... Чыбык буйлап атлады ул кыз һәм шул чакны ак аягын болгады...» Сөйләшү жыр фонында бара.

**Алсу.** Беләм мин сине. Вадим исемле бит син.

**Вадим.** Ә син — Алсу!..

**Алсу.** Әйе.

**Вадим.** Алсу... Мин әле синең исемнең татарчадан тәрҗемәсен дә беләм: «Вода», «возьми»! Су ал!

**Алсу.** Әйе...

**Вадим.** Яки алсу су. Яки нәфислек. *(Китмәкче була.)*

**Алсу.** Авырмы сиңа? Яшәрме ул?

**Вадим.** Белмим. Ярты тонна чамасы балчык астында калган... Хәзер генә алып киттеләр. Мин... гаепле монда.

**Алсу.** Килә идең... Син хәзер минем янга килә идеңме?

**Вадим.** Белмим.

**Алсу.** Авыр сиңа, әйеме?

**Вадим.** Синең белән мондый көнне очрашырбыз дип уйламаган идем.

**Алсу.** Белдем мин синең киләсеңне. Һәм көттем дә.

**Вадим.** Ә мин... Хәтереңдәме, бер ай элек...

**Алсу.** Әйе...

**Вадим.** Син, мөгаен, аңламагансыңдыр?

**Алсу.** Аңладым.

**Вадим.** Ә мин...

**Алсу.** Әйе.

**Вадим.** Төнен вагон тирәли йөрдем...

**Алсу.** Әйе. Белдем мин. Белдем.

**Вадим.** Күзләрең... Сихерченеке кебек.

**Алсу.** Татар кызы мин.

**Вадим.** Татар әкиятләрендә ни өчендер барлык сихерчеләр шундый коточкыч... Ярты тонна диярлек балчык! Бөтенләй изгәндер ул аны!

Чыр-чу килеп, көлешеп, Гәүһәр белән Нюра күренә.

**Нюра** *(Алсу белән Вадимны күреп)*. Ай-яй!

**Гәүһәр.** Нинди яшь егет!

**Вадим.** Салют!

**Гәүһәр.** Сәлам!

**Вадим.** Киттем мин, Алсу. *(Китә.)*

**Гәүһәр.** Ярыйсы-ы!

**Нюра.** Менә егет бу, ичмасам!

Музыка. Жыр.

*
* *

Байков кабинеты. Кайдадыр якында гына тулай торактыр, күрәсең. Музыка шаулый.

Б а й к о в *(телефонга).* Беренче төзелеш кенә түгел бу минем! Әмма ансыз булдыра алмыйбыз! Иң кыен вакытлар җитәчәк. *(Пауза.)* Аппетит дигәннән... Аппетит бит төзелеш мәйданына бәйле. *(Пауза.)* Илле җиде миллион сум җитми... *(Кулы белән микрофонны каплый, ярсып.)* Нәрсә, без бу музыканы көне буе тыңларбыз микәнни?

М ө н и р. Нindидер бер сөрхәнтәй, күрәсең.

Б а й к о в. Сөрхәнтәй икән, акылына утыртырга кирәк. Югыйсә, анда, Мәскәүдә, болар музыка гына тыңлап яталар икән дип уйлаулары бар. Белеш әле шәһәр властьларыннан, аларның музыкага мөнәсәбәтләре ничегрәк икән.

М ө н и р. Яхшы, Иннокентий Владимирович. *(Югала.)*

Б а й к о в *(телефонга, башка тон белән).* Проектлаштыручылар һәр вакыт аяк чала. Проект түгел, нindидер дуңгыз абзары. *(Пауза.)* Яхшы, яхшы. Сау булыгыз... *(Трубканы ташлый, йөзен җыера.)*

Баш механик Дунаев керә, радиодинамикны тоташтыра.

Д у н а е в. Хәзер безнең турыда булачак. Кабул иту булмәсендә ишеттем... Нигә чакырдың?

Д и к т о р т а в ы ш ы. Шушы көннәрдә безнең хәбәрчебез республикабызда төзелә торган Ватаныбыз индустриясенең гигант төзелеше начальнигы белән очрашты һәм аннан төзүчеләрнең бүген нinди уйлар белән яшәве турында сөйләвен үтенде.

Х ә б ә р ч е т а в ы ш ы. Иннокентий Владимирович! Менә хәзер, елның уртасында, сезнең карашча, эштә иң мөһиме нәрсә? Иң четрекле, иң хәлиткеч проблемалар нидән гыйбарәт?

Б а й к о в т а в ы ш ы. Кыска гына итеп әйткәндә, бу ел — безнең комплекс төзелеше өчен хәлиткеч ел. Беренчедән, хәзер заводның барлык объектларында эш башлана. Икенчедән, киләсе елда нормаль эшләү өчен нигез салына. Без барыбыз да төзелешнең быелгы елы удар темпта үтәр дип ышанабыз.

Б а й к о в *(документлар тулы папка чыгара, динамикны ычкындыра).* Куеп җибәр әле кулыңны. Баш механик имзасы белән саллырак булыр.

Кабинетка С а л и к о в а керә.

С а л и к о в а. Гафу итегез, Иннокентий Владимирович, сезнең янга иркенрәк итеп кайчан керергә мөмкин? Киңәшәсе бар иде.

Б а й к о в *(аңламыйча).* Нәрсә турында?

С а л и к о в а. Бәхетсезлек очрагы турында киңәшәсе бар, Иннокентий Владимирович. Мин... Леснякны күздә тотам. Теге... кою заводы участогындагы...

Б а й к о в. Нәрсәсен киңәшергә? Тикшерегез.

С а л и к о в а *(өстәл янына килеп).* Әйе-әйе! Анда бер инженер, прораб, авыру булуын сылтау итә... Үз белдеге белән котлованны ташлап киткән.

Б а й к о в. Тикшерү материалларын һәм приказ проектын минем өстәлгә китереп куегыз. *(Дунаевка.)* Я, нәрсә басып торасың?

Д у н а е в. Тагын өстәмә техника кирәкме?

Б а й к о в. Запас эчне тишмәс.

Д у н а е в. Күз яшенә чыланган кәгазьләрне Госпланга бик еш язабыз түгелме? Туйдым мин аларга кул куеп!

Саликова. Гафу итегез. Миңа аңлашыла. *(Ишеккә юнәлә.)*

Байков *(ярсулы)*. Борчылма! Имчәге бар, имәргә кирәк.

Саликова *(ишек төбеннән)*. Аңладым!

Байков. Нәрсә?

Саликова. Аңладым! *(Чыга.)*

Дунаев. Ил кесәсе зур, әлбәттә...

Байков. Үзем дә белгән нәрсәгә ышандырып маташма син мине.

Дунаев. Төзелештә техника норма буенча бик җиткән. Ә без тагын сорыйбыз. Намусыбызны югалттык.

Байков. Норма буенча дисеңме? Ә бу махинаның шундый кыска срокта төзелүенә норма кая? Синең намусың белән нишлим мин, җир казыйммы әллә?

Мөнир Зарипов керә, динамикның штепселен розеткага тыга.

Мөнир. Иннокентий Владимирович, сез!..

Байков тавышы. Безгә Ватаныбыз бик юмарт бирә торган техниканы хуҗаларча файдалану проблемасы — иң мөһиме. Һәм бу проблема кадрлар проблемасы белән тыгыз бәйләнгән. Быелның ахырына кадәр генә дә без утыз меңнән артык кеше кабул итәчәкбез. Безнең бурыч — кешегә нормаль яшәү өчен кирәкле барлык шартларны булдыру...

Байков *(штепсельне ачу белән розеткадан тартып алып, Мөниргә)*. Син нәрсә? Экият тыңларга вакытыбыз бармы әллә безнең монда? Кем кушты сиңа бу музыканы монда кертергә? Туктат тизрәк, шайтаныма олаксын!

Ярдәмче ашыгып ишеккә чигенә, репродукторны да алып китә. Шул ук вакытта тәрәзә аша ишетелгән музыка да тынып кала.

Менә... ичмасам, монда җиңдек. Бер сөрхәнтәйне ничек тә булса җиңдек, ә үзебез борын салындырабыз... *(Дунаевка.)* Я?

Дунаев. Материаль-техник ресурска мондый мохтаҗлыкны Госпланда исбат итә алмыйм мин.

Байков. Төзелешнең дошманы булырга уйлыйсыңмыни?

Дунаев. Шелтәләр белән куркытырга кирәкми, Иннокентий Владимирович. Мин үз гомеремә аларны шул хәтле күп алдым ки, обой урынына алар белән бөтен фатирым стеналарын сылап чыга алам. Син әле генә әнә хәбәрчегә бөтенләй бүтәнчә сөйләдең...

Байков. Моңарчы мин сезне начар белгеч дип исәпләмәдем. Моңарчы сез план органнарыннан кирәк нәрсәнең барысын да ала алдыгыз.

Дунаев. Чөнки мин элегрәк кеше идем. Ә хәзер талаучы кебек. Моны минем күземә үк карап әйтәләр инде. Үзегез барыгыз да Госпланга, үзегез сорагыз...

Байков. Юк инде, кадерлем, син барырсың.

Дунаев. Бармыйм, Иннокентий.

Байков. Төзелеш патриоты булмаган берәүне дә янымда тотмадым мин.

Дунаев. Төзелеш патриотымы, илнекеме?.. Болай гына китмим мин. Үз теләгем белән китү турындагы гаризаны өстәлгә китереп куймаячакмын! Андый теләк юк миндә! Син миңа икенче нәрсәне әйт: төзелешнең мөһимлеге белән кайчанга кадәр авыз чайкарбыз? Сатынский идеясен тизрәк гамәлгә ашырырга кирәк, ә без умырабыз да умырабыз — техникасын да, акчасын да!

Байков. Ташла син буш идеяләреңне! Күктә торна күп ул! Ә монда шайтан белмәс хәлләр. Цемент, әнә, нибары ике көнгә җитәр-

лек. Баржалар әле моннан алты йөз километрда! Куясыңмы кулыңны, юкмы?

Д у н а е в *(паузадан соң).* Юк.

Карап торуга чандыр гына, әмма үз вазифаларын төгәл белүче ярдәмчедән ычкынып, кабинетка бала күтәргән хатын керә. Бала елаган тавыш.

М ө н и р. Буш түгел ул, буш түгел!

Т а и с и я. Кит, дим, кит! Нәрсә дип баланы этәсең син? Кеше туарга өлгерми, аны инде төрткәли дә башлыйлар!

М ө н и р. Иннокентий Владимирович пәнҗешәмбе көн кабул итә, сәгать өчтә.

Т а и с и я. Ә пәнҗешәмбегә, сәгать өчкә кадәр ни эшлим ди мин?

Б а й к о в. Акрынрак! Чын базар оештырдыгыз. *(Ярдәмчесенә.)* Керсен! *(Хатын аның өстәле янына килә.)* Я? Бер-ике сүз белән генә аңлат!

Т а и с и я. Менә... бала таптым.

Б а й к о в. Котлыйм.

Т а и с и я. Кайчандыр ул да төзелештә эшләсен дип таптым. Бала табып яткан арада тулай тораktан чыгарып атканнар... Өеңә кайтып кит, балаңны шунда тәрбиялә, диләр. Кайгырталар, имеш. Ә өем кайда соң минем, сорадылармы шуны? Петя хатыны мин! Аның кабере яныннан кая китим ди хәзер?

Б а й к о в. Нинди Петя? Кайсы Петяныкы?

Т а и с и я. Петя Леснякныкы! Моннан ике көн элек үлгән экскаваторчыныкы... Хәзер үксеп еларга кирәк, ә мин менә башканы уйлыйм!

Б а й к о в. Туктагыз әле, туктагыз. *(Селектор кнопкасына басып.)* Дания Кәримовна, бер генә минутка кереп чыгыгыз әле.

Т а и с и я. Моның белән кая барыйм инде мин? Комендант әйтә: бала белән тулай торакта торырга ярамый, ди. Ә яшәр урыным юк.

Б а й к о в *(уйланып).* Тору урыны эшчеләр җитмәгәнгә җитми, ә эшчеләр тору урыны җитмәгәнгә җитми. *(Пауза.)* Менә шуларны ничек балансларга?

Т а и с и я. Миңа сезнең балансыгыз кирәкми. Барыбер берни дә аңламам. *(Баласын күрсәтеп.)* Миңа менә бу кеше өчен тору урыны кирәк. Беркая да китмим. Миңа штукатура өчен, сиңа балансларган өчен акча түлиләр. Кирәгенчә балансла менә шуларны!

Б а й к о в. Әйе-е... Гафу итегез. *(Тора, аның янына килә, балага карый.)* Димәк, кеше туды... *(Дунаевка.)* Ни эшләргә инде хәзер моның белән? *(Таисиягә.)* Арыдыңмы? *(Үзенең кәгазьләр белән тулы зур өстәлендә урынга охшаш бер нәрсә әмәлли.)* Әлегә куй әле шунда...

Т а и с и я. Шушы кәгазьләр өстенәме? Кәгазь кирәкми аңа!

Д у н а е в. Куй, куй.

Б а й к о в. Бөтен крайның киләчәге шушында! Киләчәк өстендә ятсын. *(Таисиягә.)* Дуамалрак хатын син! *(Пауза.)* Сезнең никах рәсмиләштерелгәнме?

Т а и с и я. Жилстройда эшлим мин, штукатур булып. Икебез ике тулай торакта яшәдек.

Б а й к о в *(түземлелек белән).* Язылышкан идегезме сез?

Т а и с и я *(паузадан соң).* Язылыштыгызмы, язылышмадыгызмы! Хатыннар мәхәббәтендә ни аңлыйсыз соң сез! Юк!.. Ул... без әле язылышырга җыенган гына идек. *(Елый.)* Аны сезнең улыгыз эшли торган участокта җир басып үтерде!

Б а й к о в. Беләм.

Бала елавы.

Т а и с и я *(тирбәтеп)*. Мин... болай гына.

Б а й к о в. Минем улымны, түгелме, анысын тикшерерләр... *(Пауза.)* Белерләр. *(Балага карап.)* Малай... *(Бәби өстенә иелә. Дунаев та балага карый. Иелгәндә бәрелешәләр.)* Имза саласыңмы син, әллә юкмы?

Д у н а е в. Юк. Кара әле, ул синең киләчәгеңне юешләп алмасмы хәзер?

Икесе дә көлә. Бәби аларны килештерде.

Б а й к о в *(Дунаевның иңсәсен этәреп)*. Ярый, бар! Аннары сөйләшербез! *(Дунаев китә.)* Шундый онык турында хыялланам мин... Кара әле, калдыр син аны миңа, ә? Ичмасам, бер генә атна булса да карармын.

Т а и с и я. И-и, нинди тәрбияче чыксын ди ул синнән. Күкрәк сөтеңне дә имезерсеңме? Баланс түгел ул сиңа.

Б а й к о в. Бер генә атна булса да карармын.

Д а н и я К ә р и м о в н а Ә х м ә д у л л и н а керә. Бөтен килеш-килбәтендә ирләргә охшашлык бар — эшлекле йөз, эшлекле йөреш, кырыслык, тәвәккәллек.

Б а й к о в *(Әхмәдуллинага)*. Менә... бу хатын... бала табу йортында булган арада тулай торактагы урынын алганнар. Кемгә дә булса тиз арада тикшерергә кушыгыз. Комендантны... эшеннән куудан да тартынмаска!

Т а и с и я *(өмет белән)*. Балансга һәр вакыт кирәкле ярык табарга мөмкин.

Б а й к о в *(Таисиягә борылып)*. Ярый, әни кеше, ярый. Бар. Хәерле булсын. Ярдәм итәрбез. Ни эшләмәк кирәк? *(Әхмәдуллинага.)* Хәзер үк табыгыз.

Т а и с и я *(әле Байковка, әле Әхмәдуллинага карый)*. Урнаштырмый торып, беркая да китмим.

Б а й к о в. Шулай, кечкенә семьялыларга дигәнне бирегез. Резервтан.

Ә х м ә д у л л и н а. Колачны ул кадәр киң җаярга ярамый, Иннокентий Владимирович. Хәзергә квартираларым юк минем.

Б а й к о в. Табыгыз.

Ә х м ә д у л л и н а *(хатынга салкын гына карап тора, кәгазь кисәге ала, нәрсәдер яза, ачкыч ала)*. Сез арыгансыз, йончыккансыз. Менә адрес, ачкыч. Гафу итегез, хәзергә минем сезнең белән шөгыльләнергә вакытым юк.

Т а и с и я. Бу квартираны... сез миңа бирәсезме?

Ә х м ә д у л л и н а. Минем квартирам ачкычы. Әлегә шунда яшәп торырсыз.

Хатын китә.

Б а й к о в *(звонок кнопкасына басып һәм шундук кабинетка кергән ярдәмчесенә карап)*. Син нәрсә, Мөнир. *(Каты.)* Кабатлап әйтәм: шәхси йомыш белән кабул итү вакытым — пәнҗешәмбе көнне сәгать өчтә. Бу турыда кешеләргә минем кабинетта түгел, ә кабул итү бүлмәсендә төшендерергә кирәк. Ә балалы хатынны төрткәләп чыгару?! Мондый мәсьәләләр буенча!..

М ө н и р. Аңлыйм, Иннокентий Владимирович. *(Чыга.)*

Б а й к о в. Киң күңеллелек күрсәтәсезме? Күчмә йортларга ник кертмисез кешеләрне?

Ә х м ә д у л л и н а. Әзер түгел алар. Бернинди коммуникация дә юк. Коры стеналар гына.

Б а й к о в. Миңа бу айда унбиш мең кеше кабул итәргә кирәк. Юкса, икенче ярты еллык план пыран-заран киләчәк... Кая урнаш-

тырыйм мин аларны? Бу хатынны, аның баласын кая куйыйм мин? Бу инде безнең бала, Дания Кәримовна, төзелеш баласы. Бүген үк кертә башлагыз күчмә йортларга.

Әхмәдуллина. Хәтта су да юк бит анда.

Байков. Түзәрләр! Әлегә цистерналар белән ташып торырбыз.

Әхмәдуллина. Боларның барысын да туктатмасак, без шәһәр төзербез, завод төзербез, ә тирә-як коточкыч кырмыска оялары кебек алачыклар белән тулыр. Бик тирәнгә кереп батуыбыз мөмкин.

Байков. Сез нәрсә? Үз принципларыгыз алдында бөтен төзелешне тезләндерергә телисезме? Аңламый дип уйлыйсызмы мине? Тормыш таләп итә!

Әхмәдуллина. Өченче көн яр буена списать ителгән дүрт пароход килеп туктады. Ә поселокка әлегә кертә алмыйм.

Байков. Кертә алмыйсыңмы? *(Яңадан ярсып.)* Алайса, төзелеш белән дә'үзең үк шөгыльлән.

Әхмәдуллина. Әгәр дә көнкүреш буенча урынбасарыгызның эше аз булып тоелса һәм аның вазифасына әле төзелеш тә керә дип исәпләсәгез...

Байков *(звонок кнопкасына басып).* Сындырырга кирәк сезне, Дания Кәримовна, сындырырга.

Әхмәдуллина. Сындырыгыз. Сыгылырга ничектер күнекмәгәнмен.

Байков *(йөзен чытып, ачуын яшерергә тырышып).* Ярый! Күчмә йортларга кертүне ике атнага кичектереп торабыз. *(Ул бик тә арыган.)*

Әхмәдуллина китә, ярдәмчесе керә.

Җир эшләре ничегрәк? Металл конструкцияләрне монтажлау ничек бара?

Мөнир *(кәгазьләргә карап).* Тулы булмаган мәгълүматларга караганда...

Байков. Кемгә кирәк сезнең тулы булмаган мәгълүматларыгыз?

Мөнир. Информация әле эшкәртелә генә.

Байков. Начар! *(Пауза.)* Димәк, начар эшкәртелә. Димәк, кирәкле кешенең койрыгын начар борасың. Әгәр тагын бер тапкыр әзерләнми килсәгез, тулы булмаган мәгълүматларыгыз белән бергә үз теләгегез белән эштән китү турында гариза китерегез! Башын төятөя өйрәтсәң, куян да шырпы сыза беләчәк!

Мөнир. Ә мин куян түгел, Иннокентий Владимирович. *(Кесәсеннән кәгазь чыгарып.)* Менә, рәхим итегез!

Байков. Нәрсә бу?

Мөнир. Гариза. Җибәрегез мине, заводка җибәрегез! Инде бит вәгъдә дә биргән идегез! Төзү-монтаж идарәсе бирәм, дидегез!

Байков. Җибәр дисезме?! *(Гаризаны ерта, кәрзингә ташлый. Мыгырданып.)* Миңа бирелә, бәлкем, синең кебек башлы, шул ук вакытта синең кебек тискәре кеше кирәктер? Әйдә, язуны тәгәллик. *(Селектор буенча.)* Беркемне дә кертмәскә. *(Мөниргә.)* Нәрсә иде әле анда? Нәрсәдә тукталган идек?

Мөнир *(язылганнарны тиз-тиз укып).* «...төзелештә шундый хәл туды... Эшнең тиешле темпын ала алмыйбыз...»

Байков *(бүлдереп һәм булмә буйлап йөренеп).* Яз! «Җентекле инженерлык тикшерүе планны формалаштыруда җитди кимчелекләрне ачты. Хөкүмәт карарында билгеләнгән объектларны сафка кертү өчен өстәмә 56,9 миллион сум акча кирәк».

Мөнир *(бер үк вакытта яза да, сөйли дә).* Проектлаштырганнан кыйммәткәрәк төшә безнең төзелеш. Проектлаучылар, мөгаен, безне

Госпланның башын бутыйлар дип расларлар. Шулай түгелме, Иннокентий Владимирович?

Б а й к о в *(кызып).* Акыл сатма, яз!.. Җиңүчеләрне хөкем итмиләр. Шул. Яз! «56,9 миллион сум». Нокта!..

*
* *

Төнге дала күренеше. Күктә — йолдызлар, җирдә — хәрәкәт итүче утлар. Тәҗрибә полигонындагы бушлык. Юл. Кулларына чемоданнар тоткан егетләр һәм кызлар төркеме үтеп бара.

А ш о т. Кадрлар бүлеге кайда бирердә?

Ю р и й. Борчылма, таңга кадәр шушында да үткәрербез! Гражданочка, гражданочка, булышыйммы сезгә? Алай-болай ялгышып минем авылдан түгелме сез? Кайдадыр очрашканыбыз бар кебек?

Р у ш а н и я. Ай, тигәнәк! Мә, күтәр!

Ю р и й. Их, куянкай гынам! Өске сәндерәдән йөзеңне күргәч тә телсез калдым. Үзем карыйм, үзем нинди ягымлы, нинди кадерле йөз дип уйлыйм. Ай, чибәркәй генәм!

Р у ш а н и я. Чибәркәй генәң түгел, иргә чыкканыма алты ел инде минем!

Ю р и й. Ирдәмени?! Хатын кеше кирәк тә инде миңа! Завод һәм семья корырга килдем мин. Ә син, сеңелкәем, ни хәлдә? Әниең ничек җибәрде сине?

В е р а. Үзем килдем мин.

Ю р и й. Димәк, үз көнеңне үзең күрә башладың?

Р у ш а н и я. Нигә дип бала-чагага бәйләнәсең әле син?

Ю р и й. Көнләшмә чибәркәй генәм... Сине яратам, дип әйттем бит инде. *(Верага.)* Бир, бир, мин дә берәр нәрсәңне күтәреп барыйм. Югыйсә, минем каккан казыгым да, йортым да, гаиләм дә, чемоданым да юк.

В е р а. Ә сез... соңыннан аны үземә бирерсезме соң?

Ю р и й. Әй, бәләкәчем! Ничек кыерсытыйм ди инде мин сине? Зурларны гына кыерсытам мин! Зурларны гына! Минә мондый хатыннарны, шундый крокодилларны!.. Күрдеңме, нинди крокодил!

Р у ш а н и я. Мактанчык!..

К ы з. Утларын кара әле! Газеталарда дөрес язганнар икән!

Ю р и й. Ә монысы кем?

А ш о т. Француз теле укытучысы.

Ю р и й. Нәрсә, нәрсә? Ишетәсеңме... Ашот — укытучы?! *(Рушаниягә.)* Минә синең белән французча аңлашырбыз.

Барысы да китә. Сәхнәдә — Байков белән Саттаров.

С а т т а р о в. Өйгә кайтышмы?

Б а й к о в. Өйгә. Ә син нишләп монда?

С а т т а р о в. Балчык төягән БелАЗлар тинтерәп йөри. Карарга чыктым. Монда, без басып торган урында, соңыннан нәрсә булачак инде?

Б а й к о в. Мондамы?.. Завод... Бәлки. әле завод буфеты булыр, ә анда йомырка һәм суганлы сумса сатарлар. Ашыйсы иде.

С а т т а р о в *(кесәсеннән чыгарып).* Минә... Сохари... ашыйсыңмы?

Б а й к о в *(сохарины сындырып).* Арыдым. Алтынчы яртыдан бирле туктап хәл алган юк. Өйгә я үнбердә, ә үникедә генә кайтып җитәсең. Күпме еллар инде якшәмбе юк, ял юк. Бетерәбез үзебезне әкренләп... Бер генә тәүлек булса да барысын онытып торасы иде.

Саттаров. Арымаган әле син, бары аптырашта гына калгансың.

Байков. Ә син аптырашта түгелме? Хәзер монда без икәү. Шундый кыска срокта төзергә! Аптырашта... Әйе, аптырашта! Көзгә кадәр монтаж өчен ике меңгә якын фундамент тапшырасы бар. Нәрсә, уен эшме әллә? Көн саен төшемә керәләр алар минем... Шул фундаментлар эчендә калганмын, имеш! Тере килеш күмелгәнмен дә ары сугылам, бире сугылам. *(Пауза.)* Әгәр быел торак йортларны тапшырырга өлгермәсәм, предприятиеләрне җибәрмәсәм, тимер һәм шоссе юлларны өлгертмәсәм, төп заводлардагы эшне башлап җибәрмәсәм, ул чакта — хана! *(Көлемсерәп.)* Беләсеңме, кайчак инфаркт турында хыялланам. Ял итәр идем кебек...

Саттаров. Юкны сөйләмә.

Байков. Хатыным сөйләсәң дә аңламас моны. Үзеңә буйсынганнар алдында да барысын ачып салып булмый. Күпме җыярга була инде эчтә...

Саттаров. Бездә Сатынский фундаментлары бар. Аларны куллансак...

Байков. Кайчан фатиха бирәләр бит әле... Беркатлы кеше син.

Саттаров. Ашыктырырга да була.

Байков. Барысы да башлана гына әле. Җиһазлар, техника, азык-төлек төягән эшелоннар монда, миңа килеп әләккәч тә бушатылмыйча атналар буе тора. Кешеләр аз, торак җитми. Эшчеләрнең уртача разряды — ике бөтен дә уннан алты. Әнә шул ике бөтен уннан алты шайтан үзе баш ватарлык нәрсә төзергә тиеш! Гомумән, дөньяда булмаганны төзергә тиеш! Баш инженер больницада. Партком секретаре әле яңа кеше. Уң кул да юк, сулы да! Рәтлерәк кешеләр куркалар монда килергә, муеннарын сындырасылары килми! Бары тик мин, карт ахмак кына, китереп тыктым башымны бу камытка. Ә ул инде мине кыса да башлады! Ә икенче яктан караганда, бу камыттан башка... аннан башка яшәүнең дә яме юк!

Саттаров. Кичә Ганиев бригадасы егетләре юл төзелешендә биш йөз квадрат метр бетон биргәннәр. Дүрт сменалык норма! Синең шул ике бөтен уннан алтың биргән аны!

Байков *(кул селтәп).* Беләм. Барын да беләм.

Саттаров. Минемчә, таяныр кешеләрең бар синең. Алай бик фәкыйрь булып кыланма. Дунаев, мәсәлән, ә? Яки Әхмәдуллина?

Байков *(йөзен чытып).* Ә-әй, Әхмәдуллина! Аның турында син яхшырак беләсең, әлбәттә.

Саттаров. Нәрсә?

Байков. Сезнең... теге... ни... күптәнме аның белән?

Саттаров. Нәрсә ул күптәнме?

Байков. Ярыйсы... ярыйсы ул... Гафу ит... Ярыйсы хатын. *(Басым ясап.)* Тик... артык үзсүзлерәк!

Саттаров. Димәк, беләсең?

Байков. Пышылдаучылар табыла анысы, ярарга тырышалар. Бәлки сиңа минем турыда үткәндә-сүткәндә генә пышылдыйлардыр, ә миңа — синең турыда...

Саттаров. Без аның белән бер балалар йортында бергә тәрбияләндек. *(Кисәк.)* Ярый, бетердек бу темага сөйләшүне.

Байков *(Саттаров күзләренә текәлеп карап торып).* Без икәү. Бу срокта төзеп бетерү мөмкин түгеллеген без икәү генә беләбездер дә бәлкем. Эш... менә шунда, Гайнан!

Саттаров. Юк, белмибез без синең белән бу турыда!

Байков. Ташла, ташла, Гайнан Сәлимович, беләбез. Юк, юк, без синең белән төзеп бетермәскә мөмкин түгеллеген дә беләбез. Пулеметлар атып торганда чәнечкеле тимер чыбыкка артиллерия әзерле-

геннән башка ташланыргамы? Кирәк булгач, ташладым мин сугышта үз ротамны андый атакага. Хәзер дә ташлаячакмын! Бөтен көчне ташлаячакмын! Быелгы планны да тутырырмын! Ләкин арзан булмас бу. Кыйммәткә төшәр!

Саттаров. Тәҗрибәң бик зур синең. Мин синнән өйрәнәм... Уйла, Иннокентий.

Килеп туктаган машина тавышы. Тәэсирләнгән тавышлар. Мөнир йөгереп керә.

Мөнир. Бәхетсезлек, Иннокентий Владимирович. Больницага барырга безнең машинаны сорыйлар.

Байков. Бир соң! Нәрсә басып торасың? Кемгә ни булган?

Мөнир. Бик каты итеп ток бәргән. Тәҗрибә полигонынннан сварщица. Ниндидер Алсу. Дәүләт комиссиясе килүгә фундамент арматурасын әзерләп бетерергә ашыккан. Ике смена рәттән эшләгән. *(Чыга.)*

Байков. Тагын! *(Пауза.)* Сугышта башыннан ахырынача булдым. Минем күз алдымда йөзләгән, хәтта меңләгән кеше... Әмма монда?.. Малай эшләгән котлованда бәхетсезлек... Судка бирергә кирәк аны!

Саттаров. Беләм... Күрәзәче. Үзенә юрый алмаган.

Байков. Каеш белән каезларга иде мондый батырлык өчен. Каеш белән! Комиссия алдыннан бит. Бәхетсезлек. Шул гына җитмәгән иде!

Саттаров. Әнә шундый акланмаган батырлык булмасын өчен уйлан да син! Бүтәне булмасын, аңладыңмы? Югыйсә, кешеләрнең энтузиазмын да планлаштырасың бит син...

Байков. Мондый киң колачлы объектларда артык чыгымсыз мөмкин түгел. Беләсезме, бездә, русларда, ничек диләр? Урман кискәндә йомычка очмый булмый.

Саттаров. Ә бездә, татарларда, болай диләр: төтене күп, уты юк. Бик еш оча башладылар ул йомычкалар.

Байков. Я-я! Нишләмәк кирәк, синең эш — стакандагы судан фәлсәфә эзләү, йомычкалар турында сөйләнү, ә минем эш — төзү. Миңа хәзер илле җиде мең сум җитми. Аннан башка ни эшлим мин? *(Саттаровның күз карашына җавап биреп.)* Тикшеренүләр нәтиҗәсендә смета күрсәткечләренең киметелүе беленде! Кемдер анда премия алгандыр, ә менә кемдер хәзер бөкресен чыгара. Шуны аңлый аласыңмы син?

Саттаров *(катгый)*. Ел ахырына проектны тагын да җентекләбрәк тикшергәч, сиңа әле тагын егерме миллион сум җитмәс. Ә син... бу миллионнарны каян алуың турында уйланганың бармы? Илдән, халыктан аласың син аларны! Монда син, тегендә башка берәү... Синең белән минем кебекләр аркасында кешеләр тиешле шартларда яши алмыйлар. Синең шул турыда кайчан да булса уйланганың бармы?

Байков. Синең өчен бу беренче зур төзелеш, ә минем өчен...

Саттаров. Өйрәнгәнсең! Син, ичмасам, юлларга күрсәткечләр куй, команда бир! Бетон ташыйлар, ә кая ташырга белмиләр, юл читенә аударалар. Шуннан, юл читләреннән эзлә син сумнарны. План органнарыннан миллионнар сорыйсың, ә кирпечеңнең яртысы ватык. Кирпеч заводларының ярты куәте җилгә очырыла.

Байков. Гайнан Сәлимович, гафу ит, зинһар, шәһәр комитеты секретаре булсаң да, бу — синең өчен беренче зур төзелеш, ә минем, беләсең килсә...

Саттаров. Сатынский фундаментларын онытма, Иннокентий. Синең белән без шулар өстендә торырга тиеш. Сатынскийны бит

монда син үзең алып килдең. Ул эшне үзең башладың. Ә хәзер кыл да кыймылдатканың юк.

Б а й к о в. Синеңчә, мин, Байков, субайларга каршы, шулаймы? Нигә монда өстерәләм соң мин? Нишләп монда килдем?

С а т т а р о в. Каршы түгел син. Син — алар яклы. Барысы да — алар яклы. Тик бәласеннән башаяк дип уйлыйсың. Нәрсә көтәсең?

Б а й к о в. Рәсми «рөхсәт» кирәк, рәсми!

С а т т а р о в. Төкер комиссия карарына! Төкер! Кабул итәчәкләр, рөхсәт бирергә мәҗбүр булачаклар алар. Ә сиңа әзерләнергә кирәк.

Б а й к о в. Тәзелештә кытлык, бетон кытлыгы. Аңлыйсыңмы син шуны? Гомумән, беләсеңме, мондый төнге сөйләшүләр... Әйтерсең көндезгеләре җитәрлек түгел! Ярый, сау бул!

С а т т а р о в. Минем белән кайтасыңмы? Машинаңны... җибәрдең бит.

Б а й к о в. Юк.

С а т т а р о в. Иннокентий Владимирович, тыңла мине. Соң булганчы, ул текучкадан котылырга кирәк. Югыйсә, бөтен эчәк-бавырларың белән бергә йотачак ул сине. Муеныңнан кереп батачаксың! Муеныңнан!

Б а й к о в. Я, ярый, хәерле төн!

С а т т а р о в. Сау бул! Сиңа да шундый ук теләк.

*

* *

Байков кабинетын хәтерләткән бүлмә. С а л и к о в а белән В а д и м керәләр.

С а л и к о в а. Шундый сорауга җавап бирегез әле. Прорабка эшнең куркынычсызлыгын тәгәл күзәтергә күрсәтмә бирдегезме?

В а д и м. Әйттем, әлбәттә.

С а л и к о в а. Безгә шунысы билгеле: котлованда турыдан-туры җаваплы прораб эшкә иртәнге җидедә килә, әмма котлованда булмый һәм, берәүдән дә рөхсәт сорамыйча, сәбәпсез каядыр китеп бара. Сез... боларны раслыйсыздыр дип уйлыйм?

В а д и м. Юк, прораб Гәрәев миннән сорап китте. Авырый иде ул көнне.

С а л и к о в а. Сезнең бу сөйләшү вакытында кем дә булса барчдеме?

В а д и м. Юк.

С а л и к о в а. Менә күрәсезме. Авырганлыкка язуы да юк.

В а д и м. Без шулай сөйләштек. Авырганлык язуы нәрсәгә?.. Поликлиникада чират, халык күп. Без болай гына сөйләштек.

С а л и к о в а. Бер дә, бер дә принципиаль түгел. Әйбәт түгел.

В а д и м. Нәрсә принципиаль түгел?

С а л и к о в а. Ул сезнең дустыгыз бугай?

В а д и м. Дустым.

С а л и к о в а. Күптәннәнме?

В а д и м. Укыган чакта тулай торакта бер бүлмәдә тордык. Монда бергә килдек.

С а л и к о в а. Алты ел буе бергә яшәдегезме?

В а д и м. Аңламыйм. Моның эшкә ни катнашы бар?

С а л и к о в а. Бик тә катнашы бар! Сез шактый тайгак позициядә торасыз.

В а д и м. Нишләп?

С а л и к о в а. Дустыгызны яклыйсыз, аңа җаваплылыктан качарга ярдәм итәсез. Ә ул — инженер! Ул андый кысынкы урында ике

экскаваторга эшләве куркыныч булуын белергә тиеш иде. Производство проектын бозуга юл куелган!..

Вадим. Мин сезнең белән бәхәсләшмим бит: тик аның ни катнашы бар монда? Гәрәевнең ни катнашы бар?

Саликова. Аңлыйм мин сезне. Иптәшне бәладән коткару — һәрберебезнең эше. Тик бу очракта... Сезгә караганда зуррак тормыш тәҗрибәм буларак, мине тыңлагыз.

Вадим. Гәрәев юк иде ул чакта котлованда!

Саликова. Мондый эшләрне гафу итә алмыйбыз без. Аларны гафу итәргә сезнең белән безгә бераү дә ирек куймаячак! Судка бирелә торган эш бу. *(Пауза.)* Тикшерү материаллары прокуратурага тапшырылачак.

Вадим. Аңлыйм мин, ләкин монда...

Саликова. Гәрәев төп башына утырткан сезне. Авыруын сылтау итә һәм шуның белән... сезнең фамилиягезгә тап төшерә.

Вадим. Ничек шулай әйтә аласыз? Ничек? Сез бит—хатын-кыз!

Саликова. Сез мине аңламыйсызмы әллә? Дустыгызны яклап, үзегезне һәм шуның белән бергә... Иннокентий Владимировичны удар астына куярга телисез. Аның үз кайгысы да җитәрлек... Ә сезнең дустыгыз, теге Гәрәев...

Вадим. Гәрәев дөресен әйткән!

Саликова. Ә дәлилләре кая ул дөреслекнең? Фактлары кая?

Вадим. Нинди фактлар җыясыз соң сез? Шәп егет үлде. Аның баласы туган, хәзер инде әтисез үсәчәк. Ә сез!.. Мин генә гаепле монда дип әйттем бит инде. Минем сатлык та булуымны, Гәрәевне сатуымны телисезме? Минем гаеп аркасында кеше үлү генә җитмәгәнме?!

Саликова. Тынычланыгыз, тынычланыгыз. Мин бары тик... бу эшкә бөтен җаваплылыгы белән каравыгызны гына үтенер идем.

Вадим. Бу нәрсә, әти приказымы?

Саликова. Безнең һәркайсыбызның үз тормышы. *(Паузадан соң.)* Хәлнең катлаулылыгын гына аңлагыз сез. Яшьлегегез белән әле сезгә барысы да бик җиңел тоела. Ә тормыш, беләсегез килсә, бик кызык. Я тегесен, я монысын сайларга кирәк чаклар була. Аңлагыз, Вадим...

Вадим. Иннокентьевич!

Саликова. Нәкъ шулай... Иннокентьевич... Исегездә тотыгыз, кайвакыт уйланмаган бер ялгыш адымның бөтен тормышны харап итүе мөмкин. Мин сезгә әни булыр яшьтәге кеше.

Вадим. Сез бит... беркайчан да әни булганыгыз юк!

Саликова *(ачынып)*. Булмасын!.. Сез хаклы...

Вадим. Гафу итегез.

Саликова. Шуңа күрә дә кызганыч сез миңа. Улым кебек кызганыч.

Вадим. Ярый. Җитәр. Языгыз. Болай дип языгыз. Котловандагы эшләрне тизрәк тоту нияте белән... мин Гәрәевкә забойга икенче экскаваторны кертергә куштым! Үзем куштым! Аның каршы килүенә карамыйча... *(Пауза.)* Языгыз, яз. Куркыныч туса, икенче экскаваторны чыгарып өлгерермен дип уйладым. *(Пауза.)* Ник язмыйсыз? Әгәр дә бу рәсми документ икән, сез язарга тиеш!.. Языгыз, дим!

Саликова. Әһә, ул әйтә! *(Кинәт йодрыгы белән өстәлгә суга.)* Карагыз әле — ул әйткән, имеш. Кем соң сез! Эш сездәмени! Сез әле үзегез генә беркем дә түгел! Беркем дә!

Вадим. Ни өчен беркем дә түгел? Мин — Байковның улы. Әмма мин үзем дә Байков бит. Иң әлек мин кешедер дә әле? Языгыз! Шуның өчен дә өстәл янына утырыгыз да мин әйткәннәрнең барын да языгыз.

Саликова. Яхшы... Әйдә, шул урынга барыйк. *(Китәләр.)*

Дунаев белән Мөнир Зарипов керә.

Дунаев. Аларга нәрсә? Алар килделәр дә киттеләр, ә без монда җиде кат тир түгәргә тиеш. Аларга командировкага кул гына куйдырасы. Мин бүген кешеләрне һәм техниканы котлован казырга куям, ә иртәгә, бәлкем, аларны күмдерәсе дә булыр.

Мөнир. Эшне фәнни оештыру, имеш. «Фитиль»дәге кебек.

Дунаев. Кирәкмәс эш өчен кешеләр зур зарплата ала.

Мөнир. «Фитиль»дәге кебек, дип әйтәм бит. *(Китәләр.)*

Сатынский белән Качаева, аз гына соңрак Гоголев керәләр.

Качаева. Комиссия бер нәрсә дә хәл итмәде бит әле. Нигә дип сез ул кадәр пыр тузасыз? Сынауларны дәвам иттерергә дигән карарга килдек бит.

Сатынский. Шундый беркатлымы сез? Сез — бәхетле кеше... Ай-яй, тагын шундый тәмле хушбуй исе! Парижда торырга кирәк сезгә! Парижда, мадам!

Гоголев *(сүзгә кушылып)*. Ну, кадерлем, Николай Николаевич, әллә инде картаясыз? Нәрсәдә гаеплисездер безне, хода үзе белсен... *(Качаевага елмаеп карап һәм аның исеменнән сөйләгәндәй.)* Хәер, мин сезгә үпкәләмим.

Сатынский. Иң талантлы шәкертем идегез. Анысы да шәп! Сәгать ничә?

Гоголев. Өч туларга егерме минут.

Сатынский. Ә мин бүген чәршәмбедер дип уйлаган идем. Ярый, сау булыгыз. *(Китә.)*

Гоголев. Менә картлач... Аның акылы белән шәп карьера ясарга мөмкин булыр иде... Валлаһи. Ә ул бөтен гомере буе әнә шулай... Ә син молодец. Шундый илһамланып, ышандырырлык итеп сөйләдең... Синең кайнар чыгышыңнан соң үзем дә... бер секундка гына... бу фундаментларның кирәклегенә шикләнеп карадым..

Качаева. Сәер юмор.

Гоголев. Шаяртам, шаяртам! Гостиницага кайтабызмы? Хәзер шәп кенә вино алырбыз, боларның барын да онытып, тормыш хакында гәп корырбыз. Югыйсә, бер-беребезне егерме... ягъни ун, дүресрәге, биш ай буе беләбез, ә мин ничектер сиңа бер тапкыр да хатын-кыз итеп караганым юк.

Качаева. Оятсыз син, ичмасам, үз-үзеңне алдама.

Гоголев. Нәрсә?

Качаева. Мине берни дә төшенми дип уйлыйсыңмы? Барысын да аңлыйм мин. Идиотка түгел лә мин. Шулай булмыйча, политик капиталыбыз, институтыбыз абруе куркыныч астында бит. Ә без — мода чыгаручылар, илнең иң зур проект фирмасы, безнең элекке казанышларыбыз бар... *(Әче көлү белән.)* Аннары бит проект тапшырылган, бер вагон сызым сызылган, акча тотылган инде, яңадан проектлау мөмкин түгел. Ә монда кешеләр нәрсәләрдер эшлиләр. Бер кыз үзенең саксызлыгы аркасында чак үлмәде! Ә без шатланабыз! Бәйләнергә тагын бер сәбәп табылуына куанабыз. Хәер... фундаментларның монда ни катнашы бар! Әйе... мин бик тә дәлилле сөйләдем. *(Шашынып.)* Җир асты суларының агрессивлыгы факторы, субайларның бетонлау сыйфатын эффектлы методлар белән тикшерү мөмкинлеге булмавы... Бары да бик акыллы уйланган!

Гоголев *(үзен ничектер уңайсыз тоеп, каранып).* Я, ярый, килешәм, миңа бераз чистарынырга кирәк. *(Яңадан гадәти көлемсерәү белән.)* Менә... гөнаһлардан бергәләп чистарынырбыз да әле. *(Аякларына карый.)* Кулларың... нинди матур синең!

Качаева. Кәефем шәптән түгел. Син бар. Бар, чистарын. Бәлки әле тагын шефыңны да канәгатьләндерергә кирәктер?

Гоголев. Әй, син, кызыкай!

Качаева. Аһ, син, ир-егет! Ирлек горурлыгыңа кагылдыммы әллә? Гафу ит!

Гоголев *(көч-хәл белән елмаеп).* Я, ярый, гафу үтенден, дип исәплик.

Качаева. Син дә инструкциядәгечә сиптерден.

Гоголев. Һәркем үзен күңелсез хәлләрдән сакларга тырыша.

Качаева. Әйе, барысы да. Мин дә шулай. Ә менә кайберәүләрни өчендер сакланмыйлар.

Гоголев. Яратам мин Сатынскийны, яратам, аның шәкерте мин, ләкин аңламый ул тормышны! Һәрчак үзенең хыялый планнары белән ведомствоара ызгышка килеп эләгә дә, тирә-юньдә бары юләрләр генә яши, дип уйлый. Юк, юләрләр түгел алар! Идея үз бәясен алды. Яхшы, бик яхшы бәя алды. Ләкин кайчандыр нинди дә булса башка бер төзелештә кулланылыр. Ә хәзергә... Әгәр дә бу фундаментларны куа башласак... тулы бер ташкын булачак бит. Без өлгермәячәкбез!.. Хәзер дә безнең министр эш фронты юкка зарланып йөри! Әгәр дә без Сатынский фундаментын куллансак? Икенче бер министр, матурым, инде безгә зарланачак. Әгәр дә төзелеш срогы өзелсә, без, безнең министрлык гаепле булып кала. Әлегә без киң колачлы монтаж эшләре алып барырга әзер түгел, эштә сезнең данлыклы институт проекты булганда, без күңелсезлекләрдән азат. Шулай булгач, сез бүгенге көн түгел, ә утызынчы еллар исе килеп торган хәшәрәт... гафу ит... хәчтерүш проектыгызны яклаганга рәхмәт кенә әйтергә тиеш!

Качаева. Ә мин соң ник уйнап маташам бу уенны? Мин? Я, алла, анда ниләр сөйләдем, ниләр сөйләдем мин...

Гоголев. Я, тынычлан, апай, тынычлан... Нәрсә, синең үз институтыңда эшлисең килмиме әллә? Кайтып, синең номерда утырырбыз да барын да онытырбыз.

Качаева. Утырырга да теләмим, сөйләшергә дә теләмим.

Гоголев. Тынычлан, алла хакы өчен тынычлан. Бөтен кеше барын да белә, аңлый. Гөнаһ кылабыз да — тәүбә итәбез, тәүбә итәбез дә — гөнаһ кылабыз. Барысы да дөрес. Әгәр тагын утырыш була икән, сөйләгәннәреңне сүзгә-сүз кабатлаячаксың син. Без — кечкенә кешеләр.

Качаева. Кечкенәлекнең монда ни катнашы бар?

Гоголев. Ә монысы кирәкми. Кирәкми! Минем шеф та кечкенә кеше. Безнең кебекләр алдында зур ул үзе, ә гомумән алганда — кечкенә. Минем шефның шефы да кечкенә. Бер тапкыр күрдем: бер кабинетта калтыранып басып тора иде. Кечкенә, кечкенә. Без барыбыз да кечкенә буйлы. Синең кебек. Барыбызның да өйдә бәхетле кешеләр итеп үстерергә тырышкан кечкенә балаларыбыз бар. Ә ул кечкенә балаларыбызны без бик тә яратабыз. Үз дәрәҗәбезне дә яратабыз! Монда ни гаебебез бар безнең?

Качаева. Күңелем болгана! Синең фәлсәфәңнән күңелем болгана!

Гоголев. Менә ничек! Чиста булып калырга телисеңме? Барып чыкмас! Барып чыкмас! Хәтта бер-берсен яратып яшәүче семьяда да гаепләләрне акылга утыртырлык ниндидер чаралар була. Кечкенә кеше, үз тәэсирләренең дөреслегенә ышанып та, буйга аннан бер

генә сантиметрга биегрәк кемдер берәү аның карашын ялгыш дип таба икән, анда аның ялгышуы турында шик туарга тиеш. Үзеңнең матур маңгаеңны җыер да уйлан бераз!

Качаева *(аннан читләшә).* Ярый, калдыр мине, бар.

Гоголев. Зур кешеләр аз. *(Авыз чите белән елмаеп.)* Бар кеше дә зур була алмый, димәк.

Качаева *(аңа куркынып карап).* Бар син, Алексей, үзеңнең шул кечкенәләрең янына бар. Бар!

Гоголев *(бәлки беренче тапкырдыр, җитди кыяфәттә).* Әйе, чиновник булдым мин, гади бер чиновник! Ләкин миңа һәр вакыт яхшыдыр дип уйлыйсыңмы? *(Пауза.)* Миңа да кайчак бик начар була. *(Пауза.)* Ярый, үзеңә кара! *(Пауза.)* Гафу ит... ни дә булса... *(Ишеккә таба бара.)*

Саттаров күренә.

Саттаров *(Качаева белән Гоголевка карап).* Йөзләрегез качкан түгелме? Нигә тантана итмисез? Әшкә аяк чалдыгыз — инде шатланырга кирәк.

Гоголев. Сезнең белән танышуыма бик шатмын. Иртәгә очам. Изге эшегездә уңышлар телим. Кайбер принципиаль мәсьәләләрдә төрле позицияләр киләчәктә безгә...

Саттаров *(бүлдереп).* Әлбәттә! Бу танышуга мин дә бик шатмын. Хәерле юл!

Гоголев *(кул сузып).* Сау булыгыз!

Саттаров. Хәерле юл.

Гоголев китә.

Качаева *(ашыгып).* Минем сезгә сөйлисем, аңлатасым килә!

Саттаров. Берни дә аңлатырга кирәкми миңа.

Качаева. Мин... аңлыйм...

Саттаров *(ул чынлап арыган).* Аңлатмаска, ә оялмаслык эшләр эшләргә кирәк. Кешенең үз карашы булырга тиеш. Үз проект институтың баскычыннан гына карарга ярамый.

Качаева. Ләкин бер нәрсә дә югалтылмаган бит әле! Комиссия бернинди дә карар кабул итмәде. Кире дә какмады... *(Саттаров җавап бирмичә, китә.)*... кабул да итмәде...

*
* *

Тулай торак. Ишек төбендә — күпләгән аяк киеме: туфлиләр, резин һәм кирза итекләр.

Койкалар. Стеналарда анда-монда киноартистлар фотографияләре. Бауда кер кибә. Радиоалгыч чыелдый.

Вера. Кызлар, ә минем кулларым зурайды! *(Кулларына гаҗәпләнеп карый.)* Ямьсезләр!

Рушания. Кайгырма, аның каравы, катырак кочакларсың!

Вера. Мин инде бүген стеналар шомарттым. Рамнарны да сыладым.

Гәүһәр. Юләр син.

Вера. Ә нишләп юләр?

Гәүһәр. Институтның өченче курсын ташларга соң! Төзелеш нәрсә бирәчәк сиңа? Профессияме? Штукатурка белән гомер үткәрмәячәгеңне үзең дә беләсең бит.

Вера. Минем... үз-үзем буласым килә. Син бит минә...

Гәүһәр. Мин — башка мәсьәлә! Мин үземә тормыш итү өчен әчми, тартмый торган, эш яратучы егет таптым, аннары әйбәт квартира алырмын, мебель юнәтермен.

Вера. Мине балалар бакчасына йөрттеләр. Музыка мәктәбенә йөрттеләр... Җитәр инде!

Алсу. Нигә дип бәйләнәсең син аңа?

Гәүһәр. Бәйләнмим, дөресен әйтәм.

Алсу. Урынлымы-түгелме, үз белгәненне такылдарга яратасың!

Вера. Миңа, кадерлекәйләрем... кире өйгә кайту юк. Әткәй гафу итмәячәк.

Рушания. Кызлар, Верка шигырь яза икән бит! Шагыйрә!

Нюра. Шигырь? Ха-ха!..

Рушания. Әйе шул!

Тарткалаш. Шау-шу, көлеш, куышу.

Рушания *(дәфтәрдән укып):*

Гел качам мин синнән,
Гел дорфа сөйләшәм шаяртып;
Үзе, дим, сизмәсен; йөрәгем
Мәңгегә тик сине яратты.

Нюра. Мәхәббәт турындамыни?

Вера. Нишлисең син? Нишлисең? Ничек оялмыйсың?!

Рушания *(дәвам итә):*

Күрешергә һич җитми кыюлык,
Сиздерми карашың күзәтәм,
Арт белән торсам да, син барын
Мин күрәм —
Күңел күзләрем белән.

Чыркылдау, көлеш.

Рушания. Ай, үпкәчел дә инде син, Верка. Кичә миннән көлдегез бит. Син дә бик әйбәт үчекләдең! *(Сөеп һәм тынычландырып.)* Ә үзеңнең серкәң су күтәрми. Көлеп үләрсең!

Алсу. Мин беләм: ярата ул сине.

Вера *(өмет белән).* Чынлапмы?

Алсу. Чынлап.

Вера. Барыбыз да кемне дә булса яратырга тиештер инде ул. Безне дә кемдер сөяргә тиеш! Менә шул фикернең икесе туры килсен иде!

Гәүһәр. Юләр генә булмаска кирәк. Мәхәббәт мәхәббәт белән, ә мәми авызланып торырга ярамый, якаларыннан эләктерергә кирәк аларның! Ташлап карасын иде мине берәрсе!.. Мин, Верочка, шигырь язып маташмас идем.

Нюра *(Верага).* Үпкәләмә син миңа. Мин шулай инде, һәр вакыт ниндидер бер мөгез чыгарып куям. Шаярып кына бит мин!

Рушания. Мин дә әйбәт... турылыклы булыр идем... аны гына сөяр идем.

Алсу. Ни булды сиңа?

Рушания *(көлеп).* Юк ла, мин болай гына... Шаяртып кына! Верканы котыртам! Их, телевизор юк.

Җырлыйлар.

Гәүһәр. Ә без ике атнадан язылышырга торабыз. Җитәр инде, яратмый да башладым, күп газапландым да, яшь башларга кирәк.

Алсу. Яратмый башладым дисеңме? Ничек инде ул яратмый башладың?

Г ә ү һ ә р. Ярата-ярата гарык булдым. Хәзер миңа кешенең хөрмәте кирәк.

В е р а. Ә кайда яшәмәкче буласыз?

Г ә ү һ ә р. Табарбыз әле. Квартира вәгъдә итәләр.

Н ю р а. Әчми ул синең, анысы яхшы.

Г ә ү һ ә р. Әчмәс тә!

В е р а. Ә әкият? Әкият сөйлисеңме, Алсу?

Н ю р а. Әйе шул, сөйлә! Телевизор да юк.

Утны сүндерәләр. Алсу караваты янында өстәл лампасы гына яна.

Р у ш а н и я. Тик озынга сузма син аны. Кызыклы, тетрәндергеч булсын. Тегесендәге кебек, яме? Мәхәббәт тә күбрәк булсын.

Н ю р а. Әй, Алсу... Мин шулай уйлап чыгара алсаммы?

Вагон тынып кала — ул тыңлый, бала чакка күчә.
Радиоалгычтан йомшак кына көй ишетелә.

А л с у. Егетләр һәр вакыт үзләренең сөйгәннәрен эзлиләр. Ул да үзенең гүзәл Фирдәвесен эзләгән. Ул көнне егет бик тә арый һәм үзенең җәнлек-җанварлары белән учак янына ята. Кинәт күрә: якындагы агачта бер чибәр кыз утыра һәм шунда ул кинәт хәшәрәт карчыкка әверелә дә шаркылдап көлә, төрлечә сүгә һәм каргый башлый.

Р у ш а н и я. Әшәке сүзләр беләнме?

В е р а. Син бигрәк инде!

А л с у. Әшәке сүзләр белән. Егет карчыкка мылтыктан ата, ләкин пуля, тактадан сикергән борчак кебек, кире кайта. Егет моның гади карчык кына түгел, ә убырлы, үзенең гүзәл Фирдәвесен харап иткән убырлы карчык икәнлеген төшенеп ала! Үзенең көмеш пулялы махсус патронын ала да, төзәп, убырлыга тагын атып җибәрә.

Р у ш а н и я. Карчыккамы?

Н ю р а. Комачаулама әле!

Р у ш а н и я. Карчык кеше бит!

В е р а. Карчык түгел, карчык кыяфәтендәге сихерче бит ул.

А л с у. Күктә сигез тапкыр әйләнә дә убырлы җиргә мәтәлеп төшә. Егет аны эләктереп ала һәм сорый: син җиттеңме гүзәл Фирдәвесемнең башына?!

Виктор күренә.

В и к т о р. «Ванька Морозовның бернинди гаебе дә юк бит». Нәрсә, ошамыймы? Миндә тагын бар әле ул. «Ул чыбык буйлап атлый һәм ак аягын болгый да Морозовның дәртен рәхимсез куллар белән эләктерә...»

А л с у. Кит! Ишетәсеңме? Хәзер үк кит!

Р у ш а н и я. Кем чакырды сине монда?

Н ю р а. Хәзер мин сине атаң-анаң белән сүгәм!..

Г ә ү һ ә р. Үз башыңа йөрисең син, салдырабыз без синең ыштаныңны. Төнлә түгел, көпә-көндез йөгерәчәксең син төзелеш буйлап.

В е р а. Ягез инде, нишләп шундый сез!

В и к т о р. Мин тормышка чакырусыз-нисез килеп кердем. Җырлыйсызмы? Әкият сөйлисезме? *(Алсуга.)* Дустымны үтерде! Сине тартып алды! Кая ул? Әйе, исерек! Исерек! Аның участогында кеше үлгән, ул гаепле, ә суд каршына башка берәү басачак! Чөнки зу-ур әтинең малае... Га-ад! Ул сине дә сатачак әле! Хәсис!..

А л с у. Алдыйсың!.. Барын да алдыйсың... Син...

В и к т о р. Алдыйммы?

В е р а. Ничек инде? Кеше үлә, ә аның үлеме тирәсендә ниндидер пычраклык?

Виктор. Алдыйммы? Пычраклыкмы? Ә менә бу нәрсә? Приказ кисәге! Бөтен кеше күз алдына элгәннәр. Гәрәевне судка бирергә, ә малайны бер-ике айга эштән алырга. Күз буяу өчен!.. Нишләттегез Ванька Морозовны, ә?!

Сатынский керә, кыюсыз гына барысына да күз йөртеп чыга.

Ә Гәрәев ул чакта бөтенләй булмаган да! Алдыйммы?.. *(Кулындагы кәгазьне йомарлап, кызның аяк астына ташлый.)* Ярый! Үбеш, ялаш үзеңнең тәти егетең белән... Миңа кем дә караячак! *(Рушаниягә карый, борыла.)* Андый товар җитәрлек монда. *(Верага карап.)* Менә син, курчаккай... ярыйсы гына! Киттекме куаклыкка?

Рушания. Ә минем белән, минем белән бармыйсыңмы?! Кит аның яныннан! Карарга чирканыч!

Сатынский. Әй, сез, егет... Ычкыныгыз әле моннан! Ишетәсезме, ычкыныгыз!

Виктор. Син, абзыкай... Ух, ниндиләр без... Ярый, башка берәүнең маңгаен ярырмын.

Сатынский. Анысы нишләп тагын?

Виктор. Син бик карт. Пока. *(Китә.)* «Ванька Морозовның бернинди дә гаебе юк бит...»

Алсу караватына барып йөзтүбән ава.

Сатынский. Исәнмесез.

Кызлар. Исәнмесез.

Сатынский. Бүген якшәмбе, ә урамда яңгыр ява. Бик үк пычратмыйммы мин монда? Чүпрәк кисәгегез юкмы...

Рушания идәнне сөртә.

Сатынский *(Алсуга)*. Ә син ят, ят. Больницага барган идем дә, бүген чыкты, диделәр. Йөрдем шунда әрле-бирле. Менә гөмбә җыйдым.

Нюра. Безгәме бу?

Сатынский. Сезгә. *(Алсуга.)* Ә бу конфетлар сиңа. Конфет яратасыңмы син?

Алсу. Рәхмәт.

Сатынский. Хәлең ничек?

Алсу. Хәлем ничек булсын минем? Минем хәл... Коля абый бу, кызлар.

Нюра. Коля абый, дисеңме?

Рушания. Нигә баштук әйтмәдең аны? Салыгыз плащыгызны, бездә яңгыр юк.

Сатынский. Рәхмәт... *(Алсуга.)* Рәхмәт сиңа.

Алсу. Ә миңа ни өчен?

Сатынский. Беркайчан да әле минем мондый теш-тырнагы белән яклаучым булганы юк иде. Скважинага кергәнсең... Ток сугып үтерүе ихтимал иде бит сине!

Гәүһәр. Әйтегез әле менә үзенә, Коля абый.

Алсу. Берни дә булмый ла миңа. Йөз яшьлек карчык булып үләм, бик әрсез җанлы мин.

Сатынский. Алай димә, алай димә! Әле дә хәтеремдә... Амурда Комсомольск шәһәрен төзегәндә сал тыгылды, бүрәнәләр берберсе өстенә өелеште. Су күтәрелә башлады. Бар кеше аптырашта калды, беркем берни эшләргә белми.

Алсу. Тыгылган җирен кузгатырга иде!

Сатынский. Әйе-әйе! Дөрес! Фамилиясен инде хәтерләмим. Авыл егете иде. Кулына балта алды да бүрәнәләр өстеннән китте. Мин аның юл өстендә тора идем... Миңа күз кысты. Аннары, суга

чумып, тыгылган урынны ачты, ә салдан бар бүрәнә аның өстенә ишелде... Ә менә фамилиясен хәтерләмим.

Р у ш а н и я. Кызганыч... үлдеме?

С а т ы н с к и й. Әйе... үлде.

Р у ш а н и я. Кызганыч... Ә сез анда нәрсә эшләдегез?

С а т ы н с к и й. Завод белән шәһәр төзедек.

Р у ш а н и я. Сез завод белән шәһәр төзегәнсез, ә без шәһәр һәм завод төзибез... Көлеп үләрсең!

Г ә ү һ ә р. Квартира бирделәрме сезгә анда?

С а т ы н с к и й. Юк.

Г ә ү һ ә р. Менә сиңа кирәк булса!

Р у ш а н и я. Һәр вакыт шулай ул: язалар, вәгъдә итәләр, ә аннары...

С а т ы н с к и й. Бәлки биргән дә булырлар иде. Кузнецкига киттем мин аннан.

Г ә ү һ ә р. Анда бирделәрме соң?

С а т ы н с к и й. Андамы?.. Әйе, анда бирделәр бирүен...

Г ә ү һ ә р. Нишләп, әшәкене бирделәрмени?

С а т ы н с к и й. Юк, ярыйсы иде... Кеше кайда да яши.

А л с у. Кызлар, чәй куярга иде бит, ә?

К ы з л а р *(Сатынскийга)*. Утырыгыз зинһар. Без хәзер сезнең конфетлар белән... Чынаяклар гына төрлерәк безнең. Менә сезгә иң матуры... Менә монда... Кызлар, прәнникләр кая соң? Вера, тулы бер пакет прәнник бар иде бит! Әллә берүзең ашап бетердеңме?

С а т ы н с к и й. Тартырга ярыймы соң сездә? Әйтегезче, ә сезнең исемегез кем?

Н ю р а. Мин Нюра исемле.

С а т ы н с к и й. Ә сезнең?

В е р а. Вера.

С а т ы н с к и й. Ә сезнең?

Г ә ү һ ә р. Гәүһәр.

С а т ы н с к и й. Ә сезнең?

Р у ш а н и я. Рушания.

С а т ы н с к и й. Ә мин — Коля абый.

Н ю р а. Коля абый! Кызлар, хәзер безнең үз әтиебез бар.

Р у ш а н и я. Көлеп үләрсең!

А л с у. Әйбәт кенә градуслы шәраб бар биредә. Эчәбезме?

Н ю р а. Бир миңа! Бүлимме? Стаканнар җитәме барыбызга да?

А л с у. Әйдәгез, кызлар, нииндидер чын-чын бер нәрсә өчен эчәбез. *(Сатынскийны кочаклый.)* Менә кем ул иң чын кеше, кызлар! Менә кем!

С а т ы н с к и й. Рәхәт сездә. Элегрәк ничек килмәгәнмен мин монда?!

А л с у. Ә хәзер инде ешрак килегез.

С а т ы н с к и й. Килермен, һичшиксез, килермен. *(Шырпы алырга плащы янына бара, кабыза.)*

А л с у. Коля абый?

С а т ы н с к и й. Тыңлыйм.

А л с у. Борчылмагыз сез. Мин, мәсәлән, сезгә ышанам. Бригададагылар да ышана. Сез миңа комиссиядән иң-иң әшәкеләреннән берсен күрсәтегез. Иң эресен. Мин аны буш скважинага... Акыллы булып кәпрәеп, минем аякка карап йөрсә, төртәм дә төшерәм. Яки полигонга теге чал чәчле, сөйкемле министр килсә, мин аңа әйтермен, тикшерегез сез, диярмен.

С а т ы н с к и й. Анысы кирәкми. Савык әле син, савык.

Алсу. Ә нигә? Дәүләт файдасына зарар күрергә дә мөмкин. Кеше атлап бара һәм кинәт кенә... минем караштан абынып егыла.

Сатынский. Кирәкми. Завод фундаментлары нык булырга тиеш. Алар чүптән... гафу итегез зинһар, шлактан түгел, ә тимербетоннан коелырга тиеш. Ярый, китәрмендер инде мин.

Тавышлар. Ни сөйлисез, Коля абый, килүегезгә кайчан гына әле, «китәм» ди дә башладыгыз. Чәй дә эчмәдегез бит.

Вера. Коля абый, мин шуны сорамакчы идем... Без төзи торган шәһәр дөнья йөзендәге яңа шәһәрләрнең иң матуры булачак, диләр, дөресме шул? *(Ишек шакыйлар.)* Алсу, ни булды сиңа?

Нюра. Коля абый, икенче разряд минем, ә миңа эшне дүртенче буенча бирәләр, түләвен икенче белән түлиләр! Дөрес түгел бит бу? Шулаймы, Коля абый?

Сатынский. Кадерлеләрем, матурларым, каян белим ди мин?

Нюра. Әй, Коля абый, сез барын да беләсез.

Ишектән Вадим Байков күренә.

Вадим. Исәнмесез.

Алсу *(кинәт уянгандай һәм барысына да карап).* Китегез әле, ә? Китегез! Коля абый, сез үпкәләмәгез! Үпкәләмәгез, яме! Китегез! Үпкәләмәгез, яме. Сөйләшәсем бар минем.

Сатынский. Әлбәттә, әлбәттә.

Алсу *(кызларга карап).* Ә сез нәрсә дип катып калдыгыз? Икебезне генә калдырыгыз! Барыгыз. Миңа сөйләшергә кирәк...

Сатынский. Кызлар, беләсезме нәрсә, әйдәгез җыйнаулап минем гостиницага киттек. Мин сезне чәй белән сыйлармын. Шәп итеп каты чәй пешерә беләм мин. Сере бар аның.

Гәүһәр. Киттек.

Рушания. Ай, кайнар чәй эчмәгәнемә күпме гомер.

Нюра. Коля абый, минем тагын шуны сорыйсым бар иде...

Вадим белән Алсуны калдырып, таралышалар.

Вадим. Алсу, теләмәсәң... Теләмәсәң, берни дә сөйләмә. Мин инде барын да беләм...

Алсу. Беләсең?

Вадим. Больницага барган идем. Сине монда диделәр. Чаптым. Хәлең әйбәтрәкме инде? Агарып калгансың... Урыннан торырга ярыймы соң?

Алсу. Миңа барысы да ярый.

Вадим. Ни булды сиңа?

Алсу. Ә сиңа ни булды?

Вадим. Миңа ни булды? Берни дә булмады.

Алсу тора, караватына баса.

Вадим *(аны тота һәм кочаклый).* Ни булды сиңа? Ни булды? «Аерылышу минутлары җитә. Айга менеп, Җир белән радио аша беренче сөйләшкән кеше аңа барысыннан да якынрак. Шуңамы соң, син бик тә ерак... Аерылышу якынайта».

Алсу. Кирәкми, җибәр!

Вадим. Ә хәзер монда кара! *(Сикерүче маймылны борып җибәрә.)* Кызык бит, әйеме?

Алсу. Кызык. *(Бөгәрләнгән, идәндә яткан приказ янына килә, аны ала, өстәлгә җәеп сала.)* Ә сезнең эшләр әйбәт, Вадим Иннокентьевич, барысы да әйбәт. Сез гаепле түгел. Шуңа күрә туп-туры... аэродромнан туп-туры өегезгә, әтиегез янына кайтырга иде.

Вадим *(паузадан соң, приказны укыгач).* Мин... китим инде. *(Китә.)*

Ә маймыл һаман сикерә. Алсу аның янына килә, кулы белән каплый.

Алсу. Җитмәсә, шигырь сөйли бит әле... Ниндидер сүзләр. Сүзләр.

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

Әхмәдуллинаның бер бүлмәле квартирасы. Уйга чумып, ул өстәл янында утыра, машинкада яза. Эш кичкә дә күп калган. Таисия баласын тирбәтеп идән буйлап йөренә. Бала елаган тавыш.

Таисия. Комачауламыйммы?

Әхмәдуллина *(машинкада язып).* Йөри бир, йөри бир.

Таисия *(туктый).* Карап торам-торам да, ап-ак чырайлы син, көннәр буе ашамыйсың. Ниндидер кәгазьләр, гел эш. Хатын-кыз эше түгел бу. Шәп кенә бер ир кирәк сиңа. Буй-сының бөтен яктан әйбәт булса да, күрәм, бер ир затың да юк. Әйбәт түгел. Хатын-кыз икәнеңне оныткансың.

Әхмәдуллина. Оныттым, оныттым.

Таисия. Иргә чыгарга кирәк сиңа.

Әхмәдуллина *(көлемсерәп).* Бирәү дә алмый.

Таисия. Алмый! Үзең алмыйсыңдыр әле, баксаң.

Әхмәдуллина. Үзем дә алмыйм.

Таисия. Әйттем бит менә! Ә хатын-кызга нәрсә кирәк? Тыныч, ягымлы булсын ул. Ешрак бала тапсын. Менә мин монда Петька белән кушылгач, хатыны булып аның кирләрен юа башлагач, үземне ничектер бәхетле итеп сиздем. *(Пауза.)* Без бит аның белән... Үзен әллә кемгәрәк куеп йөри иде әзрәк! Ә минем бала табасым килде... Утызның теге ягында бит инде! Гомер буе ялгызым яшәмәс өчен, бала турында хыялланам, дип әйттем. Әйбәтләп кенә шулай үтендем... Әнә шуннан соң бер-беребезгә ияләшеп, яратышып киттек. Миңа бала калдырды... ә үзе үлеп китте... *(Елый, күз яшьләрен сөртә.)*

Әхмәдуллина. Ярый, ярый, Таечка. Нишләмәк кирәк соң?

Таисия. Бирәр сөяркә тап үзеңә. Тыңламыйсың да бит син.

Әхмәдуллина. Тыңларга вакыт юк минем, Тая, вакыт юк.

Таисия. Нигә соң, алайса, мине куып чыгармыйсың?

Әхмәдуллина. Көзен бик күп йорт тапшырачакбыз... Сиңа кайдан да булса бер бүлмә табармын әле... *(Машинкада яза.)*

Таисия. Сәер хатын син. Синдә хатын-кыз кулы сизелми. Мине еш кына үз акчаңа ашатасың. Әгәр дә, мәсәлән, мин синең, син минем урында булсак, мин инде күптән сине сыпыртып чыгарган булыр идем.

Әхмәдуллина. Һәркем үзенчә яши.

Таисия. Ичмасам, кереңне юыйм. Бир!

Әхмәдуллина. Кирәкми. Мин үзем.

Таисия. Балалар йортында үскәнсең шул син. *(Бала елаган тавыш.)* Элек тә йортың булмаган, хәзер дә юк. *(Аңа кызганып карый.)* Ә гомерең уза. *(Баласына карап.)* Ай, матурым минем! Коры чүпрәкләр кирәк, Петенька, коры чүпрәкләр! *(Әхмәдуллинага.)* Сиңа да табарга кирәк. *(Ишектә звонок.)* Хәзер ачам, ачам! *(Таисия алгы бүлмәгә чыга, аннары ишектән шатланып керә, дулкынланып пышылдап кына сөйли.)* Даңька, бер ир кеше синең янга килгән! Чишенә!

Әхмәдуллина. Нинди ир кеше?

Таисия. Чын ир. Шундый... пешеп торган ир! *(Баласын караватка салып, аны тиз генә төрә башлый.)* Тизрәк, Петенька, тизрәк, матурым. Апага комачауламыйк, тизрәк.

Әхмәдуллина. Ни эшлисең син, Тая, ни эшлисең?

Таисия. Синең бәхеткә комачаулап торыйммы әллә мин?

Саттаров керә.

Узыгыз, уз.

Саттаров. Хәерле кич.

Әхмәдуллина. Исәнмесез.

Таисия. Узыгыз сез, узыгыз. Мин хәзер, хәзер. Йөреп керим әле. Саф һава сулап керергә җыенган идем. Улыма кирәк.

Әхмәдуллина. Нәрсәләр уйлап чыгарасың син?

Таисия. Бераз йөрергә кирәк. *(Паузадан соң.)* Йокы алдыннан бераз йөреп керергә дим. *(Саттаровка.)* Дания Кәримовна эшли дә эшли. Килеп бик яхшы иттегез әле, бераз күңелен ачарсыз. Ачыгыз инде бераз күңелен, зинһар ачыгыз.

Саттаров. Ачармын, ачармын. *(Таисия чыга.)* Нинди... фәрештә бу?

Әхмәдуллина. Таисия. Машинист ярдәмчесе үлде бит әле, экскаваторчы...

Саттаров. Ә-ә... Әйе шул. Дөрес...

Әхмәдуллина. Бәлки үз вөҗданымнан котыламдыр. Кешеләргә, квартира юк, дип әйтергә дә җиңелрәк.

Саттаров. Аңа мәрхәмәт-хәер түгел, ә үзенә тиешлесе кирәк.

Әхмәдуллина. Хәзергә бер нәрсә дә юк миндә! Юк! *(Пауза.)*

Саттаров. Чәй белән сыйларсың бәлки? *(Аны кочаклый.)*

Таисия *(ишектән башын тыгып).* Дания Кәримовна, мин бөтенләй истән чыгарганмын. Петюнчик белән без бүген кунарга кайтмыйбыз.

Әхмәдуллина. Берәүгә дә комачауламыйсың син монда!

Таисия. Юк, юк! Кунакка чакырганнарын бөтенләй онытканмын мин, ә аннан кайтырга ерак. Хатын-кызлар тулай торагы бит. Һәркайсының иркәлисе килә бәбине. Кызганалар да мине, көнләшәләр дә. Беләсезме, нәрсә бүләк иттеләр аңа? Конструктор! Нигә кирәге бар инде аңа конструкторның, я?

Әхмәдуллина. Тая!..

Таисия. Нигә? Юешләтүдән башканы белмәгән балага ник кирәк ул?

Саттаров. Ярый, ярый, бирсеннәр. Кечкенәдән үк баш ватып үссен. Карагыз әле, Дания Кәримовна бик тә хаклы. Китмәгез. Мин сезнең дә күңелегезне ачармын, Петюнчигыгызныкын да. Булдырам мин. Китмәгез!

Таисия. Юк, юк. Рәхмәт, зинһар, тыныч кына күңел ачыгыз. Гафу итегез зинһар. *(Китә.)*

Саттаров белән Әхмәдуллина бер-берләренә карашып торалар. Тынлык.

Саттаров. Күптән булганым юк синдә. Халат кигәч, син...

Әхмәдуллина. Чәй кайнар чакта ник эчмисең?

Саттаров. Нәрсә?

Әхмәдуллина. Ясыйммы?

Саттаров. Юк, эчәсем килми. *(Пауза.)* Ябыккансың, сулыгып калгансың.

Әхмәдуллина. Бүген чираттагы шелтәне эләктердем. Бу турыда ике атна элек син кайгырткан идең, бүген — партком.

С а т т а р о в. Шелтә дисеңме? Анысы яхшы. Файдалы ул. Ә ни өчен?

Ә х м ә д у л л и н а. Оформление әзерләгән идек. Беренче зур йортта: «Гигантны төзүчеләргә — киләчәккә юл алучыларга дан!» дигән лозунг булырга тиеш иде.

С а т т а р о в. Шуннан?

Ә х м ә д у л л и н а. Бөтенесен эшләргә куштым. Ә менә хәрефләрне юньләп беркетмәгәннәр. Шул сәбәпле сызык...

С а т т а р о в. Сызык нишләгән?

Ә х м ә д у л л и н а. Төшкән. Гигантны данлы төзүчеләрнең берсесенең... башына төшкән. Ярый әле, таза ир булган. Метр ярым чамасы шул сызыкны күтәргән дә парткомга киткән.

С а т т а р о в. Шуннан?

Ә х м ә д у л л и н а. Шуннан шул — шелтә.

С а т т а р о в. Әйтәм бит, шелтә әйбәт ул, дип! Ул сызык синең башка төшсә, ә? Кара әле... күчмә йортлар белән ни эшлисез сез? Кая туры килде шунда ташлыйсыз бит. Ә суы, газы кая? Соңыннан үзегез үк, төзелештән кешеләр кача, дип сөрән сала башлыйсыз. Нигә качмасын ди алар?

Ә х м ә д у л л и н а. Бик күп халык килә бит, ташкын булып. Өлгереп булмый. Байков аларны мине тыңламыйча идарәләргә өләшкән, ә тегеләре йортларны кая телиләр шунда куялар. Тик объектка якын булсын да, кеше тизрәк кереп утырсын.

С а т т а р о в. Синеңчә, барысына да һәр вакыт Байков гаепле! Әйбәт идеяне тумас борын харап итәсең.

Ә х м ә д у л л и н а. Нигә дип кычкырасың әле син? Үз өемдә мин генә кычкыра алам.

С а т т а р о в. Ярый, бу мәсьәләне партиянең шәһәр комитеты бюросы өчен калдырыйк. *(Янәшәсенә утыра, кочаклый.)*

Ә х м ә д у л л и н а. Өркетмә. Мин кулымнан килгәннең барысын да эшлим.

С а т т а р о в. Димәк, азрак килә кулыңнан.

Ә х м ә д у л л и н а. Сиңа дулкынланырга ярамый. Тәүлекләр буе эшләргә дә ярамый. Хәлең ничек?

С а т т а р о в. Әйбәт.

Ә х м ә д у л л и н а. Шулаймы? Әйбәт, янәсе. Синең йөрәк ни хәлдә икәнен бераү дә белми бит.

С а т т а р о в. Я, ярый, җитәр!

Ә х м ә д у л л и н а. Ярчык борчымыймы?

С а т т а р о в. Нинди ярчык?

Ә х м ә д у л л и н а. Йөрәгең янына кереп урнашкан ярчык. Аның белән тыныч яшисезме? Бер-берегезгә сугыш ачмау турында килештегезме?

С а т т а р о в. Каян беләсең син?

Ә х м ә д у л л и н а. Шулай... монда берәүне очраткан идем. *(Ирония белән.)* Синең чик буенда батырларча хезмәт итүең турында сөйләде. *(Пауза.)* Хәлең ничек? дип сорыйм мин синнән.

С а т т а р о в. Син сорадың, мин җавап бирдем: әйбәт. Гомумән, җитәр бу турыда! Аңладыңмы, җитәр!.. Һәр минут, һәр секунд...

Ә х м ә д у л л и н а. Ә бит... кинәт?

С а т т а р о в. Бернинди дә «ә бит», бернинди дә «кинәт» юк. Мин сау-сәламәт. Бу турыда барысы да белә... *(Кинәт аны күтәрә, әйләндерә.)*

Ә х м ә д у л л и н а. Җибәр, кирәкми!.. Сиңа начармы?

С а т т а р о в *(читкә китеп һәм бөкрәеп)*. Кичә кич сиңа шалтыраткан идем... Менә шушылай ук нидер бөтереп алды. Үтәр, үтәр...

Хәзер үтә... Хәтта телефон янына көчкә өстерәлеп бардым. Һәм кинәт ялгызлык... Нигәдер эч поша.

Әхмәдуллина. Врачлар ни диделәр соң сиңа? Мин беләм. Син бит ул вакыт отпускага кайтып киттең! Син бит тикшеренер өчен көньякка киттең! Һәм бу ярчык та... Аны бит...

Саттаров. Йөрәккә бигрәк якын. Җайсыз урында. Борчылма. Барысы да әйбәт. Башкалар әле ул металлны әнә сугыштан бирле тәннәрендә йөртәләр. Күптән түгел миңа бер көрәзәче күпме яшәячәгемне әйтте. Озак яшим. Врачлар да... шуны ук әйттеләр. Озын энәләр генә сатып алырга кирәк!..

Әхмәдуллина. Нинди энәләр?

Саттаров. Бәйли торган...

Әхмәдуллина. Нәрсә бәйли торган? Нигә дип һәр вакыт көләсең син? Нигә кичә мине тапканчы шалтыратмадың?

Саттаров. Мин... синең янга... бөтенләйгә килдем, Дания.

*Озак тынлык.*

Әхмәдуллина. Бөтенләйгә? Хәзер инде бөтенләйгәме? Бик тә бәхетле иттең.

Саттаров. Дания!

Әхмәдуллина *(паузадан соң).* Күптән түгел генә шушы өстәл янында кәгазьләргә чумып утыра идем. Кинәт кенә соңгы еллар тормышымнан бөтенләйгә җуелгандай булды. Яңадан кечкенә кызчык булып калдым. Безне балалар йортында йокларга яткырдылар, ә синең белән мин, аяк очларына гына басып, бүлмәдән коридорга чыктык. Син шунда конфетыңның яртысын миңа бирдең. Төн иде, шул чакта без үскәч ничек яшәячәгебез турында пышылдап кына сөйләштек. Аннары мин төне буе елап чыктым! Айнып китсәм — тагын мин... Берни дә юк. Куркыныч ул... андый кинәт үзгәрешләр! Ә безнең бала чактагы хыялларыбыз, антларыбыз! Хәтерендәме!

Саттаров. Хәтеремдә, Дания... Икебезне ике якка ташлады бит дөнья... Шундый эзләдем мин сине...

Әхмәдуллина. Эзләдең...

Саттаров. Соң бит мин таптым сине.

Әхмәдуллина. Таптың! Кайда соң син? Син бөтенләең белән тегендә... һәр вак-төяк турында кайгыртасың. Ә минем өлешкә берни дә калмый.

Саттаров. Ә син... Синең эшең азмыни?

Әхмәдуллина. Мөгаен, шуның өчен яратамдыр да мин сине. Ләкин минем өлешкә беркайчан да берни дә артмады.

Саттаров. Кешеләрдән ник качарга соң безгә?

Әхмәдуллина *(паузадан соң).* Мөгаен, боларның барын да бик соң... уйлагандырсың син. Әгәр дә теге вакытта булса...

Саттаров. Аңламыйм.

Әхмәдуллина *(елмаеп, авырлык белән).* Күңелемә хәнҗәр кададың да хәзер инде аңламыйсың. Сине әле мин кызганырга да тиешме?.. Сине кызганырга теләмим мин! Син соң мине кызгандыңмы? Кызгандыңмы син мине?

Саттаров. Туктале... *(Чәчләреннән сыйпап.)* Туктале. Димәк, син бу балалы хатынны... шуның өчен үз яныңа алдыңмы?

Әхмәдуллина. Тилекәем син. Кадерлем һәм бердәнберем.

Саттаров *(аны кочаклап).* Синең белән монда егерме елдан соң очрашканбыз икән, димәк, очраклы гына түгел бу, ә?

Әхмәдуллина. Киселгән икмәкне кире ябыштырыргамы? *(Пауза.)* Үп инде мине, үп! *(Ярсып.)* Бөтен җаны-тәне белән яратса да, мин бер көнне бирә алган мәхәббәтне гомеренә дә бирә алмас иде синең ул хатының.

С а т т а р о в. Күптән булган нәрсәдән көнләшәсең.

Ә х м ә д у л л и н а. Бер киселгән икмәкне ябыштырыргамы, Гайнан... Нигә кирәк миңа киселгән икмәк?! Көнләшмим мин, көнләшмим...

С а т т а р о в *(кызып)*. Ярый, булды! Ялгыштым! Соң хәзер ни эшләргә, атылыргамыни инде?.. Мин сиңа тәкъдим ясыйм, әйдә, миңа киттек. Квартираңны аңа... балалы хатынга калдыр. Миндә яшәрбез. Киттек! Без бит кешеләр... Без кешеләр бит, ачуым да килмәгәе!

Тынлык.

Ә х м ә д у л л и н а. Ә аны, үз хатыныңны оныттыңмы син?

С а т т а р о в. Хатынымны! Нинди хатын ди ул миңа? Безнең аның белән бергә яшәмәгәнгә алты ел инде. Суд белән аерылышмавыбызның сәбәбе — минем вакыт юк, ул иренә! Син — минем хатын!

Ә х м ә д у л л и н а. Читен безгә... Без бер-беребездән башка да яши алмыйбыз, бергә дә...

С а т т а р о в. Ә болай яши алабызмы? *(Пауза.)* Болай бит берберeңне үлем хәленә китерергә мөмкин. Нигә соң син катлаулы ялганнан курыкмыйсың да иң гади дәреслектән куркасың?

Ә х м ә д у л л и н а. Ни сөйлисең син? Нәрсә турында? Я аллам, эш анда гынамы соң? Күпме еллар буе ялгызым яшәдем? Бик җиңел булды дисеңме? Күпме наз, күпме ягымлылык... һәлак булды миндә! Таш мин хәзер! Киптем! Куркам мин! *(Пауза.)* Мин моны сиңа, мөгаен, гомергә дә кичермәмдер! Бу бусага аша син дә, мин дә атламаячак. Таисиядән көнләшәм. Аның улы бар. *(Кызганыч елмаю белән.)* Соң инде. Соң.

С а т т а р о в. Нишләп соң? Нишләп?

Ә х м ә д у л л и н а. Куркам мин. Аннары нинди ир белән хатын ди инде без синең белән! *(Пауза. Коры, кискен.)* Син боерырга күнеккән, ә минем белән... Мин үзем дә кешеләргә каты куллы!

С а т т а р о в *(паузадан соң)*. Ә мин... Синең янга шундый өметләр белән...

Ә х м ә д у л л и н а *(ачынып)*. Нинди хатын ди инде миннән хәзер? Без синең белән дуслар гына. Дуслар, дошманнар... Һәм нииндидер ярым сөяркәләр!.. Ни икәнен дә белмәссең! Гомергә дә булмаган һәм булмаячак улым кебек хәзер син миңа. Безнең улыбыз кебек. Үз улым кебек яратам мин сине.

Озак пауза. Саттаров тора да чыгып китә.

Ә х м ә д у л л и н а *(сикереп торып)*. Гайнан!

Ишек ябыла. Әхмәдуллина хәрәкәтсез, бөтенләй хәрәкәтсез. Аннары ул әкрен генә тора, бүлмә буйлап ишекле-түрле йөренә. Ишек тагын ачыла. Тик... Саттаров түгел, - ә А л с у керә.

Ә х м ә д у л л и н а. Нәрсә бар? Әллә аңа бер-бер хәл булдымы?

А л с у. Кемгә? Вакытсыз кердемме әллә? Гафу итегез! Күптән түгел экскаваторчы ярдәмчесе үлде... Аның хатыны сездә яши дип ишеткән идем. Мин... Бәлки аңа бирәр ярдәм кирәктер... Ярдәм итәм мин аңа! Мин бурычлы!

Ә х м ә д у л л и н а. Ул кайдыр чыкты... Кая китте соң ул?

А л с у. Йөгерегез! Куып җитә аласыз әле сез аны! *(Кинәт елый башлый, Әхмәдуллинага сыена.)* Күрдем мин, ул сездән чыкты...

Ә х м ә д у л л и н а. Ни эшлисең? Ни булды сиңа?

А л с у. Сез аны яратасыз. Мин аңа... күрәзәлек иттем. Сез дә... яратасыз... яратасыз...

Ә х м ә д у л л и н а. Елыйсыңмы син? Кем син?..

А л с у. Әйе, әйе, мин үзем дә... Моңарчы әле берәүне дә яратканым юк иде! Беркайчан да! Ә хәзер күралмыйм!.. Ярдәм итәргә тиеш мин хәзер, ярдәм итәргә!..

*
* *

Тән. Полигон. Егет белән кыз. Саттаров, аларга бәреләязып, чигенә, икенче якка китә.

Кыз. Кара әле, ай калыккан.

Ашот. Элек шәп булган ул, ичмасам — ай да урман. Мәхәббәт өчен шуннан да шәбе юк инде. Ниндидер Тургеневта, мәсәлән, шулай. Аһ, ух һәм ай.

Кыз. Ә хәзер? Хәзер дә шулай ук...

Ашот. Ә хәзер, әнә, күрәсеңме, краннар, балкалар. Айның кайда икәнен дә аңлап булмый. Ничек үзгәрүебезне шайтан үзе генә белә!

Кыз. Ә хисләребез барыбер, их син, тилекәй! *(Үбешәләр.)* Тавышланма, кемнәрдер килә!

Ашот. Әйтәм бит, элек мәхәббәт өчен менә дигән шартлар булган, ә хәзер бернинди шарт юк.

Ике егет күренә.

Виктор. Бүген Леха белән бердек тә соң кирәген! Ул — БелАЗда, мин — КрАЗда. Газга басып, дала буйлап сыптырам гына!

Юрий. Нинди Леха ул?

Виктор. Леха инде. Икенче колоннадан.

Юрий. Кара әле, Витек, синең тамак ялгарлык берниең дә юкмы?

Виктор. Ашказаның синдә түгел, син ашказанында икән.

Юрий. Аппетитым гына кузгалды. Көне буе саф һавада бит.

Гәүһәр керә.

Гәүһәр. Юра! Син нәрсә! Мин сине көтәм дә көтәм! Киттек, әйдә!

Юрий. Витя, таныш бул, Гәүһәр.

Виктор. Ярый, ярый...

Юрий. Кәләшем минем, кәләшем.

Гәүһәр. Көтәм мин сине, көтәм.

Юрий. Көтәм дә көтәм! Менә, монда мин.

Гәүһәр. Тагын эчтеңме?

Юрий. Баллон җибәрде бит, мин гаепләме әллә?

Гәүһәр. Кил әле монда, кил! Нинди баллон, ник башымны катырасың син, ә?

Юрий. Гәүһәр, нигә син кулларың белән...

Гәүһәр. Кул кул белән, әйт, нинди баллон?

Юрий. Шәхесемне хөрмәт ит минем!

Китәләр. Кулларына чәйнек, кәрзин тоткан Сатынский күренә.

Саттаров. Николай Николаевич, Николай Николаевич!

Сатынский. Туйдым мин ул сөйләшүләрдән, Гайнан Сәлимович! Миңа каршылардан да, мине яклаучылардан да туйдым. Менә чәйнек, үтүк, ит тарткыч сатып алдым. Кибетләрдә һәр вакыт булып тормыйлар. Алсуга бүләк итәрмен. Һәм шул!

Саттаров. Без мәсьәләне кискенрәк куячакбыз, Николай Николаевич.

Сатынский. Мәсьәләне теләсә күпме тапкыр куярга була. Аның белән генә эш кыймылдамаячак.

Саттаров. Ахыргача тыңлый аласызмы сез мине?

Сатынский. Ни телисез миннән, Гайнан Сәлимович? Мәсьәлә куюдан, мәсьәлә күтәрүдән, бусага таптаудан туйдым. Туйдым мин

ул мәсьәләләрдән. Байков мине монда өстерәп китерде. Яклады! Рәхмәт аңа. Ә хәзер, комиссия бер урында таптана башлагач, куак артына посты. Ә сез, сез куак артына кайчан посасыз?

Саттаров. Күрәм, сез инде шурлагансез!..

Сатынский. Әйтегез әле, миңа кирәкме бу! Минем үземәме?

Саттаров. Аңлагыз, төзелеш хәзер ике чат уртасында. Гадәти формула буенча — казна исәбенә һәм исәпсез китүе бар аның. Башка юл белән китәргә дә мөмкин! Барыбыз бергәләп, менә синең белән мин, нинди юлга этәрәбез бит...

Сатынский. Мин инде этәрдем. Беләсезме, гомерем буе этәрәм. Дан эзләмәдем, башкасын таптым!

Саттаров. Николай Николаевич, беләсеңме, мин кемнән күбрәк куркам? Көчле кешеләрдән түгел, юк, көчсез кешеләрдән куркам...

Сатынский. Ә мин көчсез кеше. Пенсиягә чыгам.

Саттаров. Чыкмаячаксың син пенсиягә. Иртә әле сиңа пенсиягә! Шуны аңла, Николай Николаевич, син, Сатынский булмасаң, бүтән Сатынский булыр иде! Шундый ситуация хәзер. Син бик тә кирәк, син булырга тиеш. Әгәр инде син бар икән... үз-үземә хыянәт итәргә бирмәячәкмен мин хәзер, бирмәячәкмен!

Сатынский. Тыңлагыз әле, менә сез барыгыз да сөйлисез дә сөйлисез. Сез яклыйсыз, Гайнан Сәлимович. Ләкин, гафу итегез мине, сез ни эшлисез? Конкрет ни эшлисез? Партиясез мин. *(Әхмәдуллина керә.)* Ә сез шәһәр комитеты секретаре. Әгәр сүздә генә сарыф итәсез икән, сезгә власть, авторитет ни өчен бирелгән соң? Сез!.. Бөтен ышаныч фундаментларда икәненә сез хәтта Байковны да ышандыра алмыйсыз. Гафу итегез, мине, Гайнан Сәлимович, иң яхшысы, тапшырыгыз үзегезнең партбилетыгызны. Әйе, әйе, үзегез барыгыз да, кулыгыздан алганчы, аны үзегез үк өстәлгә китереп куегыз! Булдыра алмыйм, диегез! Гафу! Гафу! *(Китә.)*

Саттаров Әхмәдуллинаны хәзер генә күрә.

Әхмәдуллина. Мин сине бөтен җирдән эзләдем.

Саттаров *(паузадан соң)*. Карт хаклы... Карт һәм хәйләкәр, борыч савытымыни! Мәскәүгә очарга кирәк! Аның белән, Байков белән очарга! Өлкә комитетын, Үзәк Комитетны бу эшкә тартырга кирәк!

Әхмәдуллина. Әйе, әйе, әлбәттә. Тик үзеңне сакла.

Саттаров. Юк, муеным сынса сынар, әмма эшне барыбер ахырынача җиткерермен! Ниһаять, бу — минем намус эшем.

Әхмәдуллина. Тик болай борчылма гына. Сакла үзеңне.

Саттаров. Менә бу эшне бетерермен дә беркайчан да борчылмам.

Әхмәдуллина. Мондый сүзләр күпме булды да, бу эшләр күпме булды инде.

Саттаров. Монысы соңгысы!... Ахырына җиткерәм дә, үземә ике бәйләм чигү җебе алып, тәрәзә янында чигеп утырам. Яки бәйләү энәсе алырмын.

Әхмәдуллина. Ант итәсеңме?

Саттаров. Син миңа шунысын әйт, Дания, безнең бу кычкырышу да соңгысымы?

Әхмәдуллина. Соңгысы.

Саттаров *(як-якка каранып һәм аны кочып)*. Дөрес әйтте теге егет: мәхәббәт өчен бернинди шарт юк монда. *(Китәләр.)*

*
* *

Кухня. Байков квартирасы. Стенада — аптечка. Ишектә звонок тавышы.

Байков *(кухняга Саттаров артыннан кереп).* Уз, әйдә, уз. Хәзер без синең белән...

Саттаров. Шулай бик соң килүемә ачуланмыйсыңмы?

Байков. Кем өчен соң? Утыр, әйдә, утыр. Килеп бик яхшы иттең әле. Теге чакта без синең белән... Шундый тойгы — аз гына якага-яка әләгешми калдык.

Саттаров. Нәрсәсен искә төшереп торырга инде аның.

Байков. Килүең бик яхшы булды. Шатмын. Слушай, без хәзер синең белән... Слушай, әйдә, акрынрак кыланыйк, юкса, хатын күптән йоклый. Малайны инде берничә тәүлек күргән юк. Менә шулай яшим!

Саттаров. Аңлашыла.

Байков. Кайсысын эчәсең, коньякмы, әллә сухойнымы?

Саттаров. Кайсысын бирәсең...

Байков *(аптечкадан бер шешә коньяк алып).* Күр әле, йокламыйсың, димәк.

Саттаров. Күрәм, син дә йокламыйсың бит.

Байков. Менә эшләрдәге, документлардагы... кайбер нәрсәләрне караштырасы бар иде. Аннары газеталар атна буе укылмаган. Шулай... Ни өчен эчәбез инде без синең белән? Әйдә, болай: татулык өчен!

Саттаров. Әйдә, җиңү өчен, Иннокентий!

Байков. Безгә синең белән килешеп, дуслыкта яшәргә кирәк. Җиңү өчен... Сырын капкала... палтусын таты менә... Булыр бит инде ул, шайтан алгыры!

Саттаров. Минем нигә килгәнне беләсеңме?.. Бу фундаментлар ызгышын кичекмәстән Мәскәүгә җиткерергә кирәк дип уйлыйм. Мин әле генә өлкә комитетына шалтыраттым. Өенә... Беренче белән, икенче белән сөйләштем. Икесе дә каршы түгел. Иртәгә беренче ЦКга шалтырата. Без иртәгә үк синең белән икәүләп... Мәскәүгә очабыз.

Байков. Тукта әле, тукта! Кая очарга? Ә төзелеш?

Саттаров. Ну бары ике көнгә.

Байков. Вакытың бар икән, оч.

Саттаров. Мин төзелеш начальнигы түгел. Мин шәһәр комитеты секретаре.

Байков. Секретарь булсаң, үз эшең белән генә шөгыльлән, үз эшең белән, аңлыйсыңмы? Гомумән, Гайнан Сәлимович, без болай килешик... Менә минем кабинетта...

Саттаров *(аны бүлдереп, сөйләшүне шаянлык белән генә икенчегә борырга тырышып).* Бу — синең кабинет түгел, ә кухня.

Байков. Менә шул шул — кухня! Кайчакта эшне ун минутта хәл итәргә мөмкин кебек, бары да бик җиңел кебек тоела. Ә ул ел буе да хәл ителми. Мин заводлар комплексы төзергә тиешмен. Миңа срок бирелгән.

Саттаров. Син бит үзең... Сатынский идеясен беренче булып яклап чыктың.

Байков. Мин... Мин!.. Хөрмәтле ике проект институты проектчылары белән ике министрлык аппаратының бу идея турында бердәм фикергә килүен күтәргә кем рөхсәт бирә миңа?

Саттаров. Ә нигә күтәргә? Ә нигә көрәштән баш тартырга.

Байков. Көрәш юк монда, юк. Мәсьәләнең инстанцияләр аша үтүе генә бар. Инстанцияләр аша, аңладыңмы? Капкала, әйдә, капкала. Моннан ун ел элек мин Төньякта ГЭС төзедем. Ә ул елларда...

ул чакта план органнары хөкүмәтне күбрәк җылылык станцияләре төзергә кирәклегенә ышандырдылар. Шундый мода чыккан иде ул чакта! Проектлаучыларның берсе әнә анда, Төньякта да җылылык станцияләре төзү проекты тәкъдим итте. Өч мең километр ераклыкта чыгарыла торган ташкүмерне ягып эшли торган станция. Андагы салкыннарда таш булып ката торган мазутта эшли торган станция. Күз алдыңа китерәсеңме? Әле ачылмаган газда эшли торган станция. Ха-ха!.. Һәм, ышансаң ышан, ничек кенә көлке тоелмасын, әнә шул кретин эшне тоткарлап, төзелеш башлауны бер елга кичектереп тора алды... Тыңла, кадерлем минем, тинтәкләр әле шундый күп һәм боларның барысы да миңа шундый таныш!..

Саттаров. Фаш итәргә кирәк аларны.

Байков. Син каршы чыккан кешеләр белән миңа, Гайнан Сәлимович, эшләргә дә эшләргә әле. Аннары шуны да әйтәм: Мәскәүгә барып ультиматум куяргамы? Беренчедән, тәвәккәллеге зур, икенчедән, слушай... Син ничек фикер йөртәсең, ничек уйлыйсың? Бу фундаментларда куркыныч як бер дә юкмы? Мин — башкаручы, мин — солдат. Проектым бар икән, төзим. Яхшырак проект бирсәләр, аның буенча хөкем йөртермен. Ә ультиматум куярга...

Саттаров. Синең катнашу бик тә кирәк.

Байков. Вакытым юк минем! Иң мөһиме, ызгышта катнашырга вакытым юк. Төзергә кирәк миңа. ТЭЦ төзергә, ГЭС төзергә, промбазалар төзергә кирәк! Завод, шәһәр төзергә кирәк! Мин 600 миллионнан артык сумма белән кереп баттым инде. Кирегә китсә... моның белән ел буе йөзебезгә бәрәчәкләр бит...

Саттаров. Әлбәттә, аңлыйм мин, аңлыйм. Корпусларны болай да өяргә була. Гомумән, ни шайтаныма кирәк сиңа бу яңа фундаментлар идеясе! Нигә вакланырга! Бандитизм белән шөгыльләнү җиңелрәк, гадәтләнгәнрәк.

Байков. Нинди бандитизм?

Саттаров. Нинди? Үзеңә каерасың.

Байков. Нәрсә?

Саттаров. Әйт әле миңа, син илне һәр вакыт таладыңмы? Барлык төзелешләрдә дә таладыңмы? Очсызракка төшәме, кыйммәткәме — синең өчен барыберме?

Байков. Ярый, булды, әйдә... болай килешик, Гайнан Сәлимович, син үз эшеңне бел, минекенә тыгылма! Әлегә монда төзелеш начальнигы мин. Ә теге... комиссарлык итүеңә мин күп түзеп тора алмам!

Саттаров. Бар шундый кешеләр, алар бөтен мөнәсәбәтләрен, бөтен тормышларын власть мәсьәләсенә кайтарып калдыралар. Янәсе, кем кемнән өстенрәк? Мин синең хокукларыңа дәгъва белдермим.

Байков. Безнең арадагы үзара мөнәсәбәтләр нинди — һич аңламыйм, аңламыйм.

Саттаров. Үзара мөнәсәбәт турында сөйләшәсең килә икән инде, әйтим: син төзелеш өчен җавап бирәсең...

Байков. Әйе, әйе.

Саттаров. Ә мин — барысы өчен дә! Мондагы бөтен тормыш өчен. Кибетләрдә... менә бу кыярлар булсын өчен дә, халык кешечә яшәсен өчен дә, синең ничек эшләвең өчен дә, Байков!

Байков. Минем ничек эшләвем өчен? Ярый-ярый. Гомумән, күрәм, син бу фундаментлардан... үзеңә сикерер өчен фундамент ясамакчы буласыңмы? Демагог! Лыгырдадым да шуның белән эш бетте дип уйлыйсыңмы? Синең кебекләр өчен төзелеш трамплин гына ул. Бәлки монда йолдыз тагарга уйлыйсыңдыр? *(Күкрәгенә суга.)*

Саттаров *(көлеп)*. Таксалар, тыйнаклыктан үлмәм. Тик безгә йолдызны беркем дә бирмәячәк. Синең белән минем аны бирерлек

эшебез юк әле. Шундый бер проблема турында беркайчан да уйланганың юкмы синең, Иннокентий Владимирович?..

Б а й к о в. Акрынрак.

С а т т а р о в. Исемдә хатынның йоклаганы, исемдә. Менә шул, кеше һәм аның эше проблемасы турында беркайчан да уйланып караганың юкмы синең? Эше үзеннән зуррак булганда, кешегә ни булуы турында уйлаганың юкмы? Эше кешенең үзеннән бәләкәйрәк булган очрак турында да уйлаганың юкмы? Ә без синең белән кечерәк аннан, кечерәк!

Б а й к о в. Ташла, фәлсәфә корма син!

С а т т а р о в. Фәлсәфә корма! Мин төзүче түгел... Ләкин шуны аңла син: әнә шул Сатынский фундаментларыннан, идеясен син үзең үк биргән кучмә йортлар индустриясеннән... төзелешнең ниндидер яңа стиле укмаша башлый бит. Бу инде шуның сыйфатлары, шул стиль штрихлары! Илебез күтә ул яңалыкны. Чөнки ул ансыз яши алмый инде! Бөтенләй казырга кирәк булмаган котлованнарга без миллионнар, дистә миллионнар, ил буенча йөзләрчә миллион сум ташлыйбыз! Инерция буенча ташлыйбыз! Ә хәзер бөтенесе төзелешкә барып тоташа! Бюджетның төп өлеше — төзелешкә. Төзелеш — илнең киләчәге, халыкның киләчәге ул!.. Ә безнең газаплар, туктаусыз уздырган киңәшмәләр, эштә тәнге уникегә кадәр утыруларыбыз барысы да әнә шул эшли белмәвездән, стилебез булмаудан! Ул стиль барлыкка килә башлады инде. Монда, бездә, барлыкка килә башлады. Авырлык белән, газап белән булсын, әмма барлыкка килә башлады! Моны бит үз тирең белән тоярга, сизәргә кирәк! Без омтылган нәрсә бары шул чакта гына яуланачак!

Б а й к о в. Тел ярыйсы синдә, яхшы чарланган. *(Паузадан соң.)* Әйтеп карарга кирәк, бәлкем, «Белем» җәмгыятенә лектор итеп алырлар үзеңне, ә?

С а т т а р о в. Димәк, стенага борчак чәчтем! *(Стаканын күтәреп.)* Иннокентий Владимирович! Әйдә, без хәзер иң яхшысы...

Б а й к о в. Әйдә.

С а т т а р о в. Безнең урынга көчлерәк кешеләр килсен өчен эчик. Бездән көчлерәк кешеләр! Әйдә!

Б а й к о в. Алай, алай. *(Стаканын куеп.)* Димәк, конфликтта торуны дәвам иттерәбез?

С а т т а р о в. Син әйбәт кеше, Иннокентий Владимирович. Кеше буларак, мин сине хәтта яратам да. *(Пауза.)* Аңламасаң, бер хәл иде. Бәлкем син йомшап калгандырсың. Бу еллар эчендә күп нәрсә үзгәрде бит. Башка масштаблар.

Б а й к о в. Гомумән, икебезнең беребезгә бирелән китәргә кирәк булачак.

С а т т а р о в. Син аңла, Иннокентий Владимирович, шулай булмаганда, сине иң беренче булып тормыш үзе куачак һәм мин беренче булып кул күтәрәчәкмен.

Б а й к о в. Ә нигә әле син, синең тавыш минекеннән көчлерәк, дип уйлыйсың, ә? Юк, кадерлем, мин үзем дә синең кебекләрне беренче кабуда ук йота алам. Әйдә, хәзер эчик инде... Менә кыярын капкала.

С а т т а р о в. Мин ышанган идем сиңа, Иннокентий. Ләкин бу ышаныч аркасында эш тукталса? Һәм кирәк якка бармаса? Иртәгә Мәскәүгә очам. *(Китә.)*

Б а й к о в. Бар, бар, кая телисең, шунда оч! *(Телефон янына килә, номер җыя.)* Алло, Байков бу... Зинһар, тиз бирегез... Мәскәүне һәм... өлкәне. Әйе, әйе, кичекмәстән... Телефон — ике, сиксән алты, дүрт, җитмеш бер...

Полигон. Үзәктә — Мәскәүдән килгән җаваплы работник Саттаров, Байков, Дунаев, проект институты директоры Пыпин, Качаева белән Гоголев та шунда.

П ы п и н. Монда үзегез килүегез һәм безнең проект институтының җитәкчеләрен чакыруыгыз бик яхшы, Корней Петрович, бик яхшы бу. Сез барысын да хәзер үз күзләрегез белән күрдегез. Әлбәттә, без идеягә каршы килмибез. Болай ул үзе бер дә, бер дә начар түгел.

С а т ы н с к и й *(зәһәр)*. Мин монда комплиментлар тыңларга килмәдем! Эш, ниһаять, үле ноктасыннан кузгалыр дигән өмет белән килдем мин монда!

П ы п и н. Мин дә шулай дим, сезнең эшкәртмәләр, Николай Николаевич, һичшиксез, перспективалы дип әйтәм. Киләчәктә...

С а т т а р о в. Иптәш, иптәш Пыпин! Перспективалы идеяләрне эшкә ашыруга сез һәр вакыт шундый ысул белән ярдәм итәсезме?

П ы п и н. Гафу итегез, иптәш Саттаров... Белемегез нинди сезнең?

С а т т а р о в. Мин... белемем буенча юрист.

П ы п и н. Аһ, менә ничек икән. Алайса, аңлашыла. Безгә, әлбәттә, тагын да компетентлырак кешеләр фикерен белү файдалырак булыр иде. Шунысын күрү гаҗәбрәк: шундый зур төзелеш барган шәһәрдә... *(Әйтеп бетермичә.)* Мине гафу итегез, иптәш Саттаров, әмма сез белгечләргә ничек эшләргә кирәклеген нәкъ чын төзүче кебек күрсәтергә батырчылык итәсез. Бу, белсәгез әгәр, шактый куркыныч шаяру.

С а т т а р о в. Шулай дип исәплисезме?!.

К о р н е й П е т р о в и ч *(бүлдереп)*. Иптәш Пыпин, минемчә, монда компетентлы булмаган кешеләр юк! Мавыгулар турында исә ял вакытында сөйләшербез!

Г о г о л е в. Рөхсәт итегез, Корней Петрович! Шунысы көн кебек ачык: заводларның зур комплексы гүзәл идеяләрдә түгел, ә вакыт сынавын узган ныклы фундаментлар өстендә торырга тиеш...

С а т т а р о в. Йөз еллар сынавынмы?

Г о г о л е в. Мондый искиткеч зур колачлы төзелешләрдә, хөрмәтле иптәш Саттаров, хәтта кечкенә генә хата да һәлакәтле нәтиҗәләргә китерүе мөмкин! Әгәр дә инде дәүләт комиссиясе дә шушы көнгә кадәр билгеле бер карарга килә алмаган икән...

С а т ы н с к и й. Тагын бер тапкыр әйтәм: мәсьәләгә карашы буенча да, үзенең составы буенча да ведомство комиссиясе иде ул!

Д у н а е в. Без, Корней Петрович, мәсьәләнең асылын объектив тикшерүче яңа дәүләт комиссиясе билгеләнүен сорыйбыз.

Г о г о л е в *(Дунаевка)*. Аңлагыз, иптәш Сатынский экспериментларын без үзебез дә түземсезлек белән күзәтәбез. Бик шат булыр идек, әгәр дә...

С а т т а р о в. Ташлагыз! Сез шуны яхшы аңлыйсыз: әгәр дә фундаментлар вакытында яки хәтта иртәрәк өлгерсә, төп башына утырачагыгызны бик яхшы аңлыйсыз. Ә монтаж эшләрен башлап җибәрергә әзер булмаячаксыз! Икърар итегез шуны, я! Сез бит әзер түгел, сезнең министрлык әзер түгел! Эшнең төп асылы менә шунда!

Г о г о л е в. Гафу итегез! *(Корней Петровичка.)* Бәхәснең мондый методлары белән минем очрашканым юк иде әле!

Д у н а е в. Сез әйберләрне үз исемнәре белән атамаска өйрәнгәнсез.

С а т т а р о в. Ә бездә чак-чак кына башка темперамент!

Г о г о л е в. Дәүләт комиссиясе нәтиҗәсен шик астына куясызмы?

С а т т а р о в. Әйе, куям!

Г о г о л е в. Нәрсәгә нигезләнеп?

С а т т а р о в. Нәрсәгә нигезләнепме? Менә сезгә карыйм мин, иптәш Пыпин... Сез зур проект институты директоры... Сезгә карыйм да шуны уйлыйм: монда сүз проблеманың техник ягы турында түгел, ә проблемага якын килү турында баруын аңламыйсызмыни соң сез? Ә бу караш бик тар, дәүләт карашы түгел, ведомство карашы.

П ы п и н. Үтә кызыл төс зәвыксыз кешегә һәр вакыт матур күренә. Сез нәрсә, иптәшләр! Кыска вакытлы дан өчен гигант заводның киләчәген куркыныч астына куяргамы? Ул фундаментларны сынарга кирәк әле! Сез мине гафу итегез!..

С а т ы н с к и й. Саратов ГЭСын җыелма тимер-бетоннан төзедек. Күпләр тоташ бетон ягында иде. Кемнәрдер безне дә авантюристлар дип атады!

П ы п и н. Сез, Николай Николаевич, һәр вакыт кынсыз кылыч болгыйсыз! Кылыч бит кыныннан чын сугышта гына чыгарыла!

С а т ы н с к и й. Ә бу нәрсә соң? Үз күләгәң белән сугышмыни?

К о р н е й  П е т р о в и ч. Иптәшләр, иптәшләр! Артык сүз безнең вакытны ала. Миңа төзелеш начальнигының позициясе бик үк аңлашылып бетми. Шундый тәэсир туа, әйтерсең лә боларның барысы да тик шәһәр комитеты секретаре белән баш механикка гына кирәк, Иннокентий Владимирович?..

Б а й к о в. Беләсезме, Корней Петрович...

С а т т а р о в. Корней Петрович, хөрмәтле... кадерле Иннокентий Владимирович Байков белән килешенмәгән булса, шәһәр комитеты секретаре буларак, мин һәм, баш механик буларак, Дунаев сезгә мөрәҗәгать итәрләр һәм мәсьәләне шундый кискен итеп, зур итеп куярлар иде дип уйлыйсызмы?

Б а й к о в. Беләсезме, Корней Петрович, эш нәрсәдә... Принципта мин иптәш Сатынскийның субай фундаментлары идеясенә теләктәш. Бу турыда... иптәш Саттаровка әйттем инде мин. Әлбәттә, мәсьәлә... мөһим. Официаль төстә фатиха бирсәләр, мин... Төзелеш интересында бит... Әйе!..

П ы п и н. Майя Михайловна, комиссия члены буларак, сезнең караш төгәлрәктер. Үтенәм сездән! Ник дәшмисез?

К а ч а е в а *(авырлык белән).* Әйе, чынлап та төгәл. Мин, комиссия члены буларак, заключениегә кул куйдым.

Озакка сузылган тынлык.

П ы п и н. Я, нигә дип тукталып калдыгыз? Үтенәм сездән!!

К а ч а е в а. Нәрсә үтенәсез? Ни турында? Сез сораганны әйтә алмыйм мин! Башкача булдыра алмыйм! Булдыра алмыйм! Әйе, куйдым мин кулымны заключениегә! Куйдым! Ләкин эш шунда, иптәшләр, бу заключение инде каралама төсендә анда — Мәскәүдә үк язылган иде. Монда килгәнче ике атна элек!

П ы п и н. Ни сөйлисез сез?! Бу бит!..

К о р н е й  П е т р о в и ч. Дәвам иттерегез, дәвам иттерегез, Майя Михайловна.

К а ч а е в а. Минем яктан... сатлык җанлылык булды бу. Әйе! Әйе! Сатынский фундаментларын куллануның техник яктан максатка ярашлылыгы тулы бер тәҗрибәләр сериясе белән нигезләнгәнен белгән идем мин.

Г о г о л е в. Бәхетсезлек очракларына нигезләнгәнен дә белдегез, шулай түгелме? Субайларның техник төзелеше әле эшләнмәгән. Теге кызны, сварщицаны хәтерлисезме, Николай Николаевич? Хәле ничегрәк аның?

С а т ы н с к и й. Шәп! Бик тә шәп!

К а ч а е в а. Полигонда бәхетсезлек башка сәбәптән килеп чыкты. Фундаментлар ышанычлы. Безнең заключение... күрәсең, без үзебез... шәхес буларак, ышанычсыздыр.

П ы п и н. Мөмкин түгел бу! Ничек җөрьәт итәсез сез?..

Г о г о л е в. Көтмәгән идем. Сез бит, Майя Михайловна...

К а ч а е в а *(Пыпинга).* Эштән китү турында гаризаны бүген үк, хәзер үк бирәчәкмен. Хәзер үк!

П ы п и н. Гариза?.. Ә сез шуны аңлыйсызмы, бу бит... судка бирерлек эш! Моның аркага пычак кадау, хезмәт җинаяте икәнен аңлыйсызмы сез? Аңлы килеш чынбарлыкны бозып күрсәтү бу!

К о р н е й П е т р о в и ч. Тынычрак, иптәшләр, тынычрак. *(Пауза.)* Башка берәүнең дә әйтер сүзе юкмы? Яхшы, алайса. Карашлар ачык. Мәсьәлә бик җитди. Ахыр чиктә сүз илдәге барлык төзелешне ниндидер яңа нигезгә күчерү турында баруы мөмкин. Төзелеш өлкәсендә яңа техник политика турында... *(Пауза.)* Мин сезгә, Иннокентий Владимирович, бер генә нәрсә вәгъдә итә алам: мәсьәлә иң якын арада хәл ителәчәк. Дәүләт комиссиясе — ә аның составында объектив кешеләр булыр дип ышанам — нәтиҗәләр өчен кирәкле материаллар бирер. Сезгә, Николай Николаевич, әлегә фундаментларны сынауны дәвам иттерергә кирәк. Менә шул, иптәшләр... Рәхмәт.

П ы п и н. Корней Петрович?..

К о р н е й П е т р о в и ч. Сез дә китә аласыз, иптәш Пыпин. Ачыкларбыз. Сау булыгыз, Майя Михайловна.

Б а й к о в. Корней Петрович, шуны сорыйсым бар иде...

Таралыша башлыйлар.

К о р н е й П е т р о в и ч. Иннокентий Владимирович, син үзеңә кайта тор. Мин озакламам, сөйләшербез.

С а т т а р о в. Майя Михайловна, бик тә читен була икән, кыюлык тапсагыз, безгә килегез. Нәрсә-нәрсә, ә эш бездә җитәрлек.

Д у н а е в *(якын килеп).* Эш бездә муеннан.

С а т т а р о в. Менә ул табып бирәчәк сезгә.

К а ч а е в а. Рәхмәт.

С а т ы н с к и й. Майя Михайловна, ничек соң сез? Ай-яй...

К а ч а е в а. Николай Николаевич!

С а т ы н с к и й *(бик тә нәзакәтле итеп аның кулын үбә).* Кулыңны бир, иптәш! Әйдә, киттек!

К о р н е й П е т р о в и ч *(Саттаров белән икәүдән-икәү генә калып).* Ошамый миңа синең йөзең, юрист. Авырмыйсыңмы?

С а т т а р о в. Юк, авырмыйм.

К о р н е й П е т р о в и ч. Читенме?

С а т т а р о в. Читен.

К о р н е й П е т р о в и ч. Алайса, сөйлә: кайда авыр, ни өчен авыр, ничек авыр? Кара әле, Байков белән синең арада нәрсә килеп чыкты анда?

С а т т а р о в. Ник алай дисез?

К о р н е й П е т р о в и ч. Болай гына.

С а т т а р о в. Бәхәсләшәбез кайчак.

К о р н е й П е т р о в и ч. Шуннан, шуннан... Ә, гомумән, ничегрәк соң Байков?

С а т т а р о в. Ярыйсы. *(Пауза.)* Аның кебек акыллы, тәҗрибәле һәм карт атны бүгенге ладта җигәргә мөмкин һәм кирәк тә. Аңласа, ышанса... Ә ул ышаначак башкача хуҗалык итү мөмкинлегенә, ышаначак.

К о р н е й П е т р о в и ч. Яклыйсың, димәк?

С а т т а р о в. Яклыйм. Ә нигә якламаска?

К о р н е й П е т р о в и ч. Завод бик тә мөһим. Бу һәм стратегик, һәм экономик, һәм политик яктан удар булачак. Мондый төзелеш башында...

С а т т а р о в *(аны бүлдереп).* Хәзергә әле башлангычларның башлангычы, Корней Петрович. Авыр, читен, баш буталырлык. Маңгаең

җиде, хәтта ундүрт карыш булса да!.. Җитәкчене кинәт төшергән вакытлар да була. Яңасы килә, ә кем киләсе билгесез, ә проблемалар, әлбәттә, шул ук!

Корней Петрович. Я, я?

Саттаров. Мин болай гына... Җитәкчелекнең министрлык стиле турында... кайбер борчыган уйлар гына. Минем белүемчә, кайчак шулайрак ишетелә... анда хәзер... төзелешнең башында барлыкка килгән бөтен гаепне өярлек бер корбан турында уйлый башлаганнар. Үзләре судан коры чыгарга маташалар!

Корней Петрович. Ә соң Байков ничегрәк?

Саттаров. Нәрсә, Байков? Кирәк ул төзелешкә. Аның төзелеше бу... Бер нәрсәне...

Корней Петрович. Нинди бер нәрсәне?

Саттаров. Бернәрсәгә карамастан.

Пауза.

Корней Петрович. Ярый, алайса, бик яхшы. Сезнең арада аңлашу булу яхшы. Югыйсә, миңа кайбер нәрсәләр ишетелгән иде. Я, ярый, Байковка киттем. Сау бул.

Саттаров. Яхшы.

Корней Петрович китә.

Сатынский. Гайнан Сәлимович, Гайнан Сәлимович! *(Якын килеп.)* Гайнан Сәлимович, мин теге вакыт сезне тактик ният белән рәнҗеттем. Бары тактик ният белән генә...

Саттаров. Нәрсә, нәрсә?

Сатынский. Беләсезме, тагын да ныграк ярсытырга тырыштым мин сезне.

Саттаров. Әһә, димәк, син үзеңә тәҗрибә куяны таптың? Эксперимент үткәрәсеңме?

Сатынский. Гафу итегез мине, Гайнан Сәлимович, зинһар, гафу итегез. Беләсезме, минем анда, Мәскәүдәге өемдә, бердәнбер кыйммәтле нәрсәм — Левитанның автографы язылган картина бар. Шуны җибәрермен мин сезгә.

Саттаров. Николай Николаевич, без нәрсә, бер-беребезгә мәхәббәт белдерешә башлыйкмыни инде? Менә бу эшләрне тәгәллик тә, мөгәрич куярсыз, сез пенсиягә чыккач, сагынып искә алырлык бер истәлек булыр, ичмасам.

Сатынский. Нинди пенсиягә ул? Пенсиядә ни эшләрмен мин?

Саттаров. Пенсиягә китәм, дип әйткән идең, янаган идең бит!

Сатынский. Нинди пенсиягә?

Саттаров. Янаган идең бит соң!

Сатынский. Пенсиядә ни эшлим ди мин? Әйттең син дә сүз: пенсиягә, имеш! Нишлим мин пенсиядә? Үзең чык син ул пенсиягә! *(Китә.)*

Саттаров. Югыйсә бит, җиңү көне киләсенә бөтенләй ышанмый иде. Ярый, ничек тә булса күрербез әле ул көнне!..

* * *

Байковның эш кабинеты. Кич. Байков, Салихова һәм Мөнир Зарипов.

Салихова. Мин булдыра алганча тырышам, Иннокентий Владимирович.

Байков *(кәгазьләр актарып)*. Нәрсә?

Саликова. Арыдым.

Байков. Без, туган, барыбыз да арыдык.

Саликова. Хатын-кыз икәнемне дә онытттым инде.

Байков. Нәрсә?

Саликова. Сез дә арыдыгыз. Сакламыйсыз үзегезне. Ә кешеләр моны бәяли белми. *(Дәшми торгач.)* Ә без... алай ук корычтан түгел инде без. Бер-беребезне сакларга кирәк. Бер буын кешеләре без.

Байков. Әйттегез! *(Кәгазьгә кул куеп һәм аны биреп.)* Йомышыгыз беттеме сезнең?

Саликова. Аһ, әйе, мин сандугачтай сайрый башладым... Мин бит сезнең янга һәр вакыт эш белән генә керәм. *(Ишеккә таба барып.)* Кою комплексы төзелешендәге хәл турында сез мең кат хаклы, Иннокентий Владимирович. Тикшерәчәкмен мин аны.

Байков. Нәрсә?

Саликова. Мин барын да аңладым. *(Китә.)*

Байков *(кабинет буенча йөренеп).* Нәрсәгә дип кашыңны җыердың? Яздыңмы?

Мөнир *(язып).* Юк әле. Яратмыйм мин бу хатынны.

Байков. Аңларга була аны, четреклерәк яшьтә ул хәзер. Кайчандыр арыслан кебек көчле, матур булган. Бөтенесенә баш булып яшәгән. Ә хәзер менә нинди... Болай, гомумән, эшлекле хатын иде.

Селектордан тавыш. Иннокентий Владимирович, сезне улыгыз сорый, кабул итүне үтенә. Нәрсә диярга?

Байков. Улым?

Селектордан тавыш. Әйе, Вадим.

Байков. Әйтегез, сөйләшер өчен аңа кич һәм төн бар! Табан ялтыратсын моннан! Шулай... *(Мөниргә.)* «Өченче пункт. Июльдә алты кучмә бетон заводын монтажларга һәм эшләтә башларга...» Мин объектларда йөргәндә, Саттаров шалтыратмадымы?

Мөнир. Юк.

Байков трубканы ала, әмма номер җыймыйча кире куя.

Мөнир. Шулай да урыныннан куптарды бит фундаментларны, э, Иннокентий Владимирович?

Байков. Нәрсә? *(бик каты ачуы чыгып.)* Минем түгел, аның ярдәмчесе булып эшләргә кирәктер сиңа! Мин дә үз каналларым буенча хәрәкәт иттем, беләсең килсә!

Селектордан тавыш. Иннокентий Владимирович, улыгыз кабул итүне бик тә үтенеп сорый.

Байков *(паузадан соң).* Ярый, керсен. *(Мөниргә.)* Әйдә, туктатып торыйк, Мөнир. Җибәр әле берәрсен крюшон алырга. Бөркү.

Мөнир китә. Арган-талган Байков маңгаен учлары белән тотып утыра. Вадим керә.

Вадим. Әткәй.

Байков. Я? *(Телефон трубкасын яңадан ала, яңадан куя.)*

Вадим. Ник андый приказ чыгарылган? Мин әле генә прокуратурада булдым, тикшерүче белән сөйләштем.

Байков. Шуннан?

Вадим. Мине күрәсең килми. Әллә ничә көн инде синең белән очраша алмыйм мин.

Байков. Үкенергә килдеңме? Вөҗданың шулай куша башладымы? Хәшәрәт!

Вадим. Ә нигә үкенергә? Ни өчен хәшәрәт?

Байков. Чөнки иптәшеңне саттың. Уңайлы хәлләрдән файдаланып, үз гаебеңне башка берәүгә аудармакчы булдыңмы?

Вадим. Нинди хәлләр? Нинди? Бары тик мин генә гаепле, дип әйттем бит мин.

Байков. Ни сөйлисең син? Тагын боргаланырга тотындыңмы? Хәшәрәт!

Вадим. Техника куркынычсызлыгы бүлегендәге ул сволочька басым ясарга кем кушты сиңа? Кем? Нигә дип кул куйдың син ул приказга?

Байков. Приказ бәхетсезлек очрагын тикшерү нәтиҗәләре нигезендә язылды. Үз гаебеңне инкарь иткән, ул гына да түгел, үз прорабыңны бик тырышып һәм шактый оста батырган күрсәтмәне укыдым мин.

Вадим. Минме? Мин прорабны батырганмы?

Байков. Ә кем соң? Минме әллә? Тәүбә итәргә килдеңме? *(Аның яңагына суга.)* Кит моннан! Хәзер үк олак!

Вадим *(сакланмыйча)*. Үз гаебемне танмадым мин, аны башкага аудармадым! Мин андый... андый... күрсәтмә бирмәдем! Беркемне дә батырмадым мин! Батырмадым!..

Байков. Аңламыйм... Нәрсә, ул Саликова үз белдеге белән шулай эшләдеме икәнни?.. Бәлкем үзен эштән алырга җыенуымны сизгәндер, үз-үзен яклау эзләп, миңа шундый «бүләк» әзерләгәндер, ә?

Вадим. Судтан курыкмыйм мин, әткәй, үз карьерам өчен дә калтыранмыйм.

Байков. Ярар. Әгәр дә син әйткәннәрнең барысы да дөреслеккә туры килсә, Саликова эшеннән алыначак һәм судка биреләчәк. Синең статья буенча түгел, башка статья буенча!

Вадим. Син прораб Гәрәевне... Мин шуның өчен килгән идем.

Байков. Прорабны эшенә кире алырмын. *(Улын кочаклап.)* Гафу ит. Авыртмыймы инде? *(Аны ишеккә таба этәреп.)* Я, ярар, бар. Вакытым юк. Бар. Булды! Булды!

Вадим *(ишеккә юнәлеп)*. Шулай да, әткәй, безгә бер төзелештә эшләргә кирәк булмаган.

Байков. Сәрхәнтәй.

Вадим. Нигә алай дисең, нигә? Туйдырды мине синең исем астында яшәү. Ә бәлки мин үзем дә күптән Байковтыр, бәлки миңа да үз исемем белән яшәргәдер. Вакыттыр инде!

Байков. Көчле кеше булып үсүеңне теләгән идем. Шуңа күрә дә җәһәннәм авызына илтеп тыктым. Киләчәктә син дәвам иттерәчәк бит. Сез, яшьләр...

Вадим. Мине баштук участок начальнигы итеп куйдың. Бер генә тапкыр булса да сөйләшеп караганың булдымы синең: миңа чит тенме, юкмы — шул турыда сөйләшкәнең булдымы? Без синең белән, әткәй, алты ел буе кешеләрчә сөйләшкәнебез юк. Хәтта монда да, мондый хәлләр килеп тугач та...

Байков. Әһә, кешеләрчәме... Мин — чин кешесе, улкаем, чинлы кеше мин. Минем хәзер синең белән дә сөйләшергә хокукым юк. Әйе, әйе, сиңа — үз улыма да вакыт әрәм итә алмыйм. Мине синең хәсрәт борчыйдыр дип уйлыйсыңмы? Мин шул турыда баш ватадыр дип уйлыйсыңмы? Шулай булмыйни! Субай фундаментларын уйлыйм мин. Төзелештә тәүлеккә миллион сум акча тотарга вакыт җитүен уйлыйм. Министрлык каршында ярты еллык отчет бирәчәгемне уйлыйм. Менә нәрсәләр турында баш ватам мин. Я, ярый, бар син, Вадим. Кайчан да булса якамнан тотып пенсиягә озатырлар, шунда сөйләшербез кешеләрчә.

Вадим. Менә шул, пенсиягә куганчы әйтәсе сүзем бар, әткәй. Нигә дип бөтен ваклыкларга тыкшынасың син? Кешеләргә ышанмыйсыңмы әллә? Хәтереңдәме, төзелешкә, минем участокка бары бер генә минутка килдең, ә үзең шундук, нигә алай, нигә болай түгел,

икенче экскаваторың нишләп тик тора, тык аны котлованга, дип өйрәтә башладың.

Байков. Өйрәтсәм ни, шуннан?

Вадим. Мин тыктым, һәм кеше үлде. Нишләп соң әле без Сатынский фундаментлары барында котлованнар казып ятабыз? Казуны дәвам иттерәбез. Ә нигә дәвам иттерергә? Нигә?..

Байков. Тукта әле, тукта... Син нәрсә?.. Мине гаепли башладыңмы? Мин сиңа эшне тизләтергә куштым. Нәрсә, кешеләрне балчык өеме астына тыгарга куштыммыни мин? Буш куык!

Вадим. Буш куык түгел мин, әти, аңламадың син мине. Син бит бөтен төзелеш начальнигы. Синең кул астында дистәләрчә төзелеш идарәләре, йөзләрчә төзү-монтаж идарәләре. Еш кына бик тә оят була. Кайвакыт син иң булдыксыз төзү-монтаж идарәсе начальнигы дәрәҗәсендә фикер йөртәсең.

Байков. Иң начары дәрәҗәсендә дисеңме?.. Шәп!

Вадим. Мин бит мәктәптә укыган вакытта ук синең хактагы барлык газета мәкаләләрен җыеп бардым. Синең турыдагы барлык газета кисәкләре, очерклар бар миндә. Ачыктан-ачык әйткәндә, төзелеш институтына керүем дә... синең янәшәңдә булырга хыялланудан. Тирәңдә түгел, янәшәңдә булырга хыялланудан.

Байков. Иң начары дәрәҗәсендә дисеңме? Их, Вадька. Хәзер минем кул астында илле мең кеше эшли. Ел ахырына җитмеш мең булачак. Ә менә шуларны бер уч төбенә җыярга... Бу төзелешнең минем өчен бигрәк тә зур булуын белмәдем мин. Дан җырым булыр дип уйладым. Тормышымда эштән башка бернәрсәм дә юк бит минем! Туган шәһәрем дип атарлык шәһәрем дә юк, чөнки мин теләсә кайда яшим! Үзем үләчәкне белгән йортым да юк! Сез... семья... шулай... Мин сезнең өчен ят кеше булып калдым, чөнки мин сезне күрмәдем диярлек. Бөтен гомеремне төзелешкә бирдем! Эшемнән башка күз алдына китерә алмыйм мин үземне. Бөтен көчемне эшкә бирәм. Беләсеңме, Вилюй, Ангара, Казагыстан, Балхаш төзелеше... Ләкин ул чакта барысы да җиңелрәк булган икән. Җиңелрәк. Аңлаешлырак...

Вадим. Иң яхшысы, Саттаровка әйт син боларны!.. Шалтыратып ятканчы, аның белән бергә эшлә!

Байков. Тукта әле, тукта! Һич аңламыйм. Саттаровның ни катнашы бар монда?

Вадим. Мин теге вакытта өйдә идем һәм синең Мәскәүгә шалтыратып Саттаровны төрле яклап яманлавыңны ишетеп тордым.

Байков. Юк, аңламыйм. Саттаровның ни катнашы бар? Әйе, яманладым мин аны! Мәрхәмәте өчен аңа миннән рәхмәт әйттерергә телисеңме әллә? Минем отставка мәсьәләсендә мине яклавы өчен рәхмәт әйтимме? Бернинди мәрхәмәтне дә җенем сөйми. Аякларым белән басып торган җирне тартып алмакчымы? Җиңүгә, тормышка шанс бирде, әмма үз-үземә ышанычымны тартып алды ул минем! Күралмыйм һәм түзә алмыйм!..

Вадим. Кызма, әткәй! Шуны аңла син: Саттаров синең йөкнең бер өлешен үз җилкәсенә алган. Саттаров...

Байков. Нәрсә? Нинди йөк? Нәрсә чыркылдыйсың син? Я хода! Менә мин — мин үземне һич юк нәрсәне юнып, бик акрын, бик тә кыенлык белән шомартып ясадым. Мин барлык баскычларны берсен дә читтә калдырмыйча намус белән үттем, һәр нәрсәне үз җилкәмне бөкрәйтеп таптым! Хәзер ничек бар икәнмен — моңа мин үземнең ихтыярым, хезмәтем, бөтен тормышым белән ирештем! Я хода, мин шул кадәр күп төзедем. Ә ул нәрсә төзеде соң? Саттаровыңны әйтәм! Әйт миңа, нәрсә төзеде ул?

Вадим. Тынычлан.

Байков. Юк, юк! Ул нәрсә төзеде? Нигә син Саттаров дип минем колак итемне чәйнисең? Нигә дип аны телеңнән төшермисең? Бу төзелешне миңа ышанып тапшырдылар. Миңа! Миңа ышандылар! Нигә соң ул көчләрәк? Ни өчен?

Вадим. Тынычлан, эткәй, барын да булдырырсың син. Тик шуны аңла: ялгызың гына булдыра алмыйсың, юк!

Селектордан тавыш. Иннокентий Владимирович?

Байков. Тыңлыйм, Надя, тыңлыйм!

Тавыш. Трубканы алыгыз. Сезне... Саттаров эзли.

Вадим. Киттем мин. *(Китә.)*

Байков *(трубканы алып)*. Әйе, Гайнан Сәлимович! Әйе... Әһә! Аңлашыла. Кайчан? Сәгать өчтә дисеңме?.. Ярый, яхшы... Булырмын... Булырмын...

*
* *

Төзелеш мәйданы: Саттаров белән Сатынский.

Сатынский *(бара-бара)*. Үтенеп сорыйм, Гайнан Сәлимович, үтенеп сорыйм! Барлык башка эшләрегезне куеп торыгыз... аларын... башка вакыт! Соңгара күрмәгез, зинһар! Дәүләт комиссиясе бөтенләй башка составта килде, кем белә, бәлкем?!

Саттаров. Колакларыңны үрә тот һәм сау бул. Соңга калмам.

Китәләр. Шундук Ашот белән Виктор күренә.

Виктор. Нәрсә кирәк сиңа, я нәрсә?

Ашот. Ни пычагыма өченче катны алып килдең? Беренче кат кирәк миңа! Беренче кирәк, аңлыйсыңмы?

Виктор. Зинһар дим бәйләнмә, алла хакы өчен ялварып сорыйм!

Ашот. Ни эшлим ди мин бу панельләр белән? Ни пычагыма алар миңа?

Виктор. Ни бирәләр, шуны китерәм! Мин гаепләме әллә? Аларга тимер-бетон заводындагы мәйданны бушатырга кирәк, шуңа күрә күзләренә ни күренде, шуны җибәрәләр.

Ашот. Слушай, син бар да шушы панельләр белән Геворгянның конторасын каплап куй, пожалыста! Мәнсез дип әйт, пожалыста!

Виктор. Үтенәм синнән, кит моннан, кит... Синең кайгың түгел миндә... Я, олактырыйммы үзеңне? Ераккарак олактырыйммы? Ишетәсеңме син! Иң якын дустым Юрка өйләнә.

Ашот. Юрка дисеңме? Ни сөйлисең син? Юрка? Мин дә өйләнәм.

Виктор. Өйлән, өйлән! Барысы да өйләнә.

Икәүләп шау-шулы, көлеш, җыр белән тулы туй күренешенә таба китәләр. Өлкән яшьтәге Захарыч, бала коляскасы этеп Таисия, кулына самавар тоткан Рушания күренәләр.

Захарыч. Шушында каршылыйбыз. *(Рушаниягә.)* Куй самаварыңны.

Таисия. Язмыш шулайдыр инде, күрәсең. Кемгә тулы чынаяк, кемгә төбендә генә. Карап калыйм, ичмасам!

Захарыч. Түз, әни кеше. Тормыш әле сиңа чынаякны тутырып бирмәсәме, менә минем битемә төкерерсең. *(Самаварга карап.)* Кирәкме... мин сиңа... самавар бүләк итәм, ә? Үз исемемнән, үзем бүләк итимме?

Таисия. Нигә кирәк миңа самавар?

З а х а р ы ч. Һа!.. *(Каушап кала.)* Чәй эчәргә.

Т а и с и я. Чәйне мин... чәйнектән эчәм!

Р у ш а н и я. Тая самавар алып кайтып килә! Көлеп үләрсең! *(Көлә.)*

З а х а р ы ч. Их, сез!..

Туй күренеше. Загстан кайтышлары. Яшьләр уртасында — Гәүһәр белән Юрка. Шунда ук Алсу, Нюра, Вера. Мәңге авызыннан төшми торган, әйтерсең иреннәренә ябыштырылган сүзләр: «Ә Ванька Морозовның бернинди дә гаебе юк бит!»... сүзләре белән Виктор. Ашот та монда. Ике төркем бергә кушылгач, шау-шу көчәя, берләшә.

Ю р и й. Захарыч, киттекме эчәргә? Соңгы тапкыр эчәм. Рөхсәт итми менә...

Г ә ү һ ә р. Кая алып килдең син, билдән саз бит монда! Ярый да, син итектән, мин бит туфлидан гына!

Н ю р а. Зарар юк, зарар юк. Юра, ал инде кәләшеңне кулыңа.

Г ә ү һ ә р. Нишлисең, акылдан шаштыңмы әллә? Нишлисең дим?

Р у ш а н и я. Төшермә, Юрка! Ай, төшерә инде!

Г ә ү һ ә р. Менә, рәхмәт!

Ю р и й. Ә син курыккан идең!

З а х а р ы ч. Хәзер нотык тотам!

Н ю р а. Тавышланмагыз, Захарыч сөйли!

З а х а р ы ч *(тамак кырып)*. Без хәзер нәрсә күрәбез? Без зур электр самавары күрәбез. Бу самаварны без тантаналы һәм чын күңелдән якын итеп, сердәш итеп бүләк итәчәкбез... Рушания! Яңа өйләнешүчеләрнең меңенче парына!

Н ю р а. Ә нигә сердәш итеп?

Ю р и й. Чөнки меңенче пар.

З а х а р ы ч. Аның эмаль өслегендә...

Н ю р а. Никель өслек, Захарыч!

З а х а р ы ч. Гафу, никель самавар. *(Кыенсынып.)* Бүлдермә! Мин нотык сөйлим! Без хәзер, иптәшләр, көләч йөзләр күрәбез!

Р у ш а н и я. Ай, әкәмәт тә кеше инде син, Захарыч! Көлеп үләрсең!

З а х а р ы ч. Менә шул, маймычлар... Менә шул!.. Бүген профкомда, башкарма комитетта шундый сүз булды: меңенче парга иң беренче йорттан шундук бер бүлмәле фатир...

Н ю р а. Ура, кызлар!

Ю р и й. Мин әйттем инде аңа — балконлы квартира!

Г ә ү һ ә р. Син түгел, мин әйттем!

З а х а р ы ч. Менә шул, маймычлар! Тәмам картайгач, шушы самаварга карап, үзегезнең яшьлегегезне, безнең көләч йөзләрне искә алырсыз.

А ш о т. Син сөйлисең дә сөйлисең, ә минем баш авырта башлады. Тост әйтергә ирек бир. Сезнең гүзәл мәхәббәтегез чәчәк атсын өчен!

Т а и с и я. Ә миңа ачы! Ачы!

Б а р ы с ы  д а. Ачы!

Н ю р а. Вера белән безгә дә берәр эчми торган егет, берәр самавар кирәк.

В е р а. Ай, Нюра, ни сөйлисең син?..

Н ю р а. Егетләр, әйдә, башла!

Музыка.

Җырлап китәләр. Бары тик Алсу белән Рушания һәм дә Алсуга берекә Виктор кала. Авызында шул ук җыр: «Ул тимер чыбык буйлап атлады...»

А л с у *(Викторга)*. Нигә дип һаман шыңшыйсың, эчне пошырасың син, ә? Миңа да ачы хәзер, Витька! Ачы, ачы!

В и к т о р *(Вадимны күреп).* Әнә ул! Әнә! Ачы икән, бар, бар!

Аз гына читтәрәк — Вадим Байков. Алсу аңа таба бара. Әкренләп якынаялар.

В а д и м. Синең туйдыр дип уйлаган идем.
А л с у. Ни сөйлисең син?
В а д и м. Мөгаен, үземне дә, сине дә... кызганмаган булыр идем...
А л с у. Ишеттем мин... Барын да беләм... Теге вакытта ышанмаган идем сиңа. Ә аннары... аңладым да... тик соңдыр, кире кайтарып булмас дип уйладым. Күзләреңне күрмәгәнмен мин ул вакыт.
В и к т о р. Хуш, Алсу.
А л с у *(аптырабрак).* Ни дидең?
В и к т о р. Хуш.
А л с у *(аптырап).* Хуш дисеңме?
В и к т о р. Димәк, син аның белән... Ә мин... кая булса да китәрмен. Җир шары зур ул. Адашырлык хәтта. Хуш! Хуш! *(Китә.)*

Рушания кинәт елый башлый.

А л с у. Ни булды сиңа, Рушания?
Р у ш а н и я. Китәме ул? Китә бит!
А л с у. Син?
Р у ш а н и я. Әйе, әйе, яратам! *(Виктор артыннан йөгерә.)*

Шундук атылып Саттаров, аның артыннан ук инженер керә.

И н ж е н е р. Иптәш Саттаров, төзелештән җибәрүегезне үтенәм мин.
С а т т а р о в. Качасыңмы? Чистарту корылмаларысыз шәһәрнең дә, заводның да була алмаячагын яхшы беләсез, ә качасыз!.. *(Алсуны күреп.)* Ә, күрәзәче! Хәзер инде качып котыла алмассың, багарсың. Әйеме? Исән-саумы? Бик шатмын. Сәлам, Вадим.
И н ж е н е р *(үз сүзен тәкърарлап).* Үз теләгем белән килдем мин монда. Үз теләгем белән китәчәкмен дә! Үтенеп сорыйм, әйтегез, учеттан төшерсеннәр!
С а т т а р о в. Без башта сине партиядән чыгарачакбыз, аннары инде кая телисез шунда китәрсез! Фронтта сатлыкларны аттылар, без дә... *(Кинәт тынып кала.)* Партия билетын... карьера коралы гына итүче барлык бушавызларны... барлык демагогларны... тимер себерке белән куачакбыз!..
И н ж е н е р. Сезгә ни булды?
С а т т а р о в. Бар, бар! Шайтаныма олак! Мин андый үз теләге белән килүчеләрне...
А л с у. Хәлегез начарландымы?
С а т т а р о в. Күрәзәче...
И н ж е н е р һәм В а д и м. Хәзер шалтыратам, хәзер! Шалтыратырга кирәк. Яныннан китмә! *(Инде ерактан.)* Иптәш Байков, Саттаровның хәле бик начар! Иннокентий Владимирович! Әткәй!

Субай фундаментлардан берсенең тирәве буйлап Саттаров аска шуып төшә. Фундамент тирәвенә терәлеп утыра.

С а т т а р о в. Өлгермәдем...
А л с у. Миңа нишләргә?.. Әйтегез! Ярдәм итәрмен. Әйтегез, нишлим?..

Байков күренә.

Б а й к о в. Гайнан Сәлимович, син нәрсә болай? Ни булды сиңа?
С а т т а р о в. Берни дә юк. Хәзер үтә ул. Борчылма.
Б а й к о в. Тик кузгалма гына, кузгалма. Тыныч кына утыр.

«Ашыгыч ярдәм» чакыралар хәзер. Борчылма, бер-ике атна ятарсың, ял итәрсең. Бары да үтәр, без әле монда синең белән... беләсеңме!..

Саттаров. Хәзер анда дәүләт комиссиясе, син шунда бар. Мин сиңа бик тә ышандым, Иннокентий. Шуны бел, ышандым...

Байков. Я, нәрсә инде син, ә? Я алла! Бөтенесе... башлана гына бит әле. Синең белән әле без... шундый итеп төзербез! Хәзер «ашыгыч ярдәм» килеп җитәчәк, хәзер. Дания Кәримовна! Дания Кәримовна, тизрәк кил бирегә!

Әхмәдуллина *(кереп).* Гайнан! Хәлең авырмы?

Саттаров. Синең белән безнең... берни дә барып чыкмады, Дания.

Әхмәдуллина. Юкны сөйләмә, юкны сөйләмә! Яратам мин сине, Гайнан! Яратам! Яратам!.. Нишләргә соң? Ярдәм итегез кем дә булса, ярдәм итегез!

Аның кулындагы Саттаров кинәт йөзтүбән ава. Спектакль башындагы кебек ук очкыннар чәчрәве, көн белән төннең, төн белән көннең алышынуы. Һәм шушы төн уртасында Әхмәдуллинаның йөрәк яргыч тавышы: «Гай-на-ан!..»
Ут яктысында — телефон трубкасы тоткан кыз.

Кыз. Алло, алло, алло!.. Әни, әнием!.. Мин бу, мин!... Менә, күрәсеңме, күрәсеңме, дүрт мең чакрым ара, ә ничек ачык ишетелә. Әнием, беләсеңме, мин озакламый уналты катлы йортлар сала башлыйм... Юк ла, әнием, юк! Ни булсын ди миңа, ялгызым гынамы әллә! Беләсеңме, монда барысы да башкача, бөтенләй башкача! Тормыш, кешеләр башкача! Гел шашкандай йөрим... Нәрсә? Шашып! Шашынып!

Полигон мәйданы. Әхмәдуллина, Байков, Сатынский, Дунаев, Алсу, Вадим, инженер, коляска тарткан Таисия, Захарыч — Саттаров үлгән урында басып торалар. Алар монда аны күмгәннән соң килгәннәр.

Әхмәдуллина. Нәрсә диде ул тагын? Тагын нидер әйтте, нидер пышылдады бит ул соңгы минутында.

Инженер. Без әйткәләштек. Мин әйттем: миңа өйгә кайтырга кирәк дидем мин...

Сатынский. Ышана алмыйм. Нигә соң ул, ә мин түгел! Мин өлкәнрәк бит. Минем дә нидер әйтәсем бар иде аңа. Ә менә оныттым. Нәрсәне оныттым соң мин?

Әхмәдуллина. Хәзер исемә төшерәм... Ул вакыт аңламаганмын мин, ә хәзер төшенәм... Озакламый үләсен белде бит ул.

Дунаев. Белде дисеңме?

Әхмәдуллина. Әйе. Хәзер исемә төшердем... Әйе...

Байков. Белде? Ничек белде? Ничек инде белде?

Әхмәдуллина. Белде! Белде!..

Яңадан музыка, яңадан спектакль башындагы җыр.

Русчадан МИРГАЛИМ ХАРИСОВ тәрҗемәсе.

## Булат Сөләйманов

### Юлда

...Язмышны гомремдә
Бар дип тә белмәдем.
Язмышка кол булып
Ияреп йөрмәдем.

Үткәнгә кайту юк,
Юлларда мин һаман,
Юлдашым — бүгенгем:
Самотлор һәм Аган.

Күк тә юк, җир дә юк,
Нәкъ шаман бураны —
Карларны сихерләп,
Яшерә юлларны.

Тайганың үрләре
Гел алга чакыра.
Вакыт юк, тукталып
Торырга чак кына.

Әй, гомер, үткәндә
Калмады кемнәрең?
Юлларның дәвамы —
Киләчәк кеннәрем.

### Ак төн

Кояш сүнде тагын.
Хыяллардай якты,
Керсез күңелләрдәй
Ак төн җирне япты.

Кышны куып җирдән
Язлар кабат килде.
Кышкы төннәр сагы —
Караңгылык үлде.

Әсәренеп баксаң
Тирә-якка әгәр,
Күз күреме җитә
Офыкларга кадәр.

Язның күңеле — гөлләр,
Тайга чәчәк атсын!
Йөзеп бара таңга
Ак бәхетла ак төн.

## Төн буена

Бер-беребезнең эреп куенында,
Без утырдык икәү төн буена.
Төн буена яшен биеде
Барабаннар кагып күк туенда,
Без утырдык икәү төн буена.

Таң аткачтын гына абайладык:
Яшен сизеп изге теләкләрне,
Төн буена утлы җепләр белән
Теккән икән безнең йөрәкләрне —
Таң аткачтын гына абайладык.

## Фәния Чанышева

# ОЧРАШУЛАР, АЕРЫЛУЛАР...

## Ана һәр чак көтә

Аналарның бар гомере
Нидер көтеп үтә:
Сабыеның баш очында
Уянуын көтә.
Үзен танып, тәүге тапкыр
Елмаюын көтә.

Башын тотып, мендәреннән
Калкынуын көтә;
Дөнья ямен үзе танып,
Талпынуын көтә.

Онытып ялын, йокысын,
Карап туймый йөзен,
Көтеп ала тәүге тапкыр
«Әни» дигән сүзен.

Көтә аның тәпи басып
Атлап китәр көнен,
Көтә акыл, зиһен туплап,
Буйга җитәр көнен.

Аерылганда шомланырга
Таба сәбәпләрен.
Сагыш йотып, санап көтә
Кавышу сәгатьләрен.

Ана һәр чак якты хисләр,
Изге эшләр көтә...
Аналарның бар гомере
Шулай көтеп үтә.

●

Ызаннары — зәңгәр тасма,
Арышлар — атлас юрган.
Көнбагышлар — сары урман,
Кояшка карап тынган.

Яшәреп купергән болын —
Печәнгә төшкән вакыт,
Үләннәренә уралып,
Җиләкләр пешкән вакыт.

Аты атлый салмак кына,
Әтием көйләп килә.
Моңсу тавышлы җыр белән
Ул нәрсә сөйләп килә?

«Сайра, сары сандугачым,
Сайра, гөлләргә күмел,
Уйланмас, моңланмас идем,
Сабый чакларым түгел...»

... Чаба, машиналар чаба
Басулар буйлап юлдан.
Җәй-сылуым төрле төстән
Бизәкләр чигеп куйган.

Ызаннары зәңгәр тасма,
Арышлар — сары юрган,
Яфракларның шыбырдавын
Сагаеп тыңлый урман.

Яшәреп купергән болын...
Җитәкләп улым улын,
Атлыймын таныш юллардан,
Җырлыймын әти җырын.

●

Синең уңнан, минем исә
Килә сулдан барасы,
Бер уртак юл табалмыйча
Йөри адәм баласы.

Син күрәсең агын гына,
(Юк түгел бит карасы!)
Йөрәгең ачык җилләргә —
Килә пәрдә ябасы.

Берең көлә, икенчеңнең
Әрни иске ярасы,
Яшь аралаш елар җирдә,
Көлә адәм баласы.

Сиңа — тизлек, мин дигәннең
Ашыкмаска чамасы,
Һаман янып, һаман талып
Яши адәм баласы.

Син күкләргә омтыласың,
Мин җир-ана баласы,
Бер карасаң, безнең ара —
Җир белән күк арасы.

Күрелгәнгә күнегелгән.
Алга юллар ярасы.
Ялгышлар, табышлар өчен
Икәү бергә янасы.

## Алтын комлы Варна янында

●

Алтын комлы Варна янында
Бер карт килә диңгез ярына.

Колак салып төрле телләргә,
Туктап кала безнең тирәдә.

«Россиядан» дигән сүзеңә
Шат елмаю балкый йөзендә.

Күргән сыман үзенең улларын,
Якын итеп, суза кулларын.

— Дәва булсын, — ди ул, — дусларга,
Миндаль сала безнең учларга. —

Үсә миндаль минем җиремдә,
Шифалы ул йөрәк чиренә.

Йорт-җиремә рәхим итегез,
Ширбәтемне авыз итегез.

Якын күрә сезне һәр күңел,
Дуслар өчен җан да җәл түгел!

... Алтын комлы Варна янында
Бер карт килә диңгез ярына.

Хисе тирән безгә карата,
Ак чәчләрен җилләр тарата.

●

Коела, яңгыр коела,
Нигә коела икән?
Боега, күңел боега,
Нигә боега икән?

Күбеккә баткан диңгезнең
Төбе таш кына икән,
Ашкына, йөрәк ашкына,
Кая ашкына икән?

Нигә розалар күзеннән
Тамчылар тама бүген?
Нигә Балкан якларының
Томанлы җире, күге?

Диңгез ярында тирәкләр
Нигә бөгелә икән?
Ник Агыйделне сагынып
Үзәк өзелә икән.

●

Әллә инде акчарлаклар
Бүген иртә торган,
Берсе күктә, икенчесе
Җавап бирә судан.

Төнге яңгыр ап-ак итеп
Таш юлларны юган,
Диңгез өсте — зәңгәр күзге,
Күтәрелә томан.

Күзләр сүзсез аңлашалар,
Хушлашалар куллар.
Күңелләрне җилкендереп,
Җәйрәп ята юллар.

Куллар, гөлләр, ачык йөзләр...
Чуар ишек алды.
Кояш көлдө, нур бөркелдө,
Гайда [1] уйнап калды.

[1] Гайда — милли уен коралы.

## Равил Бикбаев,

башкорт шагыйре

### Уфа—Казан

●

Могҗизалар көтеп, ерак юлга
Атлыктым мин, «Өфө, Өфө!» дип.
Йөгерсәң дә ярсып,
Өфө сине
Каршы алмый икән «өф!» итеп.

Ялбыр башлы ялан малаеның
Алларына сибеп мең төсен,
Бер яндыра, бер туңдыра икән,
Уфтандыра икән бу Өфө.

Кичә генә кебек урамнарны,
Авыз ачып, карап йөргәнем.
Мин урлаттым шул көн юл капчыгын,
Торып калды бары йөрәгем.

Тәүге көннән мине Уфам ничек
Сак булырга шулай өйрәткән!!
Тик мин җыйдым хәзинәсен җирнең,
Юк, кесәгә түгел, йөрәккә.

Алып килде Идел бу калага
Илнең күпме тонык инешен.
Күңелемә моңын, нурын койды
Мең инешнең холык-килеше.

Кешеләрнең өмет авазларын
Аерып алдым шәһәр шавыннан.
Зур Ватанның чиксез офыклары
Ачылып китте Уфа тавыннан.

Сусавымны баса алганы юк
Ят якларда сулар уртлавым.
Агыйделем, диеп, ашкынамын,
Уфам, диеп, кайтам уфтанып.

Хәйран калып торам тәү күргәндәй,
Кайткан саен ерак яклардан.
Күңел әзер гомер буе Өфөсен
«Өф-өф!» итеп кенә сакларга.

●

Уралымның төнге күкләренә
Күтәрелеп кенә бер кара:
Ир кулыннан төшкән калканмыни —
Ай ялтырап ята уртада.

Гаҗәпләнмә. Минем калканым ул.
Хыянәтнең татып яманын,
Минем дә бар иде, шатлык эзләп,
Җирдән күккә очкан заманым.

Бер ямь тапмый, җиһан гизгән чагым,
Калкан итеп айны капланып...
Сине күргәч, янә җиргә төштем,
Һаваларда калды калканым.

●

«...Без киттек. Башкалар килер».
*(Казан Кремлендәге язулардан)*

Кайный Казан.
Бер гаме юк
Гашыйклар дөньясында.
Сөю хатлары укыймын
Кремль коймасында.

Таштан сыгыла кешенең
Көлгәне, елаганы.
«Мин сине өзелеп көттем,
Нигә килмәдең, җаным?»

Учка йомып йөрәк-кузны,
Бу сүзләрне кем сызды:
«Синең эзләреңә басып,
Мин моннан синсез уздым».

Кайчан тугандыр бу гадәт,
Бозылмаган тик әдәп.
Минем егет кебек ярсып
Торуым гына гаҗәп.

Сәер лә соң... Давыл тынып,
Туармы бер тын көнем?
Мин киттем. Башкалар килер,
Башка йөрәк җилкенер.

Тик кайчан басылыр минем
Егеттәй җилкенгәнем.
Мине беркем көтми монда,
Нигә чыңлый колагымда:
«Нигә килмәдең, җаным?»
«Нигә килмәдең, җаным?»

●

Җиркәенә тамырланып үскән
Салкын ташларда да бар яра.
Иңендәге еллар йөгеннәнме
Җиргә иелә бара манара.

Тарихларның тыны бәрелгәндә
Ирләреңнең көя чигәсе.
Таш манара җиргә иелә микән
Күрергә дип Сөембикәсен.

Кем булгандыр шушы манараның
Нигез ташын тезеп коручы...
Ул исемнәр чал тарихта калган.
Мине әле башка уй борчый.

Үтәм дигәч, шулай үтү кирәк
Туу белән үлем арасын:
Син киткәч тә калган эзләреңә
Кыялар да иелеп карасын.

●

— Эзләсә үз Ирәмәлен [1],
Тапмасмы ир әмәлен?
Эретерме ир-егетне
Таңнарның иркәләве?

— Урап чыгып бар тарафны,
Актарып бар галәмен,
Эзләзә үз Ирәмәлен,
Тапмасмы ир әмәлен?

Шулай дип уята мине
Көннәрнең иртә мәле.
Якынайган саен ара
Һаман өскә калка бара
Эзләгән Ирәмәлем.

Тик тагын да яңа таңның
Сискәндерә сәламе:
— Эзләсә үз Ирәмәлен,
Тапмасмы ир әмәлен!

---

[1] Ирәмәл — тау исеме.

## Акъегет



*Биографиям кыска:*

*1951 елда Балык бистәсе районы, Юлсубино авылында тудым. 1968 елда урта мәктәп тәмамлагач, бер ел Казанда, производствода эшләдем. 1974 елда Казан дәүләт университетының тел-әдәбият бүлеген тәмамладым. Бүгенге көндә — Татарстан радиокомитетында әдәби хезмәткәрмен.*

*Шигырьләр язам. Аларда мин үземне борчыган уйларымны, шатлык-кайгыларымны, дөньяга карашымны укучылар белән уртаклашырга телим. Иң зур теләгем шул: үз иманыма — ышанычыма хыянәтсез, якты рухлы, заман сулышы белән сугарылган шигырьләр язасы иде...*

### Кил син, яме...

ҖЫР

Бел син, яме, бел син, яме,
көнгә көн бәйләнәсен,
алмагачның ал чәчәге
алмага әйләнәсен.

Ләйсәннәрдә кил син миңа,
килмә син көзләремдә.
Кояш булып балкырга кил
күк төсле күзләремдә!

Бел син, яме, бел син, яме,
көнгә көн бәйләнәсен,
алмалар да алсуланып
җирләргә тәгәрәсен.

Ләйсәннәрдә кил син миңа,
килмә син көзләремдә.
Кояш булып балкырга кил
күк төсле күзләремдә!

## Шигъри парчалар

•

Кем кемгәдер үпкәләгән,
кемдер сөйми кемнедер.
Ә тереклек хәрәкәттә,
хәрәкәттә барыбер:

Бакчаларда алмагачлар
ел да ак чәчәк ата;
алмадай тәгәри кояш,
каннарга бата-бата...

## Апрель иртәсе

Тәрәзләрдән яктылык ага,
яктылыкка кушылып —
язгы ис.
Сөңгеләрдән тамчы тама, —
каян килгән диген
бозга... хис!

•

Дөнья кайгылары баса,
әнисе елап ала...
«Әнием,
син бик әйбәт бит», — дип
юата аны бала.

## Манзара

Исмә, Җил,
Ай, янма болай, —
яфраклар дөрли башлады.
Ә бер болан
якты аланда
сискәнде нидер уйлап
һәм чапты ул җан-фәрманга
ут-әрәмәлек буйлап...

Язлар алда дибез,
язлар алда —
ашыгабыз ялган белән
күңелне ямарга...

Ә бит... сары яфракка
ятарга туфракка...

●

Китмәкче булсам илдән...
...Каеннар бирмәс бәхиллек,
фатиха бирмәс имән,
күңелне урар пәрәвез,
җанымны — мүкле үлән...

Шушы җирдә михнәте дә,
шушында — булса кадер!
Шушыннан мине җибәрми
тәнне йотачак кабер...

# БЕРЕНЧЕ МАРШРУТ: ЧАЛЛЫ—МӘСКӘҮ!

Таң калдырып, КамАЗ, бар дөньяны,
Күтәрелдең күзгә күренеп.
Сулышың ерак җәелә, төзүченең
Кайнар хисе белән үрелеп.

Бәйрәмеңдә бүген сиңа һәркем
Чын йөрәктән сөеп эндәшә:
— Гаҗәпмени көчле моторларың
Киләчәккә узып гөрләсә!

... 1976 елның 16 феврале Чаллының героик елъязмасына алтын хәрефләр белән язылыр. Бу көнне, баш конвейер пультыннан бирелгән командаларга буйсынып, комплексның катлаулы организмы беренче тапкыр хәрәкәткә китерелде һәм тигез ритм белән эшли башлады.

Баһадир заводның пульсы сак һәм төгәл, эшчеләр һәм белгечләрнең йөзләре җитди.

Җыючылар эшне тизләтүче, хезмәтне җиңеләйтүче өр-яңа җайланмаларны тагын бер тапкыр игътибар белән сынап-тикшереп чыгалар. Һәм менә конвейердан «КамАЗ» маркалы беренче машина төшә! Автомобиль төзүчеләрнең язылмаган кагыйдәсе буенча, тәүге машина Советларның дәүләт флагы төсенә — куе кызыл төскә буялган.

Беренче экипажның составында өч кеше. Рульдә — баш конструктор идарәсенең танылган шофер-сынаучысы, сабыр холыклы Себер егете Валерий Перетолчин. Машина кабинасында аның белән янәшә — Чаллының үзендә туып-үскән төзүче, бригадир, КПССның XXV съезды делегаты Р. Сабирҗанов. Экипажның өченче члены — төзелештәге иң яхшы монтажчыларның берсе, украинлы Д. Загребельный.

Конвейердан беренче машина төшүгә, автомобиль җыю заводында уздырылган тантаналы митинг кыска, ләкин бик шатлыклы һәм дулкынландыргыч булды. Анда чыгыш ясаучылар төзүчеләрнең, автозаводчыларның, монтажчыларның хезмәт батырлыгы турында сөйләделәр, чын мәгънәсендә бөтен халык төзелешенә әверелгән КамАЗга искиткеч игътибарлы булулары өчен КПСС Үзәк Комитетына, Совет хөкүмәтенә кайнар рәхмәтләрен белдерделәр.

Митингта катнашучылар барлык төзүчеләргә, автозаводчыларга, Кама автомобиль комплексын коруда булышучы барлык тердәш заводларның коллективларына, КамАЗның беренче чиратын эшләтү буенча партиябез тарафыннан 1976 елга билгеләнгән заданиеләрне үтәү өчен бөтен көчләрен берергә чакырып, мөрәҗәгать кабул иттеләр.

«Правда», Мәскәү.

Бу җиңү — комплексны төзүчеләрнең, монтажчыларның, аның барлык заводлары эшчеләренең һәм белгечләренең генә түгел, партия чакыруы буенча тугызынчы бишьеллыкның бөтен халык төзелешендә катнашкан йөзләрчә коллективларның да җиңүе. Монда социализм илләре экономик интеграциясенең уңай принциплары ачык чагылды. КамАЗны һәр ике як өчен дә файдалы нигезләрдә җиһазландыруда чит ил фирмалары да катнашты. Димәк, бу — КПСС-ның XXIV съезды тарафыннан кабул ителгән Тынычлык программасының зур җиңүе, ленинчыл партиябез Үзәк Комитеты, аның Политбюросы һәм КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре иптәш Л. И. Брежнев үткәрә торган үзара тату яшәү политикасының җиңүе.

Төзүчеләр бүген эстафетаны завод эшчеләренә тапшыралар. Баш конвейер янында — исемнәре билгеле булган, зур тәҗрибә туплаган белгечләр. Ниһаять, соңгы операция тәмамлана, руль артына шофер-сынаучы менеп утыра... Көчле алкышлар астында конвейердан беренче машина төшә. Бу машинаның «визит карточкасы»: бортлы, өч күчәрле «КамАЗ-5320» тягач-автомобиле, йөк күтәрешлеге — 16 тонна, двигателенең җегәрлеге — 210 ат көче, тизлеге — сәгатенә 80 километр. Ул ун төрле тизлеккә күчерелә торган тапшыру тартмасы, көчәйткеч идарә, ышанычлы тормозлар һәм җилләткече, җылыткычы, тавыш изоляцияләгече булган уңайлы кабина белән җиһазландырылган. Салкын көннәрдә моторны кабызу өчен махсус җайланма эшләнгән. Машина плюс 50 градустан минус 40 градуска кадәр температурада эшли ала. Аны Мәскәү авто«Зил»ы, двигателен Ярославль мотор төзүчеләре иҗат иткән.

— 1976 елгы Дәүләт планында 4 мең Кама автомобиле чыгару күздә тотыла, — ди КамАЗ автомобиль комплексының генеральный директоры Л. Васильев. — КПСС үзәк Комитетының партиянең XXV съездына «1976—1980 елларга халык хуҗалыгын үстерүнең төп юнәлешләре» проектында КамАЗ төзелешенең беренче чиратын унынчы бишьеллыкта төгәлләү билгеләнгән.

**«Известия», Мәскәү.**

...Митингка җыелган кешеләр, илебез автомобиль төзелешендә әле моңарчы тиңе булмаган куәтле бу комплексны корганда, 1508 көн дәвамында һәр көн саен хезмәт батырлыклары күрсәттеләр.

— 1969 елның декабрь көне минем хәтеремә гомерлеккә уелып калды, — дип сөйли йортлар төзү комбинатының 61 нче номерлы СМУ бригадиры Рәвис Сабирҗанов.— Экскаваторчы Михаил Носков туң балчыкны умырып алып, аны үзбушаткычның кузовына салды һәм шуның белән Кама автомобиль заводына нигез салына башлануын белдерде...

«ЗИЛ» һәм «ГАЗ», Ярославль моторлар, Минск, Кременчуг һәм Волжск автомобиль заводлары КамАЗга үзләренең тәҗрибәләре белән ярдәмгә килделәр.

... «КамАЗ» йөк машинасының конструкциясе әйтерсең лә совет автомобиль төзүчеләре туплаган барлык бай тәҗрибәне берләштерде. Сынаулар күрсәткәнчә, яңа автомобильне күп төрле эшләрдә файдаланырга мөмкин.

Коллектив предприятиеләренең барлык камазлыларга кабул иткән мөрәҗәгатендә болай диелә: «Хәзер төзүчеләр, монтажчылар, автозаводчылар коллективларының, «КамАЗ» коруда катнашучы барлык коллективларның төп бурычы бу ирешелгән гаять зур хезмәт уңышын ныгыту һәм үстерүдән, ел ахырына кадәр двигательләр һәм автомобильләр җыю, кою, пресс-рам заводларын, шулай ук бөтен комплексны тулаем төзүдән гыйбарәт».

Тулы көченә эшли башлагач, КамАЗ елына 150 мең авыр йөк автомобиле, 250 мең дизель двигателе эшләп чыгарачак.

**«Труд», Мәскәү.**

Төзелеш һәм монтаж эшләренең моңарчы әле шушындый кызу темплар белән алып барылганы юк иде. Партия һәм комсомол бирегә үзенең иң тырыш, иң ышанычлы вәкилләрен җибәрде, алар төзелеш практикасындагы барлык

яңа һәм прогрессив алымнар белән коралландылар... Тугызынчы бишьеллыкның беренче елында КамАЗда 223,8 миллион сум акча үзләштерелгән булса, 1975 елда ул 418 миллион сум үзләштерелде.

Алты завод: кою, тимерчелек, пресс-рам, двигательләр, ремонт-инструментлар һәм автомобиль заводлары 100 квадрат километр зурлыктагы бер мәйданга урнашканнар. Тәгәрмәчләр һәм дистанцион идарә итү аппаратлары заводы күршедәге Яңа Зәй шәһәрчегендә. Аларның һәркайсы автомобиль төзелешендә хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүне тәэмин итүче яңа технологиягә нигезләнеп корылган...

«Советская Россия», Мәскәү.

КамАЗ... Чаллы... Бу сүзләр безнең көннәрнең зур төзелеше синонимнары булып әверелделәр. Ул сүзләрдә совет кешеләренең үз-үзләрен аямавы, батырлыгы, хезмәт даны гәүдәләнә.

Менә комплекс корпуслары панорамасы. Аларда көйләү-җибәрү эшләре бөтен көчкә бара. Ә КамАЗ корпуслары белән янәшә төзелеш индустриясе завод-



КамАЗ машиналары Кызыл мәйданда

лары эшли. Яңа төзелгән яшь шәһәрнең ак кварталлары 15 километрга диярлек сузылган. Аның гомуми торак мәйданы 2 миллион квадрат метрдан арта. Хәзер Чаллыда 200 меңнән күбрәк кеше яши.

Чаллы элеккеге кечкенә район үзәгеннән тиз арада куәтле промышленность үзәгенә әверелүе белән генә түгел, үзенең эшләре белән дә данлыклы.

«КамАЗны бөтен ил төзи» дигән канатлы сүз төзелештә бара торган эшләрнең төп асылын билгели. Шул ук вакытта КамАЗ, үзенең уникаль булуы аркасында, яңа идеяләрнең һәм ачышларның генераторы ролен дә үти. Әлеге сүзләрнең инде «КамАЗ — илгә» мәгънәсендәге бәйләнештә әйтелешен дә ишетәбез.

КамАЗның төп үзенчәлеге — аның Бөтенсоюз удар төзелеше булуында. Барлык совет халкы белән бергә төзелештә комсомол вәкилләре, илебезнең меңнәрчә егетләре һәм кызлары актив катнашты. 1970 ел башында ВЛКСМ Үзәк Комитеты КамАЗны Бөтенсоюз удар комсомол төзелеше дип игълан итте һәм аны шефлыкка алды. Шул вакыттан башлап Чаллы комсомол путевкасы белән килгән 4 меңнән артык яшь төзүчене, профессиональ-техник училище тәмамлаучыларны һәм инженер-техник работникларның зур отрядын кабул итте.

Әйе, Кама буйларына кыю кешеләр килде. Аларны уртак бер теләк — илебездә тагын бер индустриаль маяк кабызу теләге дәшеп китерде.

Комсомолның XVII съездында Байкал-Амур магистрален кору турында сөйләгәндә Л. И. Брежнев болай диде: «Без комсомолларның, яшьләрнең бу зур төзелешкә үзләреннән лаеклы өлеш кертәчәкләренә нык ышанабыз. Амур буендагы Комсомольск, Магнитка һәм Төрксиб, Днепрогэс һәм чирәм җирләр, Братск һәм КамАЗ эстафетасын алар Себернең яңа, әле үзләштерелмәгән киңлекләренә алып барырлар». Үз төзелешләренең илебез тарихындагы төп этаплар белән бер рәткә куелуына камазлылар чиксез горурланалар.

**«Комсомольская правда», Мәскәү.**

Комсомолларның һәм яшьләрнең күп меңләгән армиясе — Мәскәү, Ленинград, Татарстан, барлык тугандаш республикалар егетләре һәм кызларының шәһәр партия оешмасының, төзелеш һәм завод коммунистларының сугышчан ярдәмчеләре булулары белән горурланабыз.

КамАЗ комсомолларының һәм яшьләренең мактауга лаек героик хезмәте партиянең XXV съездына Ленин комсомолы рапортына якты сәхифә булып язылды.

**ВЛКСМ Үзәк Комитетының беренче секретаре**
**Е. Тяжельников хатыннан.**

Почетлы пьедесталда — «КамАЗ»да эшләнгән беренче машина. Баш конвейерның соңгы позициясендә аның двигателен эшләтә башладылар. Һәм машинаны бирегә, тантаналы митингка, трибуна янына алып килделәр. Барлык кешеләрнең карашы аңа текәлгән... Конвейерда җыелып яткан тагын җитмеш «КамАЗ» төрле стадияләрдә тынып калган.

Тантаналы, күптән көтеп алынган минутлар...

Әле тулысынча корылып бетмәгән булса да, автомобиль җыю заводының баш корпусы хәзер үк инде сокланып туймаслык. Баш корпусның озынлыгы 1150, ә киңлеге 400 метр чамасы.

Тантана башланыр алдыннан төзелеш һәм автозавод җитәкчеләре журналистлар өчен пресс-конференция үткәрделәр. Аны оештыру эшендә бай тәҗрибәсе булган, зур тормыш мәктәбен узган иптәшләр алып барды. Төзелеш начальнигының беренче урынбасары Е. Н. Батенчук сугыш елларында пулеметчы булган. Сугышта алган яраларның һәм фашистлар тоткынлыгының түзә алмаслык авырлыкларын кичергән. Ул — илебездәге иң өлкән төзүчеләрнең берсе. Кавказда һәм Иркутскида, Колымада һәм Якутиядә электр станцияләре корган, берничә ел Вилюйск ТЭСы төзелешен җитәкләгән.

Л. Б. Васильев исә Бөек Ватан сугышында шофер булып хезмәт иткән. Аннан Мәскәүдәге Ленин комсомолы исемендәге заводның цех эшчесеннән алып автомобиль промышленносте министры урынбасары һәм КамАЗның генеральный директоры дәрәҗәсенә күтәрелгән.

Беренче автомобильләрне чыгара башлау — үзенә күрә бер «бүленеш сызыгы» ул. Кичә КамАЗ әле үзе төзелеш иде, ә бүген инде ул, әле файдалануга тапшырылмаган булуга да карамастан, хәрәкәттәге предприятие санала. Менә шуңа күрә дә комплексның күпчелек корпусларында автозаводчылар, монтажчылар, төзүчеләр кулга-кул тотынышып бергә эшлиләр.

«Социалистик индустрия», Мәскәү.

Моннан берничә көн элек КамАЗ автомобиль заводының баш конвейерыннан төшкән йөк машиналары колоннасы Мәскәүгә килде. «КамАЗ» маркалы бу беренче машиналар — автозаводчыларның КПССның XXV съездына бүләге.

Өр-яңалар, февраль кояшының гадәти булмаган җылы нурлары астында ялтырап торалар. Шома өслекләренә аз гына юл тузаны кунган. Мәскәүгә вакытлы «теркәү» алган бу машиналарны башта без Үзәк автомобиль һәм автомотор фәнни-тикшеренү институты янында күрдек. Спидометрларда — 1300 километр. Башкалага килеп җиткәнче автомобильләр шушы кадәр юл үткәннәр.

— Бик яхшы килеп җиттек, — ди шофер-сынаучы Валерий Перетолчин.

Алда — билгеләнгән олы маршрутның соңгы участогы: ул башкаланың үзәк урамнары һәм проспектлары аша уза. Шул вакыт команда яңгырый:

— Машиналарга!

Без В. Перетолчин янына кабинага кереп утырабыз. Калган шоферлар: Н. Идрисов, М. Межов, В. Андрианов, В. Красиков һәм башкалар да юлга әзер.

— Чаллыга без күптән түгел генә илебезнең төрле почмакларыннан кайтып төштек, — ди Валерий. — Һәрберебез аңлатып бирә алмаслык горурлык хисе кичерә, чөнки бу машиналарны Мәскәүгә алып килү, совет кешеләренең партия наказларын ничек үтәүләрен күрсәтү бәхете безгә туры килде. Шунысын да ачыктан-ачык әйтим: съезд алды социалистик ярышында җиңеп чыккан төзүчеләр, автозаводчылар арасында беренче машиналарны йөртергә лаеклылар бик күп иде.

Алда патруль машинасының зәңгәр уты җемелди. Озатып бару группасы бу гадәттән тыш караванга «яшел урам» тәэмин итә.

Һәм менә Садовое кольцо. Башкала бәйрәмчә матур итеп бизәлгән. Һәркайда кызыл әләмнәр җилферди, биналарда — транспарантлар... Калинин проспектындагы кыска гына тукталыш вакытында машиналар янына мәскәүлеләр җыелды. Аларның: «Хәерле юл сезгә, «КамАЗ!» дигән сүзләре ишетелә.

Күп тә үтмәс, гигант автозаводның бу беренче карлыгачлары артыннан трассаларга илебезнең халык хуҗалыгы өчен бик кирәк булган меңнәрчә эур йөк күтәрешле автомобильләр чыгар.

... Машиналар Кремльнең Спасск башнясы янында тигез сафлар булып тезеләләр. Валерий Перетолчин машинадан төшкәндә акрын гына әйтеп куя:

— КамАЗ машиналарын каршы ал, съезд!

«Правда».

# КАМАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

## ИЮНЬ, 1975 ЕЛ

Үзәк документаль фильмнар студиясендә режиссер З. Фомина «Советлар Союзы буйлап» дигән киноальманахның чираттагы санын эшләп бетерде. Бу киножурнал чит ил тамашачылары өчен чыгарылды.

Киноальманах Чаллы күренешләрен сурәтләгән кадрлар белән башланып китә. Экранда — тугызынчы бишьеллыкның мөһим төзелеше КамАЗ. Андагы йөз мең төзүченең өчтән ике өлеше яшьләр. Киноальманах авторлары тамашачыны Рәис Ганиев белән таныштыралар. Егерме дүрт яшьлек Рәис монтажчылар бригадасын җитәкли. Егетләрнең барысы да бригадирның яшьтәшләре. Алар Украинадан, Белоруссиядән, Әзербәйҗаннан — СССРның төрле республикаларыннан килгәннәр.

**ТАСС, Мәскәү.**

КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советының Кама автомобиль комплексының беренче чиратын сафка кертү чаралары турындагы карары чыкканга бер ел тулды. Андагы җиде заводның барысы да 1976 елның өченче һәм дүртенче кварталында эшли башлаячак. Хәзер завод коллективлары төзелеш һәм монтаж подразделениеләрендә хезмәтнең яңа чикләрен билгелиләр, югары социалистик йөкләмәләр кабул итәләр. Болар барысы да КПССның XXV съезды ачылган көнгә «КамАЗ» автомобильләренең беренче партиясен чыгаруга юнәлдерелгән.

**«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».**

Сидоров кольцосыннан старт алып, яңа трамвай вагоны иртәнге шәһәр буйлап уза. Тирә-якта — трамвай йөртүче Анна Чернятьевага таныш күренешләр. Чаллының һәр урамында һәр көнне яңа үзгәрешләр барлыкка килә. Узган сайлаулар алдыннан төзелеш яңа җәелеп кенә килә иде, ә хәзер биредә хәлиткеч финиш көннәре якынлаша.

Менә шушы нарат урманы янында дүртенче больница төзелеп ята. Ул шәһәрдә иң зур больница булачак.

Трамвай Муса Җәлил проспекты буйлап ашыга. Менә «Энергетик» культура сарае, элемтә үзәге, ундүрт катлы «Татарстан» гостиницасы артта калды. Әле шушы көннәрдә генә үзәк шәһәр китапханәсе ачылды. Аңа легендар Муса Җәлил исеме бирелде. Анда лекция залы, уку залы, йөз мең том сыешлы китап саклау урыны бар. Якында гына — шәһәр музее. Трамвайның чираттагы тукталышы — «КамАЗ дирекциясе». Әле бик иртә булуга карамастан, дирекция бинасы тирәсе машиналар белән тулы. Төрле төстәге автобусларга утырып, төзүчеләр эш урыннарына ашыга.

КамАЗ дирекциясе — гаять зур производство коллективының штабы. Аның составына ун меңнәрчә эшчеләр һәм белгечләр, комплексның инде сафка баскан объектлары: ремонт-инструменталь заводы, ТЭЦ, төзелеш һәм монтаж идарәсе һ. б. лар керә. КамАЗ хезмәткәрләрен зур төзелешнең барлык участокларында очратырга мөмкин. Инде эшли башлаган цехларда алар инструментлар, заводлар өчен технологик җиһазлар әзерлиләр.

Трамвай юллары буйлап гигант заводларның көмеш сыман тестәге корпуслары тезелеп киткән. Двигательләр заводының, кою, тимерчелек, пресс-рам, җыю, ремонт-инструменталь заводларының һәрберсе гаять зур берничә корпустан тора. Аларның барысында да җир асты һәм җир өсте коммуникацияләре урнаштырырга, идәннәрен тигез итеп җәяргә кирәк. Ноябрь аена кадәр, җиһазлар урнаштыру соңламасын өчен, идәннәр җәюне тәгәлләү бурычы тора. Беренче чираттагы унбер мең җиһаз урнаштырылырга тиеш. Алар арасында токарь станоклары да, биш катлы йорт биеклегендәге гигант пресс та бар. Төзүчеләр, монтажчылар моңа кадәр мондый зур масштаблы эшне башкармаганнар иде әле.

Трамвай үз маршрутының соңгы тукталышына җитте. Каршыда Яңа каланың ак таштан салынган күп катлы йортлары. Йортлар карнизына зур хәрефләр белән: «Кама автомобильләрен үз вакытына өлгертик!» — дип язылган. Ә моның вакыты — партиябезнең XXV съезды ачылган көн.

«Труд», Мәскәү.

Халык хуҗалыгында мөһим бурычларның берсе — Коми АССРның төньягында һәм Ненец милли округындагы нефть чыганагы районнарын үзләштерү.

Бу районнарда нефть һәм газ чыганакларын ачу — СССРның Европа өлешендә, Төньяк-Көнчыгыш якта, нефть эшкәртү һәм газ куллану районнарына якын җирдә, илебезнең яңа зур нефть һәм газ чыгару базасын булдырырга мөмкинлек тудыра.

Һәм менә инде Ухта һәм Печора елгалары тирәсендәге нефть чыганаклары-на электр үткәргечләре сузылды. Печорада зур ГРЭС төзелә. Ул газ яндырып эшләячәк... БАМ, Төмән нефте, КамАЗ, Саян-Шушенск комплексы... Бөтен илебезнең һәр почмагында грандиоз эшләр алып барыла.

«Неделя», «Известия» газетасының атналык чыгарылышы. Мәскәү.

Чаллы шәһәрендә Казан шәһәренең профсоюз клубларының үзешчән сәнгать коллективы булып китте. «Гренада», «Юность» җәйге кинотеатрларындагы концертларда хор, бию ансамбле, үзешчән цирк осталары һәм җырчылар катнашты.

«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».

«Спецстрой»ның Чаллы идарәсендә Радик Җәләев җитәкләгән труба салучы слесарьлар бригадасы «Камгэсэнергострой» берләшмәсендә ел саен социалистик ярышта җиңүче булып килә. Җәләев — бригадада менә дигән эш шартлары тудырырга сәләтле егет. Хәзер аны трестның бригадирлар советы председателе итеп сайладылар, ул — КамАЗ төзелеше ударнигы, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры, Чаллы шәһәр Советы депутаты.

«Комсомолец Татарии», Казан.

Чаллыга Свердловск студиясенең кинога төшерү группасы килде. «Дәүләт сынаулары» дигән нәфис фильм кадрларын натурадан төшерүләр башланды. Бу фильмда гигант төзелештә эшләүче яшьләр хезмәте, автомобильләрнең яңа модельләрен сынау барышы сурәтләнәчәк. Сценарийны Юниор Шилов язган, режиссер — «Санников җире» дигән фильмга катнашучы Леонид Попов. Фильмны оператор Вадим Михайлов төшерә, музыка авторы — Илья Катаев. Баш рольләрдә — Мәскәү театр училищеларында һәм вузларында укучы студентлар.

**«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».**

Бүгенге Чаллы — ак таштан салынган күп катлы торак йортлар, төгәл тәртип белән урнашкан башня краннары күренеше ул.

Чаллыда инде 203 мең кеше яши. Соңгы ике ел эчендә КамАЗ эшчеләре өчен 930 мең квадрат метр яңа торак мәйдан өлгертелде.

«Главмосстрой» — Чаллыда алдынгы төзелеш оешмаларының берсе. «Главмосстройның» Михаил Тищенко җитәкчелегендәге коммунистик хезмәт бригадасы үзенең удар темплары һәм эшенең яхшы сыйфаты белән аерылып тора. Беренче кварталда аның бригадасы объектлар төзү срокларын 57 көнгә кыскартты. Биш айның эш нормасы 196,2 процентка үтәлде. Бу — КамАЗ темпы, КамАЗдагы эшләрне бәяләүдә гадәти күрсәткеч.

**«Комсомолец Татарии», Казан.**

Узган елның август аенда «Огонек» журналы редколлегиясе, «Камгэсэнергострой» парткомы, профсоюз оешмасы һәм администрациясе белән берлектә, Злобин методы белән эшләүче бригадаларга конкурс игълан иткән иде. Күптән түгел «Энергетик» культура сараенда бишъеллыкның соңгы елындагы ярты еллык эшләргә йомгак ясалды. Беренче урынны Рәис Сәлахов бригадасы яулады. Икенче урында — «Гидрострой»ның СМУ-31 идарәсеннән Валентин Тихонов җитәкчелегендәге бетончылар, балта осталары бригадасы. «Огонек» журналының баш редакторы А. В. Софронов җиңүчеләргә журналның күчмә призын тапшырды.

**«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода»**

## Җәүдәт Кәлимуллин

# ЯШЬЛЕККӘ ТАРТЫЛА КҮҢЕЛ

Федор Васильевич авылдашлары арасында «тыйнак Федор» буларак билгеле иде. Бу сыйфат аңа иң авыр минутларда да хас булды. Фронтка киткәндә дә, мәсәлән, ул кайберәүләр шикелле, өйдән-өйгә йөреп саубуллашмады, көндәлек эшенә барган шикелле, тотты да юлга чыкты.

Һәм шулай ук тып-тын гына, кө̄тмәгәндә кайтып та килде.

1941 елның зыкы декабре иде.

Таң әле ярылып кына килә. Ул ишек шакыды. Керде. Озак кына буылып-буылып йөткерде. Чи салам янмый яткач, мичтән өйгә балта асып куярлык төтен чыккан иде. Агач сәке өстендә аның күзенә ике түмгәк чалынды. Алар кыймылдыйлар да. Мария Васильевна мичкә юеш салам якканда гел шулай итә: Володя белән Валентинның башларына ис капмасын дип, юрган астына яткыра иде.

— Бөтенләйгәме, Феденька?! Бетерепме, бәгърем?!

Бит буйлап көмеш бөртекләр тәгәрәде. Болары татлы яшьләр иде. Салам төтененнән чыккан әче яшьләр түгел...

Федор Васильевич ике көнгә генә кайткан булып чыкты. Бу төбәктән егерме-утыз чакрымнар читтәрәк яңа хәрби часть оештырыла икән. Мәрхәмәтле командир шушы якын-тирәдән булган кешеләргә, семьясын-балаларын күреп килсеннәр дип, ике көнлек ял биргән. Бу зур бәхетнең канаты Федор Васильевич Турановка да бер очы белән кагылган. Менә ул, пехота солдаты, шул шатлык-куанычтан исереп, үзенең салкын, төтен баскан караңгы куышында басып тора. Бу — җәһәннәмнән чыгып, җәннәткә керү шикелле түгелме?! Фронтка киткәндә, күпме генә әйләнеп караса да, аркасындагы зур биштәре аңа туган авылын, туган тугаен кат-кат төбәп карарга комачаулаган иде шикелле бит. Аның өчен бу төбәккә юл мәңгегә ябылган кебек тоелды ул чакта.

Ике көндә ике айлык эш эшләнде. Ишек тупсалары «сайрау»дан туктады. Лапас кыегына да ниндидер мал ризыгы мендерелде. Ягарга бер олау тал-чыбык кисеп кайттылар. Володя, бишенче яшьтә

генә булса да, әтисенең олы улы буларак, хәйран гына кайнашты. Тепза елгасына суга дип агач мичкә белән баргач, ул, зурларча, «ах», «ах»» дип, бәке ачышты, чана тартышты.

Яр буенда зифа чыршы үсеп утыра иде. Шунда җиткәч, Володя әтисен чабуыннан тартып туктатты:

— Әти, ат-ат уйныйк әле бераз.

— Ничегрәк уйныйк соң аны, улым?

— Син абаланасың да, мин синең аркаңа утырам.

— Шуннан?

— Син йөреп кит!

Әти кеше, карт аю шикелле, «дүрт» аяклап көрт ерып бара, ә аркадагы «җайдак» кылыч белән дошманнарны тураклый.

— Әти, синең аркаң, ай-һай, киң, минеке дә шулай булырмы икән?

— Булыр, улым, булыр.

...Район үзәгенә юл әлеге шул чыршы яныннан уза. Салкын иде. Мария Васильевна ирен озатырга чыкты. Володя өйдә калырга һич тә риза булмады. Әтисе кулына утырып, аның тыны белән җылынып, озак барды. Бөдрә чыршы янына җиткәч, сабыйларча беркатлылык белән:

— Әти, сугышта син шундый чыршы артына кач, юкса, үтерерләр үзеңне! — диде.

— Шулай итәрмен, улым. Кайткач синең белән без тагын ат-ат уйнарбыз.

— Көтәм сине, әтием!

Ләкин Пешкалово авылы кешеләре авырлыклар килгәндә читкәчатка поса торганнардан түгел иде. Фашист пулялары Федор Васильевич Турановны да чыршы артына качыра алмады. 1942 елда 10 нчы биеклек өчен булган тиңсез көрәштә аның гомере өзелде...

Кострома өлкәсенең Пешкалово авылы. Унсигез йортлы кечкенә төбәк. Зәңгәр сулы елга, әрәмәлекләр. Авылның кайсы ягыннан гына килеп керсәң дә, кайсы гына йортка шакысаң да, сине якты йөз белән каршы алалар. Биредә ишекләр, гадәттәгечә, бервакытта да бикләнми, кешеләр кеше әйберенә кул салу, туры ятмаганны әләктереп китү дигән нәрсәне белмиләр. Табигать тә, кешеләрнең берберләренә булган мөнәсәбәте дә, көнкүреш шартлары да халыкта рәхимлелек, ягымлылык, намуслылык сыйфатларын тәрбияләгән.

Федор Васильевич Туранов шушы җирлектә үскән иде. Сугыш бу изге сыйфатларны һәркемдә тагын да көчлерәк ялкын итеп дөрләтте. Яу кырында башларын салган ирләрнең балаларын тәрбияләү авылның сакалсыз «аксакаллары» — хатыннар кулына күчте.

Шундыйларның берсе — Иван дәдәй. Аңа авылда кечесе-олысы шулай дип эндәшә. Ә бит аның фамилиясе, әтисенең исеме дә бар. Шуларның бөтенесен кушып әйтсәң,— Иван Иванович Гусев булып чыга ул.

Мария Васильевна, таң әле беленер-беленмәс вакытта фермага китешли, Иван дәдәйләр тәрәзәсен шакый.

— Зинһар, күз-колак була күрче инде балаларга, мин, баш-күз алгач, үзем дә кайтып әйләнермен.

— Син, Мәтрүнә, ник борчыласың, ул Гришка Распутиннарыңа берни дә булмас. Бар, бар, малларыңны кара...

— Рәхмәт, Иван дәдәй, мин хәзер...

Мария Васильевна атлап түгел, йөгереп чаба. Ризык көткән сыерларның мөгрәве аның бәгырен кисә. Үз малайлары — Володя белән Валентинны Гриша Распутин дип атавына Мария Васильевнаның исе дә китми. Теләсә кем теләсә ни дисен — тик күз-колак була да белсен.

Распутин дигәнне тәгаенләбрәк карасаң, эш болайрак тора. Иван дәдәй, армиядә хезмәт иткәндә дә, үзе әйтмешли, «Рәсәйне соңгы тамчы канына чаклы сакларга гына түгел, аның тарихын «аркылыга-буйга» өйрәнергә дә азмы-күпме вакыт тапкан. Дәрвиш-күзбуар Гриша Распутинның акылга шактый чамалы булган Рәсәй патшасы тәхетенә кадәр үрмәләргә маташуы дәдәйнең җан ачуын чыгара. Шуннан башлап Гриша Распутин сүзен ул, шаяртып, «шайтан» мәгънәсендә куллана икән.

Иван дәдәй — авылда бер дигән балта остасы. Көне буе тук-тук, көне буе нәрсәдер ясый, нәрсәдер эшли. Шул «тук-тук»лар янына бөтен авыл малайлары диярлек җыела.

— Килдегезме, Распутиннар!

Беренче сүзе шул була аның. Аннан кулына үзенең эш кораллары берәм-берәм ала. Ялтырап торган балта йөзе белән сакалына кагылып, балтаның үткенлеген чамалый. Шуның тылсым көченә ия булуы турында сөйли. Сүзе үтемлерәк булсын өчен, ботаклары тырпаеп торган бер агач кисәге алып керә. Аның янына нәкъ чын кошны хәтерләткән агач уенчык китереп куя. Кош та кош, бу уенчык та кош.

— Эш яратсагыз, кошы булыр аның. Машинасын аннан да тизрәк бирерләр: хезмәтне сөегез, сыбызгылар, хезмәтне!..

Инде төш якынлашып килә. Володя, бабайлар шикелле, кулын кашы өстенә куеп күккә карый. Анда, әкиятләрдә тасвирланганча, ике келәм йөзеп бара, имеш.

— Ни кайгыга баттың? — ди Иван дәдәй, малайның хәленә керергә тырышып.

— Менә аргы як басуында печән җыеп кибәргә калдырган идек, яңгыр явар, ахры.

— Ялт беләбез аны — яварсы-юкмы?..

— Ничек, Иван дәдәй, ә?..

Малайлар, авызларын ачып, карашларын Иван дәдәйгә төби.

— Әйдәгез, өйгә керик, чөйгә багып карыйк...

Шигырьләп әйтелгән бу сүзләрнең мәгънәсен малайлар, билгеле, аңламады. Алар гына түгел, олылар да төшенмәсләр иде: чөйгә багып кемнең һава торышын әйтеп бирә алганы бар?

— Күрәсезме, чиборыннар, — диде Иван дәдәй, малайларны түр башындагы стенада эленеп торган чөй сыман агач ботагы янына алып килеп.

— Күрәбез, күрәбез.

— Ә ни күрәсез соң?

— Ботак.

— Ничек тора ул?

— Безгә карап тора, — диде Володя, күзләрен челт-челт иттергәләп.

— Кояшка! — диде Иван дәдәй, кеткелдәп көлеп.— Кояшка карап тора. — Димәк, кояш аны үзенә тарта. Димәк, яңгыр булмаячак. Ботак борын салындырса, яңгыр сибәләр иде.

— Нинди агач ботагы бу, — диде чәче арыш саламы төсендәге малай, булачак галим кыяфәтендә кыланып.

— Анысы әлегә сер булып калсын. «Лаеш» шулпасы белән бер пот тоз ашагач белми калмассыз, — дип, Иван дәдәй малайларны капка төбендә озатып калды.

...Володя, әтисе шикелле, тыныч-тын, барысын да үлчәп-исәпләп эшли торган малай булып үсте. Төскә-буйга да әтисенә охшаган иде ул. Күршеләр һәм бөтен авыл халкы шулай ди иде. Мария Васильевнаның йөрәген ике хис телгәләде: Володя һаман әтисен — Мариянең ире төсен хәтерләтеп үсә. Ул — йөрәккә бер төрле дәва сыман. Икенче яктан исә бу төс — мәңге төзәлми торган ярага сибелгән тоз шикелле. Бәгырьне нәкъ шунысы ныграк кисә дә.

Атлар да фронтка китеп беткәннәр иде. Тәртәгә үгезләр җигелде. Каникул көннәрендә мәктәп укучылары да шуларны җигеп эшләргә тиеш иде. Мария Васильевна да беркөнне Володяны фермага алып барды.

— Син зур инде, улым, үзеңә дөнья көтәргә вакыт җитте.

Үгезгә камыт кидерергә көче дә, буе да җитми иде Володяның. Ә үгезнең күзен бер акайтып каравыннан котларың ничек очмасын?..

Мария Васильевна үгезне үзе җигеп, улын арбага утырта һәм кулына дилбегә тоттыра да, Иван дәдәй әйтмешли, «енструктаж» бирә: «Бу мал, улым, кигәвеннән бик курка, шуны исеңдә тот. Кигәвен сырып алды исә, дилбегәңне ташла да арбадан җиргә сикер. Үгез берәр чокырга барып егылмыйча барыбер туктамаячак. Аннан аны кояш сүрелгәч кенә алып чыгарга мөмкин сиңа... Тагын шунысын да онытма, улым: колхоз милкенә, кеше әйберенә кулыңны якма. Берәүне дә алдама. Үзең эшләп тапкан мал гына мал ул».

— Володя, синең трай тибеп йөрер чагың узды, эшли башларга вакыт җитте. Берәр һөнәр алырга уйламыйсыңмы?..

— Әллә сез әни белән үзара сөйләштегез дәме инде? Эшлә дә эшлә... Мин бит әле эшләмим дип әйтмәдем...

Бу сөйләшү инде Володя җиденче классны тәмамлагач, әнисе белән бертуган апасы янына Кострома шәһәренә баргач булды. Апасы «Хезмәт байрагы» исемендәге фабрикада алдынгы тукучы булып санала, активистлар рәтендә йөри. Өендә зур китапханәсе бар, газета-журналларны күп алдыра иде.

— Үзең шикелле тукучы итәргә уйлыйсыңмы әллә мине? — диде Володя вәкарь белән.

— Әйе, — диде апасы.

— Һәй, кызлар эшенә...

— Кызлар тотып ашар дисеңме әллә...

— Ашамасалар да...

— Тукучы һөнәре — күптәннән килгән мактаулы һөнәр, Володя, укы, өйрән, үкенмәссең. Билгеле, тукуны хәзер машина тукый, әмма ул машиналарны көйләп-карап торучы осталар кирәк. Мин сине шул эшкә кыстыйм, — диде апасы, сүзне йомгаклап.

...Һәм менә ул — Кострома җитен комбинаты каршында оештырылган туку осталары ярдәмчесен әзерләү мәктәбенең чыгарылыш курс укучысы — Казанга атаклы җитен комбинатына практика узарга килде. Унҗиде яшьлек мастер ярдәмчесен комбинатта эшләп «лаеш» шулпасын аз эчмәгән апалар, кызлар төрлечә каршылады: өлкәннәр — баласындылар, ә яшьләр — яшьсенделәр. Ә комбинат администрациясе исә, яшьлеккә аз гына да ташлама ясамыйча, менә

сезгә, иптәш Туранов, 30 станок, эшләтегез шуларны, ярдәм кирәк булса — тарсынмагыз, диде.

Һәм менә мастер ярдәмчесе Владимир Федорович Турановка да (аңа хәзер рәсми рәвештә шулай дип эндәшәләр) чыннан да ярдәм дигәнең кирәк булды бит. Нинди ярдәм? Юк, техник булышлыкка мохтаҗ түгел иде ул. Станокларның төзелешен җиде төн уртасында уятып сорасалар да шартлатып аңлатып бирә алачак. Теорияне әйткән дә юк, су урынына эчә диярсең. Менә әлеге рәсмилек, шуңа бәйле мәкерлек — мастер ярдәмчесен җиз иләк аша үткәрергә теләүләре үзәккә үтә.

— Владимир Федорович! Минем станок эшләми, ярдәм итсәгезче!

— Владимир Федорович! Минем тукыма тигез чыкмый, нишлим икән?..

— Владимир Федорович! Нигә чимал юк?

Болары — кызлар.

— Володя, әй, Владимир Федорович! Миңа бу айда эш хакы нигә аз язылган?

— Володь...

Бу сүзләрне производствода байтак еллар эшләүче апалар яудыра. «Килеп каптым!» дип уфтана Володя. Ни пычагыма дип Костромага бардым да укымышлы апаның акыллы сүзләрен тыңладым. Үгез җигеп тә үгез арбасына гына утырып калмаган булыр идем әле. Тукучы — борынгы һөнәр, имеш! Әллә Костромага кире кайтып китәргәме?!.

Беркөнне төшке аштан Володяны тәҗрибәле тукучы Клавдия Михайловна Красильникова бер читкәрәк чакырып алды. Ул, ни өчендер, Володяга әнисе кебек күренде. Сабыр холыклы, төптән уйлап сөйли торган апа иде.

— Син күңелеңне төшермә, Володя. Бу шаяру-үртәүләр бетәр. Яшь кешене шулай сыныйлар инде аны. Мине башкасы борчый. Бригада сыйфатны санга сукмый башлады бит, иң куркынычы менә шул. Кичә генә күпме брак киткән?!

— Нишлим соң, Клавдия Михайловна!

— Барысын да үз җилкәңә алма. Кешеләргә таян, ярдәмгә мин дә әзер.

— Сез минем өчен эшләргә тиеш түгелдер бит инде, Клавдия Михайловна.

— Без барыбыз да бер-беребезгә ярдәм итәргә бурычлы, коллективта эшләр күмәк хәл ителергә тиеш, ә син йөкне үзең генә тартырга азапланасың, Володя.

Алайса, тартышыгыз...

Икенче көнне бригадада җыелыш булды. Эшчеләрнең күбесе ни өчен җыелганны белмиләр иде.

— Тагын мораль тукыйсызмы, тукыма урынына, — диде зәңгәр күзле, сары чәчле бер кыз.

— Әй, сөйләсеннәр лә, сүз сатып алынмаган ич, — диде кара чәчлесе.

— Сүз Клавдия Михайловнага бирелә, — диде Володя дулкынланып.

Клавдия Михайловна урыныннан да тормыйча, үзалдына сөйләгән, үз-үзе белән киңәшкән төсле, акрын гына сөйләп китте:

— Менә, — диде ул, — кулына «брак» дип тамга сугылган тукыма кисәген алып, — шуңардан үзенә күлмәк тегеп кем кияр икән? Кем? — Кызлар бер-берсенә карашып алдылар. — Менә шул шул, — дип дәвам итте ветеран, — берәүгә дә ошамый, берәүгә дә кирәк түгел. Ә кемгә дип шулай тукыйбыз?

— Капчык тегәргә ярамаган тагын, — диде кемдер.

— Капчыкка әгәр алтын бәясенә торган бөртек салынса, капчык ил оборонасына хезмәт итсә...

Бәхәсләшүчеләр телләрен тешләделәр. Аларга ничектер оят булып китте. Чыннан да бит, кибеткә керсәк, тукыманы зурайткыч пыяла белән тикшергәндәй сайлап алабыз, аз гына начарын да гафу итмибез. Син брак җибәрсәң, мин җибәрсәм — яхшы товар кайдан килер соң?

— Рәхмәт сезгә, Клавдия Михайловна, — диде соңыннан Володя. — Миңа ничек җиңел генә аңлатып-төшендереп бирдегез, мин инде бөтенләй кул селтәргә әзер идем.

Коллектив мастер ярдәмчесен әнә шулай сынады. Кем белә, бу бәлки сынау да булмагандыр. Ул, мөгаен, чыныгуның үзедер. Бригада өчен дә, яшь җитәкче өчен дә. Ничек кенә булмасын, Володяга армиягә китәргә вакыт җиткәч, кызларнең күңеле йомшарды.

— Әй, нигә ямансуладыгыз әле, — диде Володя кызларга. —Мин китсәм, яңа ярдәмче килер, изге урын буш тормый ул.

— Без сезгә күнеккән идек инде, — диделәр кызлар беравыздан.

— Бик көтсәгез — яңадан әйләнеп кайтырмын, алайса.

— Көтәбез, көтәбез!.. — Кызлар яулык болгап калдылар.

Володяны армия чыныктырган, җыйнаклandырган иде. Иңнәрендәге өлкән сержант погоннарын салган булса да, солдатта булганлыгы аның әллә кайдан күренеп тора. Иң мөһиме — хәзер тәҗрибә бар. Сержант бит ул солдат өчен әти дә, әни дә, начальник та. Бригада да шулай түгелмени? Производствода хәрби тәртип булмаса да, кешеләр белән эшләү алымнарында уртаклык зур: шул ук индивидуаль эш, һәркемнең күңеленә ачкыч таба белү. Ни генә булмасын — бер ел эчендә яшь мастер ярдәмчесе Владимир Туранов җитәкчелегендәге тукучылар бригадасы, финишка җиткәндә көчле ыргым ясаган йөгерүче шикелле, халыкны ах иттерде: коммунистик хезмәт бригадасы дигән мактаулы исемне, комбинатта беренчеләрдән булып, алды да куйды. Ветераннар үз сүзләрен партия җыелышында әйттеләр: Володяны партия сафларына кабул иткәндә, аның эшенә чын бәя бирелде.

— Безнең борынга чиерттең, егет, һәм сиңа шуның өчен рәхмәт! — диде өлкәннәр, Володяның кулын кысып. — Яшьлек шулай булырга тиеш тә ул. Юлың гел алга барсын, артка әйләнеп карама!..

Әмма карарга туры килде. Кирәк иде.

...Ул залга килеп керде дә буш урынга барып утырды. Яз иде. Кояш нурлары бөтен бүлмәне тутырган. Алар күзгә, йөзгә кадала сыман һәм йөрәкне җылыталар. Володяның исенә кылт итеп Иван дәдәй килеп төште. Уйламаганда-көтмәгәндә. Бәлки аңа шушы кояш нурлары сәбәпче булгандыр. Кояш, Иван дәдәй стенасындагы агач ботагы, яңгыр... Менә каян килә ул хатирә. Иван дәдәй ул чагында стенадагы агач ботагына карап һава торышын билгели алу серен ачмаган иде. Хәзер ачар идеме икән?..

Партия оешмасы секретаре да нинди дер сер турында сөйли иде. Тик бу башка, производствоны яхшырту сере турындагы сүзләр:

— Иптәшләр, артта баручы бригадаларны алдынгылар рәтенә чыгару турында безнең илдә баш ватучылар аз булмады. Министрдан алып курьерга кадәр. Һәм бу серне безгә көтмәгәндә-уйламаганда гади бер тукучы чишеп бирде. Сез аны яхшы беләсез, аны бөтен ил белә. Валентина Гаганова ул. Барлык уңайлыктан, даннан ваз кичеп, артта калган бригаданы җитәкләүгә күчкән бу тукучы үрнәге безнең йөрәкләрне тирән дулкынландырды.

Аннан соң секретарь комбинаттагы хәлләргә анализ ясады һәм сүзенең ахырында болай диде: «Безнең база училищесында укучылардан оештырылган бригадага Валентина Гаганова шикелле олы йөрәкле, оста куллы кешенең күчеп килүе сорала. Коммунистлар бүген шул мәсьәләне хәл итәргә тиешләр дип уйлыйм».

Ораторлар, берәм-берәм сүз алып, Валентина Гаганова башлангычын хупладылар. Ләкин берәү дә «мин ул бригадага күчәргә риза» дип әйтмәде. Чөнки гади эш түгел иде бу. Барысы да яхшы аңлыйлар: кадровый эшчеләрдән торган бригадага күчеп анда эшләрне җайлап җибәрү бер хәл әле ул. Ә инде үз җилкәңә производствоны әле рәтләп белмәгән 15 өйрәнчек кызны алып, шулар белән тиешле планны үтәү. Шулар эшенә карап хөрмәткә ия булу, эш хакы алу — болар бөтенләй башка нәрсә.

Бу шик-шөбһәләрне шушында, партия җыелышында ук ачыкларга, исәпсез күп сорауларга да әлеге җыелышта җавап табарга кирәк иде.

— Ышаныч күрсәтсәгез, мин — риза! — диде коммунист Туранов. — Кемдер бу эшкә алынырга тиеш бит инде.

Зал аңа шаулатып кул чапты.

Нинди җаваплы, четерекле, мәшәкатьле эшкә алынганлыгын аңлау өчен аңа күп вакыт кирәк булмады. Беренче көнне үк конфликт чыкты.

Алдагы көнне бригадада шимбә өмәсенә чыгабыз дип килешкәннәр иде. Володя абыйлары солдат итеге, гимнастеркасы киеп, билен ялтырап торган йолдызлы каеш белән бәйләп, канатланып өмәгә килде. Әмма, күпме генә көтмәсеннәр, бер-ике кыздан артык кеше күренмәде.

— Көтмәгез, абый, — диде бите сипкелле Вера. — Килмәячәкләр алар.

— Нишләп алай дисең?

— Соң, бушка эшләп йөрергә минем кебек юләрләр күп табылыр дисезмени?

— Шимбә өмәсе — бәйрәм, хезмәт бәйрәме бит ул, Вера. Аннан соң — үзебез өчен эшлибез. Менә бу ишегалдын ялт иттереп себереп куйсак, аяклар йөгереп үтәчәк бит чиста җирдән.

— Абый, мине дә кайтарып җибәрегез инде, әй! Барыбер берәү дә килмәячәк!..

Вера якын-тирә авыллардан килеп училищеда укучы кызларның барысы да диярлек авылларына кайтып китүләрен белә иде. Ләкин бу турыда Володя абыйсына әйтмәде. Телгә беткән, яшь булса да хәйләкәр, усал кыз иде ул.

Яңа сынауларның башы гына иде әле бу.

Көннәрдән бер көнне кызларның бөтенесе эшкә килмәде. Бусы инде шимбә өмәсенә чыкмау гына түгел иде.

— Кайсының эше булыр икән бу? — дип баш ватты Володя.— Кемнеңдер кулы уйнаган булырга тиеш монда. Зина Мазанованыкымы? Сабыр, һәрнәрсәгә объектив карый торган бу кыз андый ямалыкка бармас. Вера Гуськовамы әллә? Бәлки, бәлки? Шулай да ди. Тик аны ничек исбатлыйсың? «Яшүсмернең үз-үзенә бәясе кылдан нечкә, кылычтан үткен — берүк сак кагылыгыз аңа!..»

Кайсыдыр шәрык мәгърифәтчесе әйткән бу сүзләр бу минутларда янә искә төште. Әлбәттә, эшкә чыкмый калуның берәр сәбәбе булгандыр. Кызлар яңа җитәкчедән канәгать түгелләрме, хезмәт хакы аз диләрме әллә? Володя бу сорауларга алай да, тегеләй дә җавап эзләп карады. Ләкин тиз генә таба алмады...

Көннәр бер-бер артлы үтә торды. Бригада, канаты ныгып килә торган кош шикелле, һаман көчлерәк талпына башлады. Кайтаваз шикелле, бригаданың эшкә чыкмый калу вакыйгасы да кәтмәгән, уйламаган ягы белән ачылды. Бу инде теләсә нинди бүләккә караганда да кадерлерәк, мөһимрәк иде. Шатлык иде. Инструктор Халисә Нәбиуллинага Зина Мазанова, үзенең эч серен ачып, болай дигән: «Без, кызлар, Владимир Федорович алдында үзебезне гаепле саныйбыз. Теге вакытта прогул ясап без бик начар эшләдек. Сәбәбен дә аңлатмадык. Сәбәбе —җавапсызлык иде, безнең балалык иде. Мин Владимир Федоровичны әтием кебек хөрмәт итәм. Андый кешеләр алдында ялганлашырга, начар эшләргә оят безгә. Моннан соң бернинди тәртипсезлек тә эшләмәбез, зинһар, шуны Владимир Федоровичка җиткерегезче».

Шушы көннән башлаптыр бәлки, Владимир Федоровичны үз итеп тә, рәсми төстә дә «остаз» дип йөртә башладылар. «Остаз», — дип елмаеп куя иде ул үз-үзенә. — Кешеләргә акыл өйрәтеп йөр, имеш, ә үзеңнең әле семьяң да, бала-чагаң да юк. Мораль хокукың бармы соң? Эх, яшьлек юләрлеге. Менә бүген дә, сөйгән кызың белән кинога барасы урынга, бөтенләй таныш булмаган кешеләр ишеген шакып кер, тагын шул бала тәрбияләү турында акыл сат, үзеңнең балаң булмаса да...»

Ул бүген кич Валерий Тимофеевның әти-әнисе янына барырга тиеш иде. Өстенә ап-ак күлмәген, яңа костюм-чалбарын киде, армиядә чагында ук сатып алган чәчәкле галстугын такты. Кулына көзге алды. Көзгедән олыгая башлаган егет карап тора, чигәләрдән андасанда көмеш энәләр очы ялтырый, кара күзләр тирәсендә беленербеленмәс кенә берничә сызык күренә.

Валерийлар өенә аның беренче тапкыр килүе генә түгел инде. Валерийның язмышы хәтта судка барып җиткән иде.

Комбинатка аны әнисе җитәкләп килде. Ул үзе дә шушында эшли иде. Урта буйлы, битләре кабартма кебек күпереп торган яшүсмернең куллары эшкә ятышлы булып чыкты. Тукыма җебен машинага күз ачып йомганчы тоташтырып өлгерә, эш урынында үзен иркен тота, тәҗрибәле эшчеләр кебек эшли иде. «Менә дигән кадровый эшче чыгачак моңардан!» дип сөенгән иде остаз Володя.

Мондый нәтиҗәгә килергә иртәрәк булган икән әле. Аңа кадәр шым гына йөргән, аз сүзле яшүсмер турында бөтен комбинат сөйли башлады. Бигрәк тә әнисе өзгәләнде. Иптәшләре алдында оят иде аңарга. Ләкин факт күз алдында, әллә кайдан күренеп-кычкырып тора иде. Эштән кайтканда Валерий үзе кебек бер яшүсмернең свитерын салдырып алган һәм иртән шуны киеп эшкә килгән. Кеше талаучыны станок яныннан алып киттеләр.

Суд, билгеле, энәсеннән алып җебенә кадәр тикшерәчәк, акны — ак, караны — кара дип әйтәчәк. Бусы берәүне дә шикләндерми. Яшь остаз өчен боларга караганда күп тапкыр катлаулырак, четереклерәк мәсьәләне ачыклау мөһим иде. Хата кайда, кайчан җибәрелгән? Владимир Федорович, кино тасмасын яңадан әйләндереп караган шикелле, үзенең иртәдән алып кичкә хәтле булган эш көннәрен күз алдыннан үткәрде. Көн, гадәттә, цехны карап-әйләнеп чыгудан башлана. Барысы да тәртиптәме, материаллар бармы, кызларның кәефе нинди? Авыручылар юкмы? Бу, бер караганда, врачның авырулар палатасына иртәнге обход ясавын хәтерләтә. Һәм хәтерләтеп кенә дә калмый.

Энә зәңгәр косынка бәйләгән кызның йөзе янып тора. Хәерлегә түгел бу — сизә остаз күңеле.

— Сеңелем, авырыйсыңмы әллә?

— Юк, Владимир Федорович.

— Санчастька барып кил әле, синең температураң бар бугай.

— Эшли алам мин, Владимир Федорович.

— Аласың, билгеле, акыллым. Шулай да врачка күренеп алу комачауламас.

Һәм ул көнне зәңгәр косынкалы кыз кичкә кадәр цехта күренми...

Ә кыз шат күңелле, эшне җиренә җиткереп, булсын дип эшли, үзе мәзәк ярата. Иртән тулай торакта еш кына йоклап кала... Оялтып та карадылар — булмады: «Сәгать звоногы эшләми, шуңа тора алмыйм», — дип аклана. Башка бүлмәгә дә күчәсе килми — мин бер үзем, бер бүлмәдә рәхәтләнеп йокларга яратам, ди. Уйлашкач-киңәшкәч, техниканы «эшкә җигәргә» булдылар: бригададан кем дә булса тулай торакка шалтыратып вахтердан кызны уятуын үтенә. Шулай итеп мәсьәлә, яхшымы-начармы, уңай хәл ителә.

«Бәлки Валерий белән дә шулай мәшәкатьләнергә кирәк булгандыр миңа», — дип, үз-үзенә нәтиҗә ясады остаз, — эшен яхшы белгәч, калганы белән бик нык кызыксынмадым да бугай шул».

Күңелне каршылыклы уйлар борчый. Ни генә булмасын, егетне беткәнгә санарга ярамый. Күңеле эшәкелектә булырга тиеш түгел аның. Әнә бит өендә түбәсен ябарга дип материал әзерләп куйган, яшелчә үстерергә төрле-төрле орлыклар сатып алган. Күңеле бозыклыкта булган кеше моны эшләмәс иде. Әмма кеше өстеннән салдырып алынган кием белән бернинди вөҗдан газабы сизмичә ничек итеп эшкә килмәк кирәк инде? Өлкән кеше булса, ике дә уйламас идең — талагансың икән, җавабын да тота бел! Тик бу юлы хөкем каршына яшүсмер басачак бит. Шушы хәл Владимир Васильевичны судта җәмәгать яклаучысы сыйфатында чыгарга мәҗбүр итте.

— Мине иптәш малайлар котыртты. Алар сүзенә бирелдем, — диде Тимофеев судта.— Куркак дип уйламасыннар, тукта, батыр булып карыйм әле, дидем. Гаебемне таныйм, бик нык үкенәм...

Суд биргән җәзаны үтәп срогыннан күпкә алдан кайтты ул. Ләкин бригадага килмәде:

— Миңа хәзер анда эшләргә оят, — диде Валерий остазына. — Сезнең алда да, иптәшләр алдында да. Мин сездән читтә — ерактагы заводка эшкә урнаштым, минем өчен кайгыртуыгызга рәхмәт инде.

...Гомерләр агым судай тиз уза. Алар өйләнешкәнгә дә күпме вакыт үтте инде! Өлкән кызлары хәзер унбиш яшьтә, уллары да унның икенче ягына аяк баскан.

— Владимир Федорович!

— Әү, үскәнем?

Бу — мастер ярдәмчесе эшенә өйрәнүче егет Саша иде. Ул остазыннан киңәш алырга килгән. Өйләнү мәсьәләсендә. Бригаданың зәңгәр күзле, алсу йөзле бер сылуына гашыйк булган икән.

— Үз кызым кебек яратам, Саша, аның турында яхшыдан да башка сүзем юк.

Ә ике айдан соң — туй. Башкода булып түр башында хөрмәтле Владимир Федорович Туранов утыра...

Цехта шаярталар: безнең Владимир Федоровичтан да бай тагын кем бар икән, янәсе? Ел саен күпме кыз тәрбияләп үстерә, ел саен башкода булып туй бәлешләрен авыз итә. Вәт бәхет кешедә!

Ә Владимир Федоровичның сүз эзләп кесәгә керәсе юк:

— Кешеләрне күзле-башлы итәсе җиңелен җиңел дә, үз хатыныңны тыңлатулары авыр икән ул. Кешеләр шөбһәгә төшәләр. Ә ул һаман елмая:

— Шул, шул — хатын тыңламый — мине дә, кызым Галяны да, улым Диманы да.

— Нәрсә, ничек тыңламый...

— Безнең белән чаңгы шуарга чыкмый. Бау белән тарттырсагыз да чыкмыйм, ди. Ә иртәгә, иптәшләр, Аккош күлендә Кыш бәйрәмен ачу тантанасы. Беләсездер, барыгыз да килегез. Чаңгылар белән, билгеле. Мин моны сезгә башкода буларак кына түгел, парткомнан шушы эшкә җаваплы кеше буларак та әйтәм.

— Болай булгач бармый булмас,— диләр эшчеләр.— Эш җитдигә китте, җәмәгать.

Ә Аккош күленнән туп кебек атылып башта Дима кайтты. Аның сулышы кысылган иде.

— Әни, чаңгы ярышында беренче урынны безнең әти алды. Менә кәгазе!

Кәгазь дигәне — шул беренчелекне раслаучы Мактау грамотасы иде. Анна Петровна өсте әле дә карлы улын чишендерде дә шкафтан папка алды. Грамотаны шунда салырга кирәк иде. Папканы ачуга, аның эчендәге өлкә газетасының таныш саны күренде. Беренче биттә СССР Верховный Советы Президиумы Указы басылган иде. Инде ничәнче тапкыр укыган, сүзләре хәтта яттан беленгән Указга ул сабыйларча карап озак кына сокланып торды. «Бишьеллыкның өченче елында эштәге һәм яшьләрне тәрбияләүдәге уңышлары өчен...» дигән сүзләрдән башланган иде В. И. Ленин исемендәге Казан җитен комбинатының туку станоклары мастеры ярдәмчесе Владимир Федорович Турановны Ленин ордены белән бүләкләү турындагы Указ.

Х. Гобәйдуллин,
И. Ингвар

# МӘГЪНӘВИ ТЕАТРЫБЫЗ ОСТАЗЫ

Профессиональ татар театрының тууын һәм мәйданга чыгуын без, бик хаклы рәвештә, 1905 ел революциясе белән бәйлибез. Театрның җирлеген исә татар зыялыларының алдынгы вәкилләре шактый элгәрерәк, үткән гасырда ук сала башлаган. Татар милли театрын булдыру хыялы, реакция һәм искелек тарафдарларының театр сәнгате хакындагы фикерне үк катгый рәвештә тыюына да карамастан, ныгый һәм үсә бара.

...Катырак ээрлекләгән, ныграк тыйган саен бу омтылыш көчәя, театрны яклаучыларның сафы ишәя генә килде. Революция исә бу иҗтимагый хәрәкәткә тыелгысыз куәт бирде, яңа һәм яшь яралгының тернәкләнеп аякка басуы өчен мөмкинлекләр тудырды.

Татар театрының беренче артистлары гади халык вәкилләре, хезмәт ияләре арасыннан юл ярып чыккан кешеләр иде. Үзләренең талант куәтен, дәртле хисләрен ирек өчен көрәшкә багышлау теләге белән күңелләрендә янган фидакарьлек уты аларны сәхнәләргә менгерде. Әнә шундый шәхесләрнең иң зурларыннан, иң тугрылыклыларыннан берсе Габдулла Кариев булды.

Мәгълүм ки, татар телендә беренче спектакльләр Россиянең күп шәһәрләрендә куелган, әмма алар бер-берсеннән аз аерылып торганнар. Кыска вакыт эчендә, берничә репетиция белән әзерләнеп, ярлы җиһазлы сәхнәләрдә суфлер ярдәме белән уйнала торган ул тамашаларда һәвәскәр һәм ярым һәвәскәр артистлар катнашкан. Аларның уен дәрәҗәсе, актерлык техникасы, әлбәттә, шактый түбән дәрәҗәдә булып, тормышта тоткан урыннары, карашлары һәм сәнгатьнең ролен аңлаулары да бердәй түгел иде.

Бу халык җәүһәрләрен театрга булган чиксез мәхәббәтләре бер-берсенә якынайта, бер-берсенә тартылырга мәҗбүр итә. Әмма очраклы тестә оешкан мондый труппаларга тотрыклылык, эшләрендә эзлеклелек җитешми, якты йолдызлыкларны хәтерләтүче ул төркемнәр, бик тиз таралып, юкка да чыгалар. Ул да булмый, икенче бер урында, яңа төркем эчендә тагын балкый башлыйлар.

Үзенең тарту көче белән ул талантларны бер үзәккә туплап һәм юнәлеш биреп, алга әйдәп барырлык якты бер маяк җитми иде. Халыкның талантлы улларын һәм



кызларын үз тирәсенә җыйган Г. Кариев татар театр сәнгате күгендә әнә шундый маяк булып балкыды.

Крестьян малае, искиткеч сәләтлелеге белән танылган шәкерт Габдулла иске тормыш-көнкүреш канунннарына, караңгылык көчләренә, коллык һәм ким-хурлыкка каршы баш күтәрә. 1906 елда ул, хәр фикерле дуслары белән бергә, кадим мәдрәсәне ташлап чыга. Театрны җаны-тәне белән сөйгән, шигырьләр сөйләп, төрле әдәби кичәләрдә электән үк катнашып килгән егетнең 1907 елда ук И. Кудашев-Ашказарский труппасына килеп кушылуы табигый да, зарури да адым иде. Монда ул сәхнә сәнгатенең тылсымлы куәтенә, сихри гүзәллегенә бөтен күңеле белән гашыйк була, шул вакытта ук язмышын гомергә театрга бәйли. Барлык сәләтен, илһами һәм рухи көчләрен ул ихлас күңел белән сәхнәгә тәбәлгән гади тамашачы массасына, шул садә гавамга багышлый. Залдагы тамашачыларның һәрберсе белән аерым-аерым һәм барысы белән берьюлы күзгә-күз карашып, ачык күңел белән иң кадерле, иң мөһим сүзләрне сөйләшү мөмкинлеге хакына ул патша самодержавиесе елларында гаять авыр һәм газаплы булган актерлык юлына аяк баса. Һәм тамашачылар аңа шундый ук тирән хөрмәт, кайнар мәхәббәт хисләре белән җавап бирәләр.

Театрдагы юлын артист булып башлаган Габдулла Кариевка тиздән үзенә труппаны җитәкләргә, аның рухландыручысы, юл күрсәтүчесе, таянычы булырга туры килә. «Мөсафир артистлар җәмгыяте» — Кариев труппага әнә шундый исем бирә. Җәмгыять... Ул еллар өчен гаять зур мәгънәгә ия булган сүз ул. Кариев, театр эшен оештыруның ул чорда киң таралган антреприза формасын кире кагып, бөтен коллектив тарафыннан идарә ителә торган фикердәшләр берләшмәсен оештыра. Ул Казанда даими эшли торган, халыкның киң катлауларын тартырлык алдынгы демократик театр, яхшы җиһазландырылган, көчле актер составы булган театр төзү турында хыяллана.

Художникларның иҗади берләшмәсе идеясе, аның бурычлары һәм эш принциплары, труппаның эшчәнлеге белән беркетелеп, үзенә күрә бер устав формасын ала. Шушы «устав» һәм труппаның иҗат принциплары белән танышканда, без Г. Кариевның татар театры алдында торган бурычларны никадәр тирән аңлавын, карашларының киңлеген, труппа җитәкчесе буларак кыйбла иткән иҗтимагый-политик позициясен күрәбез. Кариев һәм аның тарафдарлары театрны, барыннан да элек, халыкка алдынгы демократик идеяләр илтүче культура-агарту учагы дип карыйлар. Шул максаттан чыгып, тамашачыларга һәр вакыт ихтирамлы мөнәсәбәттә булырга, алар белән даими бәйләнешне киңәйтә барырга омтылалар. Спектакльләрдә катнашучыларның уенында ансамбльлеккә ирешү труппа эшчәнлегендә шулай ук мөһим принципларның берсе булып тора. Артистлар барлык мәсьәләләрне коллегиаль хәл итәләр. Г. Кариев «уставы» тиздән труппа тормышында нормага әверелә, «Сәйяр» труппасы фикердәшлек нигезендә берекккән коллектив булып, чын мәгънәсендәге профессиональ театр булып җитешә. Аның күчмә театр булуы да, күп җәһәттән, әнә шулай үз эшчәнлеген киңрәк колачлы итү, халык массаларына якынрак булырга омтылуыннан килә.

Шушы изге максатларын тормышка ашырып, «Сәйяр» артистлары Иделне буйлыйлар, Әстерханга, Кавказ һәм Урта Азиягә кадәр барып җитәләр, Урал һәм Себер шәһәрләрен иңләп чыгалар.

Татар теле һәм сүзе кайда колакка чалынса — алар шунда. Телне аңлап җиткермәүчеләр өчен исә ишарә, йөз-кыяфәт, хәрәкәт ярдәмгә килә. Тамашачы,— татармы ул, русмы, яисә әзербайҗанмы,— бер нәрсәне яхшы күрә, аңлый һәм чамалый: монда кәмит уйнамыйлар, монда тормышны, дөреслекне күрсәтәләр, монда хаклык

һәм хәр фикерне һәрнәрсәдән өстен саныйлар, болар — гаделлек, ирек тарафдарлары. «Сәйяр» спектакльләренең һәм актерлары уеныының нәкъ менә шушы иҗтимагый яңгырашын тамашачылар яхшы тойган һәм тиз тотып алган. Труппаның Идел буе шәһәрләре, Урта Азия буйлап узган гастрольләре җәмәгатьчелек фикерен уята, халыкны дулкынландыра. «Сәйяр» үрнәгендә һәвәскәр театр коллективлары, кечкенә-кечкенә труппалар калкып чыга. Самара, Сембер һәм башка шәһәрләрнең прогрессив матбугаты беренче татар профессиональ труппасы куйган спектакльләрнең художество кыйммәтен генә түгел, иҗтимагый әһәмиятен дә билгеләп үтә. «Голос Самары» газетасы, мәсәлән, 1907 елның 19 июнендә болай дип яза: «Алар (тамашачылар — Х. Г.) арасында урта элемент өстенлек итә, өстен катлау кешеләре бик аз иде. Яшь артистларның башкаруы... иң җылы сүзләр белән бәяләүгә лаек». «Волжские вести» (Сембер) һәм «Казанский вечер» газеталары да «Сәйяр» спектакльләрен шундый ук рухта бәялиләр. «Нижегородский листок» (1896 елдан 1901 елга кадәр бу газетага М. Горький да язышкан) үзенең баш мәкаләсендә яңа гына туган татар труппасына мәгърифәтче-демократик карашлы бәяне бирә. Анда театрның «томаналыкка һәм татар җәмәгатьчелегенең үзенә башка яшәвенә каршы» көрәш башлавына куаныч белдерелә. «Мәгърифәт,— диелә мәкаләдә,— аларның руслар белән якынаюларына ярдәм итәчәк, кысрыклау тарафдарлары (ягъни Россиянең хаким сыйныфлары — авт.) исә моңа ирешә алмадылар»[1].

Г. Кариев һәм сәйярчыларның үз эшчәнлек колачын киңәйтә баруы, театрны халыкка якынайтырга омтылуы, эшчәнлегендә демократик тенденциянең көчәюе, әлбәттә, жандарм идарәсенең «уяу күзеннән» читтә калмый. Аның агентлары «Сәйяр»ның спектакльләренә йөриләр, Г. Кариевны хөкемгә тарту өчен тырышып материал җыялар. Гастрольләр узачак һәр урында труппа өстеннән яшерен күзәтү оештырыла. Мәсәлән, Казан губерна жандарм идарәсе начальнигы Әстерхан жандармериясе начальнигына болай дип хәбәр итә:

«Минем карамактагы идарәнең формаль яктан әле ачыкланмаган мәгълүматларына караганда, татар актеры Габдулла Кариев «Сәйяр» труппасы белән шушы көннәрдә түбәндәге шәһәрләргә чыгып киткән... (шәһәр исемнәре санала — авт.) Шуны белдереп, исеме югарыда аталган Кариев артыннан күзәтү оештыруыгызны, нәтиҗәләре хакында миңа хәбәр итүегезне үтенәм»[2].

«Сәйяр» труппасы алган юнәлешне гамәлгә ашыру, алга куйган максатларга җавап бирерлек әсәрләр сайлау, лаеклы репертуар булдыру өстендә Г. Кариев җитди эшчәнлек күрсәтә. Ул драматурглар белән даими һәм якын бәйләнештә тора. Галиәсгар Камал, мәсәлән, үзенең пьесаларын махсус рәвештә «Сәйяр» труппасын күздә тотып яза. К. Тинчурин, Ф. Бурнаш, М. Фәйзи, Ш. Камал кебек күренекле татар драматургларының иҗат колачлары киңәюгә дә Кариев белән хезмәттәшлек ярдәм итә. Г. Кариев каләм осталары белән бик бирелеп һәм яратып эшли. Шулай ук ул даими рәвештә рус һәм чит ил классикасына мөрәҗәгать итә. Репертуарга бер-бер артлы Островскийның «Яшенле яңгыр», «Гаепсездән гаеплеләр», «Төшемле урын» кебек әсәрләре, Гогольнең «Ревизор»ы, Горькийның «Мещаннар»ы, Гейненың «Әлмансур», Мольерның «Саран», Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт» трагедиясе һ. б. әсәрләр алына.

Г. Кариев 1917 елда, татар театры тарихында беренче булып, иң яхшы сәхнә әсәренә конкурс оештыра. Кариевның «Сәйяр» труппасы һәм, гомумән, театр алдындагы бурычларны ничек аңлавын шушы конкурс шартлары ачык күрсәтеп тора. Иң элек сәхнә әсәрләренең тематикасын киңәйтү максаты күздә тотыла. Шәһәр һәм авыл чынбарлыгыннан алынып, халык тормышын «чын мәгънәсе белән тасвир иткән» пьесаларга һәм шулай ук тарихи темаларга, татар, башкорт, казакъ халыкларының фольклоры мотивларыннан файдаланып язылган әсәрләргә ихтыяҗның зур булуы әйтелә. Авторлар алдына Г. Кариев җитди таләпләр куйган: әсәрдә тамашачыларны ялыктыра торган озын монологлар һәм фәлсәфә сатулар булмасын, персонажларның теле җанлы сөйләм теленә нигезләнсен, геройларның характерлары калку бирелсен һ. б. Конкурс нәтиҗәсе буларак, репертуарга К. Тинчуринның «Соңгы сәлам», «Назлы кияү», Ф. Бурнашның «Таһир һәм Зөһрә», «Саташкан кыз» һ. б. әсәрләр өстәлә.

---

[1] «Нижегородский листок». «Пробуждение народностей» исемле мәкалә, 1907 ел, 198 сан.
[2] Әстерхан шәһәре Дәүләт архивы, 414 эш, 2 тасвирлама, 30 бит.

Сирәк очрый торган режиссер-педагог сыйфатлары, оештыру сәләте һәм искиткеч актерлык таланты — Г. Кариевта менә шулар бергә кушылган була. Ул кешеләрдәге яшерен иҗат чаткысын вакытында күреп ала белә, хезмәттәшлек процессында ул очкынны дөрләп торган ялкынга әверелдерергә омтыла, андый кешеләрне кабатланмас иҗади индивидуальлеккә ия булган шәхес итеп үстерергә тырыша. Халык арасыннан талантларны эзләп табуда Кариевның шушындый осталыгын аның белән очрашкан һәм бергә эшләгән кешеләрнең һәммәсе дә беравыздан раслый. Сәләтле яшьләрне Г. Кариев һәркайдан һәм даими рәвештә эзли. Теге яки бу шәһәрдә шундый бер егет яки кызны очрата калса, ул анда уңышсыз тәмамланган гастроль өчен дә үкенми. Егерменче елга кадәр зур сәхнәгә аяк баскан күренекле татар артистларының байтагы театрга нәкъ әнә шундый табыш буларак килгәннәр.

Спектакль уйнаучы артистлар ансамбль тәшкил итәргә тиеш, дип саный Г. Кариев. Бөтен коллективның иҗади хезмәт нәтиҗәсе булган мондый спектакльдә һәр актёр үз талантын бер максатка буйсындыра. Спектакльдә иң кечкенә рольнең дә әһәмияте бар. Профессиональ осталыкны камилләштерүне Г. Кариев труппа алдында торган иң төп бурычларның берсе дип карый. Үзе дә туктаусыз укый, өйрәнә, башкаларны да өйрәтә. Труппага ярдәмгә ул рус режиссерларын һәм художникларын чакыра. Актер белән эшләгәндә ул аның фантазиясен уятырга, кызыксыну даирәсен киңәйтергә, аңарда иҗади халәт тудырырга тырыша. Ифрат дәрәҗәдә эмоциональ, хисчән кеше буларак, ул үз тирәсендәге актерларны да тиз мавыктыра белә, ихласлыгы белән аларны үзенә ияртә.

Кариев-режиссер башкаручылар уенында барыннан да элек тормыш чынлыгын таләп итә. Тамашачыны ышандыру өчен, ди ул, сәхнә уенында дөреслек булырга тиеш. Моңа ирешү өчен натураны өйрәнергә кирәк. Һәм Г. Кариев, иптәшләрен ияртеп, үзләре уйнаячак геройларны теге яки бу халык төркеме арасында табу ихтималы булган урыннарга бара. Төрле катлау кешеләренең тормыш-көнкүрешен даими күзәтеп, ул үзенең гаять зур тәэсорат байлыгын туктаусыз арттыра килә. Г. Камалның «Безнең шәһәрнең серләре», «Банкрот», «Уйнаш» пьесаларында Г. Кариев тудырган Хафиз, Сираҗетдин, Әнвәр образлары ышандыргыч һәм тормышчан, камил, тәгәлләнгән булулары белән тамашачыларны таң калдыралар. Боларда артистның образ сурәтенә керү осталыгы, тормыш материалын җитди үзләштерүе, үткен күзәтүчәнлек сыйфатлары гаять калку күренә. Бу сәүдәгәрләрнең өчесенең дә асылы бер үк, әмма алар һич тә бер-берсенә охшамаган. Һәрберсенең үзенә генә хас төс-кыяфәте, килеш-килбәте, гадәте-холкы, үзенчәлеге бар. Кариевның Сираҗетдине — күптән инде намусын саткан, үзендә горурлыкның әсәре дә калмаган кеше. Суфи булып күренергә тырышучы бу икейөзле затның социаль асылын артист бик үткен тотып ала. Әнвәр һәм Хафиз образларында да ул шул чордагы социаль типларга хас сыйфатларны оста гәүдәләндерә. Бу типлар — яңа формалашып килгән татар реалистик сәхнә сәнгатенең зур казанышы иде. Татар артистларының бөтен бер буыны үз геройларының прототипларын тормыштан эзләп табу осталыгына Г. Кариевтан өйрәнде. Шул ук вакытта, Г. Кариев, режиссер һәм артист буларак, әлбәттә, сәхнәдә тормыш материалын кабатлау, әзер өлгеләргә ияру белән чикләнеп калмый. Куәтле иҗат фантазиясе, сәнгать кануннарын тирәнтен аңлавы аңа сәхнә натурализмыннан өстенрәк булырга, аерым шәхесләр артында типларны, вакыйга һәм образлар артында төп идеяне күрергә ярдәм итә. Зур художник Г. Кариев драматургия әсәрен бер бөтен итеп күрә белә, пьесадагы калку детальләрне, аерым эпизодларны спектакльнең үзәк фикерен ачуга хезмәт иттерә.

Г. Кариевның оештыру һәм режиссерлык эшчәнлеге революция алды һәм 1917 елгы революция елларында аеруча киң колач ала. Ул Казанда күп санлы артистлары, үз режиссеры һәм художнигы булган театр оештыру турындагы күптәнге хыялын тормышка ашыра, театрга Әшраф Синяева, Нәфига Арапова, Ситдыйк Айдаров, Габдрахман Камал, Фатыйма Ильская, Хәмит Колмәмәт кебек талантлы яшь артистларны тарта. Режиссер итеп рус сәхнәсе белгечләре Загорский, Михаленко, художник итеп П. Беньков чакырыла. «Г. Кариев исемендәге татар драмасы»[1]ның репертуары да сизелерлек байый. А. Н. Островскийның «Төшемле урын», Ж. Моль-

---

[1] 1916 елның октябреннан, труппа белән мөстәкыйль идарә итү — антреприза оештырылганнан соң, «Сәйяр» әнә шулай атала башлый. — Х. Г. искәрмәсе.

ерның «Ирексездән табип», М. Горькийның «Мещаннар», К. Тинчуринның «Беренче чәчәкләр» һ. б. әсәрләр уйнала. Труппа 1917 елның августында Г. Коләхметовның озак еллар буена цензура тыеп килгән «Яшь гомер» драмасын сәхнәгә менгерә. Бу спектакльдә тамашачы беренче тапкыр татарның эшче вәкилләре Вәли һәм Йосыф белән очраша һәм аларны алкышлап каршы ала. Октябрьдан соң театр, үзенең реалистик традицияләрен дәвам иттереп, Чеховның «Чия бакчасы», А. Сухово-Кобылинның «Кречинскийның туе» пьесаларын зур уңыш белән куя.

1918—1919 еллар сезонында Казан сәхнәсендә беренче тапкыр Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» музыкаль драмасы уйналуы театрыбыз тормышында онытылмаслык эз калдырган вакыйга була. Режиссер Г. Кариевның һәм бөтен труппаның эстетик позициясе, караш һәм максатлары бу спектакльдә аеруча ачык, калку гәүдәләнә, «Сәйяр»ның эшчәнлеге белән 1907—1908 еллардан бирле үстерелеп килгән реализм мәктәбе, аның алымнары тулы чагылыш таба. Татар крестьяннары образлары, психологиясе, тормыш-көнкүреше, сыйнфый каршылыклар — боларның һәммәсе тамашачының күңеленә үтеп керерлек якын, аңлаешлы, гыйбрәтле итеп сурәтләнәләр. Персонажларның тышкы кыяфәте, кием-салымы, нечкәләп һәм зур тырышлык куеп җиһазландырылган сәхнә — һәммәсе дә спектакльнең тәэсир көчен арттыру, әсәрнең идея эчтәлеген ачуга хезмәт итә. «Галиябану» спектакльләре, беренче музыкаль әсәр буларак, татар театрында яңа жанр — музыкаль драмага юл ача.

Г. Кариев һәм аның тарафдарлары гаять кыен шартларда сүнмәс дәрт һәм җиңүгә нык ышаныч белән татар театрына тормышта урын яулап озак еллар буе көрәштеләр. Театрыбыз реалистик театр буларак туды һәм үсте, ул халыкка мәгърифәт, демократия һәм азатлык идеяләрен таратты. Г. Кариев татар мәгънәви театрын оештыручы һәм аның байрак йөртүчесе булды. Бу мәкаләбезне татар театрының икенче бер корифее, Г. Кариевның карашларына һәм эшчәнлегенә төпле һәм лаеклы бәя биргән К. Тинчурин сүзләре белән тәмамлыйк:

«Г. Кариев — татар мәдәнияте тарихында аерым сәхифә ачтырган беренче дәвердәге татар театрының бердәнбер юлбашчысы; татар театрына беренче буларак сима [1] бирү, татар типларын беренче буларак дөрес итеп иҗат итү, татар театрын халык рухына якынлаштыру, татар театрын гомумиләштерү эшләрен үтәүче, шөбһәсез, — Габдулла Кариев» [2].

---

[1] Сима — форма, күренеш мәгънәсендә.
[2] «Артист Г. Кариев». Казан, 1924 ел, 7—11 битләр.

Игорь Алексеев

# КАЗАНДА КИНО НИЧЕК БАШЛАНГАН

Мәгълүм булуынча, Россиядә беренче киносеанслар 1896 елда Петербургта күрсәтелә. Соңга табарак кино фильмнары башка зур шәһәрләрдә, ә шуннан соң исә кечерәк шәһәр һәм поселокларда, авылларда куела башлый.

Кинематограф Казанга 1897 ел урталарында килеп җитә. 2 май көнне Шәһәр театрында «Люмьерның чын Синематографы — (хәрәкәт итүче җанлы фотография)»-ның беренче сеансы үткәрелә [1]. Аны шәһәргә Штейнфингель атлы бер кеше алып килгән була. Кырыклап җанлы күренештән торган бу кино тамашачыларга тетрәткеч тәэсир ясый, залның үтенүе буенча, күп кенә күренешләрне икенче рәт күрсәтергә туры килә.

Әмма, сеансны оештыручыларның гаҗәпләнүенә каршы, тамашачылар залда әллә ни күп булмый. Күрәсең, Россиядә беренче кинематография аппаратлары күренә башлаганнан соң үткән кыска гына вакыт эчендә, акча исен һәм яңа табыш чыганагын сизеп алып, бу өлкәгә килеп тулган бушкуык авантюристлар киноның яманатын таратып өлгергән булалар инде. Шуңа күрә, киносеанслар хакында игълан биргәндә газеталар: «...элегрәк монда булып киткән иярченнәр белән буталмасын» дигән сүзләр өсти башлыйлар. Ә киң катлау өчен беренче киносеанс хакындагы газета хәбәрендә «бу аппаратның Казанга элек китерелгән барлык төр аппаратлардан чагыштыргысыз өстен», шуңа күрә аның игътибарга тулысынча лаек булуына, аны күргән кешеләргә үкенергә туры килмәячәгенә басым ясала [2].

Газетадагы бу хәбәрнең нәтиҗәсе тиз күренә, «мохтаҗлык күрүче хатын-кызларга ярдәм максаты белән оештырылып килә торган җәмгыять файдасына» үткәрелгән икенче сеанста инде театр залы халык белән шыгрым тула.

Шул ук елның җәендә кинематограф шәһәребезнең тагын да киңрәк катлавы алдына чыга. Июнь ахырында казанлыларның күңел ача һәм ял итә торган урыннарының берсе булган Панаев бакчасында беренче тапкыр электр утлары кабына, ә тагын берничә көн үткәннән соң биредә «Люмьер Синематографының атаклы һәм дөньяда бер җанлы фотография аппараты тамашасы» күрсәтелә. Киносеанска багышланган газета рецензиясенә күз салып үтик: «...Публикага төрле-төрле алтмышлап картина тәкъдим ителде, шуларның өчесендә хәрәкәт кире ягыннан күрсәтелде. Бик күп фигуралар: кешеләр, атлар, экипажлар — берьюлы сурәтләнгән күренешләр бик үк уңышлы чыкмады, алар бер-берсенә комачау итәләр кебек тоелды. Аның каравы, бер, ике, өч фигуралы күренешләр искиткеч тәэсирле булды. Җитез хәрәкәтләрне күрсәткән күренешләр бигрәк тә яхшы иде, мәсәлән, физиономист, фокусник, балерина, су керү һ. б. күренешләр» [3].

[1] «Волжский вестник», 1897 ел, 2(14) май саны.
[2] «Волжский вестник», 1897 ел, 4(16) май саны.
[3] «Волжский вестник» 1897 ел, 5(17), июль саны.

Люмьер синематографы шуннан соңгы елларда да (гасыр башына кадәр) Казан тамашачыларында популярлыгын югалтмый. Ә 1898 елның 18 апрелендә Шәһәр театрында үткән сеанс сенсация булып әверелә. Чөнки ул көнне экранда Казан драма театры артистларының репетициядән соң Шәһәр театры бинасыннан чыгулары күрсәтелә. Бу — Казанда төшереп алынган беренче кинохроника тасмасы.

Башлангыч чорында — тууыннан алып биш-алты ел буе — халык игътибарын кинематограф үзенә җәлеп итә, моңарчы күрелмәгән техника яңалыгы буларак, гаҗәпләнү һәм соклану хисе уята. Ә соңга таба исә тамашачыны ул тормыш-көнкүрештә күрә алмаган нәрсәләрне экранда тамаша кылу чарасы буларак үзенә тарта. Чыннан да, мәсәлән, шул елларда Парижда булган вакыйгаларны яисә Лондонның зоология бакчасын казанлыларның күбесе башкача ничек тамаша итә алыр иде икән?

Әмма, шуңа да карамастан, егерменче йөз башында кинематограф белән кызыксыну көтелмәгән дәрәҗәдә кими. Шәһәрдә кинематография сеанслары турындагы хәбәрләрне 1900—1905 еллар матбугатында без очратмыйбыз диярлек. Бу бөтен Россия өчен характерлы күренеш.

Кинода җанлану чоры кабат 1906 елда башлана. Чөнки кинематограф, ниһаять, сыйфат үзгәреше кичерә. Беренче елларда ул, нигездә, хроникаль-документаль характерда булган булса, хәзер инде бик күп санда уенлы тасмалар чыга башлый. Кино, шулай итеп, күңел ачу, тамаша чарасына әверелә, төрле ярминкәләрдә, циркларда, парк һәм бакчаларда үз урынын алый. Казандагы бертуган Никитиннар цирк рекламасында тамашадан соң «искиткеч нәфис һәм хәрәкәт итүче томанлы күренешләр» вәгъдә ителә, «Аркадия» бакчасы игъланнарында да «хор, капелла, җырчылар, биючеләр, шансонеткалар чыгышлары белән рәттән, синематограф»[1] булачагы әйтелә һ. б.

Вак кинематографлар бөтен ил буенча тагын туктаусыз күчеnеп йөри башлыйлар. Алар арасында рәхимсез конкуренция хөкем сөрә. «Җанлы фотография» хуҗалары, берсеннән-берсе уздырырга тырышып, үз аппаратларына нинди генә хикмәтле һәм серле исемнәр кушмыйлар! Мәсәлән, Казан тамашачыларын матбугат аша «Энгофер биографын», ниндидер «Таумотограф»ны тамаша кылырга да, «100 квадрат аршин экранлы Примо-Электро-Биоскоп»ны һәм тагын «дөнья йөзендә иң яхшы булган» башка шундый бик күп әкәмәт аппаратларны күреп калырга өндиләр. Менә шундый гастролерларның саны күбәя барса да, Россия шәһәрләрендә әле байтак вакыт буе стационар кинотеатрлар барлыкка килми. Дөрес, 1906 елның 19 декабрь санында «Казанский вечер» газетасы шәһәрдә даими эшләячәк җирле кинотеатр ачылуын хәбәр итә. Әмма бу башлангыч озын гомерле булып чыкмый. Кинолы җәйге айларда карарга күнеккәнгәме, Казан тамашачылары театрга бик сүлпән йөриләр һәм ул тиздән ябыла. 1907 елда эшли башлаган «Л. Бови театр-кинематографы» (ул элекке Воскресенская, хәзерге Ленин урамы, 21 йортта урнашкан була.— Авт.) инде зуррак уңышка ирешә һәм, шәһәрдә ел ярым буе бердәнбер даими кинотеатр буларак, халыкка шактый хезмәт күрсәтә. Аның программасында «Мрамор эшкәртү», «Бронялы крейсерлар», «Кырым батырлары», «Көнчел хатын хәсрәте», «Нәни тәмәкече», «Шаян укучылар» кебек тасма исемнәрен очратабыз.

Казанда даими кинотеатрлар саны 1908 елдан алып нык үсә башлый. Бер-бер артлы «XX гасыр» (хәзерге Куйбышев урамы, Сәүдә работниклары клубы бинасы), «Феникс» (хәзерге Пушкин урамы, 2/1 йорт), Болак артында, Печән базары тирәсендә «Фурор» электротеатры, «Аполло» (хәзерге «Татарстан» кинотеатры), «Урания» (М. Горький исемендәге культура йорты бинасы), «Пассаж» («Пионер» кинотеатры), «Буфф» электро-синематографы (Ленин урамы, «Экран» магазины) һ. б. исемдәге театрлар ачыла. Алар тамашачыларга «тул-туры чит илдән алынган» фильмнар тәкъдим итәләр, тасмаларда төрле илләр буйлап сәяхәт итү, завод-фабрикалар эше, политик һәм хәрби тормыштан, тарихтан алынган күренешләр, юмористик һәм фантастик сюжетлар һ. б. сурәтләнә.

Әмма шунысын әйтергә кирәк, кинотеатрлар челтәре үсү бу чорда әле кинематографның, бигрәк тә кинопроекторларның техник камиллеге дәрәҗәсенә туры килеп бетми. Фильмнарны күрсәтүдә файдаланылган яктылык чыганакларының көче җитәрлек булмый, тасмалар да еш өзелә, экранда кадрларның «биюе» исә фильм карауны

[1] «Казанский телеграф», 1906 ел, 16 июнь саны.

ныk кыенлаштыра. «Бу хәл күзне ардырта һәм киногa каршы булган кешеләр өчен көчле дәлил булып тора... Төрле чараларны сынап караганнан соң иң оригиналь ысулны сайлап, сеанс вакытында залда утны сүндерми калдыра башладылар»[1].

Кинофильмнарны яктыда күрсәтү, әлбәттә, аларның сыйфатын боза. Ахыр чиктә, нинди дә булса трюкларга бирелмичә, кинематография техникасын яхшырта баруга (бигрәк тә кадрның сикерүен бетерүгә) юнәлеш тоткан кинотеатрлар өстенлек алалар.

Шушы ук елларда Казанда экрандагы сурәтне тавышлы итү омтылышлары да ясала. Кинематографның яңа туган чорында ук бу проблема белән Эдиссон шөгыльләнә башлаган. Ул, тавыштан башка сурәт ялгызы гына ардырта, дип саный[2]. Төрле илләрдә, шул исәптән Россиядә дә, бу проблема өстендә эзләнүләр башлана.

1907 елның җәендә Казанның Шәһәр театры тамашачыларны «оперо-синематографик сеанс»ка чакыра. Сеансны оештыручылар халыкка «оперomегафонга тоташтырылган оксетофон» ярдәмендә «Кармен» операсын һәм башка әсәрләрдән өзекләр күрсәтергә вәгъдә итәләр. Ләкин «җырчы артистларның хәрәкәтләре белән тавышларының тулысынча бергә кушылуын» күрергә килгән күп санлы тамашачыларның өметләре акланмый. Баксаң, аңлашылмый торган «оперомегафон» дигәне гадәти кинематографик аппарат, серле «оксетофон» исә — һәркемгә яхшы таныш граммофон булып чыга. «Казанский телеграф» бу «яңалык»ны болай бәяли: «Әлеге ике инструмент, бергә кушылып, «Кармен» һәм тагын башка опералардан күп кенә өзекләр күрсәтергә һәм тыңлатырга тиешләр иде. Асылда исә, чын җыр һәм музыкага ифрат шәп пародия килеп чыкты. Көлке һәм кызганыч пародия...»[3].

Беренче тавышлы кинотамаша, әнә шулай, уңышсызлыкка очрауга карамастан, тәҗрибәләр дәвам итә. «Аркадия» бакчасында «Биофонауксетофон», «Эрмитаж» бакчасында «Виофон — синематограф»лар ачыла.

Сурәтне тавыш белән бәйләүдә «кинодекламация» жанры ул елларда шактый уңыш казана. Мәсәлән, Н. В. Гогольнең «Акылын җуйган кеше язмалары» повесте буенча эшләнгән фильмда Мәскәү артисты В. Ниглов уены матбугат игътибарын җәлеп итә. «Казанский телеграф» язуынча, «бу картинада актер гримнан оста файдалана һәм әсәрдә сурәтләнгән обстановкада уйный, ә артистның үз декламациясе, тавышы, бу чынлык тойгысын аеруча көчәйтеп, тамашачыда зур тәэсир калдыра»[4]. Казанлылар «Шельменко-денщик» кинопьесасында чыгыш ясаган артист — кинодекламатор А. С. Капинский уенын да җылы кабул итәләр.

Әмма өнсез-тынсыз киносеансларны «җанландыру» юлларының иң ышанычлысы булып, фильмны музыкаль аккомпанемент белән алып бару ысулы таныла. Фильмда музыканы беренче булып Казанда «Фурор» кинотеатры куллана. «Фурор» үрнәген тиздән «Патэ» кинотеатры эләктереп ала. «Пассаж», «Олимп», «Аполло» кебек иң бай кинотеатрларда хәтта махсус симфоник оркестр файдаланыла.

Кино тарихы турында сөйләгәндә, бер мөһим мәсьәләгә тукталмый мөмкин түгел. Кинематографның иң беренче елларында ук Россиянең алдынгы җәмәгатьчелеге аны киң массалар арасында мәгърифәт, аң-белем тарату максатларында файдалану мөмкинлекләренә игътибар иткән. Бу мәсьәлә матбугат битләрендә дә күтәрелә. «Соңгы вакытта,— дип яза «Казанский телеграф» газетасы,— шәһәребездә кинематографлар шактый күп санда күренә башлады. Һәм шунысын әйтми булмый, эшне тиешенчә куйганда алар зур файда китерә алырлар иде... Ләкин, кызганычка каршы, безнең кинематографлар эшчәнлегенең... бернинди фәнни-мәгърифәтчелек әһәмиятләре юк, картиналар күпчелек очракта натурадан алынмыйлар, ә ясалма юл белән эшләнәләр... Тамашачыларны география, тарих, археология, астрономия, иң яхшы әдәби әсәрләр, хуҗалыкның төрле тармаклары белән таныштыруда киноның мөмкинлекләре күп. Әгәр Казан кинематографларыннан кем дә булса шундый җитди картиналар белән шөгыльләнә башласа, уңышка ирешми калмас иде дип ышанып әйтергә мөмкин»[5].

Кинематографияне аң-белем тарату максатларында файдалану мәсьәләсен Казан урта уку йортлары начальникларының махсус комиссиясе дә күтәреп чыга. Комиссия фәнни кинематограф оештыру кирәк дигән фикергә килә һәм шәһәр кинотеатрларының берәрсе белән бәйләнешкә керү, Мәскәүдән махсус сайлап алынган картиналар

[1] Лихачев Б. С. Россиядә кино. 1 кисәк, Ленинград, 1927 ел.
[2] Ф. Тальбот. Җанлы фотография. Мәскәү, 1928 ел.
[3] «Казанский телеграф», 1907 ел, 31 июль саны.
[4] «Казанский телеграф», 1909 ел, 29 октябрь саны.
[5] «Казанский телеграф», 1908 ел, 15 ноябрь саны.

кайтаруны юлга салу бурычларын куя[1]. Ләкин бу тәкъдимнәр, власть органнарының акча бүлүдән баш тартулары аркасында, тормышка ашмый. Тик 1914 елда гына шәһәр уку-укыту бүлеге, «башлангыч классларда кинематограф ярдәмендә күргәзмә-укыту эшен дәрес оештыру өчен», бер киноаппарат сатып ала.

Кинотеатрлар һәм киносеанслар саны арта барган саен балалар һәм кино мәсьәләсе дә җәмәгатьчелек алдында торган мөһимрәк мәсьәләгә әверелә. Шәһәребезнең урта мәктәпләрендә укучыларга кинотеатрларга йөрү 1912 елга кадәр гомумән тыелган булган. Шул елның ноябреннан «Эдиссон» кинотеатрында якшәмбе һәм бәйрәм көннәрендә балалар өчен махсус сеанслар оештырыла башлый. Ләкин бу башлангыч та озакка бармый, сүнеп кала. Бу хәл, әлбәттә, революциягә кадәрге кино эшенең капиталистик предприятие буларак, бары табыш алу, обывательнең кесәсеннән акча суыру максатына гына корылуыннан килә. Революциягә кадәрге кинофильмнар арасында мәшһүр «Алтын серия», «Севастополь оборонасы» кебек җитди картиналар сирәк очрый.

Кинотеатр хуҗалары андый фильмнарны үзләрендә генә күрсәтү хокукын сатып алырга һәм алар тирәсендә ажиотаж тудырырга тырышалар. Мәсәлән, «Севастополь оборонасы» фильмын күрсәтү хокукын «Пассаж» кинотеатры сатып ала һәм фильмны бары тик шул театрда гына карарга мөмкин була.

Революциягә кадәр үк Казанда фильмнарны прокатка бирү системасы барлыкка килә. Әгәр баштарак шәһәр кинотеатрлары үзәк прокат оешмалары белән турыдантуры элемтә тоткан булсалар, 1916 елда картиналарны сату һәм прокатка бирү буенча беренче шәһәр конторасы ачыла.

Ә соң революциягә кадәр шәһәребез энтузиастлары тарафыннан кино төшерүгә омтылышлар булганмы? Әйе, булган. «Казанский телеграф» газетасы хәбәр итүенчә, 1909 елда Казан гарнизоны гаскәрләренең тантаналы парады хроника тасмасына төшерелгән[2]. 1910 елда Казан кинотеатрлары экраннарында «Казандагы авиация атнасы»-ның беренче көнен сурәтләүче картина күрсәтелгән. 1914 елның 2 гыйнварында Казан җир управасының техник бүлеге тарафыннан Казан — Лаеш — Шуран маршруты буенча беренче кышкы автомобиль ярышлары оештырыла. Автоярышлар кино тасмасына да алына, «картинаның бер өлеше сәгатенә 75 чакрымга кадәр тизлек белән баручы автомобиль өстеннән төшерелә»[3]. Шул ук елда икенче бер автомобиль ярышы, тимераякта фигуралы шуу, бәйрәм көннәрендәге Казан күренешләре дә тасмага алынган була. Кызганычка каршы, бу кино кадрлары бүгенгәчә сакланмаган һәм аларны төшергән кешеләрнең исемнәре дә билгеле түгел. Ул кешеләр Казан фотография җәмгыяте әгъзалары булгандыр дип уйларга мөмкин. Мәсәлән, «Камско-Волжская речь»нең 1911 ел, 27 июль санында Казан фотографы Н. О. Прокофьевның шәһәр гарнизоны парадын кинога төшерүе хакында урнаштырылган хәбәр моңа беркадәр нигез бирә.

1917 ел революциясеннән соң шәһәр кинотеатрларының тамаша заллары пропагандистлар аудиториясенә, политик җыелышлар, митинг һәм дискуссияләр урынына әверелә. «Камско-Волжская речь» газетасы бу хакта болай дип хәбәр итә: «Электра» театрында соңгы көннәрдә ораторлар — башкарма комитет членнары чыгыш ясады. Бу чыгышлар залдагы халыкта гаять зур уңыш казанганлыктан, моннан ары ораторлар анда һәр көн чыгачаклар. Эшче, солдат һәм крестьян депутатлары Советы карамагындагы бу театрның саф җыемы Советның оештыру һәм культура-агарту эшчәнлеге өчен тотылачак».

Бөек Октябрь социалистик революциясе кинематография тарихында да яңа дәвер ача. Совет киносы алдына моңарчы күрелмәгән бурычлар куела. 1919 елда А. В. Луначарский кино эше турында болай дип яза: «Россиядә дәүләт күләмендәге кино эше алдында бөтенләй үзгә булган бурычлар тора. Эш фильмнар эшләп чыгару, таратуны национализацияләү, кинотеатрлар өстеннән җитәкчелекне дәүләт кулына бирүдә генә түгел. Эш сәнгатьнең һәм мәгарифнең бу өлкәсен бөтенләй яңа рухта төзүдә... Без социалистик дәүләтнең кинотамашаларга да социалистик рух өрергә тиешлеген истән чыгармаска тиеш»[4].

---

[1] «Камско-Волжская речь», 1910 ел, 18 февраль саны.
[2] «Казанский телеграф», 1909 ел, 8 ноябрь саны.
[3] «Казанский телеграф», 1914 ел, 18 январь саны.
[4] Кинематограф. Мәгариф халык комиссарияты чыгарган мәкаләләр җыентыгы. Мәскәү, 1919 ел.

# ӘБҮ ХӘМИД ӘЛ-ГАРНАТЫЙНЫҢ БОЛГАРГА СӘЯХӘТЕ

## Сәяхәтче һәм аның әсәрләре

Урта гасырларга караган тарихи язмаларда борынгы Болгар иле, Идел буе болгарларының гадәт-йолалары күп мәртәбәләр искә алынса да, бу якларга килеп, бабаларыбызның тормыш-көнкүрешен үз күзләре белән күргән авторлар бармак белән генә санарлык. Шундый авторларның безгә мәгълүм булганнарыннан иң беренчесе — мәшһүр Әхмәт ибне Фазлан (аның сәяхәтнамәсеннән кайбер өзекләр «Казан утлары» журналының 1972 елгы 8 санында басылган иде). Әбү Хәмид әл-Гарнатый исә Болгар җиренә килеп әсәр язган икенче кеше.

Әбү Хәмид әл-Гарнатый «Төхфәтел-әлбаб...» («Гакыллар бүләге...») дигән китабы белән аеруча зур шөһрәт казана. Дүрт бүлектән торган бу китапта дөньядагы гаҗәеп хәлләр, кешеләр һәм җеннәр, төрле илләр һәм халыклар, кызыклы корылмалар һәм серле мәгарәләр, сәер җанварлар һәм мәшһүр каберләр хакында сөйләнә. Космография жанрында язылган мондый әсәрләр борынгы заман халыклары (әйтик, грек, латин, әрмән, гарәп, фарсы һ. б.) әдәбиятында гаять киң таралган була. Бу китаплар дөньяга фәнни караш тәрбияләүдән бигрәк, укучыларны таң калдыру, аларның күңелләрен ачу һәм чамалап кына популяр белем бирү максатыннан чыгып язылган. Гыйльми хезмәт булудан бигрәк, алар әдәби әсәрләр рәтендә каралып өйрәннәр.

Реаль чынбарлыкны чагылдырган хикәятләрен әкият һәм мифлар белән үреп барган өчен әл-Гарнатыйны гаепләп булмый, билгеле. Чөнки һәр чорның, һәр җәмгыятьнең үз зәвыгы, үз стиле була. Шуңа яраклы рәвештә, язма әсәрләрдәге сурәтләү чаралары да, ышандыру алымнары да үзгәрә килә. Ниһаять, ул дәверләрдә гомум белемнең, дөньяны танып-белүнең бик түбән дәрәҗәдә торганын да истән чыгармаска кирәк. Әмма ни генә булмасын, очраклы рәвештә «каләм әһеле» булып киткән гади илгизәрнең язмаларында тарих фәне өчен гаять мөһим һәм кызыклы мәгълүматлар шактый гына.

Әл-Гарнатыйның «Төхфәтел-әлбаб...» әсәре Европа галимнәренең игътибарын нәкъ әнә шул яклары белән үзенә тарта да. Алда әйтелгәнчә, бу әсәрдә Европа халыклары тормышына караган кызыклы хәбәрләр байтак. Ул хәбәрләрнең күбесен автор: «Фәлан елда фәлан җирдә үзем күрдем», яисә «үзе күргән фәлан кешедән ишеттем,» — дип раслап та бара. Әмма мондый хәбәрләрнең төрле әкиятләр һәм хорафатлар белән үрелеп килүе Европа галимнәрен аптырашта калдыра. Шулай да Европаның «караңгы» чорын, ягъни IX—XIII гасырлар тарихын өйрәнүче галимнәр Әбү Хәмид язмаларына мөрәҗәгать итүдән туктамыйлар, ул сөйләгән хәбәрләрне башка чыганаклар белән чагыштырып карыйлар, шул юл белән чынны ялганнан аерырга тырышалар.

1925 елда ориенталист Г. Ферран «Төхфә...» не француз теленә тәрҗемә итә, сәяхәтнамәнең тәрҗемәсен һәм оригиналын тәфсилле аңлатмалар белән аерым китап итеп бастырып чыгара. Ләкин әл-Гарнатый тирәсендәге бәхәсләр һаман сүрелми. Ниһаять, 1950 елда испан галиме С. Дублер әл-Гарнатыйның «Әл-Мәгъриб ган бәгъзе гаҗаиб әл-Мәгъриб» (Мәгърибнең кайбер гаҗәп [хәлләре] хакында ачык сүз) дип аталган китабының кульязмасын таба һәм аның мөһим өлешләрен матбугатта бастырып чыгара. Бары шуннан соң гына Әбү Хәмидкә карата электән яшәп килгән мөнәсәбәтләр яхшы якка таба үзгәрә төшә.

Моңарчы фәндә мәгълүм булмаган бу китабында да әл-Гарнатый үзенең тормыш маҗаралары һәм сәфәрләре, төрле илләрдә күргән-ишеткәннәре хакында сөйли. Әмма, «Төхфә...» дән аермалы буларак, биредә төрле илләр һәм халыклар хакындагы мәгълүматлар аңлаешлырак, табигыйрак итеп бирелгән.

Шуңа күрә «Әл-Мәгъриб...» табылгач, әл-Гарнатый мирасы белән кызыксыну җитди фәнни төс алды. Соңгы ун-унбиш ел вакыт эчендә «Әл-Мәгъриб...» хакында дөньяның төрле телләрендә дистәдән артык яңа хезмәт язылды. 1971 елда совет галимнәре О. Г. Большаков һәм А. Л. Монгайт, әлегә истәлекнең иң мөһим өлеш-

ләрен русчага тәрҗемә итеп, текстка карата әтрафлы аңлатмалар язып, махсус китап чыгардылар.

Кем соң ул әл-Гарнатый? Кайчан, кайда туган, кайларда булган? Нишләп йөргән, нәрсәләр күргән?..

Әбү Хәмид Мөхәммәт ибне Габдерәхим әл-Гарнатый әл-Әндәлүси ерак Испаниянең (гарәпчә: Әндәлүс) Гренада (Гарната) шәһәрендә якынча 493 ел һиҗридә, ягъни 1099/1100 миладида дөньяга килә. (Кайбер версияләр буенча, аның туган елы 473 һиҗри ел диелә. Ләкин бу хата булса кирәк, чөнки гарәпчәдә «җиде, җитмеш» һәм «тугыз, туксан» сүзләренең язылышы үзара охшаш. Димәк, китап күчерүчеләрнең ялгышулары бик ихтимал.) Әл-Гарнатыйның бала чагы хакында төгәл мәгълүматлар юк. Күрәсең, ул үз чоры һәм мөхите өчен хас мөселманча тәрбия һәм белем алгандыр: беркадәре гарәп теле һәм әдәбиятын өйрәнеп, азмыкүпме дәрәҗәдә ислам дине законнарын үзләштергәндер.

Гыйлем эзләпме, сәүдә итепме, яисә ике эшне дә бергә кушыпмы, 17—18 яшьләр тирәсендә (1117—18 елларда) Урта диңгезнең икенче ягына — Мисырдагы Искәндәрия (Александрия) шәһәренә килеп чыга. Анда берәр ел торгач, Каһирәгә күчә. Сәяхәт вакытында Мальта, Сицилия утрауларында була. Этна вулканының шартлавын күрә. Кызыксынучан табигатьле егет зур игътибар белән яңа җирләрне күзәтә; борынгы Мисырның хәзер безгә килеп җитмәгән тарихи истәлекләре белән таныша. Мәсәлән, мәшһүр Фарос маягын, Гайнешшәместәге мәһабәт таш баганаһы (обелискны) барып карый, Хеопс пирамидасыны... Хеопс иһрамының (пирамидасының) эченә кереп йөри. Каһирә базарларында Африка һәм Азия илләреннән килгән сәүдәгәрләр белән сөйләшә, алардан ерак Кытай, серле Һиндстан турында сораша.

Мисырда бер-ике ел торгач, әл-Гарнатый тагы юлга чыга: Гаскалан, Бәгъләбәкк шәһәрләрен узып Димәшекъка барып җитә. Бераз вакыт анда хәдис гыйлемен укытып тора һәм 1122 ел тирәсендә Бәгъдадка күчеп килә. Монда ул дүрт ел чамасы яши һәм киләчәктә берничә хәлифәгә вәзир булачак Гаунетдин Ибне Һөбәйрә дигән кеше белән дуслаша. Бәгъдадта чакта әл-Гарнатыйның беренче улы Хәмид дөньяга килә (гарәпләрдәге гадәт буенча, моннан соң сәяхәтчегә «Әбү Хәмид», ягъни «Хәмиднең атасы» дигән өстәмә исем кушыла).

Озакламый Әбү Хәмид әл-Гарнатый яңә сәфәргә чыга: Әбһәр, Әрдәбил шәһәрләре аша, Муган чүлен, Апшерон ярымутравын кичеп, 1130 елда Дәрбәнд шәһәренә килеп җитә. Берәр ел Дагстанда яшәгәч, ул Иделнең түбән агымындагы Сәксин шәһәренә килеп чыга.

Сәксиндә әл-Гарнатый барлыгы 20 ел чамасы яши. Һәм менә шушында торган чагында берничә мәртәбә Болгарга, Харәземгә сәяхәт ясый. Әбү Хәмиднең Болгарга беренче сәяхәте 1135—36 еллар тирәсендә булырга тиеш, аның бу якларда бер җәй һәм бер кыш уздыруы бәхәссез. Ә 1150 елда исә Болгар җиреннән ул «урыс иленә» китә. Димәк, әл-Гарнатый рус җирләрен үз күзе белән күргән беренче шәрык сәяхәтчесе була. Иделдән Дунайга кадәр территориядә яшәгән халыкларның, җөмләдән бәҗнәкләрнең (печенегларның), тормышлары белән таныша-таныша, ул ерак Венгриягә барып чыга.

Венгриядә Әбү Хәмид өч ел чамасы тора. Картлык көннәре якынаюын сизеп, сәяхәтче хаҗ сәфәренә җыена. Ләкин ни өчендер Венгрия короле аны җибәрмәскә тырыша. Бары кире әйләнеп кайтырга вәгъдәләр биреп, улы Хәмидне дә калдырырга булгач кына, юлга чыгарга рөхсәт ала. Һәм тагы Киев, Сәксин, Харәзем җирләре аша узып, Гарәбстанга килә. Ләкин Мәккәдән әл-Гарнатый Сәксингә дә, Венгриягә дә кайтмый, бәлки Бәгъдадка юнәлә. Монда ул үзенең элекке дусты, хәлифә вәзире Ибне Һөбәйрә белән очраша.

Әл-Гарнатый, үзенең сәяхәтләре, күргән-белгәннәре, ишеткәннәре хакында сөйләп, Бәгъдад кешеләрен таңга калдыра. Яңа дуслары аңардан махсус китап язуын үтенәләр. Шуны күздә тотып, Әбү Хәмид болай ди: «Әгәр бу фазыйль (укымышлы, мәгърифәтле — Ә. Х.) имамнар миннән сорамасалар һәм шушы җыентыкны төзүемне үтенмәсәләр, мин бу җыентыкка тотынмаган да булыр идем, чөнки үземне каләм әһленнән санамыйм».

Шулай итеп, 55 яшьләр чамасындагы олы кеше, беренче мәртәбә кулына каләм алып, китап язарга тотына. Нәтиҗәдә «Әл-Мөгъриб...» дигән әсәр барлыкка килә. Әмма әл-Гарнатыйның бу китабы зур уңышка ирешмәгән булса кирәк. Ихтимал, аңардан автор үзе дә риза булмагандыр. Һәрхәлдә, 1162 елда, Маусил (Мосул) шәһәрендә торган чакта, сәяхәт материалларын яңадан эшкәртеп, истәлекләрен тулыландыра төшеп, ул «Төхфәтел-әлбаб...» исемле яңа бер китап яза. Бу әсәре инде авторга зур популярлык китерә: аның материалларыннан географлар, тарихчылар файдалана башлый. XIII—XVIII гасырларда гарәп һәм фарсы телләрендә язылган китапларда «Төхфә...»дән күчерелгән өзекләрне еш очратырга мөмкин...

Гомеренең соңгы елларында тынгысыз җанлы әл-Гарнатый Сүриягә күчә һәм 1169—70 елда Димәшекъ шәһәрендә дөньядан китә. Дөньяда исә ул язган китаплар һәм алар тирәсендәге бәхәсләр кала...

Журналның бу санында укучылар игътибарына «Әл-Мөгъриб...» китабының Идел буена, Болгар җиренә, гомумән, Көнчыгыш Европага караган өлешләре тәкъдим ителә. Истәлек турыдан-туры гарәпчә тексттан тәрҗемә ителде. Шуңа күрә иске атамалар, географик исемнәр гарәпчә оригиналга якын формада бирел-

де. Тәрҗемә иткәндә, аңлаешлылык артсын өчен, өстәмә сүзләр, гыйбарәләр кыстырырга туры килде (алар квадрат җәяләргә алынган). Әбү Хәмид язмаларында конкрет материалны яктыртуга, аңлауга кирәге булмаган, хәтта укучыга комачаулый торган лирик чигенешләр, искә төшерүләр шактый күп очрый. Андый урыннарны кыскартырга туры килде. Кыскартылган урыннарга күп нокталар куелды.

ӘНӘС ХАЛИД,
филология фәннәре кандидаты.

## Мәгърибнең кайбер гаҗәп хәлләре хакында ачык сүз

### ӘСӘРДӘН ӨЗЕКЛӘР

[Дәрбәндтән] диңгез аркылы хазарлар иленә юнәлдем. Бер зур елгага җиттем; ул Диҗләдән берничә мәртәбә киңрәк, гүяки ул үзеннән зур елгалар агып чыга торган бер диңгез [1]. Елга буенда бер шәһәр бар, Сәҗсин дип атала [2]. Шунда кырык гузз кабиләсе бар [3]. Һәрбер кабиләнең әмире үзенә [аерым]. Аларның йортлары иркен, йорт саен киң гөмбәзгә охшаган зур киез өй, йөзләп һәм артыграк кеше сыярлык [4]. Ул шәһәрдә төрле халыктан [булган] сәүдәгәрләр, ят кешеләр, Мәгърибтән килгән гарәпләр [5] [бар] — меңәрләп, санап бетергесез! Анда хазарлар җомга намазын кыла торган мәчетләр бар. Ул хазарлар да төрле нәселдән гыйбарәт. Шәһәрнең уртасында болгардан чыккан халыкның әмире тора; боларның җомга намазы кыла торган [аерым] зур мәчетләре бар. Бу мәчетнең тирәсендә төрле болгар нәселләре [урнашкан]. Тагын бер мәчет бар, анда Сувар халкы дип аталучылар [намаз кыла]. Аларның да саны күп. Бәйрәм көнне күп мимбәрләр чыгарып куялар, һәм һәрбер әмир күп халыклар белән намаз кыла. Һәр халыкның үзенең казыйлары, фәкыйһлары, хатыйблары бар, бөтенесе Әбү Хәнифә мәзһәбендә. Тик Мәгъриб кешеләре Малик мәзһәбендә, ят кешеләр Шафигый мәзһәбендә. Минем йортым хәзер менә бу соңгылар арасында, шунда бала аналары [6], улларым һәм кызларым [тора].

Бу ил бик салкын. Ә бу елгада дөньяда мин күрмәгән төрле балыклар бар, кайберсен көчле ирләр генә күтәрә алырлык, кайберләре таза дөягә йөк булырлык; арасында вaклары да бар. Ул балык кылчыксыз, [аның] башында да сөяк булмый, теше дә юк аның, әйтерсең лә эченә тавык ите тутырган куй койрыгы ул, ә үзе симез куй итеннән дә яхшырак һәм тәмлерәк. Бу балыкны эченә дөге салып пешерәләр, ул симез куй итеннән дә, тавык итеннән дә тәмлерәк була. Йөз мән [7] тарткан бер балыкны яртыданыкка [8] алып була; ә үзеннән шәмгә бер ай ягарлык май чыга; эченнән ярты мән, хәтта аннан да артыграк балык җилеме чыга. Ул балыкны каклыйлар, һәм какланган нәрсәләрнең дөньяда иң яхшысы шул була: саф кызыл гәрәбә төсендә. Аны шул килеш икмәк белән ашыйлар, пешерергә дә, кыздырырга да кирәкмәс.

Алар (Болгар халкы — Ә. Х.) арасында ак кургаш йөри, Бәгъдад мәне белән сигез мәнгә бер динар [9]; ак кургашны кисәклиләр дә шуңа теләгән нәрсәләрен сатып алалар, җимеш булсынмы, икмәкме, итме. Ит аларда арзан, хәтта кафирләр ягыннан кәрваннар килгән чакта бер сарыкны ярты данықка, бәрәнне бер тәссуҗгә [10] алып

---

[1] Әл-Гарнатыйның «Төхфә...» исемле әсәрендә бу елга Итил (Әтил) дип атала һәм Болгардан югарырак Караңгылык ягыннан (төньяктан) агып чыга дип әйтелә; ул Бәгъдад аркылы ага торган Диҗләдән (Тигрдан) 100 мәртәбә киңрәк, дип тә өсти.

[2] Сәҗсин (Сәксин, Сәхсин, Саксин) — Идел тамагындагы зур шәһәр. Монгол-татар һөҗүменнән соң ул я юкка чыккан, я Сарай-Бәркә шәһәренә әверелгән дип уйланыла; аның урынын археологлар әле дә төгәл билгели алмадылар. «Төхфә...»дә хәбәр ителгәнчә, Гарнатый Сәксин шәһәренә 525(1130—31) елда килгән.

[3] Гузз — угуз кабиләләренең гарәпчә исеме; бу кавем чынбарлыкта 24 кабиләгә бүленгән. Димәк, кырык саны я ялгыш, яисә түгәрәкләп алынган.

[4] «Йорт» сүзе гарәпчә — «дар», ә «өй» исә «бәйт» мәгънәсендә алынды. «Дар» төшенчәсенә, гадәттә, кеше яши торган өй һәм аның әйләнә-тирәсе, ишегалды керә.

[5] Көнбатыш кешеләре дип аңларга да мөмкин.

[6] Сүз үз хуҗасыннан бала тапкан кол хатыннар турында бара. Мондый хатыннарның хәле башка колларга караганда җиңелрәк булган — хуҗалары үлгәч, алар азат ителгәннәр.

[7] Мән (дөресрәге, мәнн) — 812,5 грамм чамасы авырлык үлчәме.

[8] Данык — вак акча исеме, динарның алтыдан бер өлеше.

[9] Динар — алтын акча, үлчәве 1 мыскал яки 4,235 грамм чамасы.

[10] Тәссүҗ — данықтан да ваграк (аның дүрттән бере) акча берәмлеге.



150

була. Аларда шундый күп төрле җимешләр бар ки, [андагыдан да] күбрәкне таба алмассың. Кавынның гаять тә тәмлесе бар, ә бер төрле кавынны кыш көне дә саклап була.

Кыш аларда бик салкын, аларның кышкы өйләре нарат агачыннан: берсе өстенә берсе куелган зур бүрәнәләрдән [гыйбарәт зур өйләр], түшәмнәре һәм түбәләре дә агач тактадан. Алар [өйләрендә] ут ягалар, өй ишекләре кечкенә, йонлы сарык тиреләре белән ябылып куела, ә өй эчендә җылы, мунчадагы кебек; утын күп аларда.

Ул елга [кышларын] катып җир кебек була, аның өстеннән атлар, бозаулар көтү-көтү булып йөри алалар. Алар боз өстендә сугышалар да. Туңып каткан чакта мин ул елганы аркылыга чыгып карадым: киңлеге, үзеннән агып чыккан тармаклардан башка, минем адымнар белән бер мең дә сигез йөз кырык адымнан артык булды.

Бу дәрья тирәсендә җеннәр Сөләйманга [11] мең елга пәйда кылганнар, һәрберсенең микъдары бер мил [12]. Елга ярына алар казып чыгарган туфрак [киңлеге] аткан ук очарлык тау төсле булып өелгән. Аның янәшәсендә нәкъ шундый ук мең тау һәм мең елга булган. Ул елгалар тирән, теге елгадан аларга су кереп тула һәм шунда туфрак-тузан кебек [күп] булып балык үрчи. Нинди генә кораб бу елгаларның берсенә килмәсен, елга тамагында җәтмә сала; кораблар килеп тора, [балыкка] тулып тора. Кораблар йөзәрләп булсалар да, бер генә елгадан [тотылган] төрле балык белән дә тулырлар, ә елгалар [үзләре] һич ярлыланмас иде. Моның төсле башка [бер җирдә дә] булмас!

Бу елгалар һәм таулардан ары күп көнлек юлга сузылган җир ята, бөтенесе кызыл, ак, күк һәм башка төсле тоздан [13] гыйбарәт. Корабларга төяп тозны елга буенча Болгарга ташыйлар. Сәҗсин белән Болгар арасы су буйлап кырык көнлек [юл].

Болгар да зур кала, бөтенләе белән нарат агачыннан салынган; каланың коймасы исә имәннән. Аның тирә-ягындагы халыкларның иге-чиге юк, алар инде җиде икълимгә кермиләр [14]. Көн озайгач, аның озынлыгы егерме сәгать була, ә төн дүрт сәгать. Кыш булгач төн егерме сәгатькә сузыла, ә көн дүрт сәгатькә [кала]. Җәйге көннең уртасында аларда бик каты, дөньядагы иң каты кызу була, ә кичен һәм төнлә һава суына ,хәтта күп кием кирәк була. Мин җәй көнне рамазан аенда ураза тоткан идем, тик боздым; [эсседән] өй астындагы җирдә су саркып тора торган базына кереп утырдым. Ә кышын салкын шул кадәре көчле була, хәтта агачлар каты суыктан шартлап ярыла [15].

Патша шул каты салкыннар вакытында кафирләргә каршы сугышка бара һәм аларның хатын-кызларын, бала-чагаларын һәм атларын әсир итеп ала. Болгар кешеләре салкынга иң түземле халык, чөнки [аларның] ашаган-эчкәннәре, күбесенчә, балдан гыйбарәт, һәм бал аларда арзан.

Болгар җирендә Гад кавыменең [16] сөякләре табыла; бер тешенең генә иңе — ике карыш, буе — дүрт карыш, башы белән җилкә арасы — биш колач, ә баш [үзе] зур гөмбәз төсле; андый [сөякләр] анда күп. Җир астында фил тешләре табыла: үзләре кар кебек ак, кургаш кебек авыр, бер данәсе артыгы-киме белән ике йөз мән чамасы була; аларның нинди хайваннан каерып алынган булуын белмиләр. Аны Харәзем һәм Хорасанга илтәләр. Аңардан тараклар, тартмалар һәм башка әйберләр ясыйлар, нәкъ фил тешеннән ясаган кебек, тик ул фил тешеннән ныграк — бер дә сынмый.

Бу илдән арырак исәпсез-сансыз халыклар [яши], алар Болгар патшасына җизия [17] түлиләр. «Болгар»ның мәгънәсе — белемле кеше. Болай булган бу: аларга Бохара-

---

[11] Борынгы дини китапларда (Библия, Коръән) телгә алынган Сөләйман (Соломон) бик акыллы һәм хәйләкәр, хәтта җеннәрне дә үзенә буйсындырган патша итеп тасвирлана.

[12] Урта гасырларда гарәп-мөселман илләрендә кулланылган мил яки мең «төрсәк»кә тигез булган (1800—2000 метр чамасы).

[13] Гарәпчәсендә «тоз» урынына ялгыш «кар» дип язылган.

[14] Борынгы греклар һәм гарәпләр җир йөзенең адәм баласы урнашкан өлешен көнбатыштан көнчыгышка сузылган җиде икълимгә, ягъни климатка бүлгәннәр.

[15] «Төхфә...» исемле әсәрендә Болгарда кышкы салкыннар вакытында җир тимер кебек ката диелгән.

[16] «Гад» исемле алыплар кабиләсе яисә халкы турындагы әкият (легенда) гарәп-фарсы әдәбиятында бик киң таралган; алыпларның каберләре яки сөякләре төрле җирдә «табыла» дигән хәбәрләр бик күп китапларда очрый.

[17] Җизия — җан башыннан алына торган түләү; гадәттә, мөселман феодалларына буйсынган, әмма исламга кермәгән халыклардан алынган.

дан[18] бер мөселман сәүдәгәре барган; ул дәвалауга оста фәкыйһ (шәригать белгече — Ә. Х.) булган. Патша хатыны чирле икән, патша үзе дә бик каты авырган; икесе дә үзләренә мәгълүм дарулар белән дәваланганнар, ләкин авырулары көчәйгәннән-көчәеп, үлем хәленә җиткәннәр. Аларга әлеге мөселман: «Әгәр дә мин сезне дәваласам һәм сезгә җиңеллек булса, минем динемә керерсезме?» — дип әйткән. «Әйе»,— дигәннәр тегеләр. Ул аларны дәвалаган, тегеләр савыкканнар һәм ислам динен кабул иткәннәр, илнең халкы да исламга кергән. Хазар патшасы зур гаскәр белән килеп, боларга каршы сугыш ачкан һәм әйткән: «Минем әмрем булмыйча нигә бу дингә кердегез»? Теге мөселман болай дигән: «Курыкмагыз, тәкбир әйтегез!» Болгарлылар: «Аллаһе әкбәр, аллаһе әкбәр, аллаһе әкбәр, әлхәмделилла, я алла, Мөхәммәткә һәм Мөхәммәтнең өммәтенә салават кыл!» — дип кычкырганнар һәм, теге патшага каршы сугышып, аның гаскәрен җиңгәннәр. Патша болар белән солых кылган һәм диннәренә кергән дә болай дип әйткән: «Күреп тордым: соры атка атланган алып ирләр минем дә юлдашларымны үтерде һәм мине качарга мәҗбүр итте». Теге фәкыйһ: «Ул ирләр куәтле алла гаскәрләре», — дип җавап биргән.

Галим кеше аларда «беләр» дип атала, шуның өчен аларның иле «Беләр», ягъни «галим кеше» дип аталган. Ул сүзне гарәпчәләп «Болгар» дип әйткәннәр[19].

Моны мин Болгар казые кулы белән язылган «Болгар тарихы»нда укыдым[20], ә ул Әбулмәгали Җувәйнинең (аңарга алланың рәхмәте төшсен!) шәкертләреннән иде[21].

Аның [Болгарның] хәраҗ[22] түләүче бер өлкәсе бар, Вису дип атала, аралары бер айлык юл. Тагын да бер Ару дип атала торган өлкәсе бар, анда кондыз, ас һәм әйбәт тиен аулыйлар. Җәй вакытында анда көн егерме ике сәгать була. Ул яктан бик шәп кондыз тиреләрен китерәләр. Кондыз гаҗәеп бер җәнлек, ул зур елгаларда була, ә йортны елга буенда ярда кора. Үзе өчен бер биек сәке төсле [урын] ясый, уң ягыннан бер басма түбәнрәк хатыны өчен, ә сул ягыннан балалары өчен ясый. Шул йортның идәнендә кондызның коллары өчен урын була. Йортның бер ишеге елгага, өстәрәк [ясалган] икенчесе ярга чыга. Кондыз кайвакыт хәләнҗ[23] агачын кимерә, кайвакыт балык ашый. Алар бер-берсен аулыйлар һәм әсир кылалар. Ул илләрдә һәм Болгарда сәүдәгәрләр кол кондызның тиресен таныйлар, чөнки хезмәтче кондыз хәләнҗ агачын кисә һәм авызы белән хуҗасына ташый. Кискәндә хезмәтче ике яны белән агачка ышкына һәм аның уң ягыннан да, сул ягыннан да йоны коелган була. Шуңа күрә: «Бу — кондызның хезмәтчесе», диләр. Хуҗа булган кондызның тиресендә бернинди дә эз булмый...

Вису артында Йура дип аталган бер ил бар; ул Караңгылык диңгезе буенда. Җәй [көннәрендә] аларда көн бик озын була, хәтта, сәүдәгәрләрнең әйтүенә караганда, кояш кырыгар көн баемый икән; кышын исә төн шул кадәр үк озын була диләр. Сәүдәгәрләр аларга «Караңгылык» якын дип сөйли. Имеш, Йура халкы шул Караңгылыкка бара да, ут кабызып [аның] эченә керә... Алар үзләре белән төрле әйберләр китерәләр һәм һәрбер сәүдәгәр үз малын аерым куя, аңа билге сала, аннары кайтып китә. Соңрак яңадан бара һәм үз илләрендә кирәк булган әйберләрне таба. Һәр кеше үз товары янында бераз тегеләрнең әйберләрен таба, риза булса, ул аларны ала, кире какса, үз әйберен алып тегеләрен калдыра. Алдашу юк. Теге әйберләрне кемнән алмашып алганнарын алар белмиләр.

[Сәүдә итүче] кешеләр ислам илләреннән, Зәнҗан, Әбһәр, Тәбриз һәм Исфаһанда эшләнгән кылычларны алып киләләр, тик уттан чыккан тимер килеш кенә, сап яки бизәү ясамыйлар. Ул кылычларны бик каты чыныктыралар, әгәр кылычны җепкә асып куеп, тырнак белән чиертсәң, яки берәр тимер я агач нәрсә белән суксаң, аның чыңлаганы бик озак ишетелеп тора. Йурага нәкъ менә шундый кылычлар кирәк

[18] Гарәпчә кулъязмада бу сүз ялгыш «Тохара» дип язылган. С. Дублер аны «төҗҗар» (сәүдәгәрләр) дип укыган. О. Большаков исә «Бохара» дип төзәтә.

[19] Биләр һәм Болгар шәһәрләренең исемнәрен «белү» тамырыннан чыгару «халык этимологиясе» нәтиҗәсе икәнлеге бәхәссез. Ләкин мондый примитив аңлату башка авторларда да очрый.

[20] Гарнатыйның «Төхфә...» исемле әсәрендә Болгарда үзе күреп сөйләшкән казый Ягкуб ибне Ногман телгә алына. «Мөгъриб»тә исә Болгар казыеның әсәре генә атала. Ике әсәрдә дә сүз бер үк кеше турында барса кирәк.

[21] Әбулмәгали Гәбделмәлик әл-Җувәйни (1028—1085) — Урта Азиянең дин һәм шәригать галимнәреннән. Гарәпчәдә «сахип» сүзе алынган, аны «юлдашы» яки «иярчене» дип аңларга да мөмкин.

[22] Хәраҗ — җир башыннан алына торган түләү, салым.

[23] «Хәләнҗ»не күпчелек галимнәр каен агачы дип аңлаталар.

икән[24]! Йура халкында сугышлар булмый, атланып йөрерлек яки йөк ташырлык маллар да юк, тик зур агачлар һәм балга бай урманнар гына була. Аларда кеш бик күп була, аның итен дә ашыйлар. Сәүдәгәрләр аларга әлеге кылычларны, сыер һәм сарык сөякләрен китерәләр һәм бәһаләренә [карап] кеш тиреләре алалар, шуннан зур төшем табалар.

Алар тарафына [илтә торган] юл бер вакытта да кары бетми торган җирләрдән [үтә], шуңа күрә кешеләр аякларына юнган такта бәйләп [йөриләр]. Һәр тактаның буе бер колач, киңлеге бер карыш. Ул тактаның алды һәм арты җирдән бераз күтәрелеп тора, уртасында исә йөрүчегә аяк куя торган урын була, шундагы тишекләргә аякка бәйли торган нык каеш баулар беркетелә. Аякта булган такталар берберенә ат тезгене кебек озын каеш [баулар] белән тоташтырылган, шуны ул [кеше] сул кулына тота, ә уң кулында — кеше буе озынлыгындагы таяк [була]. Таякның очында тукымадан ясалган, [эченә] күп җон тутырылган адәм башы кадәре җиңел шар сыман әйбер була. Шул таяк белән карга таяналар да таякны артта калдырып этеннәләр, нәкъ көймәдә баручы диңгезчеләр кебек. Кар өстеннән шулай тиз генә баралар[25]. Әгәр дә шул хәйлә булмаса, анда бер кем дә йөри алмас иде, чөнки кар җир өстендә ком төсле [ята], бер дә катмый. Нинди генә хайван аннан үтмәсен, шунда бата да үлә, бары эт һәм төлке-куян төсле җәнлекләр [генә] анда җиңел һәм тиз йөри алалар. Бу илдәге төлкеләр һәм куяннарның җоннары агара, хәтта мамык төсенә керә; бүреләр дә шулай ук агаралар. Болгар илендә аларның тиреләре кыш көннәрен агара.

Әлеге ислам илләреннән Болгарга китерелә торган кылычлар күп төшем бирәләр. Болгарлылар аларны Висуга, кондыз яшәгән җиргә илтәләр; аннары Вису кешеләре аларны Йурага илтеп кеш тиресенә, кыз һәм ир колларга алмашалар. Анда яшәүче һәрбер кеше ел саен кылычка мохтаҗ — [ул] Караңгылык диңгезенә ташлар өчен [кирәк].

Алар кылычларны ыргыткач, алла [үзләренә] диңгездән тау хәтле зур балык чыгара; аны йотарга теләп үзеннән ничә тапкырга зуррак икенче бер балык куып килгән була. [Балыкның] кечерәге зурысыннан качып ярга якынлаша һәм диңгезгә кире кайта алмаслык урынга эләгә дә шунда кала. Ә зуррак балык кечерәген эләктерә алмый һәм кире диңгезгә кайта. Йура кешеләре көймә белән диңгезгә керәләр дә әлеге балыкның яннарыннан [ит] кисеп алалар, ә тегесе бер нәрсә дә сизми һәм селкенми. [Кешеләр] өйләрен [балык] ите белән тутыралар. Аның өстенә менеп карыйлар, ә теге зур тау кебек. Болар ит кискән чакта балык шунда ята бирә; диңгезгә кылыч ташлаган һәр кеше үзенә тиеш хәтле өлеш ала...

Болгарда миңа сөйләгәннәр иде, ничектер бер елны шундый балыкның колагын тишкәннәр дә җеп тагып тарткансар икән. Балыкның колагы ачылып [киткән дә], эченнән адәм затына охшаган бер кыз килеп чыккан, имеш: ап-ак [тәнле], алсу битле, кап-кара чәчле, киң янбашлы — хатын-кызның бик матуры. Йура кешеләре аны җиргә тартып чыгарганнар, ә теге сурәт үз яңакларына сугарга, чәчләрен йолкырга һәм кычкырырга тотынган, имеш. Аллаһе тәгалә исә аның гәүдәсе уртасында, [ягъни] биленнән тезләренә хәтле гаурәтен каплап тора торган ак тире кебек нәрсә ясаган; нык таза тукымага охшаган ул, нәкъ билгә бәйләп гаурәтне каплый торган изар төсле[26]. Аны үлгәнче асрап торганнар. Аллаһе тәгаләнең кодрәтенә һич тә чик юк!

Сөйләүләренә караганда, Йура халкы диңгезгә әлеге кылычларны ыргытып тормаса, балык чыкмый һәм алар ачлыктан һәлак булачак икән.

Вису һәм Йура халкына җәй вакытларында Болгар иленә килү тыела, чөнки, әгәр аларның берсе генә шул илгә кызу вакытта килсә, һава һәм су кыштагы сыман салкыная, халыкның игеннәре бозыла. Бу — аларда сыналган эш.

Мин кыш көнендә Болгарда аларның бер төркемен күргән идем: төсләре алсу, күзләре зәңгәр, чәчләре киндер төсле ак, бик салкында да алар киндер кием кияләр. Кайберләренең өстендә йоны тышка каратылган кондыз тиресеннән шәп тун

[24] Күптән түгел Урал тауларының төньягында нәкъ әл-Гарнатый тасвирлаган шикелле кылыч табылды («Наука и жизнь» журналы, 1970 ел, 10 сан, 15—17 битләр). Андый кылычларны, мөгаен, гарпун урынына кулланганнардыр.

[25] Чаңгылар турында әл-Гарнатыйдан элекке авторлар да сөйли, ләкин безнең сәяхәтче бик җентекләп, чынбарлыкка якын итеп тасвирлый.

[26] Изар — сөлге-тастымал кебек озын һәм киң билбау, кайчакта тезгә хәтле җитә.

була. Эчкән нәрсәләре серкә кебек әчы арпа суы була, мизаҗлары[27] кызу булганга күрә, аларга ул килешә, чөнки алар кондыз, тиен ите һәм бал ашыйлар.

Алар илендә эре кошның бер төрлесе була, озын томшыклы. Томшык очлары уңга һәм сулга карап тора: өскесе уңга алты карышка, [аскысы] сулга алты карышка [сузылган], нәкъ менә ләм-әлиф сурәтендә; ашаганда яки эчкәндә ул кош авызын ябып эш итә икән. Ул кошның ите бөер һәм сидек куыгы ташыннан файдалы була. Болгарга аны [кошның итен] турап киптергән хәлдә китерәләр. Әгәр ул кошның йомыркасы бозга яки кар өстенә төшсә, ут эреткән кебек, аны эретә, тик җирдә яки агачта гына тора ала[28].

Саклаблар иленә юнәлгән чакта мин Болгардан чыктым да саклаблар елгасында[29] корабка утырдым. Аның суы кара, Караңгылык диңгезе суы кебек, [яки] язу карасы төсле; алай да үзе тәмле, яхшы, саф. Анда балык юк, әмма берсе өстендә берсе [яткан] зур кара еланнар балыктан да күп, [тик] беркемгә дә зарар итмиләр. Анда тиресе кара төстә кечкенә мәче кебек бер җәнлек бар, «су кеше» дип атала ул[30]; аның тиресе Болгарга һәм Сәҗсингә китерелә. Ул теге елгада яши. Аларның [саклабларның] илләренә җиткәч, күрдем ки, илләре иркен икән; балга, бодайга, арпага, тиңе булмаган эре алмага бай икән. Көн күрүе аларда [бик] арзан.

Үзара сату-алуда иске, йонсыз, бөтенләй файдаланырлык булмаган, [ягъни] бернигә дә яраксыз тиен тиреләре белән эш итәләр. Тиен тиресенең башында һәм алгы аякларында йоны калган булса, алар исәбе буенча һәр унсигезе бер көмеш дирһәм тора; [ул тиреләр] бәйләмгә бәйләнелә һәм «җукн»[31] дип атала. Шундый тиреләрнең берсенә олы таза кешегә җитәрлек һәйбәт түгәрәк икмәк бирәләр. Шуларга бөтен нәрсәне дә алып була: ир һәм хатын коллар, алтын, көмеш, кондыз яки башка товарлар. Әгәр дә ул тиреләр берәр башка илдә булса, аларның мең йөгенә дә бер хәббәгә[32] алмаслар иде, бер нигә дә ярамыйлар бит! [Тота-тота] бозылгач һәм ертылгач, ул тиреләрне капчыкларга салып бер билгеле базарга илтәләр. Анда яннарында хезмәтчеләре булган кешеләр бар, менә шулар алдына [әлеге] тиреләрне китерәләр. Унсигезәр тирене бер бәйләм итеп, хезмәтчеләр аларны нык җепкә тезәләр. Җепнең очына кара кургаш кисәген беркетәләр дә шуңа патша сурәте булган мөһер сугалар. Һәр мөһер өчен бер тире алалар; барысын да мөһерләп бетергәнче [шулай эшлиләр]. Бер кем дә [мондый] тиреләрне кире кага алмый; шулар белән саталар да, алалар да.

Саклабларның хөкемнәре каты. Әгәр дә берәү башка кешенең кол хатынына, баласына, хайванына тисә яки берәр төрле зыян китерсә, аңардан беркадәре мал алалар. Малы булмаса, шул җинаять өчен, аның ир яки кыз балаларын, хатынын саталар. Әгәр аның гаиләсе һәм балалары булмаса, үзен саталар, һәм ул шулай кол булып кала — кемгә бирелгән, шуңарга үлгәнче хезмәт итә, яки түләргә тиеш булганны бирә. Хуҗасына хезмәт итүе бер дә түләү хакына саналмый. Илләре ышанычлы. Әгәр дә мөселман кешесе аларның берәрсе белән эш итсә, һәм теге саклаб бөлсә, аның үзен, балаларын һәм йортын саталар да, әлеге сәүдәгәргә бурычын түлиләр.

Саклаблар батырлар, алар нестори христиан динендә, румнар мәзһәбендә[33].

Аларның әйләнә-тирәсендә агачлар арасында яши торган бер халык [өммәт][34] бар, сакалларын кыралар; алар зур елга буенда [торалар], шул елгада кондыз аулыйлар. Миңа сөйләгәннәренә караганда, аларда һәр ун ел саен сихер күбәя, имеш, һәм сихерче карчыклар хатын-кызларны бозалар икән. Шуңа күрә алар илләрендәге карчыкларны тоталар да кул-аякларын бәйләп суга ташлыйлар икән. Суга баткан

---

[27] Мизаҗ — темперамент.

[28] Бу урында сүз урман кошларыннан чукыр (клест) турында барса кирәк: ул балаларын кышкы салкыннарда чыгара, шуңа күрә әл-Гарнатыйның кошның йомыркасы карны эретә дигән сүзләрне ишеткән булуы бик ихтимал.

[29] Гарәпләр төньяктагы ак тәнле халыкларны (мәсәлән, славяннар, угро-финнар һәм кайбер төрки кабиләләрне) «саклаб» дигән җыйма исем белән атаганнар; «Саклаблар елгасы»н Ока суы дип аңларга мөмкин.

[30] Сүз, һичшиксез, кама җәнлеге турында бара.

[31] Бу сүзнең тамыры билгеле түгел. «Гривна» һәм «куна» дигән рус сүзләре белән якынлаштырып караучылар да бар.

[32] Хәббә — «бөртек», иң вак үлчәү берәмлеге, яки дирһәмнең алтмыштан бер өлеше.

[33] Византия һәм русларның православиеләрен әл-Гарнатый ялгыш несторианлыктан аерылмаган мәзһәб дип ала.

[34] Төрле чит илләр һәм халыклар турында язганда, әл-Гарнатый еш кына «өммәт» сүзен куллана, аны бер генә сүз белән тәрҗемә итүе яки аңлатуы кыен.

карчыкны, сихерче түгеллеген белеп, [исән] калдыралар, су өстенә калкып йөргәнен утта яндыралар икән [35].

Алар арасында кәрван белән озак вакыт торган идем, илләре ышанычлы, Болгарга хәраҗ түлиләр. Аларда дин юк, бер төрле агачка табыналар һәм аңарга сәҗдә кылалар. Бу [соңгы] хәбәрне аларның хәлләрен белүчедән ишеттем.

Саклаблар [илендәге] шәһәргә киттем, ул «гур[од] Куйав» дип атала. Анда мәгърибләр [36] меңләп, төрки кыяфәтле, төркичә сөйләшәләр, төркиләр кебек ук аталар. Ул илдә алар «бәҗн[әк]» дип аталалар. Шундагы мөселманнарның [кызына] өйләнгән бер Багъдад кешесен очраттым, исеме — Габделкәрим ибне Фәйруз әл-Җәуһәри. Шушы мөселманнарга җомга намазын укыттым һәм хөтбә өйрәттем; элек алар җомга намазын белмәгәннәр икән.

Алар арасында кайбер укыган иптәшләрем торып калды; ә мин башкортлар [37] янына киттем, саклаблар иленнән арырак егерме көнлек юл исәпсез-сансыз кафир халыклар аркылы [үтә]; алар биек агачлык һәм бакчалар арасында торалар, андый куакларны дөньяда күргәнем юк иде, үзләре җимешсез...

Ункуриййә [ягъни Венгрия — Ә. Х.] иленә киттем, анда башкорт атлы халык [яши]; ул — төрки илләрдә иң беренче булып ифрәнҗ [38] җиренә килгән ил. Алар батырлар һәм санап бетергесезләр. Ункуриййә дип аталган илләре җитмеш сигез шәһәрдән гыйбарәт; һәр шәһәрнең ныгытмалары, авыл-тирәләре, таулары, урманнары һәм бакчалары күп. Мәгърибләр анда меңләп — санап бетергесез; Харәзем кешеләре [мондагы] патшаларга хезмәт итәләр, [тыштан] христианлык күрсәтәләр, чынлыкта мөселманлык тоталар; мәгърибләр исә христианнарга сугышларда гына хезмәт итәләр, һәм алар ислам динен ачыктан-ачык тоталар.

Мәгърибләр арасына кергәч, алар миңа ихтирам күрсәттеләр, ә мин аларга бераз гыйлем укыттым, кайберәүләрен гарәпчә сөйләшергә өйрәттем. Фарыз булган намазларны һәм башка догаларны алар белән бергә тырышып кат-кат укыдым һәм такрарладым. Кыска гына итеп аларга хаҗ кылу һәм мирас [бүлү] гыйлемнәрен аңлаттым, хәтта алар [мөселманча] мирас бүлә башладылар...

Алар җомганы белмәгәннәр, җомга намазы һәм хөтбә белән таныштылар. Мин аларга пәйгамбәр: «Җомга — ярлылар хаҗы, кем хаҗга бара алмаса, шулай да җомгага йөрсә, аңарга хаҗ савабы язылачак», дигән дип әйттем. Аларда хәзер ун меңнән артык җирдә җомга көннәрендә ачык яки яшерен [рәвештә] хөтбә укыйлар, чөнки мәмләкәтләре [бик] зур.

Мин алар арасында өч ел торып, дүрт кенә шәһәрләрендә була алдым. Ул ил — бөек Румиййәдән Кыйстантиниййә (ягъни Константинополь шәһәре — Ә. Х.) чигенә хәтле. Анда алтын һәм көмеш чыгарыла торган таулар бар. Ул ил — иң бай һәм ниг্যмәтле илләрнең берсе. Егерме сарык бер динар тора, бәрән һәм кәҗәләрнең утызы бер динар, балның биш йөз кадагы бер динар, матур кыз — ун динар, ә рум егете [39]...

Бер атасы, анасы һәм абзалары исән булган мулат [40] кызын хуҗасыннан ун динарга сатып алган идем; үзе унбиш яшендә, туган айдан да яктырак, кара чәчле, кара күзле, камфора төсле ап-ак, аш пешерергә, тегү тегәргә һәм санарга белә иде. Тагын бер сигез яшьлек рум кызын биш динарга сатып алган идем. Көннәрнең берендә мин ярты динарга ике чүлмәк кәрәзле бал алдым, һәм ул кызга: «Бу балны балавызын аерып чистартырга кирәк», — дидем дә, кеше җыела торган капка алдындагы сөффәгә чыктым. Бераз кешеләр белән утырып өйгә кергәч, алтын кебек биш түгәрәк балавыз һәм роза суы төсле сыек бал тутырган зур чүлмәк күрдем — бер сәгать эчендә бал чистартып чүлмәккә салынган иде. Аңардан бер бала туган иде дә үлде. Мин аны азат иттем дә үзенә Мәрьям дип исем куштым. Аны үзем белән

[35] А. Л. Монгайт бу өзек мордваларга карый дип уйлый, ләкин карчыкларны су белән сынау гадәтенең борынгы урыс (славян) кабиләләрендә дә таралганлыгын күрсәтеп уза.

[36] Киевтә яшәүче «мәгрибләр» көтелмәгәндә төрки халкы, ягъни бәҗнәкләр (печенеглар) булып чыкты. Югарыда язылганча, Сәксиндә, алга таба — Венгриядә дә «мәгрибләр» яшәгәнлеген беләбез, боларны да бәҗнәкләр дип уйларга туры килә. Гомумән, «мәгърибләр» сүзенең мәгънәсе бик үк ачык түгел.

[37] Монда сүз Урал башкортлары хакында түгел, бәлки Көнчыгыш Европадагы венгрлар яки кайбер төрки кабиләләр хакында бара.

[38] Ифрәнҗ («франк»тан алынган) — гомумән Европа халыклары.

[39] Бу урында текст өзелгән.

[40] Мулат — гарәпчә «мәвәлләд» сүзеннән үзгәртелеп башка телләргә кергән сүз; атасы һәм анасы төрле җенестән (ягъни халыктан, диннән, кабиләдән һ. б.) булган балаларны аңлата. Галәттә исламга яңа гына кергән кешеләрнең балаларын шулай атаганнар.

Сәҗсингә алып китәргә бик теләгән идем, әмма Сәҗсиндәге балаларымның аналары булган төрки хатыннарымнан аңарга [зарар булуыннан] курыктым.

Башкортларның патшасы һаман Рум илен баса[41]. Ул мөселманнарга мин: «Бу патша ягында тырышып сугышыгыз, аның өчен үзегезгә җиһад сәвабы[42] булыр»,— дидем, [һәм алар] аның белән Кыйстантинийә иленә киттеләр. Рум патшасының үнике армия гаскәрен җиңделәр һәм бер төркем Конийә гаскәре терекмәннәрен алып кайттылар. Мин болардан: «Ни өчен Рум патшасы гаскәренә кердегез?» — дип сорадым. «Һәрберебезне ике йөз динарга яллады, ә бу җирдә мөселманнар булганын белмәдек»,— диделәр. Мин аларны, Конийәгә кайтсыннар дип, Рум иленә чыгарып җибәрдем.

Кыйстантинийәнең хуҗасы солых эзләп килде, күп акча өләште һәм әсир булган күп мөселманнарны кайтарды. Румда әсир булган мөселманнарның берсе миңа [түбәндәгеләрне] сөйләгән иде. Рум патшасы: «Ни сәбәптән башкорт патшасы минем илемне яулый һәм харап кыла, элек андый гадәте юк иде?» — дип сораган. Аңа: «Башкорт патшасының гаскәре ачык ислам тотучы мөселманнардан гыйбарәт, әнә шулар аны синең мәмләкәтеңә каршы алып киләләр һәм илеңне харап итәләр»,— дип әйткәннәр. Рум патшасы: «Миндәге мөселманнар мине яклап сугышмыйлар бит»,— дигән. Аңа: «Син аларны христиан диненә мәҗбүрлисең»,— дигәч, теге: «Бер генә мөселманны да үз динемә [керергә] мәҗбүр иткәнем юк, [киресенчә] минем якта сугышсыннар өчен аларга мәчетләр салам»,— дип җавап биргән.

Башкорт патшасы «кәрали» (король — Ә. Х.) дип атала, мәмләкәте Рум патшасыныкыннан берничә мәртәбә зуррак, гаскәре исәпсез-хисапсыз; иле Рум иленнән егерме көннән артык [юл] барырлык дәрәҗәдә киңрәк. Ул ифрәнҗләр мәзһәбен тота, чөнки алардан өйләнгән, ә үзе ифрәнҗләр иленә яу белән бара һәм аларны әсир итә. Гаскәре күп, үзе батыр булганга күрә, аның белән сугышырга куркалар.

Минем мөселманнарга хәмер эчү харам, [җарияләр] тоту һәм дүрт хатын [алу] хәлал, диюемне ишеткәч, ул болай әйткән: «Бу акылсыз эш, чөнки хәмер бәдәнне көчәйтә, ә хатын күплеге тәнне һәм мине зәгыйфьләтәдер, димәк, ислам дине гакылга нигезләнмәгән». Мин тәрҗемәчегә әйттем: «Әйт патшага, ислам шәригате христиан шәригатенә охшамаган. Христиан кешесе хәмерне ашаганда су урынына эчсә дә исерми, шул көчне арттыра. Хәмер эчкән мөселман гаять исерергә тырыша, аның гаклы оча, ул җүләргә әйләнә һәм зина кыла, үтерә, көфер кыла, аңарда хәтер калмый, коралын һәм атын бирә, бөтен малын хәмер ләззәте эстәүдә югалта. Ә мондагы мөселманнар — синең гаскәрең, син мөселманга яуга барырга боерсаң, аның аты да, коралы да, акчасы да булмас — барын да эчеп бетергән булыр. Моны белгәч син аны я үтерерсең, я кыйнарсың, яисә куарсың, яки аңарга ат һәм корал бирерсең, ул тагын барысын да [эчеп] бетерер. Әмма җариялар һәм хатыннар мәсьәләсенә килсәк, табигатьләре кызу булганга күрә [күп хатын] тоту мөселманнарга килешә. Ахыр чиктә алар синең гаскәрең, балалары күп булса, синең гаскәрең күбәер». [Моңа каршы] патша: «Бу картны тыңлагыз, ул акыллы; теләгән хәтле өйләнегез, аңарга карышмагыз»,— диде. Ул патша попларга каршы булды, җариялар тотарга рөхсәт итте. Ул патша мөселманнарны ярата иде.

Олы улым Хәмидне алар арасында калдырдым; мин аны калдырып киткән чакта аның яше утыздан арткан иде инде, күренекле мөселман кызларыннан ике хатын алган иде, угыллары да бар иде. Батыр, фазыйль иде. Ул кечкенә чагында бер мәсьәлә отып алган саен үзенә ярты данык [акча] бирә идем.

Башкортлар илендә филгә охшаган зур вәхши үгезләр бар; берсенең тиресе ике мулга йөк була, ә башы — бер арба йөге. Ул үгезне аулыйлар; аларны «сәйтәл» дип атыйлар, бик гаҗәп хайван: тәмле итле, симез, мөгезләре зур, озын — фил теше кадәре.

Ул илдә мин бик күп Гад кавеменең каберләрен күрдем. Берсенең алгы теш тамырының яртысын миңа күрсәткәннәр иде: киңлеге бер карыш, авырлыгы — 1200 мыскал; икенче бер сыйрак башы сөяген мин бер кул белән җирдән күтәрә алмадым...

Болгарда Гад нәселеннән булган бер кешене күрдем, буе җиде терсәктән артык-

[41] Сүз Дунай буендагы төрки халыкларның Византиягә һөҗүме хакында бара.
[42] Җиһад сугышы — дин өчен сугыш.

рак, мин аның белән генә җитә идем [43]. Бик көчле иде ул: сөйгән атны ала да күз ачып йомганчы бик тиз аның сөяген, итен, сеңерләрен ботарлап ташлый иде, ә мин балта белән дә алай тиз турый алмас идем. Болгар патшасы аңарга тимер күбә (күлмәк) ясаткан; аны ул сугышка барганда арбага салып бара торган иде. Аның тимер башлыгы зур казан хәтле иде. Ул нык иманнән ясалган дәү күсәк белән сугыша иде. Таза ир кеше дә күтәрә алмаслык әлеге күсәк аның кулында безнең кулдагы кечкенә таяк төсле иде. Төркиләр аңарга тәгъзыйм һәм ихтирам итәләр иде, әгәр дә каршыларына аның килүен күрсәләр: «Бу — раббымыз безгә ачуланган-дыр»,— дип качалар иде. Шуның белән бергә ул йомшак, илгәзәк, ягымлы [кеше] иде. Бөтен Болгарда бер киң, биек ишекле мунчадан башка аны сыйдырырлык мунча юк иде.

Башкорт патшасыннан мин мөселман илләренә, Сәҗсингә чыгып китәргә рөхсәт сорадым: «Балаларым, гаиләм анда, алла теләсә, мин синең яныңа кайтырмын»,— дип. Болай диде ул: «Олы улың Хәмидне калдырырсың. Синең белән бергә бер мөселман илчесен җибәрермен, ярлы-ябага мөселманнар һәм төркиләрдән миңа оста ук атучылар җыеп кайтсын». Саклаблар патшасына минем белән бергә хат язып җибәрде, аны патша сурәте төшерелгән кызыл алтын белән мөһерләде. Минем белән үземнән укыган кешеләрдән Исмәгыйль ибне Хәсән диган берәүне җибәрде. Ул — ислам динендә иконлекләрен яшермәүче батыр әмирләрнең улларыннан иде, аның белән голамлары [44] һәм яраннары бар иде.

Саклаблар иленә килгәч, [аларның] патшалары, башкорт патшасының хатына ихтирам иткәнгә һәм аңардан курыкканга күрә, менә яхшы каршы алды. һәм шунда кышка калдык. Язга таба төркиләр иленә чыгып киттек, Сәҗсингә таба юнәлеп. Саклаблар иленнән Габделкәрим ибне Фәйруз әл-Җәүһәри, [үзенең] хатыны һәм баласын алып, минем белән бергә юлга чыкты; ул соңыннан хатынын Сәҗсиндә калдырды да саклаблар иленә кайтып китте. Шушы илчегә бер төркем оста ук атучы мөселманнар җыйдым һәм алар белән бергә үз янымда булган, шәригатьтән бераз хәбәре бар укучыларымның берсен җибәрдем. Мин болай дидем: «Мин хаҗга барам һәм, алла теләсә, сезнең янга кире кайтырмын, Конйә аркылы». Алар башкортларга киткәч, мин бер ай диңгездән бардым һәм Харәзем җиренә юнәлдем, минем анда элек булганым бар иде инде [45].

Харәзем иле йөз фәрсәхка [сузылган], анда шәһәрләр, салалар, авыллар һәм кальгалар күп. Анда мин булган барлык илләрдә күрмәгән җимешләр бар; кавынның бал-шикәрдән тәмлерәк һәм әйбәтрәк төрләре очрый. Кавынның бер төре бар, аның тышы яшел, кара бөртекле, эче исә гакыйк (сердолик) төсле кызыл, үзе бик татлы, тыгыз итле була, [андыйның] бер данәсе ун мән [чамасы авырлыкта]. Ул кавынны кыш буена әйләрдә саклыйлар һәм базарларда саталар. Шулай ук йөземнең хәрмә төсле ак һәм кызыл төрләре бар, кышка [калдырылганнары] элеп куела, үзе арзан. Шулай ук алма, армуд һәм анар [күп була]. Кибетләрен һәр вакыт җимешләр белән бизиләр, бигрәк тә яз көннәрендә, кешегә алар хәзер генә бакчадан өзелгән кебек күренә.

Харәзем халкы фазыйль [46], шагыйрь [һәм] намуслы [халык]...

Менә шулай, күргәннәремнең бәгъзесен кыскача гына искә алып киттем, әгәр дә аңлатырга, [киңәйтергә] тотынсам, китап озакка сузылыр иде. Кыскасы да җитәр!..

Башкорт иленнән мин илле өченче елны чыктым, Сәҗсиннән Харәземгә илле дүртенче елны киттем, Харәземнән хаҗга киттем илле бишенче елның рабигылаввәлендә [47]...

Хаҗ кылдым да Бәгъдадка кайттым. Миңа ярдәм итүче вәзир Гаунетдин булды [48]...

---

[43] «Төхфә...»дә әл-Гарнатый бу кешене 530 (1135—36) нчы елны күрдем дип яза. Аның исеме Данкый (яисә Дәфгый, Ванкый) иде ди.

[44] Голам — кол; биредә коралллы хезмәтчеләр (сугышчылар) мәгънәсендә.

[45] «Төхфә...»дә болай әйтелгән: «Хазар һәм төрек җирендәге Сәҗсин шәһәреннән Харәземгә өч мәртәбә диңгез аркылы чыкканым бар».

[46] Фазыйль — укымышлы.

[47] «Төхфә...»дән әл-Гарнатыйның Венгриягә 545 (1150—51) нче елда килүе мәгълүм; биредә өч ел торса, ул 548/1153—54 нче елны китәргә тиеш. «Илле өченче» дигәнне һиҗри 553 дип алсак, бөтенләй туры килми. Дублер һәм Большаков биредә 1153, 1154, 1156 нчы еллар аталган булса кирәк дип уйлыйлар. Ләкин мәсьәлә бөтенләй ачылып җитмичә кала. Кулъязманың нәкъ шушы төшендә тексттан берничә гыйбарә төшеп калган.

[48] Сүз хәлифә вәзире, Әбү Хәмиднең элекке дусты Гаунетдин Ибне Һөбәйрә хакында бара.

# КӨН ТӘРТИБЕНДӘ— ДӘРЕСЛЕКЛӘР

*Узган елның ноябрь аенда Татарстан Язучылар союзы идарәсе, Татарстан АССР Мәгариф министрлыгы һәм Татарстан китап нәшрияты белән берлектә, татар мәктәпләре өчен чыгарылган әдәбият дәреслекләрен тикшерүгә багышланган зур сөйләшү уздырды. Анда Казан дәүләт университеты һәм Казан педагогия институтының татар әдәбияты кафедралары укытучылары, танылган әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләр гамәлдәге әдәбият дәреслекләре турында тирән эчтәлекле докладлар ясадылар. Фикер алышуларда язучылар һәм әдәбият галимнәре, дәреслек авторлары һәм укытучылар, китап нәшрияты һәм Мәгариф министрлыгы вәкилләре, журналистлар катнашты.*

*Журналыбызның бу санында укучыларны шул сөйләшүдә катнашкан иптәшләрнең чыгышлары белән таныштырабыз.*

## Мөхәммәт Мәһдиев

## МӘКТӘПЛӘРДӘ ӘДӘБИЯТ УКЫТУНЫҢ КАЙБЕР МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

### САРЫКНЫ КЕМ АШАГАН?..

Моннан 10—15 еллар элек «Совет мәктәбе» журналы әдәбият дәреслекләрендә М. Гафуриның «Сарыкны кем ашаган?» мәсәлен артык гадиләштереп аңлату хакында язып чыккан иде инде. Соңгы елларда басылган дәреслекләрне һәм уку китапларын күздән кичергәч, бу мәсьәләдә әле дә булса зур үзгәреш сизелмәвен күрәсең[1]. «Мәсәлдәге бүре образында, дип язалар хөрмәтле әдәбиятчыларыбыз, М. Гафури изүче катлауларны, эксплуататорларны бирә. Ә куян образында?.. Шул төшкә җиткәч, алар бераз тәртелеп торган сыман булалар. Шулай да, батырлыкларын җыеп, хөкем чыгаралар: куян образында шагыйрь хезмәт иясе вәкилен биргән. Куянга нинди сыйфатлар хас соң? Юашлык, куркаклык. М. Гафуриның бу мәсәле ничә еллар буена хакыйкатьтән ерак булган әнә шундый анализ белән бирелеп килә.

«Сарыкны кем ашаган?» мәсәлен аңлау өчен профессор булуның һич тә хаҗәте юк. Мәгълүм булганча, М. Гафури — мәгърифәтче, үгет-нәсихәтчедән эзлекле рәвештә критик реализмга, аннан социалистик реализмга таба атлаган әдип. Үгет-

[1] М. Җәләлиева, Г. Әдһәмова. Әдәбият. 4 нче класс өчен дәреслек-хрестоматия. Алтынчы басма. Казан, 1975 ел, 119—120 битләр.

нәсихәтчелек әдәбияты өчен мәсәл иң кулай жанр була. Һәм XX гасыр башында бу жанрның татар әдәбиятында киң урын алуын әнә шул иҗат методы таләпләренә бәйләп карарга кирәк тә. Мәгърифәтчеләр өчен дөньяда яхшылык һәм явызлык яши, алар гомумән явызлыкны — комагайлыкны, гаделсезлекне, наданлыкны тәнкыйть итәләр. «Мәгърифәтчеләр халыкның бер сыйныфын да үзләренең аерата игътибар предметы итеп аерып куймадылар»,— дип язган иде В. И. Ленин[1].

Әлеге мәсәлдәге куянны «хезмәт иясе вәкиле» дип аңлатуның фәннән никадәр ерак икәнлеген башка чыганакларга мөрәҗәгать иткәндә дә аңлап була. 1887 елда инглиз язучысы М. Гаркнесның «Шәһәр кызы» дигән повесте дөньяга чыга. Бу китап авторның үтенүе буенча Ф. Энгельска җибәрелә. 1888 елның апрелендә Ф. Энгельс авторга хат белән җавап бирә. Ф. Энгельсның бу хатындагы фикерләр соңыннан реализм турындагы әдәбият фәненең нигезенә алына. Сезнең повестегызда, дип язган бу хатында Ф. Энгельс, эшчеләр сыйныфы пассив, үз-үзенә ярдәм итә алмаслык бер масса итеп тасвирланган. Бу сыйфатлар 1800, 1810 елларга, Сен-Симоннар, Роберт Оуэннар заманына туры килсә дә, 1887 ел өчен характерлы түгел. Эшчеләр сыйныфының үз хокуклары өчен революцион көрәше реализм әдәбиятында ныклы урын алырга һәм дөрес чагылыш табарга тиеш — Энгельсның төп фикере әнә шуңа кайтып кала.

Инде килеп, 1913 елдагы — М. Гафуриның «Сарыкны кем ашаган?» мәсәле язылган елдагы — Россия пролетариатын алсак, аны Ф. Энгельсның шул ук таләбеннән чыгып бәяләп булмыймыни? Бишенче ел революциясен — Октябрь революциясенең генераль репетициясен — узган, кара реакция елларында да сытылып калмыйча, унынчы еллар башында яңадан революция этабына килеп кергән пролетариатны шулай изелгән, юаш итеп аңлату — әдәбиятны вульгарлаштырудан башка нәрсә түгел.

М. Гафуриның әлеге мәсәлендә исә нинди дә булса аерым бер сыйныф тәнкыйть ителми. Мәгърифәтче шагыйрь, гомумән явызлыкны тәнкыйть итеп, әсәрен менә болай тәмамлый:

Бүре төсле ерткычларга киңдер җиһан;
Һәркайда золым күрер мескен куян.
Зарарлы бәндә булып күренерсең,
Башкаларга кыйлмасаң да һичбер зыян.

Ләкин шул ук вакытта М. Гафури 19 нчы йөз мәгърифәтчеләреннән бик нык алга да киткән. Мәгърифәтчеләр явызлыкны, гадәттә, яхшылык тарафыннан җиңелүләр һәм әсәр гаделлек тантанасы белән тәмамлана иде. Күргәнебезчә, М. Гафуриның бу әсәрендә **явызлык** тантана итә. Ни өчен? Буржуаз җәмгыять өчен характерлы күренеш бу. Димәк, язучы, мәгърифәтчелек алымнарын саклаган хәлдә, критик реализм методын үзләштерә башлаган. Башлангыч класс укучылары өчен дәреслек язганда, «Сарыкны кем ашаган?» мәсәлен чын фәнни тирәнлектә аңлату авыр булыр, әлбәттә. Әмма куян образында хезмәт ияләре вәкиле сурәтләнә дип аңлату да дөрес түгел.

Әдәбият дәреслекләрендә «шүрәле»нең дә биографиясе катлаулы булып килде. Шүрәле — явызлык символы, шүрәле — кара көч, шүрәле — эксплуататорлар вәкиле... диделәр. Шулаймы соң? Халык иҗатын өйрәнгән кешеләргә мөрәҗәгать итик. К. Насыйри шүрәлене болай тасвирлый: «Шүрәлеләр урманда тора... Әгәр урманда аларга татар очраса, алар аны кети-кети уйнарга чакыралар, әгәр дә ул күнсә, аны үтергәнче кытыклыйлар. Ләкин татар шүрәлене алдалый ала; ул аны ничек алдалый соң? Балта белән ярган агачка кул тыгып уйната да, шүрәле, **аңгыралыгы аркасында**, шунда ук һәлак була»[1] (курсив безнеке — М. М.). Моңысы булды Каюм Насыйридан. Инде Габдулла Тукайга килик. Казан артындагы бер авылда шүрәлене базга биклəп яндырганнар, имеш, дип яза шагыйрь. «Шүрәле, бичара, яна, кычкыра, фөрьяд итә, ахырында янып көл була»[2]. «Мин — шүрәле һәм дә татар урманнарында гына була торган «милли шүрәле» булганга, мин җәй көне урман буена ат ашатырга килгән яшүсмер Гайнетдин вә Сәйфетдиннәрнең дә җырларын тыңладым... Бу юлы мин, «шүрәле», халык күңелен кытыкларга, аның үз бармагын күтәргә генә алып торып, ушбу китабымны мәйданга куям»[3]. «Халык моңнары» дигән җыентыкка сүз башына Г. Тукай үзенең имзасын «Шүрәле» дип куя. Хәер, китапның тышына ук «Җыючысы: Шүрәле» дип язылган. Бу — бердәнбер очрак түгел.

---

[1] В. И. Ленин. Без нинди мирастан баш тартабыз. Таткнигоиздат, 1950 ел, 39 бит.

[1] К. Насыйри. Сайланма әсәрләр. Казан, 1956 ел, 190 бит.
[2] Г. Тукай. Әсәрләр. 2 том, Казан, 1955 ел, 260 бит.
[3] Шунда ук, 277 бит.

«Яшен ташлары». 1911 ел. Авторы — шул ук Шүрәле! Наширы да халык фантазиясе тудырган шүрәле кебегрәк образ: «Су анасы!» Менә сиңа эксплуататор вәкилләре! Яки шагыйрьнең «Көтмәгәндә» дигән шигырен укып карыйк. Кышкы буранда авторга шүрәле очрый. Кытыкламакчы була, ләкин шагыйрь калын киенгән — үтми. Шагыйрь әйтә, бик бәйләнчек икәнсең син, бар йөрмә әле, суык та үтә алмаслык киенгән мин, ди.

Шул сүземнән соң томанга батты, гаип булды ул.
«Чи-и-и!» итеп бер әллә кайда, бик еракта көлде ул.

Ул көлә, һәм көлке эзләүдә үтә кич, иртәсе;
Кем кыеп әйтсен аңар сүз, ул — табигать иркәсе![1]

Г. Тукайның «Шүрәле» әсәрен укыганда да дәреслек авторларына игътибар итәрлек урыннар аз түгел. **Шагыйрь аны табигатьнең бер мәхлугы, хезмәт кешесе янында акыл ягыннан бик тә түбән торган бер «бичара» итеп бирә.** Шүрәле кеше үтереп йөрүче генә түгел. («Булгалыйдыр көлдереп адәм үтергән чакларым».) Шүрәле — «инсан хәйләсен» белми торган «урман сарыгы», аны иртәгәсен иптәшләре дә «и юләр» дип тиргиләр. К. Насыйри шүрәлене «Казан татарларының тормышында ислам дине йогынтысыннан тыш барлыкка килгән ышанулар һәм гореф-гадәтләр» дигән хезмәтенә керткән. Күргәнебезчә, шүрәленең реакцион ислам дине белән һәм, билгеле инде, изүче сыйныфлар белән бернинди уртаклыгы юк. Ул — калын кара урманнары булган халыкның фантазиясе җимеше генә. Ул — әле мәгърифәткә, белемгә ия булмаган, ләкин көндәлек тормышында табигать белән даими элемтәдә торган, һәр көнендә табигатьнең я яхшылыгын, я кырыслыгын күреп яшәгән хезмәт кешесенең хыялында туган «урман сарыгы»! Югыйсә, Г. Тукай аны шулай мәхәббәт белән телгә алыр идемени?!.

Шүрәленең әнә шундый мәхлук, кызганыч бер карачкы икәнлегенә поэманы русчага тәрҗемә итүче С. Липкин да игътибар иткән икән. «Шүрәле — юләр,— ди ул,— һәм шуңа күрә ул куркыныч кына түгел, ә көлке дә»[2]. Кыскасы, шүрәлене явыз көч кенә түгел, ә халык фантазиясе тудырган мәхлук та дип аңлатырга бик вакыт. Методик кулланма, программа, дәреслек авторлары филология фәненең бүгенге дәрәҗәсеннән артка калмасыннар иде. Югыйсә, куян образында хезмәт иясе, шүрәле образында явыз көчләр вәкиле бирелгән дип артык гадиләштереп аңлату балаларны әдәби әсәрләрдәге эстетик матурлыкны аңлаудан мәхрүм итә.

## ӘДӘБИЯТ — МӨСТӘКЫЙЛЬ ФӘН...

Бер кеше дә дөньяда булган барлык фәннәрне бертигез яратып бетермәскә мөмкин. Хәер, бу — мәҗбүри дә түгел. Әмма әдәбиятны яратмаган кеше юктыр. Әдәбият җәмгыятьнең барлык тармакларында эшләүчеләргә рухи азык бирә. Мәктәптә баланың рухи дөньясын баетуда, аңа коммунистик тәрбия бирүдә әдәбият — иң мөһим фәннәрнең берсе. Турысын гына әйткәндә, әнә шул мөһим фәнне соңгы елларда кайбер мәктәпләрдә ярдәмчел, башка предметларга хезмәт күрсәтүче («обслуживание» мәгънәсендә) дәрәҗәсенә төшереп баралар төсле. Әйтик, әдәбият дәресе алып бару өчен ЛЭТИ аппараты бик уңай. Кулыңа тоткан озын күрсәткеч таягың — синең идарә итү пультың. Таяк белән экранга төртеп күрсәтергә, үзең төзегән кадрларны экранда хәрәкәтләндерергә, кадрларны алмаштырырга, караңгылык-яктылыкны тигезләргә һ. б. ны эшләргә мөмкин. Чөнки күрсәткеч таякның очыннан нур чыга, нур — таяк хезмәтен үти. Монда машина дәрестә куелган проблеманы уңышлы чишү, бирелгән вакыт берәмлеге эчендә укучыларга максимум информация җиткерү, теорияне дәлилләр белән ныгыту кебек максатларга хезмәт итә. Укучылар моны зур кызыксыну белән тыңлыйлар, материалны, әлбәттә, яхшы үзләштерәләр. Ләкин шул ук машина ярдәмендә Ф. Әмирханның «Хәят» повестена хас нәфислекне аңлатып булмас кебек. Яки М. Җәлилнең Моабит циклы шигырьләрендәге нечкә лиризмны бу машина белән ачып булмастыр...

Хәлбуки, техник чаралардан һәр әдәбият дәресендә, һәр темада файдаланырга тырышу мәктәпләрдә инде мәҗбүри таләп дәрәҗәсенә җитеп килә. Методик кулланмаларны, укытучыларның дәрес планнарын гына алып карагыз! Менә әлегә дә баягы «Шүрәле» поэмасын өйрәнәләр. Техник чаралар шул кадәр күп — укытучы инженерга, дирижерга, экономистка, статистка әйләнә. Менә сезгә

---

[1] Шунда ук. 213 бит. (Курсив безнеке — М. М.)
[2] С. Липкин. Поэма-сказка Габдуллы Тукая «Детская литература» журналы, 1975 ел, 8 сан.

экранда Кырлай авылының рәсеме. (Класста пәрдәләр төшкән, аппаратның кенотрон лампасы гына зыңгылдый, экранга яктылык көлтәсе юнәлгән.) Укытучының тамак кыруы белән магнитофон эшкә тотына: өстәл янындагы ике малай ыгы да зыгы киләләр, класста Ф. Яруллинның моң тулы вальсы яңгырый. Экранда «Шүрәле» балетыннан фрагментлар күрсәтелә. Балетның Канада, Лондон сәхнәләрендә куелуы әйтелә. Укытучы «Шүрәле» поэмасыннан өзекләрне яттан укый. Менә тиешле урынга житкәч, машиналар туктый, тәрәзә пәрдәләре ачыла. Укытучы дәресне дәвам итә. Күз алдына китерик, тәҗрибәсе булмаган яшь әдәбиятчы, техник чаралар белән мавыгып, менә болай эшләргә мөмкин: дөнья картасыннан Канаданы, Лондонны табалар. Татарстан картасыннан Кырлайны табалар. Аннан композитор Ф. Яруллинның портреты Тукай портреты янына эленә. Шүрәледән — урманга бер карыш... Урман турында сөйләнмәгән бит әле. Безнең урманда нинди агачлар үсә? Алар промышленностьта кайларга китәләр һәм башкалар, һәм башкалар... Укытучы әнә шулай матур итеп дәрес алып бара. Монда музыка, география, авыл хуҗалыгы, рәсем сәнгате, сәнгатьле уку элементлары инде җитәрлек булды. Тукта! Г. Тукай ни ди әле? Ә, болай ди:

Әллә ник истән дә чыккан, сүз башым бит
«Шүрәле»!

Тукай булып Тукай да ычкынып киткән икән. Ләкин вакытында «корректив» керткән шагыйрь! Ә менә укытучыга «корректировка» ясаучы юк. Киресенчә, техник чаралар, тәрбиянең төрле яңа алымнары аны берәзлексез куып тора. Әле бит атеистик момент калган. Менә китә инде укытучы шүрәленең каралыгы, халык өчен зарары турында сөйләп. Монысы инде дәреснең соңгы ун-унбиш минутын йотып кына ала.

Звонок булды. Дәрес йомгакланды. Хуш, укытучы нинәргә иреште? Күп нәрсәгә. **Укучыларда информация артты.** Әйе, әйе, бу дәрестә алар моңарчы белмәгән нәрсәләре турында мәгълүмат алдылар. Бу яктан карaганда, дәрес бик нәтиҗәле узды. Ләкин әсәрнең сәнгатьчә тәэсир көчен дә сизгәннәрдер дип әйтүе кыен.

Кеше рухына тәэсир итү ягыннан әдәби текст кадәр көчле тагын нәрсә бар икән? Бер генә машина да укытучының тел белән дәрес бирүен алыштыра алмый. Машина — укытучының ярдәмчесе. **Һич тә киресенчә түгел.** Кырык беренче елның көзендә без бишенче классга укырга кердек. Бөтен класска әдәбияттан бер китап. Ул да укытучы кулында. Программа буенча И. Газиның «Катя Сорокина» дигән әсәрен узарга тиеш иконбез. Укытучыбыз Фәузия апа Мөхәммәтшина ике дәрес буена шул әсәрне кычкырып укыды да чыкты. Моның өчен инспекторлар, «балалар белән эш итмәде», дип, укытучының бу дәресенә начар бәя бирерләр иде. Ләкин укытучы эш итте, итте безнең белән... Ул безнең күңелләрне яулады. Аның тавышы, әсәрнең аерым җөмләләре әле дә колагымда. Мин шуннан бирле «Катя Сорокина»ны юри укымыйм, теге вакытта күңел ничек кабул иткән булса, шул көе саклансын дим. Димәк, дәреснең әле мондый гадие дә була икән һәм андый дәрес тә яшәргә хаклыдыр?

Мине дәрес аңлауларын өмет итәм: экраннар, магнитофоннар, ЛЭТИ аппаратлары белән уздырылган дәресләргә мин сокланып, кызыгып утырам. Ул дәресләр шәп, шиксез шәп. Әмма без тыңлаган теге дәресне дә юкка чыгармасалар иде. Чөнки ул дәрес безнең күңелләргә **художник** Ибраһим Гази, **педагог**, **әдәбият укытучысы** Фәузия апа образларын мәңгегә урнаштырды. Ә хикәя буларак, «Катя Сорокина»ның көчен әйтмим дә инде. Техник чаралар белән артык мавыгып, әдәби әсәрнең эмоциональ көчен, **сүз**, **образ** көчен онытмасыннар иде, дип менә мисал китерүем...

Дәрес саен әдәби әсәрне картиналар, экраннар, симфонияләр, география карталары белән күмеп ташлау — әдәбиятны мөстәкыйль фән буларак югалта бару түгелме? **Монда чаманы белергә кирәк.** Әдәбиятның төп көче сүз дә, тасвир да, образ да икәнен онытмаска кирәк. Юкса, менә болай кереп китеп була. Тукайның «Пар ат» шигырен узганда, мәсәлән, картадан Уральск шәһәрен эзләтәсең. Аннан парлап җигелгән ат турында сөйлисең. Әлбәттә, картинадан күрсәтеп. Аннан әдәбият гыйлеме бирәсең: шигырьнең беренче строфаларында бер үк авазлар чиратлашып кабатлана. Бу — аллитерация дип атала. Һәм ул әдәби әсәрнең музыкаль аһәңен тудыруга ярдәм итә. Хуш... Моннан бит, чыннан да, атлы арбаның таш юлдан барган тавышы ишетелә сыман. Ә хәзер юллар нинди? Асфальт, дип кычкыралар балалар. Дәрес, асфальт. Укучылар, асфальт нәрсә ул? Ягез әле, ягез,

уйлап карагыз. (Укытучы дәфтәренә күз төшереп ала: дәрескә хәзерләнгәндә ул энциклопедиядән табып язган иде. Асфальт ул 13—60% битум белән известняк катнашмасы. Ясалма асфальтта парафин да була.) Балаларга әнә шул мәгълүмат та бирелә. Шуннан «Пар ат» җырын граммофон язмасында тыңлыйлар һ. б. һ. б.

Дәрес биргәндә техник чаралар белән мавыгып китү әнә шундый шаржга китереп чыгармасмы?.. һәр техник чараның чамасы булырга тиеш. Ни әйтсәң дә, әдәбият — мөстәкыйль фән.

## ӘДӘБИЯТ — ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ ФӘН

Мәктәп баласына арифметикадагы дүрт гамәлне өйрәтергә була, ошыймы-ошамыймы, яңгыр суалчанының эчке төзелешен белдертергә була. Ниһаять, баланы Габделҗаббар Кандалыйның туган-үлгән елларын яттан белергә мәҗбүр итеп була. Әмма укыту процессында мәҗбүр итеп булмый торган бер нәрсә бар. Ул — баланың фәнне яратуы. Мәсәлән, әдәбиятны.

Мәктәпләрдә татар әдәбияты программасы балаларда әдәбиятны ярату тәрбияләүгә хезмәт итәме? Шул сорауга җавап биреп карыйк. Безнең уебызча, программа һәм методик кулланмаларда хәзерге вакытта берничә төрле кимчелек яшәп килә.

**Беренче кимчелек.** Әдәбият укытучысы класста нинди генә текстны өйрәнмәсен, шул текстны аерым кисәкләргә бүлеп, бүлек башларына исем таптыра, аларны дәфтәргә яздырта. Бу — һәр дәрес өчен шаблон рәвештә кулланыла. Әдәби әсәрнең үзе белән рәхәтләнеп эш алып барасы урында, укучылар даими рәвештә күңелсез бер эш алып баралар. Югыйсә, «Кәҗә белән сарык әкияте»нә план төзү нигә кирәк? Классыңда егерме биш бала икән, шуларның барысына да укыт, текстны рәхәтләнеп кычкырып укысыннар, ятлат, яттан сөйләт... Юк бит, алай түгел. План төзергә кирәк. Ә бит шушы әкиятне исе китеп яраткан, шуны күңелдән белгән укучының укытучы таләп иткән планны төзи алмавы да бар. Ул, әлбәттә, түбән билге алыр. Ә менә икенче бер бала — бу әкият белән артык хисләнмәс, яратмас, ләкин арифметик төгәллек белән план төзер һәм югары билге алыр. Әмма әдәбият дәресендә җиде-сигез пунктлы план төзеп утыру тегесендә дә, монысында да әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләмәс, бу дәрестән аларның гайрәте чигәр. Чыннан да, «Су анасы»на план нәрсәгә? Әдәбиятның кеше күңеленә тәэсир итү көче, беренче чиратта, әлбәттә, текстның үз эчендә. Нәрсә, сәке буена утырып, кышкы озын кичләрдә әби-бабаларыбыз «Таһир-Зөһрә»не тыңлаганнар һәм, Тукай әйтмешли, «Җантаһир белән Җанзөһрәне» кызганып елаганнар икән, әллә алар план төзегәннәрме? Бүлек башларына исем куя-куя еламаганнардыр бит? **Әлбәттә, аерым текстларны шулай бүлгәләп (зуррак эпик әсәрләрне) исемләп уку да кирәк.** Әдәбият дәресендә без баланы фәнни эшкә дә өйрәтергә тиешбез, бала план да төзесен, аңа да өйрәнсен. Әдәбият дәресе текст укуга гына кайтып калмасын. Әмма һәрбер әсәрдән андый «җәфалы» дәрес ясау кирәкмәстер. Кыскасы, әдәбиятка **мәҗбүри караш** аңа мәхәббәт түгел, ә яратмау хисе, читләшү генә тәрбияли.

**Икенче зур кимчелек.** Монысы тагын да катлаулырак, матур әдәбият укытудан максат нәрсә? Кешенең күңелен, аның тойгысын тәрбияләү, матурлыкны танырга өйрәтү, кешенең рухи дөньясын баету. Коммунистик тәрбиянең аерылгысыз сыйфатларын — патриотизм, интернационализм, материализм тәрбияләү; гаделсезлеккә нәфрәт, гаделлеккә мәхәббәт тәрбияләү. Кыскасы, бала күңелендә гуманизм тәрбияләү. Бу сыйфатларны нинди әсәрләр генә уята ала? **Сәнгатьчә югары сыйфатлы халыкчан әсәрләр генә.** Димәк, мәктәп программаларына демократик әдәбиятның һәм совет әдәбиятының иң югары сыйфатлы һәм бала күңеленә үтәрлек әсәрләрен генә кертергә кирәк. Язучының барлык әсәрләре дә тигез күләмдә була алмый. Г. Тукай — реакция елларында язган шигырьләре белән бөек, М. Җәлил — Моабит циклы белән тиңсез югарылыкка ирешә. Г. Камал шигырьләр дә, проза да язган, ләкин ул үзенең «Беренче театр», «Банкрот» комедияләре белән бөек. М. Фәйзинең иҗат күгендә якты йолдыз булып «Галиябану» драмасы тора. «Яшьләр алдатмыйлар», «Кызганыч» әсәрләре, күп санлы шигырьләре әдәбият тарихын өйрәнгәндә кирәк булсалар да, М. Фәйзинең бөтен таланты — «Галиябану» драмасында. Ф. Әмирханның «Яшьләр» драмасы бар, бу бик тирән фәлсәфи әсәр. Ләкин Ф. Әмирханны дәреслектә

«Хәят» һәм «Фәтхулла хәзрәт» әсәрләре белән бирү отышлы. Һәм соңгы елларда бу шулай эшләнә дә. К. Нәҗмине исә җиденче класста «Язгы җилләр» кебек зур полотнолы роман белән бирү нигездә максатка ярашлы түгел. Үндүрт яшьлек сабый һәм... искиткеч катлаулы тарихи вакыйгалар. Балалар өчен К. Нәҗми нәрсә белән ялтырап керер иде? Менә алар: «Шобага», «Миңлебикә кодагыйның кайгысы», «Кояшлы яңгыр», «Яр буендагы учаклар» һ. б. Менә К. Нәҗминең хикәяче буларак иң көчле, эмоциональ куәтле әсәрләре! Менә мәктәп балаларының көнделек тетрәтерлек, граждannar сугышы чорындагы көрәшнең изгелеген югары сәнгать чаралары белән җиткергән әсәрләр! «Язгы җилләр» — үндүрт яшьлек балалар өчен түгел. Кызганычка каршы, К. Нәҗминең хикәяләре аерым алып бөтенләй дә өйрәнелми икән. Алар обзорга гына кертелгәннәр.

Урта мәктәп балаларына Г. Әпсәләмовны да «Ак төннәр» («Ак чәчәкләр» түгел!) һәм «Алтын йолдыз» белән («Сүнмәс утлар» түгел!) бирергә иде. Балаларның яшь үзенчәлеге бар бит! Программа менә мондый таләпләр куя: «Хәсән Мортазин образы. Бу образның әсәрдә үстерелеше һәм психологик тип буларак сурәтләнүендә язучының художество осталыгы. Әсәрнең идеясен ачуда бу образларның әһәмияте». Ә бит Г. Әпсәләмовның 17 яшьлек егетләр-кызлар өчен (10 нчы класс) аларның рухи дөньясына якынрак булган искиткеч матур әсәрләре бар. Монда яшьлек, хыяллар, романтика, монда геройлык! Әнә «Ак төннәр»дәге яшь сугышчылар. Мажаралы, хәтәр вакыйгалар — мәҗбүр итмә, юнәлеш кенә бир. Әнә Бөек Ватан сугышы чорындагы совет яшьләренең изге хисләр белән тулы тормышы — «Алтын йолдыз» романы...

Программада болардан тыш та кимчелекләр шактый. Бу кимчелекләрнең барысы да, безнең уебызча, бер нәрсәгә кайтып кала. Без мәктәптә әдәбият тарихын, язучының биографиясен өйрәнү белән артык мавыгабыз. Әдәбият — язучының иң яхшы әсәрләре буенча укытылырга тиеш. Югыйсә, без әдәбият тарихы мәсьәләләрен программаның нигезенә алабыз да әдәби әсәрләрне шуңа иллюстрация буларак кына хезмәт иттерәбез.

* * *

Әдәбият дәресләренең методикасын һәм дәреслекләр сыйфатын яхшырту буенча соңгы елларда Татарстан АССР Мәгариф министрлыгы һәм гыйльми-методик оешмалар байтак көч куйды, үзгәреш кертте. Хәзер дәреслек авторлары — гыйльми дәрәҗәләре булган югары хәзерлекле, компетентлы кешеләр. Димәк, программа һәм дәреслекләрнең сыйфатын бүгенге көн таләпләренә җавап бирерлек дәрәҗәгә күтәрү өчен республикабызда тулы мөмкинлекләр бар. Мөмкинлекләр бар икән, димәк, программа һәм дәреслекләрне яхшырту юнәлешендә җиң сызганып тагы да эшләргә кирәк.

## Флера Ганиева

# ӘДӘБИЯТ—ТӘРБИЯ ЧАРАСЫ ДА...

Башка фәннәрдән аермалы буларак, әдәбият чынбарлыкны кешенең хис-кичерешләре аша, матурлык тойгысы ярдәмендә таныта. Ягъни әдәбият — гаять әһәмиятле, тәэсирле тәрбия чарасы да. Әдәбиятның менә шушы ике максатка хезмәт итүе — белем дә, тәрбия дә бирүе — аны мәктәптә өйрәнелә торган башка фәннәр арасында үзенчәлекле урынга куя. Һәм мәктәптә әдәбият укытуның максаты, характеры да әнә шуннан чыгып билгеләнә. Укыту программасында бу турыда ачык һәм тулы әйтелә: «Укучыларның акыл һәм аң дәрәҗәләрен, эстетик зәвыкларын үстерү, тормыш һәм аның катлаулылыгы, үзгәреп торуы,

алга баруы, кешеләр, алар арасындагы мөнәсәбәтләр турында марксистик-ленинчыл караш белән сугарылган белем бирү, дөньяга, тормышка фәнни караш, коммунистик әхлак тәрбияләү — яшьләрне әдәбияттан белемле итүнең төп максаты» [1].

Тормыш турында белемне матур әдәбият үзе бирә, укучы өчен төп чыганак, өйрәнү предметы — әдәби әсәр. Ә менә әдәбиятның нәрсә икәнлеген аңларга, әдәби әсәрне үзләштерергә, анда әйтелгән фикерне аңлый, матурлыкны күрә белергә дәреслек өйрәтә. Шуңа күрә дәреслекләрнең сыйфаты, нинди принциптан чыгып төзелгән булулары, әдәбиятның сәнгать төре икәнлеген ни дәрәҗәдә исәпкә алулары — гаять мөһим мәсьәлә. Бу турыда дәреслекне төзүче авторлар, методистлар һәм укытучылар гына түгел, язучылар да, әдәбият өлкәсендә эшләүче галимнәр дә кайгыртырга тиеш.

Әдәбият үсә, педагогика, методика фәннәре яңа ачышлар, алымнар белән баый, дәреслекләр дә елдан-ел камилләшә бара. V класс өчен дәреслек-хрестоматия [2] шул хакта сөйләүче бер мисал була ала. Ул укыту тәҗрибәләре зур булган, педагогика һәм методика фәннәренең бүгенге дәрәҗәсен яхшы белгән авторлар тарафыннан язылган.

Дәреслек-хрестоматия программа нигезендә төзелгән. Авторлар программа таләпләренә иҗади якын килгәннәр, үз алларына ачык, конкрет максатлар куйганнар, укытуның җанлы процесс булуын даими истә тотканнар. Дәреслек-хрестоматия тематик принципка корылган. Программада таләп ителгән материаллар биш темага бүлеп бирелгән. (Алар түбәндәгеләр: «Татар халык авыз иҗаты»; «Классик язучылар иҗатында революциягә кадәрге тормыш күренешләре. Хезмәткә мәхәббәт»; «Бөек Октябрь социалистик революциясе һәм гражданнар сугышы турындагы әдәби әсәрләрдән үрнәкләр»; «Татар совет әдәбиятында Ленин образы»; «Социалистик хезмәт темасына багышланган әсәрләрдән үрнәкләр».)

Авторлар материал сайлаганда һәм аны аңлатканда, сораулар, биремнәр төзегәндә укучыларның яшь үзенчәлеген истә тотканнар. Беренчедән, дәреслек бик матур кереш белән ачыла: «Әдәбият тормыш һәм кешеләр турында белем бирә, яхшыны яманнан, изгелекне явызлыктан, уңайны тискәредән, гүзәллекне ямьсезлектән аерә белергә өйрәтә. Яхшы һәм уңай күренешләргә мәхәббәт, тискәре сыйфатларга нәфрәт тәрбияли». Икенчедән, авторлар укучыга мөрәҗәгать итеп, тигез, конкрет җөмләләр белән сөйлиләр, укучыны уйланырга, фикер йөртергә өндәп торалар. Өченчедән, һәр яңа материал укучыларның башлангыч класста алган белемнәре белән, тормыш тәҗрибәләре белән бәйләнелә, алга таба үстерелә.

Дәреслектәге әдәби әсәрләр белән танышканнан соң, татар әдәбиятының зурлыгы, байлыгы, төп сыйфатлары күз алдына киләме соң? Шул сорауга җавап эзләп карыйк. Беренче бүлек татар халык авыз иҗатының бәетләр төре белән таныштыра. Эчтәлеге һәм сәнгатьчә эшләнеше ягыннан сайлап алынган әсәрләр халык рухын, аның омтылышларын, халык иҗатына хас сыйфатларны шактый тулы чагылдыралар. Аңлатма текст та бәетләрнең үзенчәлекле жанр икәнлеген үзләштерергә ярдәм итә.

Икенче бүлектә иң зур урынны Г. Тукай иҗаты алып тора. Бу урында шул кадәресен дә әйтеп китәргә кирәк, бөек шагыйрь иҗаты барлык классларда диярлек өйрәнелә. Шуңа күрә пропорция мәсьәләсе турында да уйларга кирәктер. Мәсәлән, V класс дәреслегендә, Г. Тукай иҗат иткән әсәрләрдән үрнәкләр итеп, «Япон хикәясе», «Бәхетле бала», «Фатыйма белән Сандугач» шигырьләре һәм шагыйрьнең мәсәлләре китерелә. Балалар өчен язылган шигырьләре, дөрестән дә — шагыйрь мирасының әһәмиятле өлеше. Мәсәлләрендә дә Г. Тукай балаларга тормыш турында гыйлем бирә, тормыштагы һәм кеше характерындагы уңай һәм тискәре сыйфатларга басым ясый. Шулай да рәттән 15 мәсәлне тезеп бирү дәреслекне төссезләндерә, яңгырашын бер тонга гына күчереп куя кебек. Чөнки бу мәсәлләр шагыйрь яшәгән чорны күздә тотып, шул чор укучысына үгет-нәсихәт бирү нияте белән язылганнар. Шуңа күрәдер, дәреслектәге биремнәр дә, әсәрләрне анализлау, аларга карата укучыда иҗади мөнәсәбәт уятудан бигрәк, коры дидактикага әйләнеп калган. Мәсәлләрне, сайлап алып, 5—6 га калдырганда да Г. Тукай иҗатын өйрәнүгә кимчелек килмәс иде дип уйлыйм. 4—5 классларда шагыйрьнең үз әсәрләре генә түгел, ә аның турында башка язучыларның

[1] Урта мәктәп программалары. Татар теле һәм әдәбияты. Казан, 1975 ел, 35—37 битләр.
[2] Г. Әминев, М. Галләмова. Әдәбият. V класс өчен дәреслек-хрестоматия, Казан, 1975 ел.

әсәрләре дә өйрәнелә. 5 класс дәреслегендә, мәсәлән, И. Нуруллинның «Гафуров ничек Тукаевка әйләнде» һәм «Көзге җилләр исәр алдыннан» дигән хикәяләре кертелгән. Минем карашка бу хикәяләрне 5 класс укучысы тулысынча аңлап кабул итә алмас. Чөнки И. Нуруллин шактый хәзерлекле, Тукайның тормыш һәм иҗат юлы белән тулырак таныш укучыны күздә тотып яза. Хикәяләрдә күп мәгънәле яки күчерелмә мәгънәдәге сурәтләр бар. Мәсәлән, «Казан Тукайны кул изәп чакыргандай төсле тоела башлады»; «Ләкин Уральск чабудан тоткан»; «Печән базары исе чыга башлады» һ. б. Ни өчен Тукай Казанга ашкынып кайта? Казан аны ничек кабул итә? Ни өчен шагыйрьдә каршылыклы хисләр туа? Укучы бу сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба алмас дип уйлыйм. Бу урында, шул чор атмосферасы белән бәйләп, хикәяләргә аңлату соралып тора. Ләкин дәреслектә андый аңлатма юк. Шуңа күрә бу хикәяләрне 7 класс дәреслегенә күчергәндә яхшырак булыр иде. Чөнки 7 класста Г. Тукайның «Пар ат», «Бер татар шагыйренең сүзләре», «Көзге җилләр» кебек катлаулы сурәтләргә нигезләнгән шигырьләре өйрәнелә. И. Нуруллин хикәяләре бу әсәрләрне ныграк аңларга ярдәм итәр иде. 5 класс дәреслегенә исә Ә. Фәйзинең «Тукай» романыннан өзекләр урнаштыру яхшырак булыр төсле. Бу әсәр 4 класста өйрәнелгән «Исемдә калганнар»ны дәвам итәр, укучыларның белемен тулыландырыр, укучыларның Г. Тукайга карата үз мөнәсәбәтләрен дә формалаштырырга ярдәм итәр иде.

Өченче бүлек укучыны Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорына алып керә. Бу бүлек әдәби әсәрләрне бер тема тирәсенә җыйса да, аларның әһәмияте, әдәбиятта һәм язучының үз иҗатында тоткан урыннары ягыннан шактый чуар. Г. Гобәйнең «Маякчы кызы», А. Шамовның «Госпитальдә» әсәрләре укучыларда матур хисләр уята, күңелләргә уелып кала. Бу әсәрләр укучыга илебезнең бик әһәмиятле чоры турында белем бирәләр, татар әдәбиятының көчен, байлыгын раслап торалар. Ә менә Ш. Усманов, Ә. Ерикәй иҗатлары иң әһәмиятле әсәрләре белән тәкъдим ителгән дип әйтеп булмый. Ш. Усмановның «Гает корбаны» хикәясе диннең зарарын күрсәтү өчен язылган. Ә бүлекнең исемен искә төшерсәк, гражданнар сугышы чоры героикасын чагылдырган, язучының шәхесен дә тулырак гәүдәләндергән әсәре — «Легион юлы» алынырга тиеш иде.

Өченче бүлек «Бөек Октябрь социалистик революциясе һәм гражданнар сугышы турында әдәби әсәрләрдән үрнәкләр» дип аталса да, анда Октябрь революциясе турында сөйләрлек бер әсәр дә күренми.

«Татар совет әдәбиятында Ленин образы» дип исемләнгән дүртенче бүлек җиде әсәрдән тора. (Һ. Такташ, Х. Туфан, М. Ногман, И. Гази, Р. Ишморат, С. Хәким һәм З. Нури әсәрләре.) Сүз дә юк, уңышлы әсәрләр алынган. Ләкин укучыда Ленин турында әсәрләр шушылар гынамы икәнни дигән сорау туарга мөмкин. Башта кыска гына аңлатма бирелсә яки ахырында тулырак исемлек китерелсә, мондый аңлашылмаучылыкка урын калмас иде.

Дәреслекнең соңгы бүлеге — «Социалистик хезмәт темасына багышланган әдәби әсәрләрдән үрнәкләр». Алар тагын да азрак: Ш. Маннурның «Гайҗан бабай» поэмасыннан өзекләр һәм Н. Баянның «Комбайнчы Гөлсем» һәм «Уянсыннар кырлар» шигырьләре. Социалистик хезмәт дигәч тә, 5 класс укучысының күз алдына бүгенге көн гигантлары, КамАЗ, БАМнар, космоска очулар киләдер. 12—13 яшьлек балаңы Гайҗан бабай һәм комбайнчы Гөлсем кичерешләре дулкынландырырмы икән? Һәрхәлдә, мондый зур темада бүгенге көн турында дәшми калу аңлашылып җитми.

Дәреслек-хрестоматиягә кертелгән әдәби материалларны күзәтеп чыккач, гаҗәбрәк күренеш ачыла, бүлек исемнәре әһәмиятлерәк, зуррак була барган саен, әсәрләр кечерәя, вагая баралар. Нәтиҗәдә укучы татар әдәбиятын үсештә, хәрәкәттә, бер бөтен итеп кабул итә алмый. Татар әдәбиятын бөтен күләме белән дәреслектә чагылдыру турында сүз бармый, әлбәттә. Ләкин дәреслеккә татар әдәбиятының үсеш этаплары, язучының да төп әсәрләре алынырга һәм балалар әдәбиятының иң матур үрнәкләре дә кертелергә тиеш. Г. Гобәйнең «Замана балалары», «Без үскәндә», К. Нәҗминең «Яр буенда учаклар», «Якты сукмак», «Кояшлы яңгыр» әсәрләре бер класс дәреслегендә дә юк. 4 класста «Исемдә калганнар», 5 класста «Тормыш юлым» кебек автобиографик әсәрләр дәреслекләрне бизәп торалар. Бу матур традицияне алга таба да дәвам итәргә иде: Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек», Ф. Хөснинең «Минем тәрәзәләрем», Ш. Маннурның «Агымсуларга карап» әсәр-

ләре укучыларны хәзерге татар әдәбиятына якынайтырлар иде.

Бик урынлы сорау туа: дәреслеккә ничек сыйдырырга бу күләмне? Дәресләкләр программага буйсына. Димәк, иң беренче чиратта, программаны камилләштерү мәсьәләсе тора. Ләкин булган кадәр сәгатьләрне файдалану турында уйланырга урын бар. Мәсәлән, 5 класста «Көтүчеләр» хикәясенә 5 сәгать бирелгәндә, «Гайҗан бабай» әсәренә 4 сәгать, «Комбайнчы Гөлсем» шигыренә ике сәгать вакыт бирелгән. Минемчә, бу — сәгатьләрне иң уңышлы бүлү түгел.

Дәреслекнең сыйфатын билгеләүдә авторлар тарафыннан язылган аңлатмалар, биремнәр зур роль уйный. Дәреслекнең бу өлеше турында сүз алып барганда, Әминев тарафыннан язылган методик күрсәтмәне[1] дә искә алмый мөмкин түгел. Бу кулланма фәннилеге, дәреслек материалын методик яктан җентекләп аңлатуы, укучыларга белем бирү процессында кулланылырга тиешле алымнарны җиткерүе белән гаять файдалы. Кулланмада һәм дәреслектә проблемалы укыту, сәнгатьле укырга өйрәтүгә, укучыларда әдәбиятны үзләштерү күнекмәләре булдыруга зур игътибар ителә. Дәреслектәге мәкаләләр, биремнәр шулай ук максатлы, укучыларны мөстәкыйль фикерләүгә өйрәтү характерында төзелгән.

Шулай да дәреслекләрнең бу ягы да борчылулар, уйланулар тудыра әле. Ризасызлык тудыра торган иң зур җитешсезлек — әдәбиятның матур әдәбият икәнлеген, белемне турыдан-туры түгел, сурәт ярдәмендә биргәнлеген исәпкә алып бетермәү. Әдәби әсәрнең эчтәлеген каткат сөйләтәбез, хәтерләп калуларын таләп итәбез. Әдәбият дәресләре сәнгатьле итеп укырга, фикерләрне эзлекле итеп яза белергә өйрәтә. Укучының фикерләү сәләтен үстерүгә дә күп көч куябыз. Ләкин әдәбият дәресләре укучыны хис итәргә, кичерергә, гомумиләштереп әйтсәк, яшәргә дә өйрәтергә тиеш бит әле. Укучыда укыганына карата үз шәхси мөнәсәбәте формалашырга тиеш. Әдәби әсәрне укырга өйрәтү — һәр сурәткә, җөмләгә, сүзгә игътибар итәргә өйрәтү. Бу таләпләр бик мәгълүм, аларны гел кабатлап торабыз, ә тормышка ашыруга килгәндә, дәреслекләр һаман да әле бу югарылыкка җитә алмыйлар. 5 класс дәреслегендә дә текст өстендә эшләргә өйрәтү, сурәтне табып, аңа анализ ясап күрсәтү юк дәрәҗәсендә. Сурәт ясауда иң актив һәм әһәмиятле булган эпитетка, мәсәлән, мондый билгеләмә бирелә: «Эпитет — әйбер һәм күренешләрнең ямьле-ямьсез, ятышлы-ятышсыз, ягымлы-ягымсыз булулары ягыннан ачыклау өчен күчерелмә мәгънәдә кулланылган сүзләр». Бу, беренчедән, үзе шактый ямьсез билгеләмә. Икенчедән, монда эпитетның иң әһәмиятле төп роле әйтелми. Эпитетта — язучының, шагыйрьнең тормышны күрүе, сурәтләнгән предметка яки күренешкә мөнәсәбәте, хис-кичерешләре һәм, ниһаять, язучының ачышы. Әдәби әсәр дәреслектә эчтәлек, фикер ягыннан анализлана, әмма эчтәлек тә, фикер дә сурәттә яшәгәнлеге, язучы әсәрендә үзе гәүдәләнгәнлеге, ягъни әсәрнең субъектив ягы укучыларга аңлатылмый кала.

Соңгы бер фикер «укучыларның материалны үзләштерүләре» дигән төшенчәгә карый. Дәреслектә (һәм бу 5 класс дәреслегенә генә түгел, гомумән, әдәбият дәреслекләренә һәм программага да хас сыйфат) материалны үзләштерү дигәндә бер якны: укучыларның әдәбият турында гомуми мәгълүмат алулары, язучы биографиясе белән таныш булулары, әсәрнең эчтәлеген аңлап, хәтерләп калулары күздә тотыла. Укучының күңеле аша үтмәгән, аны дулкынландырмаган әсәр, никадәр яхшы итеп хәтергә бикләнсә дә, аны рухи баетмый, аның дөньяга карашын формалаштырмый. Бу — бик катлаулы һәм авыр мәсьәлә. Бурычның катлаулы булуы, кыенлыгы аны көн тәртибеннән алмый, киресенчә, бергәләп уйнау, эзләнүне таләп итә. Әсәрнең эчтәлеген сөйләтү, билгеләмәне кабатлау кебек алымнар гына җитми. Һәр дәрес материалына бәйләп, шәхес формалашуга игътибар итәргә, матурлыкны тою хисен үстерүне максат итеп куярга кирәк. Әдәбияттан белемне үстерү кешелек сыйфатларын да үстерү дигән сүз бит. Алган белемнең файдасы, тормышчанлыгы шушы мәгънәдә катлаулы күренеш итеп аңланырга тиешле.

Югыйсә, Г. Әминевнең бик акыллы язылган кулланмасында сәер бер фикер бар: «Укучыларның 4 класста алган белемнәре өле беркайда да файдаланылмаган. Тормыш өчен кирәксез бер белем төсле булып калган. Хәзер әнә шул тәэсирне юкка чыгару — изге бурыч. Укучылар үзләренең 4 класста алган белемнәрен-

[1] Г. Әминев. V класста әдәбият. Казан, 1973 ел.

нән бик нык файда күрергә тиешләр. Аларның шул белемнәрне бүген эшкә төшерүләре өчен, гомумән, язма эшләре өчен, журналга билгеләр куела».

Журналда яхшы хәтере һәм язма эше өчен «5»леләр тезелеп торган, хисләргә ярлы, матурлыкка, кеше кичерешләренә битараф булган укучы да булырга мөмкин бит әле, аны ничек дип атыйк икән: белемле, материалны бик яхшы үзләштергән диикме?

Бу мәсьәләләр, әлбәттә, дәреслек кенә хәл итәргә тиешле, аның гына вазифасы булган проблемалар түгел. Дәрес ул — җанлы процесс һәм укытучының роле анда алыштыргысыз зур. Ләкин укытучыларның да белем дәрәҗәләре, хәзерлекләре, тәҗрибәләре һәм талантлары төрлечә бит әле. Өстәвенә, һәркайсы өчен программа, дәреслек төп юнәлеш бирүче, мәҗбүри булган кулланмалар. Шуңа күрә әдәбиятны укытуның сыйфаты, иң беренче чиратта, программага, дәреслекләргә бәйле.

## Шәйхи Садретдинов

# ДУС ҺӘМ СЕРДӘШ ИТЕП...

7нче класс өчен дәреслек-хрестоматия[1] татар әдәбиятының иң күренекле әдипләрен һәм аларның әһәмиятле әсәрләрен эченә ала. Әдәбиятны яхшы белүче квалификацияле авторлар тарафыннан язылган бу китапта Г. Тукай, М. Гафури, Ш. Камал, Г. Ибраһимов, К. Нәҗми, Һ. Такташ, К. Тинчурин, Г. Бәширов, М. Җәлил, Г. Әпсәләмов һәм Ә. Еники кебек әдипләрнең иҗат биографияләре бирелә. Дәреслек белән танышкач, татар әдәбиятының Г. Тукай һәм М. Гафурилар заманыннан алып бүгенге көннәргә кадәр булган үсеш юлы күз алдына килә.

Дәреслек-хрестоматия халык шагыйре Г. Тукайга багышланган бүлек белән ачыла. М. Мәһдиев тарафыннан җыйнак итеп, җиңел, йөгерек тел белән язылган бу өлештә Г. Тукай иҗатындагы социаль мотивлар ассызыклап күрсәтелә, шигырьләр дә уңышлы сайланган. («Бер татар шагыйренең сүзләре», «Сафия», «Золым», «Буран», «Китмибез!», «Олуг юбилей мөнәсәбәте илә халык өмитләре».) Мәкаләнең үзәгенә реакция көчләренә күкрәк киереп каршы торган шагыйрьнең халык белән аерылгысыз бәйләнеше, аның иҗатында ил һәм халык язмышы кебек зур мәсьәләләр куелган. Шуны да әйтергә кирәк, шигырьләрне биргәндә автор Г. Тукай җыентыкларында кабатланып килгән кайбер ялгышларны да төзәтә. Мәсәлән, «Сафия» шигырендә:

Ярда торгач, ач халыкка йөз дә бормый,
туп-туры
Юргалый ул шунда тиз-тиз, кайда бай сафиясе[1],

— дип басылып килә иде. Бай ярда торды ни дә, пароходта торды ни — шигырьнең идея эчтәлеген ачуда моның берниндиәһәмияте юк. Шушы бер хәреф хатасы, әсәргә мәгънәви буталчыклык кертеп, һаман яши бирә иде. Дәреслектә бу юл:

Ярда торган ач халыкка йөз дә бормый,
туп-туры

— дип төзәтеп басылган.

Ләкин дәреслек авторларына бу юнәлештә эзлеклерәк булырга иде. М. Гафурига багышланган бүлек Г. Тукайның «Мәкаләи махсуса»сыннан алынган өземтә белән башланып китә. Тукай җыентыкларында бу өземтәнең соңгы өлеше: «Ни эшлик соң? Шагыйрь идек — әле генә язмыш ханым кыйнаган, елар идек — әле күздән яшебез дә кипкән»[2], — дип

[1] Г. Кашшаф, М. Мәһдиев, Ф. Миннуллин. Әдәбият. 7 класс өчен дәреслек-хрестоматия. Казан, 1975 ел.

[1] Габдулла Тукай. Әсәрләр. Дүрт томда. 2 том, Казан, 1956 ел, 150 бит.
[2] Шунда ук, 4 том. 150 бит.

басылып килә. Гәрчә татарча алай сөйләмиләр һәм Г. Тукай да алай язмагандыр. Бу да — типография хатасы гына булырга тиеш. «Яшебез дә кипмәгән» яисә, һич югында, «кипкән генә» кирәк. Дәреслектә дә (тиешле аңлатмасы беләнме) төзәтеп бирергә иде.

М. Гафури һәм Ш. Камалга багышланган бүлекләр шулай ук җылы тәэсир калдыра. Автор, М. Гафуриның язмыш тарафыннан кыйналуын күрсәтү белән бергә, шагыйрьнең полиция һәм жандармерия тарафыннан эзәрлекләнүен дә яктыртып уза. Ш. Камалның «минем һәрбер хикәям үз күз алдымнан, үз җилкәмнән үткән хәлләрдән, вакыйгалардан алынып языла, үз әйләнә-тирәмдәге кешеләр сурәтләнә. Яшь булсам да, шактый күпне күрергә туры килде», — дигән үз сүзләре китерелеп, әдип иҗатының шушы ягына, хезмәт ияләре белән аерылгысыз бәйләнешенә басым ясала. «Кара йөзләр» һәм «Акчарлаклар» повестьларына бирелгән аңлатма-анализлар укучыларның аңына гына түгел, күңеленә үтәрлек, йөрәгендә уелып калырлык итеп, җылы һәм матур итеп язылган. Язучыларның тел-стиль үзенчәлекләре, әсәр тукымасында пейзажның роле, образлар системасы һ. б. компонентлар гади һәм төгәл итеп аңлатыла. Г. Ибраһимовка багышланган бүлектә, язучының гаҗәп талантлы, киң колачлы зур әдип булуы белән бергә, аның җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе булуы да әйбәт ачыла. «Кызыл чәчәкләр» повестеннан соң бирелгән анализ исә язучының теленә, стиленә махсус игътибар юнәлтүе белән ота. Бу урыннар коры сүзләр белән түгел, ә ниндидер эчке бер җылылык белән, гүяки укучының янәшәсендә сөйләшеп утырган кебек итеп язылган: «Язучы теленең нинди могҗизалар тудырырга сәләтле булуын белергә теләсәгез, Галимҗан Ибраһимов әсәрләрен күбрәк укыгыз, — ди мәкалә авторы. — Ифрат камил эшләнгән музыкаль симфония кебек аның теле. Ул тел билгеле бер настроение тудыра, тон ясый, рәхәтлек бирә. Әсәренә, алынган материалның характерына карап, искиткеч җылы, якты, лирик та, ямансу да, кырыс та, шомлы да ул» (174—175 битләр).

Башка язучыларга һәм шагыйрьләргә караган очерклар да, гомумән, әйбәт тәэсир калдыра. Укучыларның яшь үзенчәлекләре, белем дәрәҗәләре искә алынып, иҗат биографияләре гади, җыйнак итеп, образлы тел белән язылган. Авторлар теге яки бу әдипнең индивидуаль иҗат йөзе нидән гыйбарәт булуын да күрсәтергә тырышканнар. Бу уңайдан материалны бирүдә төрле алымнар кулланылган. Язучы иҗатының үзенчәлекле яклары я турыдан-туры аңлатыла, яисә «Ни өчен Такташ шигыре шундый куәткә ия?», «Ә. Еникинең язучы буларак үзенчәлеге нәрсәдә?» кебек проблематик сораулар куела. Нәтиҗәдә һәр язучы үзенә хас сыйфатлары белән күз алдына килә: һ. Такташ шигырьләренең интонациягә бай булуы, К. Тинчуринның күпкырлы таланты, төрле жанрларда, сәнгатьнең төрле өлкәләрендә уңышлы эшләве, Г. Бәширов һәм Ә. Еникиләрнең үз иҗатларына гаять таләпчән караулары, М. Җәлилнең искиткеч поэтик һәм гражданлык батырлыгы, Г. Әпсәләмовның күп һәм нәтиҗәле иҗат итүе һ. б. Укучылар К. Нәҗминең «Язгы җилләр», Г. Бәшировның «Намус», Г. Әпсәләмовның «Газинур» романнары, К. Тинчуринның «Кандыр буе» пьесасы, һ. Такташның «Сыркыды авылы», «Мокамай» поэмалары, М. Җәлилнең «Сандугач һәм чишмә», «Ана бәйрәме» һ. б. шигырьләре, Ә. Еникинең «Кем җырлады» хикәясе белән танышалар. Дәреслектә бу әсәрләрнең язылу тарихы, образлар системасы, сурәтләү чаралары да яктыртыла.

7 нче класста татар әдәбияты әле бер бөтен процесс буларак өйрәнелмәсә дә, теге яки бу уңайдан әдәбият үсешендә күчемлелек, буыннар эстафетасы, традиция һәм новаторлык, әдәби бәйләнешләр кебек мәсьәләләргә дә кагылып үтелә. Мәсәлән, Г. Тукай һәм М. Гафури поэзиясендәге аваздаш мотивлар, К. Нәҗминең яшьтән ук Г. Тукай, М. Гафури, Ш. Камал кебек язучыларның әсәрләре белән танышуы, аның иҗатының үсеп китүенә Л. Толстой, М. Горький йогынтысы, һ. Такташка Г. Ибраһимов, Г. Нигъмәти киңәшләре, шагыйрьнең Х. Туфан, К. Нәҗми, Г. Кутуй, М. Җәлил һ. б. белән дуслыгы. Яисә драматург К. Тинчуринны алсак, дәреслектә дөрес күрсәтелгәнчә, ул М. Фәйзинең «Галиябану» драмасыннан килгән традицияләрне алга таба үстерә, үз чиратында, Т. Гыйззәткә зур йогынты ясый. Т. Гыйззәт К. Тинчуринны үзенең остазы итеп саный. Китапта М. Җәлил әсәрләренең халык авыз иҗаты белән бәйләнеше һәм шагыйрьнең новаторлыгы нигезле аңлатыла. Г. Әпсәләмовның язучы булып китүендә М. Җәлилнең һәм ул җитәкчелек иткән әдәби түгәрәкләрнең роле, Г. Әпсәләмов

иҗатында Г. Ибраһимов, Ш. Усмановлар иҗатыннан килә торган сыйфатларның яңаруы күрсәтелә һ. б. Болар барысы да катлаулы әдәби процессны ачыграк, тулырак күзалларга ярдәм итә.

Дәреслек-хрестоматиядә, теге яки бу әсәр уңае белән, әдәбият теориясеннән кайбер төшенчәләргә аңлатмалар бирелә. Шигъри әсәрләр мисалында метафора, эпитет, чәчмә һәм тезмә сөйләм, рифма, ритм, строфа, лирик поэзия, риторик эндәш кебек терминнар аңлатыла. Прозага килсәк, «Кара йөзләр» әсәре мисалында повесть турында төшенчә бирелгән. Шул урында ә хикәя кайда дигән сорау туа. Чөнки бу төшенчәгә аңлатма 5—6 нчы класс дәреслекләрендә дә юк. 7 нче класста «Язгы җилләр», «Намус», «Газинур» романнары үтелә. Ләкин дәреслектә роман жанрына аңлатма күренми. Әдәби жанрлар турында төшенчә бирүдә системасызлык күзгә ташлана. Повесть турында сөйләгәндә бер «Кара йөзләр» белән генә чикләнмичә, мисалга «Акчарлаклар»-ны, «Кызыл чәчәкләр»не дә алып, аларга хас уртак сызыкларны табып, гомумиләштереп аңлатырга кирәктер. «Язгы җилләр», «Намус», «Газинур» мисалында роман төшенчәсен бирү зарури. Кайбер төшенчәләргә кыска гына аңлатмалар, билгеләмәләр әсәрне анализлаганда бирелгән. Мәсәлән, М. Җәлилнең «Сандугач һәм чишмә», «Ана бәйрәме» уңае белән — баллада, Г. Әпсәләмовның «Газинур» романын анализлаганда композиция телгә алына. Боларны «Әдәбият теориясе» өлешенә чыгарып, махсус рәвештә киңәйтеп биргәндә методик яктан уңышлырак булыр иде. Гомумән, «Әдәбият теориясе» өлешен системалырак һәм тулырак итеп күрәсе килә.

Сораулар һәм биремнәр нигезендә укучыларның мөстәкыйль фикерләүләрен үстерүгә ярдәм итәрлек итеп төзелгән. Ләкин кайбер төгәлсезлекләр, аңлашылмаган урыннар очрый. Мәсәлән, Г. Тукай биографиясенең үзендә шагыйрь яшәгән, булган урыннар, шәһәр-авыллар, күп кенә даталар һәммәсе дә бәйнә-бәйнә әйтелми. Ә сораулар һәм биремнәрдә: «Тукай яшәгән урыннарны язып, елларын да күрсәтегез», — диелгән.

Укучыларга белем һәм тәрбия бирүдә билгеле бер тәртип, бердәм дидактик һәм методик принциплар сакланырга тиеш. Ә дәреслек-хрестоматиядә бу принцип урыны-урыны белән бозылган.

Бер үк сүзләрне төрлечә язу, җөмлә эчендә я баш хәрефтән, я юл хәрефеннән бирү очрый. Мәсәлән, «Шагыйрь йоклый алмый. Тәрәзә артында җил елый», «Крестьяннарның елау тавышы» (10—11 битләр). Ә менә Такташ «бәбкәләрне үбә-үбә җылый» (229 бит). «Намус» татар әдәбиятын «Бөтенсоюз һәм дөнья аренасына алып чыга» (280 бит. «Бөтенсоюз» баш хәрефтән). 342 биттә шул ук сүз юл хәрефеннән язылган. Болар да укучыны саташтыра. Укучыларга адресланган басмалар нәшрият һәм типография хезмәткәрләреннән зур җаваплылык сорый. Монда һәр өтергә, сүзне юлдан-юлга күчерүгә кадәр зур игътибар һәм саклык кирәк. Чөнки укучы китапка, басма сүзгә, бигрәк тә дәреслеккә иң зур авторитет итеп карый. Авторлар телендә кайбер стилистик кытыршылыклар да очрый. Мәсәлән, Г. Ибраһимов «патша полициясенең ике катлы күзәтүе астында яши» (129 бит) дигән җөмләдә «Ике катлы күзәтү»нең мәгънәсе укучы аңына барып җитми. Янсә «Троицк — сәүдәгәрләр, байлар шәһәре» (29 бит). Фәкыйрьләр, хезмәт ияләре булмаганмыни ул шәһәрдә? «Кызыл чәчәкләр» повестендагы Фазыйл турында сөйләгәндә, «язучы бу образ аша революция елларындагы татар интеллигенциясенең хәлен чагылдыра» (174 бит), дип артык гомумиләштерү шулай ук урынсыз.

Язучыларның туган урыннарын күрсәткәндә мәгълүматларны, чыннан да, хәзергечә бирергә кирәк. Әйтик, Г. Әпсәләмовның туган районы, дәреслектә күрсәтелгәнчә, Рыбкино түгел, ә Ковылкино районы, К. Нәҗминең Петрякс районы түгел, Сеченев районы һ. б.

Дәреслектә урнаштырылган иллюстрацияләр вакыйгаларны, геройларны конкрет рәвештә күз алдына китерергә, укучыларның эстетик зәвыгын үстерергә ярдәм итәләр. 14 биттә — Тукайның «Пар ат» шигыренә, 79 биттә — «Кара йөзләр»гә, 286 биттә — «Намус» романына бирелгән рәсемнәр һ. б. әйбәт эшләнгән. Ә менә 55 биттәге рәсемдә Закир бик ямьсез, шыксыз итеп төшерелгән. Галимә мондый зур авызлы, тукмак борынлы ямьсез егетне ярата алыр идеме икән?!.

Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту буенча гомуми искәрмә һәм уйлану рәвешендә буларак, шуны да әйтәсе килә, әдәбиятны укыганда 7 нче класста ук ниндидер бер йомгаклау, түгәрәкләү ясап булмыймы? 8 нче класс укучылары борынгы

әдәбияттан алып Г. Камал иҗатына кадәр үтеп калалар. Шуннан соң аларның байтак өлеше урта белем бирүче һөнәр мәктәпләренә, училищеларга китә. Аларда исә татар әдәбияты укытылмый. 9—10 нчы классларда үтелә торган материалдан бу укучылар бихәбәр булып кала. Бу хакта уйланырга кирәк түгел микән? Яисә әдәбият теориясен аңлатканда уңай, уңышлы үрнәкләр белән бергә, кимчелекле мисаллар да китерергә кирәк түгелме? Заманында, мәсәлән, Г. Ибраһимов шулай эшләгән. Хәзер исә гел уңай мисаллар нигезендә генә укый-өйрәнә торгач, укучылар еш кына әдәби әсәрдә яхшыны начардан, уңышлы чагыштыру, метафора, рифма һ. б.-ларны уңышсызлыкларыннан аера белмиләр.

Кыскасы, программа һәм дәреслекләрне яхшырту турында байтак уйланасы да бар.

## Хатип Миңнегулов

# ДӘРЕСЛЕК ҺӘМ ПРОГРАММА

Татарстан Язучылар союзы идарәсенең әдәбият дәреслекләре хакында махсус сөйләшү оештыруы — бик вакытлы һәм әһәмиятле чара. Бу сөйләшү, беренчедән, гамәлдәге дәреслек-хрестоматияләрнең сыйфатын күтәрүгә ярдәм итсә, икенчедән, дәреслек авторлары һәм тиешле оешмалар арасындагы координация эшләрен яхшыртачак, өченчедән, әдәбият укыту мәсьәләләренә киң җәмәгатьчелекнең игътибарын арттырачак. Һәм, ниһаять, мондый киңәшмә әдәбият укытуның нәтиҗәлелеген арттыруга уңай йогынты ясаячак. Болардан тыш, бу сөйләшүнең тагын бер әһәмиятле ягы бар: ул дәреслек-хрестоматияләр төзү өлкәсендәге уңай тәҗрибәне гомумиләштерергә һәм пропагандалауга, эш принципларын һәм ысулларын ачыклауга ярдәм итәчәк. Югыйсә, бу өлкәдә төрлелекләр, бәхәсле моментлар яшәп килә. Мәсәлән, программа белән дәреслек мөнәсәбәтен ни рәвештә һәм нинди эзлеклелектә бирергә? Дәреслектә компиляция һәм оригинальлек ни дәрәҗәдә сакланырга тиеш? Дәреслек-хрестоматияләргә күләмле текстларны ничек урнаштырырга?..

Нинди генә дәреслек турында сүз кузгалмасын, иң әүвәл дәреслекләргә куела торган гомуми таләпләрне ачыкларга кирәк. Шунсыз аерым дәреслекнең кыйммәтен билгеләү кыен булыр. Дәреслек, иң беренче чиратта, укучыга адреслана. Укытучы өчен ул программада куелган мәсьәләләрне тормышка ашыруда төп ярдәмлек, чара гына. Дәреслек программадан чыгып, программага нигезләнеп төзелергә тиеш; анда мөһим тайпылышлар, җитди өстәмә-төзәтмәләр ясарга киңәш ителми. Чөнки программа — әдәбият укытуда дәүләтнең төп документы. Дәреслектә темаларның хәзерге гыйльми югарылыкта, фәнни эзлеклелекне саклап, укучыларга аңлаешлы формада, үтемле тел белән яктыртылуы шарт. Һәр тема һәм бүлектән соң материалны үзләштерүгә, укучыларның мөстәкыйль һәм иҗади фикерләвен арттыруга, әдәби үсешләрен көчәйтүгә юнәлтерлек сорау һәм биремнәрнең булуы зарури. Югары классларда һәр тема ахырында укучылар белергә тиешле әдәби әсәрләрне, мөһим фәнни хезмәтләрне күрсәтү дә киңәш ителә. Әдәби-теоретик төшенчәләр, билгеле бер система белән, характерлы әдәби күренешләргә бәйләнештә бирелеп барырга тиеш. Дәреслекләргә карата куелган таләпләрнең иң әһәмиятлеләре менә шулар.

Инде конкрет бер мәсьәләгә — 8 нче класс өчен әдәбият дәреслегенә күчик[1]. Дәреслек борынгы чордан алып 1907 елларга кадәрге әдәбиятны үз эченә ала. Күрәсез, шактый зур ара (сигез гасыр!) һәм

[1] М. Гайнуллин, М. Мәһдиев. Татар әдәбияты. Урта мәктәпнең 8 нче классы өчен дәреслек. Казан, 1975 ел.

гаять катлаулы чор. Китап инде берничә ел буена кулланылып килә, 1975 елда аның җиденче басмасы чыкты. Димәк, 8 нче класс дәреслеге өлешчә сыналган, тормыш сынавын үткән дияргә була. Китап гомумән уңай тәэсир калдыра. Техник ягы, иллюстрацияләре, нигездә, канәгатьләндерерлек. Кайбер кытыршылыкларны исәпкә алмаганда, авторларның тел-стиле дә шактый йөгерек һәм аңлаешлы. Теге яки бу теманы яктыртканда, мәсьәләне аңлатканда проблемалы сорау куеп, эчтәлекне шуңа җавап рәвешендә бирү дә үзен аклый. Бу отышлы алым аеруча беренче бүлектә күзгә ташлана. Һәр бүлектән соң укучыларга әдәби, гыйльми әдәбият тәкъдим ителә. Методик яктан бу — әйбәт күренеш. Дәреслек белән танышканда бүлек, бүлекчә исемнәрен уйлауга да җитди игътибар ителүен күрәсең.

Мәгълүм булганча, бездә әдәбият тарихы буенча дәреслекләр язуга тәҗрибәле галимнәр тартыла. Һәм бу, кагыйдә буларак, уңай нәтиҗә бирә. Билгеле бер дәвер әдәбияты һәм аерым проблемалар өстендә фәнни-тикшерену эшләре алып баручы әдәбиятчының дәреслек өчен язган мәкаләләре дә фәнни тирәнлеге белән аерылып тора. Бу хәл 8 нче класс дәреслегендә дә күзәтелә. Аеруча Г. Камал, З. Һади һәм «Татар драматургиясенең беренче үрнәкләре» дип исемләнгән бүлекләр гыйльми тирәнлекләре, әдәби процессны тоеп язылулары белән әйбәт. Бу принцип сакланмаган урында компиляция, дәлилсез һәм каршылыклы фикерләр өстенлек итә. Бу күренеш аеруча беренче бүлектә һәм Г. Кандалыйга багышланган мәкаләдә күзгә ташлана. Дәреслекнең ике бит ярымлык «Йомгак» өлеше фикери тыгызлыгы, курсны һәм гыйльми, һәм методик яктан гомумиләштереп куюы белән көчле тәэсир калдыра.

Дәреслек программага нигезләнеп төзелгән. Авторлар андагы эзлеклелекне саклауга омтылалар. Урыны белән кайбер өстәмәләр дә кертелгән. XIX йөз әдәбиятына күзәтү барышында Әбелманих Каргалы, Шәмсетдин Зәки, Һибәтулла Салихов, Мифтахетдин Акмулла, Яков Емельянов хакында кыска гына белешмә биреп китү бу дәвер әдәбиятын тулыландыра төшә. Шулай ук 1905—1907 еллардагы әдәбиятка бәйләнешле рәвештә авторлар шул чордагы культурага да тукталып әйбәт эшлиләр.

Программа белән дәреслек арасында кайбер искә алынмаган моментлар да бар. Мәсәлән, программада XII—XVIII йөзләрдә татар халкы тормышында булып узган иҗтимагый-политик вакыйгалар, үзгәрешләр һәм аларның әдәби процесска йогынтысы мәсьәләсен өйрәнү каралган. Дәреслек авторлары исә Казан ханлыгы бетерелгәннән соңгы вакыйгаларга гына тукталганнар. «1905 елгы революциягә хәзерлек елларында (1895—1905) татар әдәбияты» дип исемләнгән теманың да беренче өлешләре (азатлык хәрәкәтенең өченче этабы, татарлар арасында марксизм идеяләрен тарату, листовкалар һ. б.) дәреслектә искә алынмаган. Шулай ук авторлар «XIX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты», аеруча «Беренче рус революциясе елларында... әдәбият» бүлекләрен бәян иткәндә программадагы эзлеклелекне шактый үзгәрткәннәр. Мондый аермалар, әлбәттә, укытучылар өчен шактый уңайсызлыклар тудыра.

Программа белән дәреслекне чагыштыру процессында әдәбият программасын әле шактый камилләштерү кирәклеген күрәсең. Төрле кабатлаулар, системасызлык, гыйльми төгәлсезлекләр анда тулып ята. Мисалга «Борынгы татар әдәбияты» өлешен генә алып карыйк. Әдәбият фәне алга бара, яңадан-яңа фикерләр әйтелә. Ә программа фәннең күптәнге дәрәҗәсеннән чыгып төзелгән. XIV йөздә күренекле гуманист әдипләр яшәгән, Идел буенда дөньяви әдәбият шактый зур үсешкә ирешкән. XVII—XVIII гасырларга караган матур гына проза үрнәкләре бар. Боларның берсе дә программада телгә алынмый. Шәрык классик әдәбияты белән бәйләнеш, поэтик жанрлар һ. б. күренешләр дә читләтеп үтелә. Гомумән, 7—8 гасырлык әдәби процесска һәм андагы әдипләргә 4 сәгать, Заһир Бигиев кебек язучыларның бер үзләренә 8 әр сәгать вакыт бирү һич тә гаделлек түгел. (Сүз уңаенда шуны да әйтик: бу әдипнең «Өлүф яки гүзәл кыз Хәдичә» романы дәреслектә, соңгы фәнни казанышларны исәпкә алмыйча, һаман искечә аңлатылып килена.) Борынгы татар әдәбиятына вакытны берничә мәртәбә арттырырга кирәк. Урта мәктәпне бетереп чыккан һәр кеше үз халкының әдәбият тарихы белән билгеле бер дәрәҗәдә таныш булырга тиеш. XIX йөз әдәбиятын бирүдә дә һаман шул кадимидәге тәртип яшәп килә (1 нче Ватан сугышы, декабристлар хәрәкәте, университет ачылу, «Иван Костин» хикәясе һ. б.).

Әдәбиятны болай укытканда шул дәвердәге татар әдәбияты да, аның үзенчәлеге дә юньләп күренми. Бит бу чорда татарлар әдәби, гыйльми әсәрләр укыганнар, үзләре дә иҗат иткәннәр. Ә без аларны я читләтеп үтәбез, яисә бөтенләй күрергә теләмибез. Программаны композицион җәһәттән дә камилләштерү сорала. Мәсәлән, мәгърифәтчелек, вакытлы матбугат кебек мәсьәләләргә берничә бүлектә урын бирелгән. Бу нәтиҗәсез кабатлауларга этәргән. Мондый күренеш башка класс программалары өчен дә хас. Бер үк әсәрләрне тикшерү, хәтта ятлату («Китмибез» VII һәм X классларда ятлана), бер әдипне бер үк курста кат-кат өйрәнү (IX класста М. Гафури) һәм башка шундый мисалларны күпләп китерергә мөмкин булыр иде. 8 нче класста ятлау өчен бер генә текстның да күрсәтелмәве гамәлдәге программаның бер кимчелеге булып тора. Хәзерге вакытта кулланылучы әдәбият программасы мәҗбүри 8 еллык белем бирүне генә исәпкә алып төзелгән кебек. Ә инде хәзер без гомуми урта белемгә күчүне тәгәлләп киләбез. Бу хәл программаның да яңасын, камилен төзүне таләп итә.

Әдәбият тарихы буенча дәреслекләр язганда әдәби процессны, андагы закончалыкларны бирү аеруча мөһим. Программаның бу юнәлештәге җитешсезлекләре дәреслектә дә эссез калмаган. Борынгы һәм 19 гасырның соңгы чирегенә кадәрге әдәби хәрәкәт бик зәгыйфь күрсәтелгән. Әдәби закончалыклар тиешенчә ачылмаган. Әдәби күренешләр, язучыларның иҗатлары, ничектер, утрау сыман аерылып карала. Әдәбият тарихын халык тарихы белән бәйләү йомшак. Бу яктан татар әдәбияты дәреслеге рус әдәбияты дәреслекләренә караганда шактый кайтыш. Ә бит рус мәктәбендә укучылар махсус рәвештә Россия тарихын өйрәнәләр. Шуңа да карамастан, аларның 8 нче класс дәреслекләрендә әдәбиятның халык тарихы белән бәйләнешенә ныграк игътибар ителгән.

Дәреслектә каршылыклы фикерләр, төгәлсезлекләр шактый күп очрый. Кайберләрен санап китәм:

12 нче бит. «Татарларда чәчмә (проза) белән иҗат итү бик күптәннән башланса да, бу әсәрләр сакланмаганнар». Ә соң «Нәһҗел-фарадис» (1358), «Гөлестан биттөрки» (1391), «Җәмигъ-эт-тәварих» (1602) һ. б. әсәрләр кайда кала?

35 нче бит. «Идел буендагы төрки халыкларының борынгы әдәбиятында ике төрле сыйфат (юнәлеш) күзгә ташлана. Боларның берсе — ханнар тормышын мактау, сарай тормышын җырлау булса, икенчесе — дини үгет-нәсихәт». Бу — хата фикер. Бередә С. Сараи, Мөхәммәдъяр һ. б. ларның поэмалары да, лирик хискичерешләргә бай лирик парчалары да исәпкә алынмый.

37 нче бит. «Кандалый татар поэзиясенә дөньявилык алып килде». Ә бит аңа кадәрге шагыйрьләрнең иҗатыннан дөньявилыкка бик күп мисаллар китерергә мөмкин. Мондый төгәлсезлекләр, берьяклылыклар дәреслекнең башка битләрендә дә очрый.

Әдәбият тарихын өйрәнү барышында укучыларга әдәбият теориясе буенча да мәгълүматлар бирелергә тиеш. Шул максатны күздә тотып, 8 нче класста күп кенә әдәби-теоретик төшенчәләр аңлатыла. Аларның бер өлеше түбән классларда өйрәнелгән мәгълүматларны кабатлау, системалаштыру, ныгыту рәвешендә китерелсә, икенче бер өлеше беренче мәртәбә өйрәнелә башлый. Авторлар әдәби-теоретик төшенчәләрне иң характерлы әсәрләргә, әдәби күренешләргә бәйләп, фактик материал белән тыгыз мөнәсәбәттә яктыртырга омтылалар. Матур әдәбият, әдәбият тарихы, халыкчанлык, тема, идея, композиция, тип, типиклык һәм кайбер башка төшенчәләр уңышлы гына аңлатыла. Образ, гуманизм, новелла (хикәят), комедия, драма, конфликт кебек атамалар гомумирәк планда яктыртылган.

Әдәбият теориясенә кагылышлы мәгълүматларны бирүдә әле уйланасы урыннар бар. Мәсәлән, кереш өлештә гомуми төшенчәләрне яктырту әйбәт булыр иде. Ә без бередә халыкчанлык, партиялелек кебек атамаларга тиешле аңлатмаларны күрмибез. Дөрес, халыкчанлык телгә алына, әмма ул, ни сәбәптәндер, беренче бүлектә аңлатыла. Повесть төшенчәсе дә таралып, берничә биткә сибелеп бирелә (143, 152 һ. б. битләр). Кайбер терминнар әдәби процессны искә алмыйчарак аңлатыла. Мәсәлән, З. Һади иҗатына мөнәсәбәттә ритмик проза хакында искәрмә бирелеп (149—150 битләр), шушындый фикер әйтелә: «Татар әдәбиятында ритмик проза стилендә язу үрнәкләрен З. Һади бирде». Бу фикер төгәл түгел. Чөнки бу алым аңа кадәрге әдипләрдә дә очрый. Дастан, кыйсса, газәл, мәдхия, мәрсия, хикмәт, мисрагъ, вәзен, кафия һәм башка шундый

терминнар борынгы һәм 19 нчы гасыр әдәбияты өчен хас күренешләр. Җае туры килгәндә аларны бик кыска гына искәртеп китү һич тә зыянга булмас иде. Аларның һәр вакыт программада күрсәтелүе бик үк зарури да түгел. 8 нче класс рус әдәбиятында шигырь төзелешенә кагылышлы бик күп атамалар тәфсилле аңлатыла. Безгә дә бәлкем аерым поэтик терминнарны 8 нче класста ук аңлату кирәктер.

Укучылар әдәби-теоретик атамаларга еш мөрәҗәгать итәләр. Шуңа күрә дәреслек ахырына китапта теге яки бу дәрәҗәдә телгә алынган терминнар таблицасын бирү зарури. Бу укучыларга һәм укытучыларга җиңеллек тудырыр иде.

Дәреслек программаны конкретлаштыра, педагогик процессны оештыруга билгеле бер методик күрсәтмәләр дә бирә. Болар аеруча сорау-биремнәрдә ачык гәүдәләнә. Һәр бүлектән соң урнаштырылган сорау-биремнәр нигездә программа материалын үзләштерүгә, укучыларның әдәби белемнәрен арттыруга юнәлтелгән. Аларның шактый өлеше конкрет, укучыларның көче җитәрлек, уйландырырлык. Әмма урыны белән гади кабатлауга кайтып калырдай сорау-биремнәр дә очрый (105, 115 һ. б. битләр). 8 нче класс дәреслегендә идеологик характердагы, конкрет әсәргә бәйләнешле сораулар өстенлек итә. Ә инде художество күренешләрен, әдәби хәрәкәтне ачуга юнәлтелгән сорау-биремнәр аз. Укучыларга тәкъдим ителгән эшләрдә проблемалылыкны, төрлелекне көчәйтәсе бар. Бу яктан карaганда, минем үземә 10 нчы классның һ. Такташ, Ш. Камал бүлекләренә бирелгән сорау-биремнәр ошады. Алар әдипләр турында элек белгәнне дә, аларга хас үзенчәлекләрне дә ачуга юнәлтелгәннәр. Өстәвенә, алар укучыны фәнни әдәбият белән кызыксындырырга һәм язучыларның әдәби процесста тоткан урыннарын билгеләргә дә этәрәләр. 8 нче класс дәреслегендә дә нәкъ әнә шундый эзләндерерлек, уйландырырлык, әдәби үсешне тәэмин итәрлек сорау-биремнәрне күбрәк күрәсе килә.

Бездә соңгы вакытта әдипләрнең индивидуаль үзенчәлекләрен ачуга игътибар көчәеп китте. Бу — уңай күренеш. Әмма әдәбиятны тарихи аспектта өйрәнгәндә, индивидуаль үзенчәлекләр белән бергә, билгеле бер чор, агым өчен хас булган гомуми яклар да күрсәтелергә тиеш. Шулай түгел икән, әдәби процессның төп закончалыклары ачылмаячак, эзлексезлек туачак. Кызганычка каршы, яңа әдәбият дәреслекләрен актарганда, дәреслек авторларының, үзенчәлек, индивидуаль як белән мавыгып, гомуми моментларны бераз читтәрәк калдыруларын күрәсең. Бу хәл укучыларга тәкъдим ителгән сорау-биремнәрдә ачык чагыла. Мәсәлән, 8 нче класс дәреслегенең беренче бүлегенә куелган сорау-биремнәрнең һәммәсе диярлек борынгы һәм урта гасыр шагыйрьләренең үзенчәлекләрен ачуга гына юнәлтелгән. Ә аларга хас гомуми якларны күрсәтерлек бирем юк. Бу күренеш башка бүлекләрдә дә бер дәрәҗәдә күзгә ташлана.

Бу мәкаләдә мин 8 нче классның хрестоматиясенә тукталмадым. Узып барышлый бары шуны гына әйтәсем килә. Әдәбияттан хрестоматия программага һәм дәреслеккә нигезләнеп төзелгән. 1975 елда аның өченче басмасы чыкты. Әгәр дә 8 нче класс дәреслеген күләм ягыннан бераз арттырырга кирәк булса, хрестоматия бу яктан канәгатьләнерлек. Аның эчтәлеге, әсәрләрне сайлап бирү дә уңай тәэсир калдыра. Әсәрләр мөмкин кадәр эчтәлеккә зыян китермәслек кыскартылган. Бер генә искәрмәм бар: авыр аңлаешлы текстларның астөшермәдә сүзлеген биргәндә, әсәрләрне хәзерге телгә тәрҗемә итеп тору кирәк микән?! Сүзлек булганда, укучылар әсәрнең эчтәлегенә җиңел төшенәләр, оригиналь текст белән эш итү аларга әсәрне ныграк тоярга, андагы тел-стиль үзенчәлекләрен тирәнрәк үзләштерергә ярдәм итәр иде. Тәрҗемә исә балаларны җиңел юлга этәрә.

Тормыш белән бергә, әдәбият үзе һәм аның турындагы фән — әдәбият гыйлеме дә үсә. Яңадан-яңа әсәрләр языла, әдәбият тарихындагы күренешләрне, мәсьәләләрне яктырту камилләшә. Бу үсеш-үзгәрешне әдәбият дәреслекләрендә ничек чагылдырырга! Сүз дә юк, дәреслекләр стабиль булырга тиеш, фәнни һәм әдәби яңалыкларны балаларга укытучы үзе җиткерергә бурычлы. Әмма бу — бик гомуми җавап. Чынлыкта әдәбият укытучыларының әле шактый өлеше, нигездә, дәреслеккә генә таянып эш итә. Укучылар психологиясендә дә дәреслеккә инану гаять көчле. Шуңа күрә дәреслек физик яктан гына түгел, рухи яктан да искермәсен өчен, аның һәр яңа басмасын, әдәби-фәнни казанышларны исәпкә алып, тулыландырып, бетәйтеп бару кирәк. Гамәлдәге дәреслекләрдә исә

бу хәл күзәтелми. Мәсәлән, 8 нче класс дәреслегенең беренче һәм җиденче басмалары, нигездә, бер-берләреннән һич тә аерылмыйлар.

Соңгы сүз итеп шуны әйтәсе килә: дәреслекләрнең сыйфаты турындагы бу сөйләшү сүздә генә калмыйча, практик эштә, туачак дәреслек-әсбапларда, программаларда да чагылсын иде. Моны бездән чор, мәктәп таләп итә.

## Шәриф Асылгәрәев

# ДӘРЕСЛЕК һӘМ ТОРМЫШ

Тугызынчы класс укучылары әдәбият дәресләрендә моннан 50—60, хәтта 70 ел элек язылган әсәрләрне өйрәнәләр. Шуңа күрә дәреслекнең төп бурычларыннан берсе — укучыларда тарихи фикерләү, язучы иҗатына тарихи якын килә белү күнекмәләре тәрбияләү. Бу проблеманы авторлар[1] В. И. Ленинның сыйнфый җәмгыятьтә ике милли культура турындагы өйрәтмәләре яктылыгында хәл итәргә омтылганнар. Укучыларга матур әдәбиятның ил тарихы, халык тарихы, Ватан тарихы белән тыгыз мөнәсәбәттә үсүе, аның иҗтимагый фикер, сыйныфый көрәш этаплары белән тыгыз бәйләнештә булуы аңлатыла.

Әдәби әсәрләргә тарихи якын килү укучыларда образ-персонажларга, язучы тарафыннан күтәрелгән этник һәм эстетик проблемаларга шәхси мөнәсәбәт булдырырга булыша. Ләкин шуны онытмаска кирәк: сәнгать әсәренә, язучы иҗатына булган шәхси мөнәсәбәт кешенең яше арта, акылы үсә, камилләшә барган саен үзгәрә. Дәреслек авторлары бу факторны да исәпкә алганнар. Һәр темадан соң тәкъдим ителә торган сораулар һәм биремнәр тугызынчы класс укучысының яшь үзенчәлегенә туры китереп, аның белем дәрәҗәсен дә, тормыш тәҗрибәсен дә исәпкә алып төзелгән. Ләкин иң әһәмиятлесе шул, авторлар укучы игътибарын өйрәнелә торган әдәби әсәрнең, әдәби теманың тарихи нигезләрен ачып бирә торган фән казанышларына, фән яңалыкларына юнәлткәннәр.

Дәреслекнең тагын бер уңышлы һәм уңай ягын күрсәтергә кирәк. Мәктәптә укытучыдан ишетеп яисә дәреслектән укып алган мәгълүматлар вакытлар үтү белән онытылырга мөмкин. Ә кешене әхлакый, эстетик яктан баетуга, аңа үзлегеннән белем алырга ярдәм итә торган гыйлем эзләү күнекмәләре гомерлеккә кала. Ләкин бу күнекмәләр үзеннән-үзе барлыкка килми, аларны тәрбияләргә кирәк. Моның өчен укытучы җитәкчелегендә укучының даими эшләве таләп ителә. Менә шуның өчен дә хәзерге этапта укучыны китап белән мөстәкыйль эшләргә өйрәтү уку-укыту процессының үзәген тәшкил итә. Дәреслек шушы әһәмиятле моментны исәпкә алган һәм укучы, минем уемча, аңардан канәгать булырга тиеш. Чөнки авторлар укучының (укытучының да) эшен җиңеләйтү максатыннан чыгып, программада каралган обзор һәм монографик темаларны зур булмаган өлешләргә бүлеп, аларның һәрберсен аерым исем белән атыйлар. Ә бу, үз чиратында, бәян ителәчәк материалның кыскача планы да булып тора. Мисал өчен Г. Тукайның тормышы һәм иҗатына караган материалны алыйк. Ул «Беренче тәэсирләр», «Мәктәп баскычлары», «Хөррият хакында», «Аның юлы «социаллардай» иде...», «Сорыкортларга каршы хәнҗәр...», «Моңлы саз» чыңнары...», «Хөр яшәү даулашлары»н кетеп...» кебек исемнәр белән бирелгән. Бу темалар укучының җавабына план хезмәтен үтәргә дә, укытучы

[1] И. Нуруллин, М. Хәсәнов, А. Әхмәдуллин. Татар әдәбияты. 9 класс өчен дәреслек. Казан, 1975 ел.

әстәмә әдәбият тәкъдим иткәндә, аларны язма эшләрнең темалары итеп тә алырга мөмкин.

Дәрес, дәреслек укучыны мөстәкыйль эшләү күнекмәләренә өйрәтү алымнарын тәкъдим итми һәм ул соралмый да. Дәреслек материалына нигезләнеп бу эшне укытучы башкарырга тиеш. Әмма дәреслектә бирелгән сораулар һәм биремнәр укучыны турыдан-туры мөстәкыйль эшкә юнәлтә. Чөнки дәреслектә һәр сорауга тулы һәм төгәл җавап бирү күздә тотылган, укучы аны башка чыганаклардан үзе эзләп табарга тиеш. Мисал өчен, сораулар һәм биремнәрдән «Тирән тамырлар» романына иллюстрацияләр һәм әсәр буенча эшләнгән спектакль турында үзара фикер алышыгыз» (234 бит) дигән бирємне алыйк. Бу сорауларга җавап бирү өчен, укучы, беренчедән, биремдә күрсәтелгән иллюстрацияләрне эзләп табарга, икенчедән, спектакльне карарга, өченчедән, шул материалларны күзәтү, карау нәтиҗәсендә туган фикерләрен билгеле бер тәртипкә китерергә, системага салырга тиеш була. Моны мөстәкыйль эшнең бер төре түгел дип кем әйтә алыр?!.

Сорау һәм биремнәрне төзегәндә авторлар укучының турыдан-туры әдәби текстка мөрәҗәгать итүен дә күздә тотканнар. Чөнки әдәби текстны ясисә аннан алынган өзекләрне даими укыганда укучыда эстетик зәвык һәм әхлак нормалары тәрбияләнә.

Укучыда дөньяга материалистик караш, коммунистик әхлак нормалары тәрбияләү дәреслекнең буеннан-буена кызыл җеп булып сузыла. Анда укучыларыбызны халыклар дуслыгы, пролетар интернационализм һәм совет патриотизмы идеяләре рухында тәрбияләрлек бай фактик материал бар. Укытучы бу проблеманы барыннан да элек классик язучыларыбызның шәхси тормышлары үрнәгендә хәл итә ала. Чөнки алар тормышыннан чын батырлык, көр күңелле, тапкыр акыллы халкыбызга мәхәббәт, туган җиребезнең гүзәллегенә соклану, Ватанга турылыклы хезмәт итү фактларын теләсә күпме табарга мөмкин. Дөрес, мәктәп дәреслегендә аларның барысын да күрсәтеп булмый, ләкин иң әһәмиятлеләре чагылыш тапкан. Мәсәлән, сөекле шагыйребез Г. Тукайның, әлкән әдип Ф. Әмирханның шәхси тормышы һәр укучыга үрнәк булырлык итеп язылган. Г. Ибраһимов, М. Гафури, М. Фәйзи, Г. Коләхметовларның тормышларын яктырткан материаллардан да укучылар үзләре өчен үрнәк булырлык, файдалы һәм гыйбрәт алырлык фактларны күпләп таба алалар.

Тәрбия процессында язучы тормышындагы аерым фактлар әһәмиятле роль уйнасалар да, укучының тирә-юньдәге табигатькә, кешеләр тормышына, үз йөрәгендәге тойгылар хәрәкәтенә күңел күзе матур әдәбият, сәнгать әсәрләрен уку, өйрәнү процессында гына ачыла. Шуңа күрә язучыларыбызның әсәрләрен уку, өйрәнү әдәбият дәреслекләренең нигезен тәшкил итә дә. Ә дәреслек программада каралган матур әдәбият әсәрләрен укучы дөрес аңласын өчен компас хезмәтен үти. Авторлар матур әдәбият әсәрләрендә язучы күтәргән социаль, әхлакый һәм эстетик проблемаларның шул чорда өстенлек иткән иҗтимагый фикер һәм язучының дөньяга карашы белән нигезләнгән булуны күрсәтергә омтылалар. Әдәби әсәр темасы һәм проблемасының чынбарлык белән органик бәйләнешен күрсәтү максатыннан чыгып, дәреслектә махсус бүлекләр бирелгән. Мәсәлән, турыдан-туры анализга керешкәнче «Печән базары, яхут яңа Кисекбаш» поэмасына «Язылу тарихы һәм сюжеты», «Тирән тамырлар» романына «Әсәрнең язылу тарихы» дигән бүлекләр килә. Ләкин моннан авторлар әсәрнең эчтәлеген гадиләштереп, күп проблемаларны бер проблемага кайтарып калдыралар дигән фикер аңлашылмаска тиеш. Киресенчә, дәреслектә язучы сурәтләгән төрле тормыш картиналарының төрле проблемалар күтәргәнлеге искәртелә. Мәгълүм булганча, зур күләмле эпик һәм драматик әсәрләр һәр вакыт күп темалы, күп проблемалы, димәк, күп идеяле булалар. Ләкин аларны әсәрнең төп, үзәк проблемасы берләштерә. Мәсәлән, дәреслектә М. Гафуриның «Кара йөзләр» повесте турында әйтелгәннәргә йомгак ясап: «Галимә һәм Закирлар фаҗигасе аша сыйнфый тигезсезлеккә корылган җәмгыятьтә хезмәт ияләренең аяныч хәле күрсәтелә», (257 бит) диелә. Ләкин шушы проблеманы сәнгать чаралары белән чишү өчен, М. Гафурига шул вакыттагы катлаулы татар тормышының киң картиналарын сурәтләргә, шул социаль чынбарлыкта тәрбияләнгән типик характерлар иҗат итәргә туры килә. Авторлар

әдәби әсәрнең төп проблемасын билгеләү, аны укучыга җиткерү өчен образ-персонажларга мөрәҗәгать итәләр. Аларның эш-хәрәкәтләренә, уй-фикерләренә, холык-фигыльләренә анализ ясыйлар. Болай эшләү бөтен дәреслекләр, шул исәптән рус әдәбияты дәреслекләре өчен дә, хас күренеш. Димәк, әдәби әсәрне анализлаганда авторлар гомум абул ителгән положениегә нигезләнеп эш итәләр һәм образ-персонажларны аерып алу әсәрнең төп проблемасын билгеләргә комачауламый, киресенчә, булыша гына. Дәреслектә образ-персонажлар күп очракта изоляцияләнгән хәлдә, аерым-аерым түгел, бәлки башка образ-персонажлар, тирә-юнь (җәмгыять, табигать) чолганышында карала. Ә бу, үз чиратында, укучыга әдәби әсәр компонентларының үзара тыгыз мөнәсәбәттә яшәвен, эчтәлек һәм форма берлегенең табигатен тагын да тирәнрәк аңларга ярдәм итә. Кыскасы, 9 класс дәреслеге һәр яктан әйбәт тәэсир калдыра.

Шуның белән бергә, ул кайбер кимчелекләрдән дә азат түгел. Минемчә, иң җитди кимчелекләрнең берсе әдәбият теориясе мәсьәләләрен яктырткан материалның эчтәлегенә, күләменә һәм урнашу тәртибенә карый. Барыбызга да мәгълүм, урта мәктәпне тәмамлаганда укучының әдәбият тарихыннан гына түгел, теориядән дә системалы белеме булырга тиеш. Моны тормыш үзе таләп итә. Вузга керү имтиханнары тапшыручы абитуриентларның, кызганычка каршы, күбесе теориядән йомшак хәзерлек белән килләр. Биредә бөтен җаваплылыкны укучыларның үзләренә һәм әдәбият укытучысына гына йөкләү дөрес булмас, аның зур өлеше программа һәм дәреслекләр өстенә дә төшә.

Тугызынчы класс дәреслегендә, программа таләп иткән күләмдә, әдәбият теориясе мәсьәләләренә караган материал бар (54—56, 258—279 битләр). Ләкин ни өчен ул китапның ахырына чыгарылган — аңлашылмый. Аның күләме һәм эчтәлеге дә, укучыга системалы белем бирүдән бигрәк, белешмә, төшенчә бирүне күздә тота. Шуңа күрә укучы күп кенә әдәби категорияләрнең, әдәби күренешләрнең асылына төшенми, аларны конкрет әсәргә анализ ясаганда, бәя биргәндә куллана алмый. Мисал өчен әдәбиятның партиялелеге принцибын алыйк. Бу шактый катлаулы мәсьәлә китапның ике битенә (262—263) сыеп беткән. Укучы В. И. Ленинның «Партия оешмасы һәм партияле әдәбият» исемле мәкаләсен дә укыган, аның эчтәлеген дә күпмедер дәрәҗәдә хәтердә калдырган. Ләкин шушы принципка нигезләнеп әдәби әсәргә бәя бирә белми, чөнки әдәбият дәресләрендә ул моңа өйрәнмәгән, ә дәреслек конкрет мисаллар тәкъдим итми. Әдәбиятның сыйнфыйлыгы белән дә шул ук хәл. Ә бит РСФСР Мәгариф министрлыгының «О преподавании литературы в 8—10 классах общеобразовательных школ РСФСР в 1971—72 учебном году» дигән махсус хатында бу принципны тагын да эзлеклерәк тормышка ашыру таләп ителә. Минемчә, әдәбиятта халыкчанлык, әдәбиятның сыйнфыйлыгы һәм партиялелеге принципларына караган материалларны дәреслекнең ахырына түгел, киресенчә — алдына чыгарырга кирәк. Кайбер дәреслекләрдә ул шулай бирелгән дә (кара: «Русская литература. Учебное пособие по литературе для восьмого класса средней школы». «Просвещение», 1971). Бу принципларның укучылар тарафыннан шактый авыр үзләштерелүен исәпкә алып, уку елы башында ук махсус дәресләр оештырылса, яхшы булыр иде. Укучы шушы дәресләрдә алган белемен ел барышында камилләштерә, тулыландыра ала. Ләкин моның өчен дәреслектә урын алган һәр конкрет әсәр шушы принциплар яктылыгында анализланырга, шушы принциплардан чыгып бәяләнергә тиеш.

Инде иҗат методына тукталыйк. Укучы һәм укытучы бу мәсьәләдә дә ризасызлык белдерергә хаклы. Чөнки аның турындагы материал шулай ук үз урынында түгел, ул шактый соң бирелгән. Дөрес, монда бөтен җаваплылыкны программа үз өстенә алырга тиеш. Укучылар күргәндер, анда иҗат методы турында белешмә бирү реакция еллары әдәбиятының ахырында гына каралган. Бу нормаль хәл түгел, билгеле.

Мәгълүм булганча, 8—10 классларда әдәбият тарихи-хронологик тәртиптә өйрәнелә. Иҗат методын белми, аңа таянмый торып, моны тормышка ашыру шактый авыр. Шуңа күрә иҗат методы турында белешмә тугызынчы класста түгел, бәлки сигезенче класста ук мәгърифәтчелек реализмын өйрәнү уңае белән бирелергә тиештер. Программа төзүчеләр бу урында бәлки критик реализм иҗат методын күздә тотканнардыр. Ул вакытта аны Г. Камал һәм Г. Тукайлар иҗаты ал-

дыннан бирергә кирәк иде. Алар да бит критик реализмның типик вәкилләре. Минемчә, И. Нуруллин «Реализм турында» (1974) дигән хезмәтендә әдәбият тарихын өйрәнүнең бер үрнәген бирде һәм ул аның нигезенә иҗат методлары принцибын алып, бәлки дөрес эшләгәндер дә. Югары класслар өчен әдәбият дәреслекләре төзегәндә дә шушы принцип нигез итеп алынырга тиеш түгелме икән?

Татар әдәбияты тарихын яхшы белгән кешене дәреслектә аның чорларга бүленеше дә канәгатьләндерми. XX йөз башы татар әдәбиятын укучы, программа һәм дәреслекләрдә күрсәтелгәнчә, 1895 нче елдан түгел, бәлки 1905 нче елдан башлап өйрәнергә тиеш. Югары уку йортларында (Казан дәүләт университеты, Казан дәүләт педагогия институты) студентлар аны шулай өйрәнәләр дә. Моның дөреслеге илнең һәм халыкның шул вакыттагы экономик үсеше, социаль үзгәрешләр, иҗтимагый фикер, азатлык хәрәкәтенең үсеше һәм әдәбиятның үз эчке закончалыклары белән раслана. Бу минем фикер генә түгел, соңгы вакытта матбугатта басылган фәнни хезмәтләрнең авторлары да шушы карашны яклыйлар.

Минемчә, реакция еллары әдәбиятына обзор ясамый торып, Г. Камал һәм Г. Тукай иҗатларын өйрәнү үзен тулысынча акламый. Чөнки аларның беренчесе драматургиядә, икенчесе поэзиядә критик реализмга нигез салучылар. Ә татар әдәбиятында критик реализм нәкъ реакция елларында формалашып җитте. Димәк, бу язучылар иҗатының үсеш-үзгәреш һәм күтәрелү чоры да шушы елларга туры килә. Шуннан чыгып, тугызынчы класс дәреслеген Г. Камал иҗатын да кертеп, реакция еллары әдәбиятына обзор белән башлап киту уңышлырак булыр кебек.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк: аерым кимчелекләре булуга карамастан, тугызынчы класс дәреслеге программа таләпләренә тулысынча җавап бирә. Яшь буынга белем бирүгә, аның дөньяга карашын, әхлакый нормаларын һәм рухи культурасын формалаштыруга кирәгенчә булыша.

## Рафаэль Мостафин

# ДӘРЕСЛЕК НИНДИ БУЛЫРГА ТИЕШ?

10 нчы класс өчен чыгарылган «Татар совет әдәбияты» дәреслеге [1], тулаем алганда, әйбәт тәэсир калдыра. Ул татар әдәбиятының Бөек Октябрьдан соңгы үсеш юлы турында шактый тулы һәм төпле мәгълүмат бирә. Анда гомуми күзәтү рәвешендә язылган бүлекләр аерым язучыларга һәм аларның иҗатына багышланган бүлекләр белән чиратлашып бара. Ш. Камалның «Матур туганда» һәм Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» исемле әсәрләре турында язылган бүлекләр миңа аеруча нык ошады. Дәреслекнең драматургиягә һәм бигрәк тә әдәби тәнкыйтькә багышланган өлешләре хакында алай әйтеп булмый. Тәнкыйть турындагы бүлекчә аеруча сай язылган.

Дәреслекнең гомум әдәби хәрәкәткә һәм шул хәрәкәттә аерым язучының тоткан урынын яктыртуга багышланган бүлекләренә тукталып тормыйм. Мин фәкать бер генә мәсьәләгә — дәреслектәге мәкаләләрнең тел-стиль якларына гына тукталырга уйлыйм. Соңгы елларда әдәби тәнкыйть кызыклы үзгәрешләр кичерә. Тәнкыйтьнең абруе, тәнкыйть мәкаләләренең ышандыру көче арта бара. Җитди уйлануларын һәм борчылуларын, тирән мәгънәле фикерләрен укучыга үтемлерәк итеп җиткерү өчен тәнкыйтьчеләр әдәби итеп,

[1] Г. Халит, И. Нуруллин, Х. Хайри, Н. Юзиев, А. Әхмәдуллин. Татар совет әдәбияты. 10 нчы класс өчен дәреслек. Казан, 1975 ел.

мавыгып укылырлык итеп язарга тырышалар. Алар яңа фикер әйтү белән генә чикләнмиләр, ә укучыларда җылы хистойгылар да уятырга омтылалар. «Эмоциональ яңгырашлы мәкаләләр язарга омтылу — хәзерге тәнкыйтьнең тәмам формалашып җиткән төп юнәлешләреннән берсе»,— ди Ф. Урманчеев [1].

10 нчы класс дәреслегендәге күп кенә мәкаләләргә нәкъ менә шул сыйфат җитми. Авторлар нигәдер бик коры, гаять дәрәҗәдә җитди, артык фәнни булырга тырышалар. Мәсәлән, дәреслекне ачу белән үк Г. Тукайның: «Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул...» дигән мәгълүм сүзләре китерелә. Һәм шушы бик гади һәм матур, аңлаешлы сүзләргә менә мондый аңлатма бирелә:

«Тукай фикерләрендә безнең прогрессив әдәбиятта чәчәк аткан халыкчанлыкның һәм тарихи оптимизмның чын мәгънәсе — халыкка һәм аның якты киләчәгенә ышанып, аның рухи көченә мәхәббәт белән иҗат итү идеалы бик матур гәүдәләнде» (3 бит).

Җөмлә төзелешенә генә игътибар итегез. «Фикерләрдә... идеал гәүдәләнде» булып чыга. Мәктәп укучылары өчен язылган дәреслектә шушы фикерне гадирәк итеп тә әйтеп булыр иде, билгеле.

167 биттә Муса Җәлилнең «Кисәк» исемле шигыреннән бер өзек бирелә. Һәм өзектән соң мондый аңлатма китерелә:

«Революцион рух белән сугарылган бу шигырьләргә шул чорга хас конкрет тормыш бизәкләренең җитмәвен дә, яңа хисләрнең ташып торуын, әмма сурәтле фикерләүдә традиционлыкның һәм шартлылыкның көчле булуын да әйтергә кирәк».

Белмим, укучылар ничек аңлыйдыр, мин үзем әлеге юлларны укыгач, шактый озак уйланып утырдым. Уйлана торгач, кайбер нәрсәләр аңлашыла да төсле. Авторлар, күрәсең, М. Җәлил шигыренең революцион рух белән сугарылган булуын, аңарда яңа хисләрнең ташып торуын мактап телгә алырга телиләр. Шул ук вакытта алар шигырьнең берникадәр абстракт булуын, әсәрдә конкрет тормыш детальләренең азрак булуын да кисәтеп үтәләр. Шулай да бу катлаулы җөмләнең ахыргы өлеше миңа аңлашылып җитмәде. «Сурәтле фикерләүдәге традиционлык һәм шартлылык» — кимчелекме, әллә уңай күренешме? Шартлы булмаган яки нинди дә булса традицияләрне дәвам итми торган сәнгать бармыни?! Димәк, авторга «традиционлык» һәм «шартлылык» төшенчәләренең мәгънәсен ачып бирергә кирәк булган. Нинди традицияләргә ияргән Муса бу чорда? Шартлы образлары ни өчен уңышсыз чыккан? Бу мәсьәләне ачыкламый торып, шагыйрь иҗатына тәгәл бәя биреп булмый.

Дәреслек ничек язылырга тиеш соң? Мавыктыргыч итепме, әллә менә шундый коры, фәнни тел беләнме?.. Минемчә, дәреслек мәктәп баласының психологиясен истә тотып, мөмкин кадәр гади, ләкин шул ук вакытта фәнни дә, тирән дә итеп язылырга тиеш. Без тикшерә торган дәреслектә артык фәнни булып күренергә тырышу авторларга зыян иткән һәм комачаулаган гына. Шул хакта сөйли торган берничә мисал китерик. 296 биттә сүз Хәй Вахитның «Беренче мәхәббәт» пьесасы турында бара:

«Тормышның катлаулы сорауларын хәл кылуда үзендәге мораль һәм ихтыяр көчен эшкә җиккән Тәлгать образын заманның алдынгы кешесе димичә булмый». «Мораль көчен» ничек итеп эшкә җигеп була икән?..

285 бит. Сүз Мирсәй Әмирнең «Тормыш җыры» исемле пьесасы турында бара: «Автор героинядагы мораль сафлыкны аның хезмәткә мөнәсәбәте белән көчәйтә». «Мораль сафлыкны» ничек итеп көчәйтеп була икән? Җитмәсә, хезмәткә мөнәсәбәт белән...

Биредә сүз аерым уңышсыз җөмләләр турында гына бармый, сүз принцип турында бара. «Фәннирәк» язарга тырышу авторларны катлаулы җөмләләр, төссез тел белән язарга этәргән. Дәреслек авторлары тикшерә торган кайсы гына язучыны алып карама — ул, һичшиксез, «катлаулы иҗат юлын» үткән, «иҗади үсеш авырлыкларын җиңеп», «тагын да югарырак баскычка күтәрелгән», аның осталыгы «һаман байый, үсә барган», аның һәрбер әсәре диярлек «социалистик реализм методын үзләштерү юнәлешендә барган». Әдип, еллар үткән саен, «тагын да югарырак баскычка күтәрелгән» һәм, ниһаять, әдәбиятта «мактаулы урыннарның берсен алган». Мондагы һәрбер сүз тезмәсе дәреслектән алынган. Һәм алар берничә үзгәрешсез диярлек уннарча мәртәбәләр кабатлана. Ә бит шаблон сүз тезмәләре

[1] Ф. Урманчеев. Тәнкыйтьченең осталыгы. «Казан утлары» журналы, 1975 ел, 8 сан, 171 бит.

шаблон фикерләүгә өйрәтә. Шундый тәссез, шаблон җөмләләр белән укучының эстетик зәвыгын тәрбияләп буламы икән?!

Дәреслектәге мәкаләләрне укыганда язучыларны бер-берләреннән аеру шактый кыен. «Г. Афзал да тормышның мәгънәле төрлелегенә үтеп керергә омтыла. Әмма ул тормыш катлаулылыгын гадилегендә кабул итә. Х. Камалга тормыш төрлелеге һәм катлаулыгы катлаулы булып тоелса, Г. Афзалга гади булып күренә» (254 бит). Шушы фикерне раслау өчен, Г. Афзал шигыреннән бер мисал китерелә:

Мин кайгырмыйм — кайгым булса да,
Ак болытлар йөзә күгемдә.
Мин еламыйм — күңелем тулса да,
Якты йолдыз яна күңелемдә.

Ләкин бит монда шагыйрьнең бары тик оптимист булуы гына күренә. Ни өчен соң Х. Камал катлаулы әйберне катлаулы итеп күрә, ә Г. Афзал гади итеп? Һич аңлашылмый.

271 бит. «Х. Туфан хәзерге заман кешесенең рухи дөньясын тикшерүдә, аның рухи байлыгын сурәтләүдә лириканың мөмкинлекләрен тагын да киңәйтә. Шагыйрь сурәтле фикерләүне бүгенге заман кешесенең рухи дөньясына кыю якынайта».

Белмим, бу әсәрне язганда, Х. Туфан «Сурәтле фикерләүне кешенең рухи дөньясына» якынайту турында уйладымы икән? Әлбәттә, аның шигырьләрендә кешенең рухи дөньясы чагыла. Һәм аның герое, һичшиксез, бүгенге заман кешесе. Әмма мондый «якынайтулар» укучының әдәбиятны аңлавына ярдәм итми.

281 бит. «С. Хәким шигырьләрендә татар халкының хәзерге рухи дөньясын, аның көнкүрешен, кешеләрен табигыйлеге, конкретлыгы белән тоябыз (ә кайсы олы шагыйрьдә бу шулай түгел?). Шагыйрь тормышны шундый якын кабул итә, хәтта аның әсәрләренә кешеләр, вакыйгалар турыдан-туры үзләре килеп керәләр».

Моны ничек аңларга? Сүз бәлки С. Хәким шигырьләрендәге реаль кешеләр, чынбарлыкта булган вакыйгалар турында барадыр? Алай булса, кайсы шагыйрь иҗатында андый реаль кешеләр һәм тормыш вакыйгалары юк?

Поэзия үсеше турында гомуми фикерләр, нәтиҗәләр ясаганда да төгәлсезлекләр киткән. 256 биттә, мәсәлән, сүз 1955 елдан соңгы поэзия турында бара: «Элегрәк поэзиядә кеше күңелендәге моң, борчылу, сагыш кебек аһәңнәр сирәгрәк урын ала иде. Кеше язмышы өчен борчылу, әрнү хәзер инде шигърият сазының бик кирәкле кылы булып китте».

Уйлап карыйк: Г. Тукай иҗатында «моң, борчылу, сагыш» булмаганмы? Һ. Такташ, Х. Туфан иҗатында «кеше язмышы өчен борчылу, әрнү» сирәк очрыймыни? Күрәсең, мондый гомумиләштерү өчен нигез юк. Мәсьәлә, минемчә, башкача куелырга тиеш. Әгәр 30—40 нчы елларда мондый сагыш, әрнү пессимизм дип бәяләнсә, хәзер инде безнең җәмәгатьчелек андый мотивларга башкачарак карый башлады.

257 бит. «Элегрәк интим лирика политик, публицистик лирикадан нык кына аерылып тора иде. Шагыйрьләр хәзер интим темаларның киң иҗтимагый яңгырашына ирешү юлында ныграк эзләнәләр».

Мондый катгый нәтиҗә белән шулай ук килешеп бетмәс идем. Г. Тукайда, Һ. Такташта, М. Җәлилнең Моабит циклында интим лириканы гражданлык хисләреннән аерып булмый. Әлбәттә, андый кимчелек безнең поэзиягә хас иде, ләкин — урта кул, йомшак әсәрләргә. Ул хәзер дә бар әле.

Дәреслектә кайбер җитди мәсьәләләрне артык гадиләштереп, хәтта примитив рәвештә аңлаткан урыннар да очрый. 162 биттә сүз ВКП(б) Үзәк Комитетының «Татарстан партия оешмасында массаполитик һәм идеологик эшләрнең торышы һәм аларны яхшырту чаралары турында»гы карары хакында бара. «Бу карар К. Нәҗмине «Язгы җилләр», И. Газизны «Онытылмас еллар», Ә. Фәйзине «Тукай» кебек зур күләмле, идея-эстетик әһәмияте ягыннан безнең әдәбият тарихында яңа сәхифәләр ачкан әсәрләр иҗат итүгә рухландырды». Мин, әлбәттә, бу тарихи карарның әһәмиятен инкарь итәргә җыенмыйм. Әмма югарыда китерелгән әсәрләр карар чыкканчы ук языла башлыйлар бит. «Онытылмас еллар», «Язгы җилләр», «Тукай» кебек әсәрләр бер карар нәтиҗәсендә генә барлыкка килмәгән, әлбәттә. Монда тормыш үзе, язучының иҗади биографиясе, аның идея ягыннан җитлегүе хәлиткеч роль уйнаган. ВКП(б) Үзәк Комитетының карары, беренче чиратта, язучының эстетик карашлары формалашуына тәэсир иткән һәм шуның аша бу әсәрләрдә дә чагылыш тапкан.

Гадиләштерүнең тагын бер мисалы:

«1934 елдан соң М. Җәлил татар халык иҗатын ныклап өйрәнә һәм аны үзенең

әсәрләрендә файдалана башлый» (174 бит).

Бу фикер белән килешүе кыен. Әлбәттә, М. Җәлил татар халык авыз иҗаты белән 1934 елга кадәр дә таныш була. Авылда туып үскән, әбисенең әкиятләрен, әнисенең җырларын канына сеңдергән Муса беренче шигырьләрен халык җырларына ияреп яза, фольклор образларын шигырьләрендә киң куллана. Әлбәттә, бу тенденция утызынчы еллар уртасында бигрәк ачылып китә. Ләкин бусы инде — икенче мәсьәлә.

Бәхеткә каршы, дәреслекнең барлык өлешләре дә мондый төссез тел белән язылмаган. Анда гади, матур, аңлаешлы итеп язылган урыннары да бар. Югарыда әйткәнемчә, миңа, мәсәлән, Ш. Камалның «Матур туганда» исемле романына бирелгән анализ ошады. «Әсәрне укып чыккач, барыннан да элек, күңелеңдә бәйрәм хис итәсең. Чөнки син гүзәл кешеләр белән очраштың, алардагы күңел матурлыгын күрдең, яңа тормыш хакына гомерләрен дә кызганмауларына сокландың... Синең шушы романдагы кешеләр кебек эшлисең, яшисең килә, алар башлаган эшне дәвам иттерәсең, үзеңне матурлыкның тантанасы өчен көрәшкә багышлыйсың килә» (90 бит).

Димәк, әдәби әсәр турында миңә шулай кешечә итеп, адәм аңларлык итеп тә язып була икән. Чыннан да, әгәр укучы күңелендә әсәрне укыганнан соң бәйрәм тойгысы кала икән, димәк, аның идеясе дә, сәнгатьчә эшләнеше дә камил булган. Димәк, язучы үз максатына ирешкән. Кызганычка каршы, бу принцип дәреслектә даими рәвештә сакланмый.

Йомгак итеп шуны әйтәсе килә: бездә, гадәттә, дәреслекләрне галимнәр яза. Бер яктан караганда, бу дөрес кебек. Галим үз өлкәсен яхшы белә, шуңа күрә тирән итеп, барлык яңа тенденцияләрне искә алып, аларны яктырта да алачак. Ләкин һәрбер галимнең дә балалар психологиясен, аларга хас стиль үзенчәлекләрен белмәве ихтимал. Дәреслек язу өчен үзенә аерым талант кирәк. Шундый талант ияләрен эзлисе, табасы, үстерәсе иде...

Гөлчәчәк Әдһәмова

# ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕ ҺӘМ ИНТЕРНАЦИОНАЛЬ ТӘРБИЯ

Яшь буынны социалистик интернационализм рухында тәрбияләү — совет мәктәбе алдында торган иң үзәк мәсьәләләрнең берсе. Бу эштә әдәбият дәресләренең хәлиткеч роль уйнавы бәхәссез нәрсә. Яхшылык, матурлык, камиллек турында уйлану, хыял итү — кеше табигатенең аерылгысыз бер сыйфаты. Кеше шунсыз яши алмый. Балаларда матур теләкләр уяту, киләчәк тормышка хыяллар уятуда әкиятләрнең дә роле бәяләп бетергесез зур.

Укучыларны интернациональ характердагы зур сәнгать әсәрләре белән кызыксындыру, аеруча революцион рухтагы әсәрләр белән таныштыру яшь буынны героик совет халкының матур традицияләре җирлегендә тәрбияләргә мөмкинлек бирә. Мондый эшләр яшь кешене тирән уйландыра, аларга җәмгыятьтә үз урынын табарга булыша. Сәнгать әсәрләре җирлегендә алар иҗади хезмәтне, аның бөеклеген, кешене бизи, матурлый торган характерын аңлыйлар, идея-политик яктан чыныгалар, җәмгыятькә файдалы кеше булырга омтылалар.

Безнең укучыларыбыз кыю, принципиаль булып үсү турында хыялланалар. Әдәбият дәресләре аларның бу хыялларын тормышка ашыруга юл күрсәтә, алар күңелендә туган күп төрле катлаулы сорауларга җавап бирә, ниһаять, шәхестә дөнья-

га коммунистик караш формалаштыруда хәлиткеч роль уйный. Тарихта тирән эз калдырган әдәби әсәрләр, халык иминлеге, азатлык, бәйсезлек өчен үзен аямаган әдәби геройларның образы укучыны тормышка әзерләүгә, аны рухи үстерүгә билгеле бер юнәлеш бирә. Шәхесне дөньяга марксистик-ленинчыл караш белән сугаруда, аның рухи җитлегүен тәэмин итүдә әдәбиятның мөмкинлекләре чиксез. Әдәбиятны фән буларак өйрәнү, сәнгать әсәрләрендә күтәрелгән социаль-политик, философик, экономик һәм иҗтимагый мәсьәләләрнең әдәби образлар күрәше аша сурәтләнүен аңлау укучыларга күп нәрсә бирә. Халык бәхете өчен үзен аямаучы, бөек максат хакына һаман алга омтылучы уңай образларга соклану тәэсирендә бу бөек идеаллар яшь кешенең үз карашына, үз ышанычына әверелә. В. И. Ленин 1920 елның 2 октябрендә комсомолның III съездында сөйләгән речендә коммунистик әхлак турында болай дигән иде:

«Хәзер без тәҗрибәгә таянып шуны әйтәбез: пролетариат кына таркау крестьяннарны ияртеп бара алырлык шундый тупланган көчне, эксплуататорларның барлык һөҗүмнәренә каршы торган көчне тудыра алды. Шушы сыйныф кына хезмәт иясе массаларга берләшергә, тупланырга һәм коммунистик җәмгыятьне бөтенләйгә саклап калырга, тәмам ныгытырга, аны тәмам төзеп җиткерергә ярдәм итә ала.

Менә шуның өчен без болай дибез: кешелек җәмгыятеннән тыш алынган әхлакны без танымыйбыз, ул — алдау. Безнең әхлак пролетариатның сыйнфый көрәш интересларына буйсындырылган»[1].

Әнә шул тарихи процесс, ягъни массаларның яңа тормыш өчен көрәше әдәбият әсәрләрендә тулы чагылыш таба. Әдәби образларның характеры, омтылышлары, эшчәнлекләре аркылы тарихи фактлар гәүдәләндерелә. Һәр әдәби әсәрне, анда чагылдырылган чорга бәйләп, тарихи яктан анализлау уңай нәтиҗә бирә. Социалистик реализм методы белән иҗат ителгән төрле жанрдагы әдәби әсәрләр халкыбызның, утлар-сулар кичеп, бөек җиңүгә ирешүен, ягъни дөньяда беренче тапкыр социализм төзү күренешен чагылдыруы белән характерлы. Мәсәлән, Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романында халык теләкләрен үзләрендә конкрет гәүдәләндергән эшче-крестьян вәкилләре Фәхри, Садыйк, Шәяхмәт, Гайшә һәм Шәрәфиләр яңа тормыш, яңа мораль өчен көрәшкән бер вакытта, Вәли Хәсәнов, Низами, Сираҗи кебекләр аларның эшенә аяк чалырга маташалар. Язучы әдәби геройлар аркылы шул чорның типик күренешләрен тасвирлый.

Урта мәктәптә программа буенча Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар», Һади Такташның «Гасырлар һәм минутлар», «Киләчәккә хатлар», Ш. Камалның «Матур туганда», Т. Гыйззәтнең «Ташкыннар» драмасы, Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» әсәрләре тәкъдим ителә. Бу әсәрләр өчен уртак бер концепция — яңа чорда яңа кешенең формалашу процессын күрсәтү. Шул темаларны өйрәнгәндә, әлбәттә, бу проблеманың, ягъни яңа кеше, яңа тормыш өчен көрәшнең, гомумән СССР халыклары әдәбиятында уртак тема икәнлеге аңлатыла һәм шул ук вакытта аның бүген дә — совет халкы тантаналы рәвештә коммунизм таңына барган бер тарихи чорда — көн тәртибендә бөтен кискенлеге белән торганлыгы әйтелә.

Безнең илебездә күп төрле милләт халыкларын дулкынландырган, иҗат эшенә рухландырган һәм законлы рәвештә СССР халыклары әдәбиятында зур урын алган уртаклык — тарихта тиңдәше булмаган социаль үзгәрешне — Бөек Октябрь социалистик революциясе казанышларын саклау өчен барган көрәш, яңа җәмгыять төзү процессында яңа кешенең формалашу күренешен сурәтләү темасы.

Тормышка турылыклы буларак, социалистик реализм әдәбияты билгеле бер чорда гәүдәләндерелгән кешене бөтен барлыгы — уңай һәм җитешсез яклары белән чагылдыра. Кеше психологиясенә хас булган икеләнү, шикләнү, сыйнфый каршылыкларның семья эченә үтеп керүен, иске идеологиянең агуы, диннең зәһәрлеге тирән киткәнлеген әдәби әсәрләр ачык күрсәтә. Мәсәлән, X класста Таҗи Гыйззәтнең «Ташкыннар» әсәреннән Биктимер карт образының идея үсешен күрсәтү аша ярлы крестьянның революциягә килү юлы ачыклана. Биктимер патша солдаты булган. Ул турылыклы кеше, ләкин әйләнә-тирәдәге явызлыкны ул күрми дә, белми дә. Ярлылык, фәкыйрьлек меңа язмыш нигезендә алдан язылып куелган, аны үзгәртергә берничек тә мөмкин түгел, дип уйлый ул. Шуңлыктан үз хакын дауламый, рәхимсез язмышына сүзсез буйсына. Биктимер генә түгел, күп еллар буена аның сыйныфдаш-

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. Дүртенче басмадан тәрҗемә, 31 том, 288—289 битләр.

лары — миллионлаган Россия крестьяннары да дәшмәгән. Газаплы тормыш өстенә, Беренче империалистик сугыш урам тулы ятимнәрне, гарипләрне, толларны китереп чыгара. Ә эксплуататор сыйныф вәкилләре моңардан файдаланалар, табыш артыннан куалар. Акча хакына балаларын сугыштан калдыралар, бурычка биреп тору юлы белән ярлыларны кабалага төшерәләр, үзләренә капитал туплыйлар. «Ташкыннар» драмасының төп образы булган Биктимер карт әнә шул явызлыкның һәм хаксызлыкның барлык рәхимсезлекләренә дучар була. Аның өч улын солдатка алалар. Берсе үлә, икенчесе югала, алма чәчәгедәй яшь кызы мәсхәрәләнә. Шуларның барысы өстенә җирсезлек, ачлык, хәерчелек аның җанын суыра. Бөтен өмет олы улы Мирвәлидә... Ул исән, ул кайта... Ләкин озакка түгел, аның артыннан күзәтәләр... Мирвәли кулга алына. Артык берни дә калмый. Ә яшәргә кирәк. Ничек? Алда бер генә юл, ул да булса көрәш!

Кичә генә улы Мирвәлинең эшчеләр хәрәкәтенә катнашмавын, андый-мондый шикле кешеләр белән аралашмавын үтенгән ата бүген үзе көрәш юлына басарга мәҗбүр була. Картның телгәләнгән күңелендә сызылып таң ата, кайдадыр еракта яктылык беленә, гүя ул озак йоклаганнан соң уяна, уянырга мәҗбүр була, революцион күтәрелеш еллары Биктимер күңеленең таңын якынайта... Ниһаять, ул актив оештыручы, солдаткаларның сүнгән күңелләренә якты маяк кабызучы, аларны үз хакларын даулап алу өчен актив көрәшкә туплаучы революция солдаты булып җитешә. Тормышның катгый таләбе буенча ул үз хакын даулау өчен көрәшкә күтәрелә.

В. И. Ленин бу хакта: «...Ярлы крестьяннарның хәерчелеге, сугыш дәһшәтләре, ачлык дәһшәтләре — барысы да массаларга пролетариат юлының дөреслеген, пролетариат эшенә ярдәм күрсәтүнең зарурлыгын һаман ачыграк һәм ачыграк күрсәтә баралар» [1], — дип язды.

Тарих, җәмгыять белеме кебек иҗтимагый фәннәрне өйрәнгән X класс укучыларына В. И. Ленинның бу сүзен китерү, хәтта аларның үзләреннән эзләтү бик урынлы була. Чөнки бу даһи сүзләрдә юлбашчының төрле милләт хезмәт ияләренең тормыш, көнкүреш, хәтта уй-теләкләрен, рухи үсеш дәрәҗәләрен билгеләве, кайгыртучанлыгы чагыла. Шуның өстенә алар Россия крестьяннарының көрәш юлын әдәби образ белән чагыштырып карыйлар һәм күп милләтле совет әдәбиятының бер тармагы булган татар әдәбиятының реаль фактларны яктыртуына иналар. Әдәбиятка бәйле рәвештә бөек көрәш еллары аларның күз алдына килә.

Дөньяда тиңдәше булмаган Октябрь социалистик революциясе һәм аның бөек юлбашчысы В. И. Ленин турында күбрәк уку, күбрәк белү яшь буынны совет патриотизмы һәм социалистик интернационализм рухында тәрбияләүгә зур өлеш кертә. Дәрестә Ленин образын һәм юлбашчының әдәбият-сәнгать турындагы хезмәтләрен өйрәнү дәвамында даһиның бөек идеяләре белән укучылар үзләре очрашалар. Тормышны үзгәртеп коруда революцион теориянең, әдәбият һәм сәнгатьнең ролен төшенәләр. Нәтиҗәдә шул бөек идеяләр белән коралланган коммунистик партия җитәкчелегендә кешелек дөньясында беренче булып Россиядә социалистик дәүләт барлыкка килүен аңлыйлар. Бу хәл исә аларның хисләренә тәэсир итә. Укучылар, нәкъ җырда җырлаганча, «җир шарында кояш булып тора безнең илебез» дигән идея белән сугарылалар. Бөтен дөнья халыкларына нур сипкән Ватан һәм аның дуслык, туганлык, тигезлек белән көчле булган күп милләтле халкының уңышларын күреп горурланалар. Без республикабызның төрле районнарындагы мәктәпләрендә тәрбияләнүче йөзләрчә укучыларның В. И. Ленин турында, Ватан турында эмоциональ хисләр белән уралган, дулкынлану һәм горурлану тойгысы белән сугарылган язма эшләрен укыдык.

Безнең алда — Әлмәт, Әтнә, Арча, Карабаш һәм Саба урта мәктәбе укучыларының иншалары. Нинди генә матур фикерләр юк аларда. Шунысы характерлы, яшьләр иншаларын иҗади итеп язганнар, төгә яисә бу әсәргә һәм художество әдәбиятына аларның үз карашы, үз мөнәсәбәте бар. Классик әдәбият әсәрләренә һәм совет әдәбиятының гүзәл үрнәкләренә анализ биргән вакытта аларның һәркайсы үзенчә фикер йөртә. Үзенең тирә-ягы, үз тормышы, үз омтылышы белән бәйли белә. Алай гына да түгел, укучылар үзләренең иҗади эшләрендә татар әдәбиятыннан мисаллар алу белән генә чикләнмиләр, рус әдәбиятына, хәтта СССР халыклары әдәбиятына да мөрәҗәгать итәләр. Әдәбият дәресләрендә, билгеле бер язучы иҗатына, аның билгеле әсәренә, художество образларына карата иншалар яздыру өстенә, рес-

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. 26 том, 42 бит.

публикада күпчелек укытучылар ирекле тема дип аталып йөртелгән гомуми темаларга карата да язма эшләр алалар. Болары исә яшьләрнең фикерләрен тагы да киңрәк ача һәм аларның дөньяга карашын, заман сулышын ничек тоюларын нечкәрәк итеп бәяләргә мөмкинлек бирә.

Яшьлек үзенең канатлы хыяллары, бетмәс-төкәнмәс энергиясе, иксез-чиксез хисләр өермәсе белән характерлы. Яшьләрнең уйлары, хыяллары, эмоциональ хисләре әдәбият дәресләрендә аеруча ачык чагыла, алар уйланалар, теге яисә бу язучының иҗаты турында тирән фикер йөртәләр, әдәби әсәрне тикшергәндә үзләренең хисләрен, тормышны күзәткәндә туган тәэсирләрен файдаланалар, бүгенге көн күренешләренә карата үзләренең мөнәсәбәтләрен белдерәләр.

Урта мәктәптә әдәбият программасы буенча бирелгән материалны укучылар укытучы җитәкчелегендә класста өйрәнәләр. Ә тормыш, бүгенге гигант адымнар белән алга баручы тормыш, үзе яшь кешене тагын да тирәнрәк уйландыра, аның каршында күп төрле сораулар туа, ул күпне белергә омтыла. Әнә шул омтылыш турыдан-туры әдәбият белән барып тоташа. Бүгенге тормышның сулышын әдәби процесстан башка нечкәләп сиземләргә мөмкин түгел. Шунлыктан, класста өйрәнелгән, класстан тыш укылган әсәрләр өстенә, укучылар бүгенге әдәбият, аның темасы, проблемалары, үзәк фигуралары белән кызыксыналар. Яңа чыккан әдәби китаплардан, журнал һәм газета битләреннән үзләренә рухи азык эзлиләр, үз теләкләренә аваздаш фикерләр табалар.

Совет халкының Бөек Ватан сугышы көннәрендәге (1941—1945) геройлыгын күрсәтүгә багышланган әсәрләрне өйрәнү процессында шул чор әдәбиятының төп герое — совет солдаты образы укучыларның күз алдына килә. Бүгенге укучы әдәбиятта сурәтләнгән уңай герой аркылы совет кешеләренең ил язмышы хәл ителгән авыр сынау көннәрендәге батырлыгын күрә. Ватан сугышы чорын сурәтләгән әсәрләрдәге әдәби образ кешенең чын матурлыгын, аның идея-мораль ныклыгы аркасында барлык авырлыкларны җиңеп чыгарга сәләтле булганлыгын аңларга тулы мөмкинлек бирә. Мондый образлар үрнәгендә укучыларда патриотизм, интернационализм хисе тәрбияләнә.

IV, VI, VII һәм X класста Муса Җәлил иҗаты өйрәнелә. Һәр класста, укучыларның яшь үзенчәлеген исәпкә алып, легендар шагыйрьнең бөеклеге аңлатыла һәм аның образы үрнәгендә коммунистик карашлар тәрбияләнә. Укучылар аның Советлар Союзы Герое икәнлеген, ягъни «изге сугыш антын соңгы чиккәчә керсез саклаучы» совет гражданы булуын истә тоталар, аның ватандашлары буларак горурланалар. Ленин премиясе лауреаты дигән исемгә лаек булган «Моабит дәфтәре» һәм ул дәфтәрнең бөтен дөнья халыкларына барып ирешелгән көчле юллары хакында класста укучылар белән әңгәмә үткәрелә. Шагыйрьнең «палач балтасына башын тоткан килеш» тә кешеләргә яңа дәрт, рух бирерлек горур, көчле җырлар язарлык тормыш юлы, бала чагы, комсомол еллары, университетта уку чоры һәм аның башлангыч иҗатында ук хыялын биләгән бөек идеал өчен көрәшкә омтылган герой образы укучыларны аеруча кызыксындыра.

М. Җәлил 1921 елда ук инде Карл Маркcның «Үләрбез, булмабыз кол» дигән сүзләрен эпиграф итеп ала һәм:

...Теләсәләр асарлар,
без үләрбез.
Ләкин һичбер вакытта
булмабыз кол [1],

— дип яза. Бу юллар бердәм рәвештә илне сакларга күтәрелгән совет кешеләренең чын теләген гәүдәләндерә. Ә инде Бөек Ватан сугышы чорында язылган:

Эзе калсын керсез намусыңның
Ни үтсә дә синең кулыңнан.
Көчлелегең белән горурланма,
Кешелегең белән горурлан!

— дигән юллар шагыйрьнең — совет гражданының фашистлардан никадәр өстен, көчле, горур икәнлеген аңлата. Шул хакта сөйләгәндә, укытучы Х. Якупованың «Хөкем алдыннан» дигән картинасын күрсәтә.

Үлем диеп әйтеп буламы соң
Җиңеп үлгән мондый үлемне,

— ди шагыйрь. Әледән-әле матбугатта чыгып торган материаллар аның бу горур сүзләрен исбатлыйлар.

Әдәбият укытуны киңрәк планда кую, аны чын мәгънәсендә хис итү, шәхеснең үз кичерешләренә, үз тормышына бәйләп карау кебек җитди мәсьәлә үзенә игътибарлы булуны сорый. Теге яисә бу әсәрне өйрәнүне илдәге вакыйгалар, тугандаш халыклар әдәбиятында күтәрелгән проблемалар киңлегендә өйрәнү тәҗрибәдә үзен аклый. Мәсәлән, «Хәзерге әдәбиятта сезнең

[1] Муса Җәлил. Сайланма әсәрләр. I том, Казан, 1955 ел, 42 бит.

иң яраткан героегыз һәм сез аның кайсы якларын аеруча бәялисез?», «Хәзерге заман поэзиясеннән сез кайсы шагыйрьне күбрәк укыйсыз?», «Семен Бабаевский, Гомәр Бәширов, Баязит Бикбай. Бу язучылардагы уртак тема турында сез ни әйтә аласыз?», «Ленин премиясенә лаек булган кайсы шагыйрьләрне беләсез?», «СССР халыклары әдәбиятыннан кайсы язучының иҗаты белән кызыксынасыз?», «Драматургия, театр сәнгате, кинематография сезне ни дәрәҗәдә кызыксындыра?», «Тукай премиясенә лаеклы булган язучылар, композиторлар, художниклар, артистлар, режиссерлар иҗаты белән сез танышмы?» кебек сорау һәм биремнәр тәкъдим ителә. Билгеле, болар һәммәсе укытучыдан күп хезмәт сорый, укучыларының белем дәрәҗәләрен, нәрсә белән кызыксынуларын, омтылышларын, әйләнә-тирәсен, кешеләр белән аралашуын, кешеләргә мөнәсәбәтен, үз-үзен бәяләү кебек сыйфатларын да исәпкә алырга тиешлеген искәртә. Әдәби геройлар тормышына бәйләп төрле типтагы сораулар кую, укучыларның ни сөйләүләрен игътибар белән тыңлау кемнең ничек фикер йөртүен, нәрсә белән сулавын белергә мөмкинлек бирә. «Нәҗип Җиһановның кайсы әсәрләре сезгә аеруча ошый?», «Бакый Урманчы кем ул, сез аның нинди әсәрләрен беләсез?», «Опера, оперетта, балет дигән терминнарны ничек аңлатасыз?» кебек, художниклар, композиторлар иҗатына кагылган биремнәр укучыларның рухи дөньясын, нәрсә белән кызыксынуын белергә мөмкинлек бирә. Мондый мәсьәләләр турында сүз барганда, татар сәнгатенә бәйле рәвештә, СССР халыклары тарафыннан иҗат ителгән, гомумән совет сәнгатенең олы хәзинәсенә әверелгән сәнгать әсәрләре турында да әңгәмә үткәрү укучыларда кызыксыну тудыра һәм интернационализм рухында тәрбияләүгә өлеш кертә.

Программа материалын үткәндә укучыны уйландыра белү, фикер йөртергә гадәтләндерү төп шарт. Дәрескә бәйле рәвештә алар әйләнә-тирәне дә күзәтәләр, табигать күренешләренең дә гүзәллеген танып беләләр, совет кешеләре тормышында хәлиткеч урын тоткан хезмәтне дә бәялиләр. Шуның өстенә яшь кешенең һәр нәрсәгә карата үзенең төпле карашы, мөстәкыйль фикере була. Бу сыйфатлар аеруча мөстәкыйль эшләр башкару дәвамында ачыклана.

Программа, дәреслек күләмендә генә белем бирү белән чикләнмичә, кешелек тарафыннан иҗат ителгән сәнгать әсәрләренә мәхәббәт тәрбияләү, тормышның үзеннән белем чыганакларын таба белергә өйрәтү дә — мәктәп алдында торган мактаулы бурыч.

Билгеле, мөстәкыйль эшләр дәрестә алган белемнәрне ныгытуга, нигезлерәк үзләштерүгә хезмәт итә. Укыту материалын кабатлау дәресләрендә укучыларның мөстәкыйль фикер йөртү җитезлекләрен үстерергә мөмкин.

Укучыларның класста телдән бирелгән җаваплары да, язма эшләрдә мөстәкыйль рәвештә язылган фикерләр дә яшьләрнең совет патриотизмы һәм социалистик интернационализм хисе белән сугарылганлыгын ачык аңлаталар. Яшь кешенең хисләре, хыяллары, үзенә генә хас булган эзләнүе бар. Язучылар иҗатына яисә хәзерге әдәбиятка бәйле рәвештә бирелгән эшләрне укучылар яратып башкаралар, һәркайсы үзенең фикерен әйтергә ашкына. Чыннан да, әдәбият яшьләрне тәрбияләүдә, аларның дөньяга карашын, характерын формалаштыруда иксез-чиксез рухи байлык чыганагы. Мәктәптә әдәбият укыту белем һәм тәрбия бирүдә, ягъни киләчәк җәмгыять өчен чын мәгънәсендә кадрлар хәзерләүдә иң үткен һәм нечкә корал.

## Туфан Миңнуллин

# НИЧӘ ЯШЬ?

ЭТЮД



Хәйбрахман бабай белән капка төбендәге бүрәнәдә утырабыз. Хәйбрахман бабай колакка катырак булса да, минем тавыш көчле, шуңа күрә бер-беребезне бик әйбәт аңлашабыз.

— Ничә яшьтә инде син, Хәйбрахман бабай?

— Фиврал ничә елга бер егерме тугыздан килә?

— Дүрт елга бер.

— Егерме ике тапкыр егерме тугызынчы фивралны күргән инде бу бабаң,— дип, Хәйбрахман бабай биш бармагы белән сакалын савып куйды.

— Тазалык ничек соң, тазалык?

— Болай ярыйсы да, бу арада йөткергәләп йөрим әле.

— Больницага барып күренергә кирәк.

— Күренер иең дә оят бит.

— Нәрсәсе оят?

— Соң, баргач фамилияңне сорыйлар, исемеңне сорыйлар, ничә яшьтә дип сорыйлар. Тегеләрен әйтәсең дә инде аның, яшеңне ничек әйтмәк кирәк. Яшеңне әйтсәң, эх, бабайка, бабайка, зачим тебе фальнис, вон каенлыкта твоя бальнис дип әйтерләр сыман. Шушы яшемә житеп бер тапкыр бардым мин анда, анысы да үз аягым белән түгел, гражданскида сугышта янәшәмдә эснәрәт шартлаганые, алып киткәннәр.

Шул вакыт каршы йортның капкасы астыннан бер эт атылып чыкты. Ул да түгел, капка ачылып, аннан кулына чыбык тоткан Миңлебану әби килеп чыкты.

— Бөтен чебешләремне куркытып бетерде, хәерсез! — дия-дия, урам буйлап этне куа китте.

Миңлебану әби ярыйсы гына чапса да, эт аңа тоттырмады, билгеле. Этне, этнең хуҗасын тирги-тирги, Миңлебану әби кайтыр юлга борылды.

— Миңлебану әби дә байтак яшьтәдер инде,— дидем.

— Мин егет булып йөргәндә ике малае барые. Туксан биштән ким түгел,— диде Хәйбрахман бабай.

Миңлебану әби аның сүзен ишетеп безнең каршыга килеп басты.

— Карт башың белән янгаллап утырма, күрше. Нишләп туксан биш булсын, җитмешкә яңа чактым,— диде дә кырт борылып китеп барды.

Миңлебану әби артыннан капка ябылгач, Хәйбрахман бабай кеткелдәп көлеп алды.

— Яшен яшерә,— диде ул аннары,— күз тияр дип курка.

— Ничек инде күз тия?

— Син аның йөгереп йөрүен күрәсең дә, ай-яй, бу карчык ничек туздыра, бигрәк таза икән дисең. Шуннан соң, янәсе, аңа күз тия, авырый башлый. Хатын-кыз җүләрлеге. Муртаеп беткән карамага чуртым буламы,— дип, Хәйбрахман бабай тагын бер мәртәбә кеткелдәп куйды.— Кичә генә бер танышым белән очрашып зарланышып алдык. Үтте гомер, картайдык диештек. Аңа кырык тулган, миңа да шул чама.

# МОНОЛОГ

хикәя

Капканы ачып кергәндә үк өнәп бетермәдем мин аны. Кыяфәте әллә нинди: аягында ялтыр-йолтыр килеп торган ботинка, өстендә буй-буй костюм, муенына чәчәкле муенчак бәйләгән, кулына сумкага охшаган әйбер тоткан. Бөтен авыл өерелеп бәрәңге ала, ә ул шушы ялтыр-йолтыр ботинкасын ялтыратып йөри. Баскыч астында сөяк ялап ята идем, күреп алдым да моны каршысына өреп чыктым. «Тик ят!» дигән була. Ятты ди, ятмыйни, хуҗам чыгып өлгермәгән булса, буй-буй ыштанын умырып төшерә идем. Хуҗам, «кереп ят, Хундыр!» дигәч тә, кереп ятмадым әле, бер читкәрәк тайпылдым да ырлап тордым.

Хуҗам белән кул биреп күреште бу, «Исәнме, эти? Әни ни хәлдә?» дип сорады. Аңлап алдым, минем хуҗаларның малае булып чыга икән ич. Алайса, нигә мин аны беренче тапкыр күрәм? Миңа быел өч яшь тулды, өч ел буена нигә бер мәртәбә дә кайтмаган?.. «Әни ни хәлдә?» диде. Минем хуҗабикәнең бик каты чирләгәнен ишетеп кайткан, мөгаен. Кем белә, бәлки чакырып кайтарганнардыр, анысы миңа караңгы. Кешеләр андый эшне, үзегез беләсез, этләргә әйтеп эшләмиләр.

Ни булса шул булды, хуҗама ияреп өйгә кереп китте бу. Мин дә, сөягемнең эшен бетерим дип, баскыч астына шылдым.

Бик озак торгач кына хуҗа белән бергә ишегалдына чыкты теге буй-буй ыштан. Миңа колбаса кисәге ыргытты. Бик исем китте колбаса кисәгенә, иснәп тә карамадым. Этнең күңеле бер сөяк дип көләргә ашыкмасын әле. Ошаткан кешемнән булса, каткан ипине дә алам мин, билгеле. Ә моңардан... Хуҗам әйтеп тә карады, «аша, Хундыр, абыең күчтәнәче» диде, алмадым.

Шуннан хуҗамнан сорашырга тотынды бу. «Нигә аның исеме Хундыр, ди, нәрсәне аңлата ул? — ди.— Ни Хунта түгел, ни контр түгел», ди. «Белмим инде, әниең шулай атады», диде хуҗам. Аңа да ачуым чыкты, белмим инде дигән була. Әйтсен иде, «анда синең эшең юк!» дисен иде.

Шактый озак сөйләшеп утырды болар. Караңгы капкач кына кереп киттеләр.

Төнлә яңгыр ява башлады. Төнлә ява башлаган яңгыр тиз генә туктамый. Әйе, анысын үзегез дә беләсез, сезгә акыл өйрәтергә җыенуым түгел, болай гына, сөйләр сүземә кирәк булганга гына әйтүем.

Иртән теге кеше баскыч алдына чыгып күккә карады. Тик карап ни күрәсең, болыт-болыт, аны карамагач та белеп була. Өрергә уйламаган идем, шулай каранүын күргәч, ачуым кабарды. Шуннан баскычка утырды да бу күзләрен миңа төбәде.

— Я, нигә өрәсең? — ди.— Мин сиңа бер начарлык та эшләмәдем ич,— ди.— Син өрәсең, ә миңа хәзер яңгыр яуганда юлга чыгарга кирәк,— ди.— Чыкмас идем, ярамый, иртәгә эшкә өлгерергә кирәк,— ди.

Үзенең күзләре монсу-монсу. Өрүдән туктавымны үзем дә сизмәдем. Күзләренең монсулыгы күңелемне йомшартты, ахрысы.

Бераз вакыттан юлга чыкты бу. Хуҗам аны капкага хәтле озатып куйды да:

— Ничек барып җитәрсең инде станциягә? — диде.

— Олы юлга хәтле җәяүләп, аннан берәр машиналы үтәр әле... Я, эти, сау булып тор, әнине кара инде, мин киләсе ялга тагын кайтырмын бәлки,— диде хуҗамның малае.

— Кайткалап йөр, әниеңнең хәле авыр,— диде хуҗам.

Шуннан китеп барды теге кеше. Хуҗам кожанын бөркәнеп капка янында басып калды. Мин дә аның янына килдем. Карыйм, көчкә атлый хуҗамның малае. Безнең якларда яңгыр яуганда ботинка белән йөреп булмый шул. Үзегез беләсез, без этләр булып та андый көндә ишегалдыннан чыгарга ашыкмыйбыз.

Малае чаттан борылып күздән югалгач, хуҗам авыр сулап куйды да өйгә кереп китте. Мин, үзем дә белмим, ни өчендер аның малае артыннан киттем. Баштарак чатка хәтле барып, авылдан чыгып киткәнен генә карамакчы идем, шуннан үзем дә авылдан чыгып киткәнмен. Бер кузгалган кузгалган дип, олы юлга хәтле озатып куярга булдым моны. Бер үзенә генә юл йөрү бик күңелсез бит ул, әйдә, эт булсам да, иптәш булырмын үзенә дидем.

Мине күргәч сөенде бу.

— Рәхмәт, туган,— ди,— миңа ямансу икәнен каян сиздең? — ди.— Дөрес, туган, миңа өрүдән сиңа ни файда, озатып куюың өчен рәхмәт яшәтәсең,— ди.

Олы юлга җиткәнче сөйләшеп бардык. Сөйләвен ул сөйләде, билгеле, мин тыңлап бардым. Нишләмәк кирәк, мин дә сөйләшер идем, кешеләрнең телен аңласак та, аларча сөйләшә белмибез шул.

Бара-бара шуны белдем: өреп чалбар балагына ябышырлык кеше түгел икән. Өч ел буе кайтмый торуын да аңлатты.

— Гомер үткәнен сизмисең дә, туган,— диде.— Менә кайтам, менә кайтам дип йөреп, өч ел кайтылмаган, авылыма кайтыр өчен, туган нигеземә кайтып күренү өчен әниемнең түшәккә егылуы кирәк булган,— диде.— Мәгънәсезлек, ваемсызлык, син мине гафу итә күр инде, туган,— диде.

Олы юлга җиткәч, юл читенә басып, машина көтә башладык. Үч иткәндәй, яңгыры да туктамый, машинасы да күренми. Безгә, авыл этенә, ярый да инде, яңгырына-карына күнеккән, моны кызгандым. Өстенә кожан да кимәгән бит. Буй-буй кәчтүннең буйлары буйлап су ага.

Борылышта бер заман машина күренде. Бу кулын күтәрде. Дөньяның ни икәнен белми икән, бичара. Андый машинага кул күтәрәләрме,

андый машина юл читендә басып торган этле кешене утыртамы инде. Телең булмагач, әйтеп булмый шул, күтәрмә андый машиналарга кулыңны дип. Хуҗамны озатып куйганым бар ич инде бу юлга, беләм кайсы машинаның утыртканын. Бу юлы да дөрес булды — пычрак чәчрәтеп үтте китте машина.

Озак көттек.

— Бар инде кайт, туңасың,— дип әйтеп карады бу.

Китмәдем, шул хәтле озатып килгәч, ничек инде бер үзен калдырып кайтып китәсең.

Китмәгәч, сумкасында актарынып, бер конфет тартып чыгарды бу. Миңа бирде. Эх, адәм баласы, әйтерсең мин шул бер конфет өчен йөрим. Аннары соң, конфет ашарга мин бала-чагамы? Дөньяны белми, мескен, дөньяны! Болай итеп ничек яшәмәк кирәк, ничек гомер кичермәк кирәк.

Күңеле кителмәсен дип, конфетны алдым, бер читкәрәк алып китеп үләннәр эченә яшердем, рәхәтләнсен кырмыскалар, баллыны алар ярата.

Ниһаять, юл читендә басып торучыларны утырта торган машина килеп туктады. Тиз генә машинага утырды да бу миңа кулын болгады. Мин дә койрыкны болгадым. Китте барды хуҗамның малае. Исән-сау өенә кайтып җитсен инде. Көне бик ямансу, көне бик күңелсез, көне бик әчпошыргыч. Мондый көндә яхшы эт хуҗасын да урамга чыгармый.

Ягез, мин дә кайтыйм ышык урыныма, сез дә кереп ятыгыз. Кайгыбыз-хәсрәтебез юк чагында ышык урында рәхәтләнеп ятып калыйк.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## МУСА ҖӘЛИЛГӘ БАГЫШЛАП

Герой шагыйребез Муса Җәлилнең 70 еллыгына багышланган бәйрәм тантаналары дәвам итә.

16 мартта башкалабыз Мәскәүдә Союзлар йортының Колонналы залында каһарман шагыйрьгә багышланган тантаналы кичә булды. Кичәне кыскача кереш сүз белән СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре, Дәүләт премияләре лауреаты М. Луконин ачты. «Муса Җәлил — безнең горурлыгыбыз, совет кешесенең идеялелеге һәм батырлыгы символы, поэзиябезнең геройлык йолдызы», — диде ул.

КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев тантаналы кичәдә катнашучыларны М. Җәлилнең иҗаты һәм героик тормышы белән таныштырды. РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре, танылган балалар язучысы Анатолий Алексин, немец журналисты, «Проблема мира и социализма» журналының редакторы Леон Небенцаль, Мәскәүнең Серго Орджоникидзе исемендәге станоклар төзү заводының комсомол-яшьләр бригадасы бригадиры Виктор Попов татар шагыйре Муса Җәлил иҗатының дөнья күләм әһәмияте турында сөйләделәр.

Ахырдан сәнгать осталарының зур концерты булды. Анда үлемсез шагыйрьнең әсәрләре, аның сүзләренә язылган җырлар яңгырады.

Муса Җәлилгә багышланган бу кичәдә татар язучыларының зур группасы катнашты. Алар арасында С. Хәким, З. Нури, Г. Ахунов, Р. Мостафин, М. Шабаев, Р. Фәйзуллин, Р. Харисов, М. Хәбибуллин, В. Нуруллин, Л. Хәмидуллиннар бар иде.

* * *

Ташкент хезмәт ияләре, киң җәмәгатьчелек М. Җәлилнең 70 еллык юбилеен зурлап билгеләп үтте. «Белем», «Домостроитель» культура сарайларында, эшчеләр тулай торакларында, Ташкент телевидениесе аша каһарман шагыйрьнең үлмәс шигырьләре, аңа багышлап иҗат ителгән җыр һәм сәхнә әсәрләре яңгырады.

* * *

Ташкентның «Домостроитель» культура сараенда РСФСРның һәм Татарстан АССРның халык артисты Илһам Шакиров җитәкчелегендәге концерт бригадасы чыгышы булды. Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең бу концерт бригадасы репертуарының бер өлеше патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең 70 еллык юбилеена багышланган иде. Илһам Шакиров татар музыка сәнгатенә зур өлеш керткән композитор Александр Ключаревның 70 еллык юбилее уңаеннан аның әсәрләрен дә башкарды.

* * *

Ташкент шәһәренең 58 нче мәктәбендә М. Җәлил исемендәге хезмәт һәм сугышчан дан музеен ачу тантанасы булды. Бу тантанада шагыйрь иҗатын өйрәнүче әдәбият галиме И. Зәбиров та катнашты. Ул шулай ук Ташкент шәһәренең 18 нче, 88 нче һәм 235 нче мәктәп укучылары янында булды.

* * *

Казагыстанның Петропавловск телевидениесе Муса Җәлилнең 70 еллыгына багышланган кызыклы тапшыру оештырды. Тапшыру барышында шагыйрьнең шигырьләре һәм аның сүзләренә язылган җырлар яңгырады, Җәлилгә багышланган фильмнардан өзекләр күрсәтелде.

* * *

Муса Җәлилнең тууына 70 ел тулу уңае белән Красноярск шәһәренең кәгазь-целлюлоза комбинаты культура йортында әдәби кичә үткәрелде. Кичәдә шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы, фашист тоткынлыгындагы көрәше турында доклад сөйләнде, каһарман шагыйрьнең шигырьләре укылды.

* * *

Язучы Г. Минский Чиләбе шәһәренең «Белем» җәмгыяте залында, ЧТЗ театрында һәм өлкәнең Аргаяш районы мәктәпләрендә М. Җәлилнең 70 еллыгына багышланган кичәләрдә чыгышлар ясады.

Очрашуларда Чиләбе халык театры артистлары, әдәби түгәрәк членнары һәм китапханә эшчеләре катнашты.

* * *

Оренбург шәһәренең Х. Ямашев исемендәге татар китапханәсе һәм «Россия» культура сарае коллективы М. Җәлилгә багышланган әдәби кичә үткәрделәр. Бу кичәдә М. Хөсәен катнашты һәм тамашачыларга Татарстан язучыларының котлау сүзләрен һәм юбилей бүләген тапшырды.

## ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНДА ОЧРАШУ

23 мартта КПССның XXV съезды делегаты, партия өлкә комитетының беренче секретаре Ф. Табеев республиканың иҗат интеллигенциясе белән очрашты.

Иптәш Ф. Табеев культура әһелләренә КПССның XXV съезды турында сөйләде, аның тарихи карарларын тормышка ашыру буенча республика хезмәт ияләре алдында торган бурычларга тукталды, сорауларга җаваплар бирде.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЛАРЫ

Г. Тукай исемендәге клубта Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының ачык җыелышы булды. Ул республикабыз язучыларының иҗат активлыгы турындагы мәсьәләне карады. Җыелышта доклад белән «Казан утлары» журналының җаваплы секретаре Л. Ихсанова чыкты. Фикер алышуларда язучылардан Ф. Хөсни, З. Нури, Ж. Тәрҗеманов, В. Нуруллин, «Азат хатын»

журналының баш редакторы А. Хәсәнова, «Чаян» журналының баш редакторы Р. Зәкиев һәм башка иптәшләр катнашты.

* * *

24 мартта Татарстан Язучылар союзы һәм Татарстан китап нәшрияты партия оешмаларының КПССның XXV съезды йомгакларына багышланган берләштерелгән җыелышы булып узды. Җыелышта партиянең XXV съезды делегаты, Татарстан Язучылар союзы идарәсенең председателе Г. Ахунов съездда алган тәэсирләре белән уртаклашты, съезд карарларын үтәү буенча Язучылар союзы һәм китап нәшрияты алдында торган бурычлар турында сөйләде. Фикер алышуларда язучылардан Н. Дәүли, Г. Шәрәфетдинов, В. Нуруллин, китап нәшриятының баш редакторы М. Шабаев, нәшриятның яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе мөдире Ш. Рәкыйпов һәм политик әдәбият редакциясе мөдире И. Беляев катнашты.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Проза секциясенең февраль ахырларында уздырылган утырышында сүз «Азат хатын» журналында басылган проза әсәрләре турында барды. Тәнкыйтьче Ф. Миннуллин 1975 елда журнал битләрендә басылган хикәяләргә күзәтү ясады. Л. Шәфикова «Азат хатын» журналындагы очерклар турында сөйләде. Фикер алышуларда А. Расих, Б. Камалов, Ф. Мансуров, В. Монасыйпов һ. б. катнашты.

* * *

Балалар әдәбияты һәм проза секцияләренең берләштерелгән утырышында А. Гыйләҗевнең узган ел «Яшь ленинчы» газетасында басылган «Күзгә-күз» исемле повесте тикшерелде. Фикер алышуларда «Яшь ленинчы» газетасының җаваплы редакторы В. Ихсанова, язучылар Г. Бәширов, Ф. Хөсни, Ш. Маннур, Г. Ахунов, Ж. Тәрҗеманов, Р. Фәйзуллин, Х. Сарьян, Г. Хәсәнов, Т. Нурмөхәммәтов, Р. Мингалимов, М. Әгъләмов, әдәбият тәнкыйтьчеләре Ф. Ибраһимова, Ф. Миннуллин һәм башка иптәшләр катнашты. Чыгыш ясаган кешеләрнең иң зур күпчелеге Ж. Тәрҗемановның «Күзгә-күз карап...» исемле мәкаләсендә («Социалистик Татарстан» газетасы, 1976 ел, 15 февраль.) А. Гыйләҗев повестена бирелгән бәя белән килешмәүләрен белдерделәр, шуның белән бергә, әсәрдәге аерым кимчелекләрне дә күрсәттеләр.

* * *

Тәнкыйтьчеләр секциясенең март аенда уздырылган утырышында Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының гыйльми хезмәткәре Р. Гайнанов «Г. Тукай һәм Г. Ибраһимов иҗатын өйрәнү мәсьәләләре» дигән темага доклад ясады. Утырышта язучылардан Н. Исәнбәт, Р. Ишморат, филология фәннәре докторлары Г. Халит, И. Нуруллин, М. Гайнуллин, Н. Юзиев, тарих фәннәре докторы Р. Нәфиков, филология фәннәре кандидатлары Ф. Мусин, М. Гайнетдинов, Татарстан китап нәшрияты редакторы Р. Даутов һәм башкалар чыгып сөйләде.

* * *

«Казан утлары» журналы каршындагы яшь рецензентлар түгәрәге утырышында «Идел» альманахының 1975 елда чыккан 6 саны тикшерелде. Э. Мостафин, Т. Әйди, М. Вәлиев, Н. Гамбәров, Ф. Низамовалар альманахта басылган шигырьләр, повесть-хикәяләр, әдәбият һәм сәнгать тәнкыйтенә караган материаллар турында сөйләделәр.

* * *

Балалар әдәбияты секциясенең чираттагы утырышы яшь шагыйрь Г. Гатауллин иҗатына багышлап уздырылды. Фикер алышуларда Л. Ихсанова, Р. Фәйзуллин, Г. Бакир, З. Туфайлова, Н. Гайсин һ. б. катнашты. Алар авторга күп кенә файдалы киңәшләр бирделәр.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

«Васильево» ял йортында Габдулла Тукайның 90 еллыгына багышланган әдәби кичә үткәрелде. Язучы Г. Минский кичәдә катнашучыларга халык шагыйренең тормышы, иҗаты турында сөйләде, аларны олы юбилейга хәзерлек уңаеннан башкарылган эшләр белән таныштырды.

* * *

«Казан утлары» журналының баш редакторы, шагыйрь З. Нури Казан төзелеш инженерлары институты студентлары белән очрашты. Ул студентларга М. Җәлилнең 70 еллыгына багышланган юбилей тантаналары, СССР язучыларының 21 июньдә ачылачак чираттагы VI съезды турында сөйләде, яңа шигырьләрен укыды, сорауларга җаваплар бирде.

* * *

Язучыларыбыз Х. Сарьян, Р. Гатауллин, М. Әгъләмов республиканың Кама тамагы районы авылларында йөреп кайттылар. Алар колхоз эшчәннәре, мәктәп укучылары белән очраштылар, матур әдәбият сөючеләрне әдәбияттагы яңалыклар белән, үзләренең яңа әсәрләре белән таныштырдылар.

* * *

Шагыйрь М. Хөсәен, Октябрь районы мәктәпләрендә, районның культура йортларында, клубларында булып, укучылар белән очрашулар уздырды.

## «ЯШЕЛ ЯФРАК»

«Юность» журналы редакциясе тарафыннан ел саен үткәрелә торган әдәби конкурс әнә шулай дип атала. 1975 елда бу конкурста җиңеп чыгучылар арасында М. Горький исемендәге әдәбият институтын тәмамлаган яшь шагыйрь Б. Сөләйманов та бар.

## ХЕЗМӘТКӘ ДАН

Казан сынлы сәнгать музеенда республикабыз художникларының КПССның XXV съездына багышланган күргәзмәсе ачылды.

Күргәзмәгә сынлы сәнгатьнең барлык төрләрендә иҗат ителгән 200 ләп әсәр куелган иде. Бу—Татарстан рәссамнарының тугызынчы бишьеллыктагы иҗаты. Рес-

публикабыз хезмәт иияләренә алар беренче тапкыр күрсәтеләләр.

Күргәзмә «Хезмәткә дан» дип атала. Анда республикабыз нефтьчеләре, КамАЗ төзүчеләр, авыл хуҗалыгы уңганнары, фән һәм культура эшлеклеләре образлары, шулай ук рәссамнарның туган як табигатенең матурлыгын гәүдәләндергән әсәрләре куелган.

## ЯҢА СПЕКТАКЛЬЛӘР

Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры тамашачыларга «Җиһангир» исемле яңа опера күрсәтә башлады. Операның авторлары — композитор Р. Гобәйдуллин белән драматург Х. Вахит.

Әсәрне сәхнәгә театрның баш режиссеры, РСФСРның халык артисты Н. Даутов куйган, декорацияләрне Татарстан АССРның халык художнигы Э. Нагаев ясаган. Спектакльнең музыка җитәкчесе һәм дирижеры — И. Лапиньш, хормейстерлары — Т. Гудкова белән И. Рәхимуллин.

Операдагы төп партияләрне РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты Ф. Насретдинов, ТАССРның халык артисты И. Ишбуляков, ТАССРның халык артисткасы Г. Сәйфуллина кебек танылган артистлар белән бергә, сәләтле яшь җырчылар Э. Хәбибуллина, С. Раннбаков, Р. Сәхәбиевләр башкара.

* * *

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры партиябезнең XXV съездын күренекле революционер, зур дәүләт эшлеклесе, В. И. Ленинның якын көрәштәше Мулланур Вахитовка багышланган яңа спектакль белән каршылады.

Трагедияне сәхнәгә ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе П. Исәнбәт куйган. Спектакльгә декорацияләрне ТАССРның халык художнигы Ә. Тумашев эшләгән, көйләрне Ф. Әбүбәкиров язган.

Мулланур Вахитов ролен Татарстан АССРның халык артисты Р. Таҗетдинов башкара.

* * *

Шул ук театр сәхнәсендә драматург Х. Вахитның «Ике килен киленд...ш» исемле комедиясе буенча куелган икенче бер яңа спектакль бүгенге колхоз кешеләре, алар арасындагы мөнәсәбәтләр турында сөйли.

Спектакльнең режиссеры — РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе М. Сәлимҗанов, художнигы—И. Фәйзуллин, композиторы—Ш. Шәрифуллин.

Рольләрне театрның яшь һәм урта буын артистлары башкара.

* * *

В. И. Качалов исемендәге зур драма театры сәхнәсендә француз драматургы Э. Ростанның «Сирано де Бержерак» исемле героик комедиясе буенча эшләнгән яңа спектакль бара. Аны режиссер С. Лерман куйган. Спектакльнең художнигы— В. Зайцев, композиторы—Л. Любовский. Төп рольләрне Е. Золотарев, Е. Кара-Гяур, В. Фролков һәм театрның башка танылган артистлары башкара.

* * *

Бөек Җиңүнең 30 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә Казан курчак театры яңа тамашачыларга «77 пәһлеван» исемле спектакль күрсәткән иде. Шушы көннәрдә театр аның русча вариантын күрсәтә башлады. Әсәрне рус теленә Ә. Хөсәенов һәм Р. Такташ тәрҗемә иткән.

Бу героик әкиятнең авторы һәм сәхнәгә куючы режиссеры—Р. Батуллин. Декорацияләрне РСФСРның атказанган, ТАССРның халык художнигы Э. Гельмс һәм Л. Сперанская ясаган. Музыкасын композитор И. Якупов язган.

Курчакларны Татарстан АССРның атказанган артисткалары Р. Утяева, В. Третьякова, артистлар Г. Вишняков, В. Маякова, Н. Шестопалова, Н. Урматскаялар уйната.

* * *

Февраль ахырларында Минзәлә татар дәүләт драма театрында Х. Вахитның «Ике килен килендәш» комедиясе буенча эшләнгән спектакльнең премьерасы булды. Әсәрне сәхнәгә Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе М. Мостафин куйган. Декорацияләрне С. Гәрәев ясаган, спектакльгә музыканы театрның артисты һәм баянисты Ф. Бәдриев язган.

* * *

Халык театрларының Бөтенроссия фестивале лауреаты булган Олы Әтнә халык театры КПССның XXV съездына багышлап Мирсәй Әмирнең «Миңлекамал» исемле драмасын сәхнәләштерде. Әсәрне Татарстанның атказанган культура работнигы Гомәр Мәрданов куйган.

## КОМПОЗИТОРНЫҢ ИҖАТ КИЧӘСЕ

Казан шәһәренең Актерлар йортында РСФСРның М. Глинка исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты композитор Ф. Әхмәтовның иҗат кичәсе булды. Ике бүлектән торган концертта республикабызның яшь башкаручылары һәм сәнгать осталары авторның соңгы елларда иҗат иткән иң яхшы әсәрләрен башкардылар.

## КИТАП АТНАЛЫГЫ

Язгы каникул көннәрендә балалар китабы атналыгы үткәрү күркәм бер традициягә әйләнеп килә. Быел да ул бик матур һәм оешкан төстә узды.

1975 елның сентябрендә Абдулла Алиш исемендәге Казан пионерлар сарае балалар өчен язылган иң яхшы китапларга конкурс игълан иткән иде. Ләбибә Ихсанованың «Очкын», Шамил Рәкыйповның «Геройлар эзеннән» исемле китаплары бу конкурста беренче урынны алды. 23 мартта, Балалар китабы атналыгын ачу тантанасында, яшь китап сөючеләр үзләренең яраткан язучыларына дипломнар тапшырдылар.

* * *

Атналык көннәрендә А. Алиш исемендәге Казан пионерлар һәм укучылар сараенда драматург Хәй Вахит, шагыйрьләр Гөлшат Зәйнашева, Резеда Вәлиева, Разил Вәлиев белән очрашу булды. Алар яшь укучыларга үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

Очрашуда шулай ук Татарстанның атказанган артисткасы, Тукай премиясе лауреа-

ты Наилә Гәрәева, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артистлары Флера Хәмитова, Рәсим Сәләхов, яшь композитор Шамил Шәрифуллин һәм баянчы Рәис Сафиуллин катнашты.

* * *

Балалар китабы атналыгы Арча педагогия училищесында олы бер бәйрәм итеп уздырылды. Актлар залында В. И. Ленинның, М. Горькийның һәм Г. Тукайның китап турында әйткән сүзләре язылган. Балалар язучыларына багышланган стендлар да карап туйгысыз итеп эшләнгән иде.

Бәйрәмгә 1 нче һәм 3 нче мәктәпләрнең башлангыч класс укучылары да килде. Алар бүләк итеп әдәби инсценировка алып килгәннәр. Нәни дусларыбыз шигырь сөйләүчеләргә конкурс та уздырдылар.

Яшь талантларга бу көн аеруча мәшәкатьле булды. Төрле әдәби әсәрләрнең геройлары булып уйнау җиңел эш түгел шул...

## МУЗЫКА АТНАЛЫГЫ

24 марттан алып 31 мартка кадәр республикабызда балалар һәм яшүсмерләрнең традицион музыка атналыгы үткәрелде.

24 мартта М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры бинасында атналыкны ачу тантанасы булды. Аны Татарстан АССРның мәгариф министры урынбасары З. Михайлова ачты. Татарстан АССРның культура министры урынбасары М. Низамиев яшь тамашачыларны олы бәйрәм белән котлады. Соңыннан сәнгать осталары көче белән күңелле концерт куелды.

Атналык көннәрендә мәктәп укучылары күренекле композиторлар, музыка белгечләре, артистлар белән очраштылар. Татарстан АССРның дәүләт симфоник оркестры Казан консерваториясенең актлар залында балалар өчен махсус концертлар бирде. Ул концертларда, Казан мәктәпләрендә укучы балалардан тыш, якын-тирәдәге районнардан килгән балалар да булды. Кинотеатрларда музыкаль фильмнар фестивале уздырылды. Казан, Лениногорск, Әлмәт, Арча, Алабуга һәм Түбән Кама музыка училищеларында махсус концерт бригадалары төзелде. Алар мәктәпләрдә концертлар куйдылар, музыка сәнгате турында лекцияләр укыдылар, әңгәмәләр үткәрделәр.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет культурасы өлкәсендәге хезмәтләре өчен «Чаян» журналының баш редакторы урынбасары **Самуил Соломонович Оффенгенденга** РСФСР Верховный Советы Президиумы указы белән **РСФСРның атказанган культура работнигы** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Ленин комсомолы исемендәге Казан дәүләт яшь тамашачылар театры артисты **Адольф Алексеевич Глушковка Татарстан АССРның халык артисты** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артистлары **Нәҗибә Гыймай кызы Ихсановага** һәм **Равил Шаһап улы Шәрәфиевка** Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1976 ел, 19 февраль указы белән **Татарстан АССРның атказанган артисты** дигән мактаулы исемнәр бирелде.

* * *

Театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Ленин комсомолы исемендәге Казан дәүләт яшь тамашачылар театры артисткалары **Антонина Васильевна Пустовалова-Поповага** һәм **Зоя Алексеевна Петровага Татарстан АССРның атказанган артисткасы** дигән мактаулы исемнәр бирелде.

* * *

Театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының бутафория цехы мөдире **Әхмәт Фатыйх улы Гыйззәтуллинга Татарстан АССРның атказанган культура работнигы** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Республикабызның матбугат органнарында озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен һәм 70 яшь тулу уңае белән **Галим Мәҗит улы Рябков** КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының **Мактау грамотасы** белән бүләкләнде.

* * *

Совет музыка сәнгатен пропагандалау өлкәсендә озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен һәм 60 яшь тулу уңае белән СССР Композиторлар союзы члены **Зәйнәп Шәйхулла кызы Хәйруллина** КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының **Мактау грамотасы** белән бүләкләнде.

* * *

Театр сәнгате өлкәсендә озак еллар нәтиҗәле эшләве өчен һәм 50 яшь тулу уңае белән Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артисткасы **Шахсәнәм Ибраһим кызы Әсфәндиярова** КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының **Мактау грамотасы** белән бүләкләнде.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Татарстан Язучылар союзының Әлмәт бүлегендә хәзерге драма әсәрләре турында кызыклы сөйләшү булды. Тукай премиясе лауреаты, театр белгече Сабир Өметбаев һәм Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, драматург Юныс Әминов узләренең чыгышларында бүгенге драма әсәрләрендә форма һәм эчтәлек мәсьәләләренә тукталдылар, республика театрларында барган спектакльләргә анализ ясадылар. Фикер алышуларда шулай ук Ш. Бикчурин, Ә. Маликов, С. Кальметов, Г. Афзал һ. б. иптәшләр катнашты.

## УКУЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА

*Кайбер урыннарда «Казан утлары» журналының 2 нче саны подписчикларга үз вакытында барып җитмәде. Техник сәбәпләр аркасында, типографиядә аны бастыру тоткарланды. Хәзер ул саннар яңадан эшләнә. Газета-журналлар нәшрияты һәм «Союзпечать»ның республика агентлыгы журналны чыгару һәм аны укучыларга җиткерүдә килеп чыккан бу тоткарлык өчен подписчиклардан гафу үтенәләр.*

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210